Көмеш арба, көмеш ат

Көмеш арба, көмеш ат

Көмеш арба, көмеш ат

Башкорт хикәяләре

Төзүчесе ГАЬДУЛЛА БАЙБУРИН

ҚАЗАН
ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ
1989

ББК 84 (2Р-Баш) -4
К97

Тышлык художнигы *Ш. Насыйров*

Көмеш арба, көмеш ат: Башкорт хı
К97 зан, Татар. кит. нәшр., 1989.— 272 **бит.**

Бу җыентыкка тугандаш башкорт язучыл
хикәяләре тупланды.

К $\frac{4702110000—010}{М132(03)—89}$ 78—89 Бı

ISBN 5-298-00066-5

© Татарстан китап

СӘГЫЙТЬ АГИШ

(1905—1973)

Сәгыйть Ишмөхәммәт улы Агишев 1905 елда Оренбург губернасының Шарлык өязе Исәнгилде авылында мулла гаиләсендә туган.

Заманындагы башлангыч белемне үз авылында алып, укуын Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә һәм педагогия техникумында дәвам итә. 1920 елда ул комсомолның кантон комитетына бүлек мөдире итеп сайлана, ә дүрт елдан соң, Уфага килеп, матбугат эшенә тотына.

1928 елда С. Агиш «Безнең көлү» дигән шигырьләр җыентыгын чыгара. Соңыннан исә ул прозаик булып таныла һәм 1934 елда СССР Язучылар союзына кабул ителә. Бу вакытка инде әдип «Куш төймә», «Өч иптәш», «Шартына килсен» кебек хикәя китаплары авторы була.

С. Агиш шулай ук «Мәхмүтов», «Тәүге дәресләр», татарның мәшһүр патриот-шагыйре Муса Җәлилнең балалык елларын сурәтләгән «Якташлар» исемле повестьларын һәм киң танылган «Нигез» романын иҗат итте. Бу роман үз вакытында татар һәм шулай ук рус телендә дә чыккан иде.

С. Агиш 1943 елда партия сафына кабул ителгән. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет Билгесе» орденнары һәм республиканың Салават Юлаев исемендәге премиясе белән бүләкләнгән.

ЭШ САМАВЫРДА ТҮГЕЛ

1

Өстәлдәге телефон кинәт шылтырый башлады. Моңарчы, тынлыктан аптырап, тирән уйга баткан Хөршидә әби дерт итеп китте, йөгереп телефон янына килде. Телефон бик аз гына туктап торды да тагы шылтырады. «Ни булды икән моңа?» — диде әби. Ишекле-түрле йөренгәндәй итте.

Телефон тагын шылтырады. Йөгереп күрше квартирага чыкты, аннан үзе кебек үк карчыкны ияртеп керде. Күршесе ишек төбендә туктады. Хөршидә әби сөйләп китте:

— Бер нәрсәләренә дә кагылмаган кебек идем, кинәт монау нәрсәләре шылтырады да җибәрде. Шуңа берәр нәрсәләре бозылмагае дип, синә чыккан идем.— Күрше карчык аны гаҗәпләндереп көлеп җибәрде.

— Ә... ул ни... телефон бит! Балаларың синең белән сөйләшергә иткәннәрдер.

Хөршидә әбинең телефоннан бөтенләй хәбәре юк түгел, авыл советында ничә тапкыр күргәне бар. Ләкин мондый түгел иде. Таныш булмаган карчык алдында бераз ояла төште һәм, үзен акларга теләп:

— Сездәгесе бигрәк кызык икән шул. Безнең авылдагысы икенче төрле, сәгать кебек стенада тора. Аннан ул монын кебек тимер дә түгел, тегү машинасының капкачы төсле сары тактадан гына ясалган.

Шул сүзләрне сөйләгәндә тагы телефон шылтырады. Бу юлы Хөршидә әби дә курыкмады. Күрше карчык трубканы алып тыңлады да Хөршидәгә сузды:

— Киленең сине чакыра!

Хөршидә әби көтелмәгән җайсызлык чыгар дип алырга теләмәде:

— Куй, күрше, үзең сөйләш тә куй, сөйләшә белеп булмас.

Ул теләр-теләмәс кенә трубканы алды. Анда чынлап та килене иде.

— Каенам, бу синме?

— Әйе, килен, мин үзем.

— Мин ял вакытында гына сөйләшәм. Киткән чакта әйтергә онытканмын. Ачыгып китсәң, чәйнекне плиткага куеп, чәй кайнатып ал, духовкада ашарга бар.

Хөршидә әби бер нәрсә дә аңламады, сөйләшү газабыннан котылу өчен трубканы өстәлгә салды. Күрше карчык:

— Анда куйма,— диде һәм, трубканы урнаштыргач, бераз вакыт, аның кайдан килүен, кем булуын сорашып торды да:

— Эчең пошып китсә, безгә кер, сөйләшеп утырырбыз,— диде һәм, Хөршидәнең риза булу-булмавын көтмичә, чыгып китте. Хөршидә тәрәзә янына килеп утырды. Тәрәзәдән кышкы каланы күзәтә башлады. Зур шәһәрнең өстенә, шушы дүртенче каттан, иртәдән бирле берничә тапкыр карады ул. Бердән, аның күзләре дә әллә ни ачык күрми иде, икенчедән, өйләр дә бер төрлерәк; әллә ни кызыклы тәэсир ясый алмады аңа шәһәр.

Хөршидә — авыл карчыгы. Карты үлгәнгә хәзер унбиш ел. Ике улы бар. Икесе дә читтә, җаваплы урында эшлиләр. Балалары аны үз яннарына никадәр генә алып килергә теләсәләр дә, авылдан китмәде ул. Һаман үзенең бәләкәй генә өендә яши бирде. Җәй булса, колхозда эшләде. Балалары аңа ай саен акча, күчтәнәч җибәреп торалар. Берүзенә күңелсез булганга, өендә бер укытучы кыз тота. Аның белән өч ел торалар. Кызга да күнекте, үз баласы кебек якын хәзер. Укытучы кыз Хәдичә исемле, бик ягымлы кыз. Дәрестән кайтып керүгә үк: «Әбекәем»,— дип килеп керә. Шартлатып утынын ярып ташлый, бергәләп тәмләп аш ашыйлар, чәй эчәләр. Кичләрен кызыклы әкиятләр укыйлар.

Хөршидәнең тормышы шундый матур бара, ә балалары хат саен: «Безгә кил, карт көнеңдә, ичмасам, хөрмәт күрсәтеп калыйк»,— дип үзләренә чакыралар. Хөршидә моңача килми йөрде. Хәдичәдән балаларына озын-озын хатлар яздырды, тигез тормыш, тәүфыйк теләде. Менә быел шушы өйнең хуҗасы булган улы Яппар кәләш алды һәм, айваена куймый, кичә үзенә алып кайтты. Кичен улы, килене өчәүләп бик озак сөйләшеп утырдылар. Килене ятар алдыннан:

— Каенам,— диде,— авырга алма, яшең алтмышка житеп бара. Яшәгән кадәр яши алмассың. Яшь чагында гомерең газапта үткән, ичмасам, бу ягында кадер, хөрмәт күр. Үзебездә тор, теләгәнчә аша, теләгәнчә йөре.

Карчык, бу ачык йөз, татлы сүзләргә куанып, йоклап китте. Иртәнчәк гөрләшеп чәй эчтеләр. Улы үз хезмәтенә наркоматка, килене үз эшенә редакциягә китте.

Менә хәзер өч сәгать инде ул ике зур бүлмәдә — ялгызы. Нишләргә белми. Әле бер җиргә, әле икенче урынга барып утыра. Йә булмаса, тәрәзә төбенә килеп, бик озаклап тышка, зур шәһәрнең өстенә карап тора.

Шәһәрне кар каплаган. Әле дә күктән, ялкау гына булып, кар бөртекләре төшә. Урамнан ары-бире машиналар уза. Карчыкның уйлары авылга, үзнең бәләкәй генә өенә кайтып китә. Хәдичә өйгә иптәш кызын чакырырмын дип калган иде. Бүген алар икәү йоклаганнардыр. Иртәнчәк ишеккә йозак салганнардыр да чыгып киткәннәрдер. Хәзер, менә шушы минутта, ишектә йозак асылынып торадыр. Аның мырылдавык песие нәкъ менә хәзер, менә шушы минутларда, Хөршидә йөргән кебек, аптырап, әле монда, әле тегендә барып, үзенә урын таба алмый мазалана-

дыр. Йә, эче пошып, казан янына менгәндер дә, күзен яртылаш кына йомып, йоклап ята торгандыр. Авылда да, шәһәрдәге кебек, экрен генә кар явадыр.

3

Кичкә табан Яппар белән килене Мәүлия кайтып керде. Керү белән карчыкның хәлен сораштылар. Мәүлия бигрәк тә ачык йөзле:

— Үзем,— ди,— кайтып киләм, үзем каенам күңелсезләнмәсә ярар иде, дип куркып киләм. Каенам, төш вакытында тамагыңа ашадыңмы соң?

Хөршидә ашамаган иде. Балаларын борчымас өчен, ашадым, дип җавап бирде. Мәүлия тиз генә табын хәстәрләргә тотынды. Яппар әнкәсе янына килеп утырды, аны сүзгә тартмакчы булды.

— Менә, әнкәй, шулай яшәп яткан булабыз. Эш бик күп, киленең дә бушый алмый.

Аш әзерләгәнче карчыкны бераз юандырыр өчен ул үзенең һәм Мәүлиянең рәсемнәре тезелгән альбомны китереп куйды. Бер юан гына, тулы битле кешенең рәсемен күрсәтте.

— Менә бу — Мәүлиянең атасы, районда врач,— диде. Карчык бөтен рәсемнәргә дә уңай характеристика бирде. Улының һәм килененең кәефе өчен:

— Бик әйбәт кешеләр икән,— дип утырды. Эш арасында Мәүлия дә килеп кысылды:

— Каенам,— диде,— иртәгә өчәүләп карточкага төшик, синең үзеңне аерым төшереп, зурайтып стенага куярбыз.

Карчык шунда ук:

— Берсен Хәдичәгә җибәрербез,— диде.

— Нинди Хәдичә ул, каенам?

Яппарның Мәүлиягә үз якыннары турында сөйләгәне бар, ләкин бу исемне телгә алганы юк иде.

— Ул безнең өйдә торган бер укытучы кыз, бик әйбәт, бик ипле бала.

— Әллә сагынып та өлгердеңме, каенам?

Карчык килене алдында бик аз гына җайсызланды, ләкин сүзне икенче якка борырга теләмәде.

— Сагындырыр да инде, бергә торган кеше бит,— дип әйтү белән чикләнде.

Яппарның да, Мәүлиянең дә бөтен сүзләре, бөтен кыланышлары карчыкның күңелен табуга юнәлтелде. Яппар һәр көнне үткәрә торган «йокы сәгатен» дә үткәрмәде.

Карчык алдында үзенең бала чакларын хәтерләргә тырышты:

— Әнкәй, Мәүлиягә минем язгы ташкында боз өстендә агып киткәнне сөйлә әле.

— Бигрәк тынгысыз иде ул Яппар, ташкын мәлендә, пароход ясыйбыз дип, боз өстенә салам салып ут төрткәннәр дә, аккан да киткәннәр, көчкә коткарып калдылар үзләрен.

— Әнкәй, Мәүлиягә кое эченә кереп яшеренгәнне сөйлә әле.

— Кыланмаганы юк иде инде. Бервакыт, әтисе мәрхүм чәчен алам дигәч, чыгып качкан да кое эченә төшкән дә утырган.

Мәүлия бу әкиятне берничә тапкыр ишетсә дә, карчыкны тик тотмас өчен аннан сөйләтәсе килде.

— Нигә инде чәч алудан шулкадәр курыккан икән соң, ул кое бик тирән түгелмени? Әллә Яппар азрак арттырып җибәрәме икән? Чынлап та, сөйлә әле, каенам.

Карчык аларның сорауларына тырышып-тырышып җавап бирә. Олыгаеп беткән, кияүле-кәләшле булган балаларның шулай иркәләнүләренең чын күңелдәнме, юриме икәнен төшенә алмый. Теләсә ничек булсын — балаларны җавапсыз калдырмый.

Кичен карчыкны театрга алып бардылар. Хөршидә театрны бик яратып карады. Килене аны фойега алып чыгып йөрде, бик матур, ягымлы яшьләр белән таныштырды. Карчык бу көнне дә үткәрде. Йокларга яткач, Хәдичәне тагы да исенә төшерде, дөресрәге, карчык аны никадәр уйламаска, сагынудан азапланмаска теләсә дә, укытучы кыз хәтеренә килде. Нәкъ янында гына басып торган кебек, хәтта әллә нинди авыр, моңсу бер көй көйләнгәндәй булды. Бераздан Мәүлия йокылы тавыш белән:

— Каенам, йоклый алмыйсың түгелме соң? — дип борчылды.

— Юк ла, йоклыйм, тик нитәм генә, — дип җавап бирде карчык.

4

Карчыкның шәһәргә килгәненә ун көн булды. Көннәр хәзер бөтенләй бертөслегә әйләнде. Кайсы көннәрдә ул көндезен генә түгел, кичләрен дә ялгыз кала. Балалар йә җыелыш, йә түгәрәк дип чыгып китәләр. Өйдә торган вакытларында да нәрсәдер укыйлар — сәгатьләр буена сөйләшми узган чаклары була. Мәүлия кинога, театрга

барганда, карчыкны ялгыз калдырмаска тырыша. Лэкин ничә әйтсәң дә, эш кешесе бит, мәшәкате бар. Ару гына сөйләшеп утырган чакта телефон белән чакырып алалар. Карчык күңелсезләнә. Дөрес, моны ул балаларына әйтми, яшерергә тырыша. Лэкин балалар, бигрәк тә Мәүлия, карчыкның йөрәге тынычсыз икәнен сизенә.

Карчык үзенә эш эзләп карый, таба алмый. Беркөн ул Мәүлиянең итәге сүтелгәнен күрде һәм килене эшкә киткәч, энә белән җеп алып, әйбәтләп тегеп куйды. Моңа карчык бик куанды. Бүгенге икмәк ашавын тиккә генә түгел итеп сизенде. Мәүлия кайткач:

— Килен,— диде ул,— энә бер итәгеңнең сүтелгән җирен тегеп куйдым, ошатырсыңмы икән?

Мәүлия итәкне алды һәм түзә алмыйча шаркылдап көлеп җибәрде.

— Каенам, аның үзенең фасоны ертык бит! Нигә юкка җәфаланасың, ертык булса, үзем дә ямармын.

Карчыкның, ун көн эчендә бердәнбер эш эшләп, аның да чиктән тыш мәгънәсез булуын күреп, эче янды. Хәдичә дә итәк кия, фасонның да нәрсә икәнен белә, тик ертыкның фасон булып йөрүен, аның кемнәр өчен матур булып саналуын никадәр баш ватса да, карчык төшенә алмады. Ертык та булган икән фасон! Мәүлия каенасының Хәдичәне сөйләвен, аны мактавын яратмый. Турыдан-туры әйтеп куймый, тик: «Хәдичә дә Хәдичә, нигә, каенам, шуны гына уйлап торасың»,— дип бик еректан әйләндереп сала. Шуңа күрә карчык соңгы вакытта килененең кәефе өчен аны сөйләми башлады.

Бүген, килене җыелышка киткәч, улы Яппар белән генә калды. Яппар бик озак китаплар актарды, әллә нәрсәләр язды.

— Нәрсә уйлап утырасың, әнкәй?— диде ул, эшеннән аерылып.

Карчык, бу сорауга бөтенләй җавап бирмичә, туп-туры үзенең йомышын әйтеп салды.

— Балам, артык кәгазең булса, Хәдичәгә бер хат язып бирер идең.

— Хәзер, әнкәй,— диде Яппар һәм шунда ук кәгазь алды,— нәрсәләр языйм, йә, әйтеп тор!

Карчык күптән өмет итеп йөргән хыялы шунда ук тормышка ашканга кинәт аптырап калды, нәрсә дип әйтергә дә белмәде.

— Нәрсә язасың инде, башта миннән, үзеңнән, килен-нән сагынып-саргаеп сәлам, диген. Сезнең фатихагызда бик сау гына ятабыз, диген. Теге иптәш кызың килдеме,

сау гына яшисэме, өй жылымы, калган утыннарыңны китерттеңме, Хөмәйрә карчыклар ничек яши, Мәрфуга киленнең баласы кызамык белән авырып тора иде, терелдеме, базар зур буламы, ит, май хаклары ничек, Ишмөхәммәтләр сугымнарын суйдылармы, малайлары кәләш алдымы, мәктәбең жылы буламы, әниеңнәр киез итек бастырып жибәрделәрме, кулмәгеңне тектердеңме, диген... Монда, диген, берүземә... сезне сагындыра, диген, олылар укырга йөриме, мичне карамый-нитми ут чыгара күрмәгез. Тагы нәрсә яздырыйм соң? Өебез жылы була, самавыр булмагач, чәй эчүе кыен, самавыр чәе эчәсем килә, диген. Тагын нәрсә яздырыйм? Калада кар бик шәп ява, авылда да шәп явамы, быел колхозда кар тоталармы, тотмыйлармы, сайлау-мазар булмыймы, агитатор булып йөрисеэме, спектакль куясызмы, ярар инде, аръягы икенче хатка калсын!

Яппар хатны карчыкка укып чыкты. Ул тынын да алмыйча тыңлады. Үзен авылга кайтып килгән, бөтен урам, тыкрыкларны кыдырып чыккан итеп күрде.

— Әйбәт булганмы?— диде Яппар.

— Әйбәт булганмы, дип ни, мин әйткәннең бөтенесен дә язгансың инде. Рәхмәт, балакаем, гомерле бул, тигез гомер итегез.

Яппарга әнкәсе, ничектер, ятимсерәгән, боеккан, шушы аз гына вакыт эчендә изелгән төсле күренде. Тик мондый хәлгә китереп төшерерлек бер сәбәп тә юк иде шикелле. «Әнкәемә бер самавыр алып бирергә кирәк»,— дип куйды ул үзалдына.

5

Күксел конвертны карчык мендәр астына салып ятты. Улы тарафыннан язылган хаттагы сүзләрне йоклап киткәнче күңеленнән берничә тапкыр укыды. Анда әле бик күп сүзләр өстәргә мөмкин иде. Хатны улы язганга, боларны эшләү мөмкин булмады. Ә соң тагын нәрсәләр әйтергә мөмкин иде? Әйе, күңелдә яткан, әле бик бәләкәй генә булган төенне чишәсе иде. Бу төенне аның балалары ясадылар, тик алар аны яратмаганга түгел, киресенчә, якын күргәнгә, ана иткәнгә эшләделәр. Аны иркен, иркеле тормышыннан алып китеп, менә монда, бүлмәгә биклән куйдылар. Моңа ачуланырга мөмкинме; алар бит аны хөрмәт итеп, анага булырга тиешле кадер итеп карыйлар.

Карчык иртә торды. Балаларын эшкә озатты. Өйне бераз жыештырганнан сон, конвертны алып, урамга чыкты.

Төне буе кар яуган, кечкенә сирень, сәрби куаклары кар астында калган. Коймаларның өстен кар каплаган. Тыш шундый матур! Җил дә юк. Кыек башларында ак түшле песнәкләр чырык-чырык килә. Алар язның якынлашуы, тиздән, бик тиздән урамнардан, үзәннәрдән ерганаклар гөрләп агасын, ярына сыймыйча Иделнең ташыйсын, беренче яңгыр, беренче күк күкрәве турында сөйлиләр, юк, алар аны тыныч телмәр белән генә түгел, шатлыклы җыр белән сөйлиләр. Ә хәзерге кар нинди таза, җиргә нинди ышаныч белән яткан! Аның, карның, өстенә басарга хәтта кызганыч кебек.

Карчык урам капкасына кадәр барды. Тротуарда дворник карт кар көри. Хөршидә рәхәтләнеп эшләп йөргән кешегә бик озак карап торды. Аның эше күңелле, үзе дә бик канәгать төсле күренә.

— Таныйсыңмы әллә?

— Юк,— диде карчык,— болай гына карыйм. Хатны кая салалар монда?

Хөршидәнең кулындагы конвертны күргәч кенә карт аңлады.

— Әнә каршыдагы ящикка сал.

Хат салынды. Бу хатны салу, бик зур эш төсле булып, карчыкны куандырып торган иде. Ящикка төшереп җибәрү белән ул да бетте дә куйды. Хөршидә тагы да үз капкалары төбенә, кар көрәүче карт янына килде. Карт исә җайлап кына тәмәке төрде, ашыкмый гына аны тартты, аннары тагы да үз эшенә тотынды. Хөршидә теләсә-теләмәсә дә өйгә керде.

Кичен Яппар самавыр алып кайтты, аның артыннан берәү күмер күтәреп керде. Самавыр чәе тәмле булды. Бу чәй карчыкка гына түгел, Яппар белән Мәүлиягә дә ошады.

Тагы да берничә көн үтте. Карчыкның күңелсезләнүен самавыр гына каплый алмады. Колхоз, Хәдичә, күршеләр һаман күңелдә йөрделәр. Аларны төштә күрү бер гадәткә әйләнеп китте. Мәүлия килене карчыктан авылны, Хәдичәне сөйләтергә телиме, теләмиме, аны тыңлау авырмы, җиңелме, берсенә дә карамастан чәй янында да, аш янында да, ятар алдыннан да сөйли торган булып китте. Ял көне алдыннан булган бер кичне, өстәлдәге самавыр, чынаякларны җыймыйча, ана һәм балалар бик озак әңгәмә суктылар. Карточкаларга төшү, җәй җиткәч пикникка чыгу, карчыкны моторлы көймә, пароходларда йөртү турында сүз барды. Әңгәмәнең азагында карчык, балаларының йөзенә карамый гына, болай диде:

— Хөрмәтегезне, балалар, күп күрдем, жылы сүзләрегезне күп ишеттем. Бик рәхмәт, әйтер хәлем юк, кадеремне беләсез, тик мине кире авылыма кайтарыгыз инде.

— Нигә алай?!

Балаларның икәүсе дә кинәт шулай дип сорадылар. Мәүлиянең күз алмалары гажәпләнү һәм куркудан зураеп китте.

— Шулай инде,— диде карчык,— сезгә тырнак очы кадәр дә үпкәм юк. Мин шул эшкә өйрәнгән инде. Анда кайтсам, азмы-күпме дигәндәй, үземә житәрлек өй эшем дә, колхоз эшем дә диярлек бар.

6

Яппар квартирасы алдына чанага жигелгән ат килеп туктады. Карчык биек йортның баскычыннан куана-куана төшә, тик улына да, килененә дә карарга ояла, аларга үзенең ахмакларча куануын күрсәтмәскә, яшерергә тырыша. Мәүлия карчыкның күңелен таба алмаган, аны үз янында калдырырга күндермәгән өчен үзен әрли, хәтта Яппарда да шундый көч булмавына эче поша. Көн язга тартым жылы булуга карамастан, карчыкны толыпка урандырып утырттылар. Балаларыннан аерылу бик кыен булса да, Хөршидә карчыкның тизрәк китәсе килде.

Ат кузгалды. Бер сәгатьтән каланың читенә чыктылар. Карчык, ат куучының ярдәмен алмыйча, толып якасын ачты. Юк, аның берәүдән дә сорыйсы, кеше кулына каласы килми. Хәтта аттан жәфаландырып, сөйрәтеп бару да аны оялткан сымак, атлап кайтырга да риза ул.

Язгы юл бик еракка кадәр караеп сузыла. Тирә-якта каргалар оча, тавышсыз гына, тын гына очалар. Күгәрченнәр дә түгел, каргалар, тик шулай да сөйкемлеләр...

— Авылга кайчан барып житәбез?— Карчыкның атка утырганнан соң кучерга беренче соравы шул булды. Кучер:

— Шәмгә ут алуга житәргә кирәк иде инде,— диде.

Шәмгә ут алган вакыт — авылның бик матур чагы бит ул!

ӘНВӘР БИКЧӘНТӘЕВ

Әнвәр Һади улы Бикчәнтәев 1913 елда Уфада хезмәткәр гаиләсендә туа.

Оренбургта педагогия техникумын тәмамлаганнан соң мәктәптә эшли, ә 1933 елдан республика матбугатына, журналист хезмәтенә күчә.

Бөек Ватан сугышы елларында башта политрук, соңыннан фронт газеталары хәбәрчесе була. 1942 елда партия сафына кабул ителә.

Аның «Кызыл мәкләр» дигән беренче китабы 1944 елда басылып чыга. 1947 елда Ә. Бикчәнтәев СССР Язучылар союзына кабул ителә. Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый һәм читтән торып М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлый.

Әдип зур күләмле эпик әсәрләрдән «Карачәй юлы», «Оҗмах вәгъдә итмим» дигән романнар, «Бөркет һавада үлә», «Илче кызы», «Бәләкәй адъютант», «Ничә яшь сиңа, комиссар?» исемле повестьлар иҗат итә. «Зур оркестр» дигән повесте укучыларда бигрәк тә зур уңыш казанды, ул ике дистәгә якын телгә тәрҗемә ителгән.

Язучының сугышта күрсәткән батырлыклары Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, Беренче һәм Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнгән. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ә. Бикчәнтәевкә Октябрь революциясе, «Почет Билгесе» орденнары, республиканың Салават Юлаев һәм Г. Сәләм исемендәге премияләре бирелгән. Ул — РСФСРның атказанган культура работнигы.

САКАЛСЫЗ КЫЕН ИКӘН

— Океанны сиңа сакларга туры килер,— диде командир.— Караңгы төшү белән, сине Коно алмаштырыр.

Кечкенә Хосе командирның бакыр төсле кызарып торган, алъяпкычтай зур сакалыннан һаман күзен ала алмый; аның көнләшүе әллә кайдан сизелеп тора иде.

— Үтәрмен, командирым!

— Шуны исеңдә тот, Хосе, бу турыда хәтта үзебезнең отрядта да беркем берни белмәскә тиеш.

— Аңладым, командирым,— дип көрсенеп куйды Хосе.

Хосе командирыннан: «Ничек итеп мин берүзем генә бөтен океанны саклый алырмын соң?»— дип сорап тормады. Кичәге митинг кылт итеп аның исенә килеп төште. Анда озын буйлы Гаспар болай дип сөйләгән иде: «Безнең алда — кара йөрәкле Батистаның[1] солдатлары, ә безнең артта — зур океан... Без, баш күтәрүчеләр, тап уртадабыз...»

«Командир шул океаннан бераз шикләнә төшә булса кирәк»,— дип уйлап куйды Хосе. Шуннан соң ул абайлап эш итәргә кирәк булачак, дигән карарга килде.

Кем генә инде озын көн буена ашамый түзә алсын! Малай аш пешерүчедән ике бәйләм банан һәм бер уч дөге ярмасы сорап алды. Елгыр Хосе өчен отряд яшеренеп торган зәйтүн урманыннан чыгып китүе берни түгел. Яр да янда гына, күп дигәндә, бер миль булыр. Ул ачык урыннардан шуышып, яшеренеп узды, куаклыкларда ашыга төште. Чөнки аны беркем дә күрмәскә тиеш. Моны ул бик яхшы аңлый.

Аңа үз гомерендә беренче тапкыр күзәтү урыны сайларга кирәк. Хәрби тәҗрибәсе булмаса да, ул зур таш янында туктарга исәпләде. «Аның өстенә үрмәләп менеп алганда, ярты океан күренеп торачак,— дип уйлады малай.— Теләгәнчә күзәт».

Ләкин Хосе таш өстенә күтәрелеп тормады — аңа гына башы җитте. Сактагы солдат үз-үзен күрсәтеп торса, аннан ни файда! Моннан, яр буеннан да, океан яхшы күренә ләбаса!

Хосе дулкыннар өстендә чыркылдап очып йөргән акчарлакларга игътибар да итмәде. Ләкин ярга якын килеп туктаган акула аның кәефен бозды. Аңа, җүләргә, ни кирәктер инде. Әллә берәр шомлык сизәме икән?

Шулай да ул, үз-үзен тынычландырырга тырышып: «Революция өчен кошлар куркыныч түгел,— дип уйлап алды.— Акуланың да зыяны юк... Юкка гына мин дөге ярмасы сорап алдым,— диде малай.— Сакта торган солдат барыбер ут яга алмый бит. Болай булгач, кичен, үләм дисәң дә, миңа ботка әләкми инде... Банан белән генә чикләнергә туры килер, ахры. Берсен хәзер үк ашарга кирәк, икенчесен — кичкә табан...»

---

[1] Батиста — Кубаның элекке диктаторы.

Ул сакта торган вакыт эчендә артык әһәмияткә ия булырлык бернәрсә дә күзгә чалынмады. Нибары бер пароход узды. Ул да күренеп алды да офык артына кереп югалды.

Дөресен генә әйткәндә, кечкенә Хосе әле үзе башкарган эштән канәгать түгел иде. «Сакалың булмаганга күрә сиңа төндә сакта торырга рөхсәт итмиләр,— диде ул үз-үзенә.— Шуңа күрә ышанып җитмиләр».

Ул, әлбәттә, командирныкы кебек мәһабәт сакал турында хыялланырга батырчылык та итми. Андый бәхет һәркемгә тими. Гади генә кара сакал үссә дә, бик риза булыр иде әле.

Сьерра Маэстра тауларында: «Гавананы азат итми торып, сакалымны кырмыйм»,— дип Фидель Кастро сүз биргәннән соң, сакал үстерү бөтен отрядларда гадәт булып китте. Хәзер инде, аның озынлыгына карап, революционерларның стажын һич ялгышмый белеп була... Барбудослар[1] сатылмый торган иң ышанычлы кешеләр алар!

Хосе отрядның ант иткән көнен үз күзе белән күрде. Бөтен гуахирослар[2] коралларын баш очларына күтәреп бер-берсе алдында: «Сакалларыбызны кырмыйбыз»,— дип сүз бирештеләр, ант итештеләр һәм кочаклаштылар.

Тик бер генә кеше, сакалсыз Хосе генә, ант итүдә катнашмады... Ул пальма агачы төбендә туйганчы елады. Агачка эч серенне сөйләп була. Агач беркайчан да гайбәт сөйләми бит!

Елап туйгач, Хосе, бәлки, сакал чыгар дип, ияген коры ком белән ышкырга тотынды. Бервакыт аңа аш пешерүче: «Яңакларны ком белән ышкысаң, сакал тизрәк чыга»,— дигән иде.

...Дулкыннар арый белмиләр, туктаусыз ярга килеп бәрелеп торалар. Менә тагы бер сәгать узып китте... Бәлки, бер түгел, ике сәгать тә узгандыр. Хосе, сәгате булмагач, күпме вакыт үткәнен кайдан белсен?

«Әллә җырлап алыргамы? Җырласаң вакыт тизрәк үтә». Хосе моны бик күп тапкыр сынап караганы бар.

Ул башка кеше авызыннан ишеткән җырларны җырларга яратмый, үз җырын үзе таба. Кубада җырларның исәбе дә, саны да юк. Чөнки монда һәркем үзенә кирәкле җырны үзе чыгара.

Мин синнән курыкмыйм, чал океан.

---

[1] Барбудослар — сакаллылар.
[2] Гуахирос — батрак.

Шулай итеп, яңа жыр башланды. Хосеның җырлары бик кыска, мөгаен, дөньяда аның җырларыннан да кыскарак җыр юктыр.

Җырың кыска булса, аны ешрак кабатларга кирәк. Шул чакта гына ул, башка җырлар кебек, озын була ала.

Мин синнән курыкмыйм, чал океан,
Чөнки минем кулымда бар карабин...

Шулай дип ул күп тапкыр кабатлады.

Океан аңа гел тере кебек тоела иде. Күбекле дулкыннарга карасаң, алар нәкъ сакалга охшап торалар. Хосе шаярып алырга теләде. Бер күзен кысып: «Әй син, океан, тыңла мине,— диде ул.— Әйдә, сине дә үзебезнең отрядка алыйк. Без бер генә барбудостан да баш тартмыйбыз. Сиңа да эш табылыр».

Ләкин артык шаярырга туры килмәде: кинәт дулкын өстенә калыккан ак көймәне күреп, ул аптырап калды.

Кечкенә солдат җәһәт кенә зур таш артына посты. Көймәдән күзен алмыйча, ул үзалдына сөйләнә башлады: «Балыкчыларның мондый очлы башлы көймәләре юк,— диде ул.— Үзе ак... Үзе җиңел... Әллә күктән төште, әллә диңгез астыннан калкып чыкты инде?.. Командир мине әллә шушы көймәне күзәтергә дип җибәрдеме икән»,— дип уйлады Хосе.

Малай мылтыгын кысып тотты. Әле аның бер генә тапкыр да атканы юк. Бәлки, менә бүген, хәзер атарга туры килер?..

Көймәне сакалсыз кеше ишә. Әлбәттә, аның ят булуы ап-ачык. Шундый вакытта сакчы нишләргә тиеш икән? Шуны белсәң иде!

Командир тик океанны гына сакларга кушты, ут ачарга әмер бирмәде бит. Нишләргә? Нихәл итәргә?

Кашын җимереп, ул уйланырга тотынды.

Әгәр шушы минутта кемнеңдер ашыгып атлаган аяк тавышын ишетеп калмаса, сискәнеп китеп, артына әйләнеп карамаса, мөгаен, ут ачарга мәҗбүр булыр иде. Чөнки башка бернинди дә чара юк кебек иде. Бу авыр хәлдән аны әлеге озын буйлы Гаспар коткарды. «Әһә, бу көймәне аңа каршы алырга кушканнар икән,— дип уйлады Хосе.— Әйдә, аның белән ул үзе генә булашсын инде! Минем кысылышым юк».

Митинг үткәргәндә Гаспардан да кычкырыбрак сөйләүче кеше табылмый. «Андыйларга ышанып була,— диде Хосе.— Менә дигән кеше!»

Малай тәмам тынычланды. «Командир мине монда әлеге көймәдән шикләнеп җибәрмәгән, күрәсең»,— дип уйлап куйды ул.

Гаспар көймәдән төшкән кешегә кул бирде. Алар бер-берсенә күп дигәндә ун сүз әйтешкәннәрдер, шуннан да артык булмас. Таш артында яшеренеп торган Хосега шулай тоелды. Шуннан соң әлеге кеше көймәсен суга этәреп төшерде дә ашыга-ашыга кире ишә башлады.

Дөресен әйтергә кирәк, моны күзәтеп торган Хосеның кәефе бик нык кырылды. Командирына үпкәсе кабарды. «Миңа ышанмагач, нигә мине океан сакларга җибәргән була икән?— дип пышылдады ул.— Әллә сакал булмаганга ышанып җитмиме? Башка сәбәп юк бит. Гаспар барбудос булгач, әлбәттә, аңа нык таяна, көймәне каршы алыр өчен дә аны җибәргән... Ичмасам, сакал да үсми бит!»

Хәзер инде таш артында яшеренеп утыруның кирәге юк. Хосе, ачык урынга чыгып, ком өстенә килеп утырды. Гаспар аны күрсен әйдә! Командирга да «күрдем» дип әйтсен. Мөгаен, шуннан командир да уңайсызлана төшәр. Бәлки, ул: «Юкка гына Хосены кимсеттем»,— дип үкенер. Үкенми булмас!

Хосе, бөтен дөньясын онытып, комнан манара төзи башлады. Ул, эшкә тотынса, җырламый булдыра алмый, әлбәттә.

Иллә мәгәр комнан манара ясап булмый икән — җимерелә дә төшә. Хосеның кәефе кырылды. Ләкин малай алдына куйган максатыннан баш тартмады — чигенә торган кеше түгел ул.

Гаспарның якынлап килүен сизсә дә, ул әйләнеп карамады. Хосе батыр ирләрнең гадәтен яхшы белә, ни генә булса да, сер бирергә ярамый. Куркак кеше генә урынында тыныч утыра алмый. Шунлыктан, ком өстендә Гаспарның күләгәсен күрсә дә, башын күтәреп карамады.

Ләкин Хосены бер нәрсә бик нык шикләндерде. Ни өчен Гаспар сул аягы белән аның мылтыгына басты әле? Малай килүче кешенең йөзенә күтәрелеп карамый түзә алмады.

Гаспарның төсе качкан иде. Ул, чабып арыган ат кебек, авыр тын ала. Нидән шулкадәр курыккан икән? Шулай да Хосе сер бирмәде, үзенең шикләнүен сиздермәде, сорашып та маташмады. Юк-бар белән кызыксыну — хатын-кыз гадәте. Вакланып тору егет кешегә килешми.

Шулай да ул: «Намуслы кеше мылтык өстенә басар идемени?— дип уйлап алды.— Монда ниндер бар...»

Шул минуттан Хосе уйга калды: «Инде ышаныч үзендә

генә, монда, буш яр буенда, сиңа ярдәмгә килүче табылмас...»

— Йә, буш корсак, син нишләп монда килеп чыктың әле?— дип сорады Гаспар.

Хосе җавап бирергә ашыкмады.

— Монда вак балык яхшы эләгә,— диде ул.

«Әгәр дә Гаспар шулкадәр курыкмаган булса, һичшиксез, синең кармакларың кайда соң, дип сорар иде, сорамый булдыра алмас иде»,— дип уйлады Хосе.

— Синең монда булуыңны берәр кеше беләме?— дип төпченде Гаспар.

Хосе иренен тешләде. «Әйе, белә» дисәң, командирның серен ачарга туры килә. «Юк, берәү дә белми» дияргә һич кенә дә ярамый. Әгәр алай дисәң, башыңа җитүе бар: үзеңне акулага ташлар, ә мылтыгыңны комга күмәр. Шуннан көрәшче Хосеның эзе-юлы да калмаячак...

— Мине монда аш пешерүче абый җибәрде,— диде Хосе.— Шулпага балык кирәк икән. Тыңламый булдыра алмадым.

Гаспар ачу катыш көлде.

— Алдыйсың, маймыл!

— Ышанмасаң, үзеннән барып сора. Берьюлы командирга да әйт,— диде Хосе.— Үзең беләсең бит, зәйтүн урманнарына рөхсәтсез килүчеләрне ул яратып җитми, мине тоттырсаң, бәлки, үзеңә рәхмәт әйтер...

Гаспар малайга, аның ниятен белергә теләгәндәй, шикләнеп карады да ашыкмый гына сигарет кабын ерта башлады. Шырпы сызганда аның кулы дер-дер калтырый иде. «Болай булгач, эш харап икән,—дип уйлады Хосе.—Минем белән нишләргә белми, күрәсең... Аның белән очрашуга үкенергә туры килмәсә ярар иде».

— Менә нәрсә, Хосе,— диде Гаспар.— Әйдә, син дә тарт!

— Мин тарта белмим!— диде малай.

— Кайчан да бер өйрәнергә туры килер.

Хосе киреләнеп тормады, аннан барыбер файда булмаячак.

— Мине командирга ошакламавыңа тәмам ышандым инде,— дип елмайды Хосе.— Бер шырпыдан тәмәке кабызган кешеләр бер-берсенә хыянәт итә алмыйдыр ул!

Бу сүзләрне Хосеның атасы еш әйтә торган иде. Хосе аларны кабатлады гына.

Ләкин Гаспар Хосе әйткәнгә игътибар да итмәде бугай.

— Инде мин әйткәнне колагыңа сал,— диде ул.— Менә бу пычакны күрәсеңме? Әгәр дә телеңне тыймасаң, синең

белән менә шушы хәнҗәр танышачак. Ул күп сөйләшми: бер әйтә, берәгәйле әйтә.

Хосе Гаспарга игътибарлы карады.

— Пычагың ошый,— диде ул.— Бүләк ит миңа!

— Мин шаяра белмим, малай актыгы!

Хосе дә ачуланган булып алды:

— Мин сиңа ышанам, ә син миңа ышанмыйсың,— диде ул.— Митингларда синнән дә кычкырыбрак сөйләүче кеше юк. Шулай булгач, син иң ышанычлы кеше булып чыгасың. Көймә турында мин оныттым да инде. Бәләкәй дигәч тә, мине ул кадәр аңгыра дип уйлама. Командир әмерен үтәп йөрүеңне аңламый дисеңмени! Юк-барга кысылып йөрергә яратмыйм мин.

Гаспар сигарет кабын комга ташлады да:

— Мә, сиңа!— диде.— Тарта башлагач, кирәге булыр.

...Хосе урманга табан китеп барган Гаспарның аркасына карап утыра.

«Әгәр бер генә тапкыр артына әйләнеп караса да, ул сатлык җан булып чыгачак»,— дип юрый ул.

Гаспар, байтак киткәч, бер әйләнеп карады. Әйләнми түзә алмады.

Караңгы төшкәч, постка Коно килеп җитте. Барбудослар арасында аннан да тәбәнәк буйлы кеше юк иде.

Хосеның кулындагы сигарет кабын күреп, ул куштанланып кулын сузды.

— Бир миңа! Син барыбер тартмыйсың бит,— диде ул.

— Юк, бирмим,— дип кырт кисте Хосе.— Сакта торганда тартырга ярамый. Дошманның күреп калуы бар.

Коно сигаретны тартып алырга дип омтылды, ләкин Хосены куып җитү җиңел түгел. Бераз йөгереп баргач, ул туктады да Кононы ирештерә башлады.

— Их син, пешмәгән!.. Бөтен отрядта синнән дә юньлерәк кеше табылмадымыни? Сине постта калдыруы да оят!

Коно йодрык кына күрсәтте.

...Аш пешерүче агай вакланып тормады: Хосены ботка белән дә сыйлады, хәтта бер кружка кофе да бирде. Ашаганда Хосе янына Гаспар килеп утырды. «Болай булгач, бу сагыздан котылып булмый икән,— дип көрсенеп куйды Хосе.— Инде командирны күрермен дип уйларга да ярамый».

Нәкъ шулай булып чыкты да. Ашык-пошык ашалган кичке аштан соң, Хосе янына Гаспар килеп ятты. «Сатлык җан миннән шүрли!»— дип уйлап алды Хосе.

Төн буена алар күзләрен дә йоммадылар. Бер-берсенә ышанмыйча, кыска төннән шикләнеп яттылар.

Таң аткач, командир үзе Хосены чакыртты. Инде кит-

тем дигәндә генә, Гаспар авыр кулын Хосеның иңбашына салды да:

— Пычакны исеңнән чыгарма!— дип искәртте.— Ул сине җир тишегеннән дә табар.

Малай «аңламадым» дип баш селекте.

Штабка кергәч, ул тыныч кына исәнләште.

— Хәерле иртә, командирым!— диде.

— Хәерле иртә, Хосе... Ләкин төн тыныч булмады,— дип куйды командир.— Конога һөҗүм иткәннәр, әгәр ул каушап калса, эш харап иде. Ком өстендә бик күп эз калган, таң аткач, үз күзем белән күрдем. Ни дип уйларга да белмим... Кичә, син сакта торганда, берәр шикле хәл булмадымы?

«Ярый әле Конога сигаретларны бирмәдем, тартмый түзә алмас иде,— дип уйлап куйды Хосе.— Исән калуы өчен миңа рәхмәт әйтсен!»

— Гаспар — сатлык җан!— диде Хосе.

Инде ул командирның бакыр төсле кызарып торган алъяпкычтай зур сакалына игътибар итми, аның төн кебек салкынаеп киткән күзләренә карап тора иде.

Командир, төсен үзгәртеп:

— Син, малай, нинди авыр сүз әйткәнеңне аңлыйсыңмы?— дип сорады.

— Аңлыйм, командирым.

— Сөйләп бир, мин сине тыңлыйм, Хосе.

Хосе кичә булган вакыйганы баштанаяк сөйләп биргәннән соң, командир кинәт аягүрә басты да:

— Син ата беләсеңме, улым?— диде.

— Беләм, командирым!

— Сатлык җанның күкрәгенә төзәгәндә кулың калтырамасмы?

— Юк, калтырамас, командирым!

Сакаллы кеше Хосены кочаклап алды.

— Кеше күкрәгенә атарга сиңа иртә әле. Ул эшне мин үзем башкарырмын. Ә син, Хосе, эшеңдә бул. Океанны сакла!

Хосе, кичәге кебек үк, бер кулына — мылтык, икенче кулына ике банан бәйләме тотып, яр буена юнәлде. «Барбудос булсаң иде,— дип көрсенеп куйды ул.— Шуннан башка бер нәрсә дә кирәкми миңа. Сакалсыз кыен... Шунсыз бер ямь юк... Рәхәт күреп булмый. Сакал үссен иде...»

РӘИС ГАБДРАХМАНОВ

(1918—1988)

Рәис Бикмөхәммәт улы Габдрахманов 1918 елда Башкортстанның Благовар районы Күчәрбай авылында туа.

Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң Уфада рабфакта укып чыга һәм үз районында укытучы, республика газеталарында хәбәрче була. Бөек Ватан сугышы башлану белән хезмәт армиясенә чакырылып, Уралмаш заводында эшли.

Р. Габдрахмановның беренче шигырьләре аның рабфакта уку чорында чыга башлый, ләкин чын язучы-прозаик булып ул сугыштан соңгы елларда гына үсеп китә. Аның «Яңа билдәләр» дигән тәүге китабы 1951 елда дөнья күрә. Хәзер инде танылган әдип «Иң якын дус», «Авыл малае», «Маҗаралы юл», «Хезмәт бабай белән Хөрмәт бабай», «Серле мәзәкләр», «Кызыл разведчик», «Кышкы салкын көннәрдә», «Өч адымнан Камчатка», «Көрәнкәй», «Тал бөресе», «Тәүге буран», «Эзләр» һәм башка китаплар авторы.

Р. Габдрахманов кырык елдан артык Коммунистлар партиясе әгъзасы, СССР Язучылар союзына 1956 елда кабул ителгән иде.

ТРУДАРМЕЕЦЛАР

Түбәләренә яңа гына таң сарысы ягыла башлаган тәбәшәк такта бараклар зәңгәр чыршы урманы куенында тыныч кына черем иткәндә трудармеецлар яши торган поселокны:

— Сугыш беткән!

— Гитлер йөзтүбән капланган!

— Җиңү килде! — дигән шат тавышлар яңгыратты.

Бу хәбәрне соңгы көннәрдә бөтен халык көтә иде. Шулай да, ачы кайгыда үткән дүрт елга якын вакыт эчендә

«сугыш» сүзенә бөтенләй күнегеп беткән колакларга ул, кырык беренче елның егерме икенче июнендә илне тетрәткән «яу!» дигән коточкыч сүз сымак, үтә сәер ишетелде.

Рәт-рәт булып тезелеп киткән ике катлы тимер койкаларның мич янындагысының аскы катында соры одеялга уранып ял итеп яткан Әхмәтгали хәтта каушап төште. Шуңа, урыныннан беренче булып сикереп торса да, иң соңыннан киенеп бетте. Тәүдә әле чалбарын, әле күлмәген таба алмыйча йөдәде. Тапкач инде, кия алмыйча интекте, йә кулыннан төшеп китте, йә булмаса балак, җиңнәре ишелде. Йөгереп кенә барак ишеге янына барып, утны кабызырга һушы җитмәде. Ул шулай ике койка арасындагы тирән тарлыкта үрсәләнгән арада, тегендә-монда башкалар да башын калкытты. Әмма әле берни ишетмәүчеләр дә «ни булды?» дип беркемнән дә сорамады. Сугыш беткәнлеген һәркем җаны белән тойды. Тыштан:

— Безнең урамга да бәйрәм килде!

— Бу көнне күрдек!

— Тынычлык! — дигән сүзләр ишетелгәч инде, караңгы барак эче бермәлгә умарта эче сымак гү итеп китте.

— Язгы сабанга өлгердек болай булгач!

— Быел үзебез үстергән әпәйне ашаячакбыз!

— Сау бул, Уралмаш!

Мичнең икенче ягындагы койканың өске катында яткан чатан Бәкер исә:

— Ха-ха-ха! — дип бөтен баракны яңгыратып көлеп, идәнгә сикереп төште дә, киенеп-нитеп тә тормастан, йөгереп барып, әле тегесен, әле монысын кочакларга тотынды.— Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!..

Ул — сугышта булырга өлгергән кеше. Мәскәү янында хәтта медаль дә алган. Шуның чыңлавын ишеткәч, һич тә уйламаганда, Әхмәтгалине әллә нинди тойгылар чолгап алды. Әйе, аның бөтен авылдашлары да, Бәкер кебек, орден, медальләрен чыңлатып кайтып төшәрләр инде менә. Ә ул нишләр икән? Кайда соң аның бүләкләре? Ул да сугышның беренче елында ук киткән кеше бит. Тик строевойга гына эләкмәде — йөрәге харап итте — төзү эшчеләре колоннасына алынды. Шулай да аны да күз яше түгеп, чәч йолкып озатып калдылар — заводка икәнен белмәделәр. Сугыш вакыты бит — военкоматның тыл хәстәрен күрүен кем уйласын? Әхмәтгали моңа үзе дә, эшелон Свердловскига туктап, колонна начальнигы: «Илебезнең даны булган Уралмашта эшләячәкбез»,— дигәч кенә төшенде. Тәүге мәлдә бу турыда хатына да язмады, әллә нидән оялды — озатканда хатыны белән бала-чагасы түккән

күз яшеннән булды шикелле. Менә хәзер кайтыр көннәре дә якынлашып беткән, имеш! Вакыт үткән дә киткән!

Әхмәтгали, идәнне дөпелдәтә-дөпелдәтә кысык кирза итекләрен киеп алгач та, артсыз утыргычтагы уңып агара башлаган майлы пилоткасын тиз-тиз генә түбәсенә каплап, абына-сөртенә ишеккә табан йөгерде. Ә атылып тышка чыккач та күрше баракта яшәүче Хөснулла исемле кешегә тап булды. Победит ярчыгы чәчрәп, быел кыш кына бер күзен югалтты ул. Әхмәтгалине күргәч, Хөснулла капыл гына туктады да тешләрен кысып:

— Их, туган, туган, нигә былтыр бетмәде соң бу сугыш? Нигә быелга калды? — дип сыкранды.

Әхмәтгали ни дисен инде?

— Хәлеңне аңлыйм, агай, ни эшлисең бит? — диде, аның аркасыннан кагып.— Ил белән бит...

— Шулай, туган, шулай, ил белән...— Инде берүк шуның белән бетә генә күрсен...

Әхмәтгали тагы да бер кат аның аркасыннан кагып ашыгып китеп барды. Йөрәге ачытып-ачытып куйды үзенең. Әйе, эш бит сугыш утының эчендә кайнауда гына түгел. Алар да мич башында ятмадылар. Нинди генә авырлыклар кичермәделәр кайчагында — атналар, айлар буена цехтан саф һава суларга да чыкмадылар. Ичмасам, бер генә кат туйганчы ашасалар әле тагын. Шулай да берсе бер зарланса иде — егылса егылды, ә станогын ташлап китмәде. Үзенең райондашы Зиннәтне беркайчан да онытачак түгел Әхмәтгали. Нинди өметләр белән яши иде ул! Янәсе, сугыш беткәнче генә түзсен — бернигә дә карамыйча, авыл хуҗалыгы институтын бетереп, агроном булачак, дөньяда иген игүдән дә изгерәк эш юк. Ә түзмәде — сугышның җиңү ягына чыккач, үлеп китте — йөрәге ярылып, тәртә арасына егылган ат кебек, станогы янында җан бирде. Строевойга ярамаса да, җимертеп яшәрлек кеше иде әле — үзеннән булды — цех начальнигы Евгений Степановичны тыңламады. Аңа ул, йөрәге начарлыгын белгәч, ничә кабат конторага күчәргә кушты. Мин монда өстәл артында утырырга килмәдем, өстәлләр авылымда да җитәрлек иде, диде. Хәер, Әхмәтгали үзе соң? Ничә кат больницада ятты! Йөрәк белән. Яшьтән ревматизм белән җәфаланган иде ул. Шул суккан йөрәгенә. Азак чиктә өченче группа бирделәр үзенә. Җиңел эшкә күчтеме? Инвалидлыгын законлаштырып та тормады. Эшли бирде станогында. Ә аның тәүдән үк авыр эшкә тотынмаска мөмкинлеге бар иде. Аны, колоннага алынгач та, кладовщик итеп тәгаенләгән иделәр. Уралмашка килгәч тә, бер-ике

ай эшләп йөрде анда. Тик шуннан артыгын булдыра алмады — тап Зиннәтчә уйлый башлады: мәктәптә артык идеме әллә? Мөгаен, аны укытучылыктан моның өчен аермаганнардыр. Цехка күчерүләрен сорап начальникка язган рапортында менә шуларның берсен дә калдырмады. Шәп адәм иде теге — аңлады аның күңелен. Менә шулай, азык-төлек арасыннан чыгып, тимер-томыр арасына барды да керде ул. Кайсыберәүләр, оҗмахтан бизгән фәрештә, дип көлеп тә йөрде аннан.

Әхмәтгали яңа такта җәелгән тар тротуарны даңгырдоңгыр китереп поселокны чыкканчы, үзен җиңү көне белән котлап үтүче трудармеецларга, озакка килгән шатлык булсын дип, бөгелеп-сыгылып, җавап кайтарып барды. Әмма берсе белән дә тукталып сөйләшеп тормады. Завод проходноена ашыкты. Тик маңгае белән килеп төртелгәч, ипләбрәк караса, капка дигәне военкомат ишеге булып чыкты. Таныгач, бот чабып, башын селкеп торды ул. Менә хәтер! Нишләп бүген исемә төшкән соң әле бу? Менә хикмәт! — дип сөйләнде ул. Шуннан: — һе! — дип як-ягына каранып алды да кабат артына борылды.

Военкомат сукмагын аз такырайтмады шул Әхмәтгали заманында. Төзелеш эшчеләре колоннасы бетерелеп, аның боецлары Уралмаш карамагына тапшырылгач, бер мәлне көн саен дип әйтерлек килеп йөрде. «Мин фронтка китәргә телим, мине фронтка җибәрегез!» — дип ялынды килгән саен. Ә военком якын да килмәде. «Сез аңлы кеше бит, дошманны күсәк белән генә җиңеп булмаячагын белергә тиешсез»,— диде. Әйе, Әхмәтгали моны бик яхшы аңлый иде. Тик һаман үзенчә уйлады: берәр вакыт аның да, кешенеке кебек, оныклары булыр, бәс шулай икән, кайчан да бер аларның сугыш турында сөйләвен үтенүләре дә бар, шул чакта ни дияр ул, авызын йомып утырырмы?

Шулай да, сугыш Идел ярына килеп җиткәч, ул военкоматны беразга онытты. Чөнки үзе турында уйланырга вакыты бетте. Танк тәгәрмәчләре чыгара торган цехта эшли иде бит. Ул көннәрдә задание көн саен артып тора: беркем цехтан чыкмый, ике смена бергә буталган, бер эшче азрак хәл җыйган арада икенчесе эшли тора, тәүлек әйләнәсенә шулай. Ә официанткалар ашны турыдан-туры станоклар янына ташый, чөнки вакытның минуты да кадерле.

Завод проходное военкомат каршында гына дип әйтерлек. Мәйданга кергәч күп тә бармады, Әхмәтгали зур тимер капка башына буйдан-буйга сузып куелган өр-яңа

кызыл материяне күреп калды. Аңа алтын хәрефләр белән эре итеп «Яшәсен бөек Җиңү!» дип язылган иде. Элек анда «Бөтенесе дә Җиңү өчен!» дигән лозунг эленеп тора иде. Әхмәтгалиләр килгәндә үк бар иде инде. Шуңа күрә хәзер материясе уңып бетеп бара иде. Шулай да аны алып тормаганнар, өстенә яңасын гына каплаганнар. Җил селкеткәндә, искесе дә ялт-йолт күренеп китә. Менә шуңа да Әхмәтгали үзе атлады, үзе берчә «Яшәсен бөек Җиңү!», берчә «Бөтенесе дә Җиңү өчен!» дигән сүзләрне укыды. Моннан аның йөрәгендә тагы да ниндидер үз-үзен барлау тойгысы уянды. Чынлап та, Җиңү өчен бөтен көчен бирдеме соң ул?

Йә кочаклашып, йә үбешеп, озак көттергән олы тантана белән бер-берсен тәбрикләп торучыларны сәламли-сәламли завод проходноена керү белән, Әхмәтгали үзенә таба җан-фәрманга йөгереп килгән Корбан әкәне күреп калды. Битләре чаңлы, өстендәге билен кысып буган комбинезоны майлы иде аның. Ә үзе кояш кебек балкый. Фирганә ягында туып-үскән ул. Гомере буена мамык иккән. Яшькә дә ярыйсы гына хәзер. Фронтта улы бар. Тик соңгы вакытта хат кына килгәне юк аннан. Шулай да Корбан әле өметен өзми. Болай булгач, тере калды инде балакаем, ди.

Корбан әкә дә Уралмашка, тап Әхмәтгали кебек, төзү эшчеләре колоннасы белән килеп эләкте. Аның да йөрәге шәптән түгел. Шунлыктан монда элегрәк төрле җиңел эштә генә йөрде; йә цехка керә торган сукмакларны көрәде, йә булмаса ашханә идәнен себерде. Былтыр ул бичәсен җирләп килде. Хәзер беркеме дә юк өендә. Шулай да Үзбәкстанын бик сагына. Бервакыт шулай ул, Әхмәтгалигә йөгереп килеп, эштән китәргә гариза язып бирүен үтенде. «Син бит мөгаллим, килештеребрәк язарсың»,— диде. Әхмәтгали гаҗәпләнүеннән иңбашларын сикерткәч: «Аптырама, Әхмәтгали әкә, мин аны сугыш беткәннән соң гына бирәчәкмен, ашарга сорамый бит, кесәмдә әзер торсын»,— дип өстәде. Әхмәтгали аның белән 1 Май бәйрәме алдыннан танышкан иде. Өеннән посылка алган иде Корбан әкә. Утызынчы апрель көнне эштән чыгу белән, цех капкасы төбендә Әхмәтгалине туктатты да бәләкәй генә бер төргәк сузды.

— Бәйрәм кучтәнәче, авыз ит...

— Ничек инде алай? — дип аптырады Әхмәтгали.— Монда күп булыр минем кебекләр...

— Син бит мөселман,— дип төргәген суза бирде Корбан әкә.— Мин сиңа күптән күз салгалый йөрим. Эшең бик

авыр. Мә, мә, ал. Көчтәнәчтән баш тарту гөнаһ ул!

Шуннан соң Әхмәтгали үзе дә бөтен тәм-томын аның белән бүлешә башлады. Корбан әкә инде паена тигән тәмәкесен башы белән аңа бирә торган булып китте.

— Мин тартмыйм, игелеген күр,— диде.

Менә шулай дуслаштылар да киттеләр алар. Цехка соңрак килүчеләр үзләрен агалы-энеле икән дип белде хәтта.

Ә Әхмәтгали больницада яткан чакларда ниләр генә эшләмәде Корбан әкә! Атнасына бер-ике кат тигән йокыларын йокламыйча барып йөрде аның янына. Үзенә юк нәрсәләрне табып китерде. Соңгы киеменә кадәр сатты. Әхмәтгали: «Азапланма!» — дигән иде дә: «Савык әле, бөтенесе дә табылыр, сугыш кына бетсен!» — дип куйды. Ә Әхмәттали больницадан чыккач инде, карточкасына тигән бөтен тәм-томны аңа гына тотты. Үзе, күз алмалары саргаеп, коры сөяккә калды. Тегесе: «Үзеңне кара, Корбан әкә, син дә тимер түгел бит»,— дигәч, отыры үпкәләде. Әхмәтгали, савыгып, өченче группа алгач, ничек шатлануларын күрсәгез иде!

Корбан әкә ерактан ук колачын җәеп җан-фәрманга йөгереп килде дә юл уртасында Әхмәтгалине кысып кочаклап алды. Бер сүз кушса икән! Хәтта Җину көне белән дә котлап тормады. Әхмәтгалине кысып кочаклады да, башын аның күкрәгенә төрткән килеш, иңбашларын уйнатып, үксергә тотынды. Моннан Әхмәтгали үзе дә тетрәп китте.

— Корбан әкә, куй әле! — дип чак-чак кына әйтә алды.

— Тыйма, Әхмәтгали әкә, аксын бу яшь, татлы яшь бит ул, дөнья тулсын, тыйма! — диде Корбан әкә.

Ул балалар кебек үкседе-үкседе дә азактан:

— Ә син үзең нишләргә уйлыйсың инде? — дип сорады.— Сәрмәсәнем [1], дип теңләрең төшә торган иде бит?..

— Сагындым, Корбан әкә, бик сагындым,— диде дә, Әхмәтгали тынып калды.

— Мин дә бик сагындым Амударьямны, Әхмәтгали әкә, үтә сагындым,— диде Корбан әкә аңа каршы.— Китәм инде, җитте, гафу итәрсең, сиңа бик зур рәхмәт, әйбәт яшәдек, улым да озакламас, аллаһы боерса, китәм инде, җитте.

Аның авызыннан кинәт кенә бу сүзләрне ишеткәч, Әхмәтгалигә әллә ничек монсу булып китте. Бер гаилә

[1] Сәрмәсән — елга исеме.

кешесенә әйләнеп беткән иделәр бит, бөтенләй аерылышмас төслеләр иде. Менә әкәмәт, аның да соңы килеп җиткән икән ләсә.

Корбан әкә сүзен бетерде дә юешләнгән нечкә кара мыегын кабарынкы учы белән сыпырып алып, кесәсенә тыгылды. Аннан капкачлы зур көмеш сәгатен алып, аптырап торган Әхмәтгалинең учына салды.

— Шушы сугышның соңын күрсәм, иң якын дустыма бүләк итәрмен дигән нәзерем бар иде, Әхмәтгали әкә, иң якын дустым син булдың, ал да игелеген күр...

Әхмәтгали артка чигенеп куйды.

— Рәхмәт, Корбан әкә, мәшәкатьләнмә...

— Бүләктән баш тартырга ярамый, Әхмәтгали әкә, ул ярый торган эш түгел...

— Ярый,— диде Әхмәтгали, тиз генә уйлап алып.— Минем дә иң якын дустыма бүләк бирергә хакым бардыр. Алайса, сиңа бүләгем булсын, мә, кире ал, минем синнән дә якынрак дустым юк монда.

Алар завод капкасы каршындагы мәйданда митинг беткәч кенә кайттылар. Корбан әкә, туйганчы сөйләшеп утырыйк әле бер дип, Әхмәтгалине юл уңаенда ук үз барагына алып керде. Кергәч тә, мендәре астыннан алып, өстәлгә алтын путаллы гәрәбәдәй сары шешә утыртты.

— Җиңү көнне ачармын дип, үзем белән бергә алып килгән идем, Әхмәтгали әкә, ике ай мендәрем астында ята, синең ризыгыңа язган икән, рәхим ит әле...

— Ә үзең, Корбан әкә?

— Мин — ураза,— диде ул, яшереп тормыйча.

— Ураза?

— Ышанганга түгел, Җиңү көнен күрсәм, шул көннән башлап бер ай ураза тотармын дигән сүзем бар иде. Күңелемдә таш булып калмасын, тотам инде, гаеп итмә...

— Җаны теләгән — елан ите ашаган, Корбан әкә, үзең теләгәнчә шатлан.

Корбан әкә моннан соң канәгатьлек белән шешәне ачып шәрабны калай кружкага койды да Әхмәтгали алдына куйды.

— Туйга чакырырмын, Әхмәтгали әкә, ерак дип торма, кил, килмәсәң, үпкәм зур булыр.— Әхмәтгалинең күзләрендә хасил булган сорау галәмәтен күргәч инде: — Улым да озакламас бит, аның әллә кайчан ярәшеп куйган кәләше көтә, бирнәсенә кадәр билгеләнгән,— дип өстәде.

— Хәбәр генә ит, Корбан әкә! — дип аның учына сукты Әхмәтгали.— Ут чыкса да, килми калмаячакмын!

Корбан әкә, җаннары рәхәтләнеп, елмаеп куйды.

— Мин сине беләм, бер сүзле син!

Аның шулай дип әйтүе булды, ишек ачылып китте дә, йөгереп тагын бер трудармеец килеп керде.

— Корбан әкә, сөенче, хат!

Корбан әкә, шатлыгыннан йөрәге ярылырдай булып, аңа каршы йөгерде.

— Шатлык та ялгызы гына йөрми ул! Ул да күмәкләп йөрергә ярата!

Ә хатны ачып укыгач, таш кебек катты да калды Корбан әкә. Тыны буылганлыктан, коңгырт бите чия көрән төскә керде, күзләрен томса гына яры каплагандай булды, иреннәре кара күмергә әйләнде.

— Корбан әкә! Корбан әкә! — дип атылып барып житте аның янына Әхмәтгали.— Ни булды сиңа?

Ул аның зур кара йодрыгыннан теге трудармеец керткән хатның яртысын да ала алмады. Алганы да бөтенләй туракланып беткән иде. Шулай да бер бәләкәй генә кисәгендәге «һәлак булды» дигән сүзне таныды. Җиргә убылган сымак тойды ул үзен.

— Корбан әкә!

Ул больницада икенче көнне генә исенә килде.

— Киленем кайда? Киленемне күрсәтегез! — диде ул, беренче сүзе итеп.

Больницада озак ятмады. Атна-ун көн дигәндә чыгардылар. Үз киемнәрен киенгәч, Корбан әкә иң тәүдә кесәсендәге теге гаризаны эзләп тапты. Тапты да тураклап җилгә очырды.

— Ә син, Әхмәтгали әкә, балаларың янына кайт, алар көтә торгандыр сине,— диде ул дустына.

МОСТАЙ КӘРИМ

Мостафа Сафа улы Кәримов 1919 елда Башкортстанның Чишмә районы Келәш авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

Җидееллык мәктәпне тәмамлап, Уфада рабфакта, шуннан педагогия институтында укый.

1938 елда аның (В. Нафиков белән берлектә) «Отряд кузгалды» дигән беренче шигъри җыентыгы чыга һәм ике елдан соң яшь шагыйрь СССР Язучылар союзына кабул ителә.

1941 елдан башлап М. Кәрим фронтта, артиллерия дивизионының элемтә начальнигы булып сугышта катнаша, каты яраланганнан соң хезмәтен фронт газеталарында дәвам итә.

М. Кәрим сугыш елларында «Декабрь җыры», «Үлмәсбай» дигән поэмалар, «Минем атым» исемле шигырьләр китабы иҗат итә. Ул шулай ук «Ялгыз каен», «Ай тотылган төндә», «Салават», «Айгөл иле», «Кыз урлау», «Ташлама утны, Прометей!», «Диктаторга ат бирегез!», «Җәяүле Мәхмүт» дигән пьесалар, «Безнең өйнең яме», «Өчтаган», «Озын-озак балачак», «Ярлыкау» исемле повестьлар язды.

М. Кәрим Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе, СССР Дәүләт премиясе, РСФСРның Станиславский исемендәге дәүләт премиясе, Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге премиясе лауреаты. Аңа Башкортстанның халык шагыйре дигән югары исем бирелде.

Аның хәрби бүләкләре — Беренче һәм Икенче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр янына әдәби казанышлары өчен алынган ике Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет Билгесе» орденнары өстәлде.

М. Кәрим КПССның сугыштан соңгы барлык съездларына да делегат булып сайланды.

ТОМАУ

Шәмсинур кодагый кич ятканда син дә мин иде. Авыз эчендә адашып йөргән догасын чак-чак кына кыймылдаган иреннәре аша тышка чыгарып бетерергә дә өлгермәде — җылы түшәктә сары май булып эреде дә куйды.

Иртән торгач, ул бик моңлы итеп өч мәртәбә төчкереп алды. Шуннан соң, самавырның суы беткәнче, тәмләп-тәмләп чәй эчте. Чәй эчкәч, борын эче кычыткандай итте. Ул янә ике мәртәбә төчкереп куйды. Үз-үзенә сәламәтлек тә теләп алды:

— Исәнлеккә-саулыкка, тазалыкка-байлыкка...

Бу иртәнге сәгатьтә шуннан артык вакыйгалар булмады.

Баллыбанат карчыкларга уймак сорарга дип кенә кергән Шәмсинур кодагый, алда күрәчәкләре барын башына да китерми әйтеп куйды лабаса:

— Томаулап торам, ахры, Баллыбанат күрше...— диде ул, сүзләрен куәтләгәндәй, нечкә генә итеп янә төчкереп алды.

Баллыбанат бу хәбәргә һич тә коелып төшмәде.

— Томауласаң, килененңнән кызу итеп мунча яктыр,— диде,— ике миндек парлат. Җаның уч төбеңә җиткәнче, шулар белән алмаш-тилмәш алып-биреп чабын. Мунчадан кайткач, картыңнан калган теге толыбыңны ябын да баллап мәтрүшкә чәй эч. Толып якаңнан гөжләп пар чыгып торсын. Бүген генә дөнья күргән кеше түгелсен лә инде. Үзең дә беләсеңдер.

Әңгәмә шуның белән тәмам да булыр иде, бәлки... Гөнаһ шомлыгына, сүзгә Баллыбанатның килене Гайшә кушылды:

— Минем каенанам консерватор ул. Җиһанга корабльләр очырган заманда мунча ташлары, каен миндекләр, мәтрүшкәләр искерде инде, кодагый. Наданлык бу! Кешегә шундый киңәшләр бирергә оялыр идең, каенанам, чак кына. Пенициллин, аспирин, амбулатория, доктор... Менә нәрсә кирәк аңа!

Чынлап та, новатор килененең сүзләреннән оялып, хурлыгына чыдый алмый, Баллыбанат икенче бүлмәгә чыгып китте. Киленгә куәт биргәндәй, кодагый тагын да нечкәрәк итеп төчкереп җибәрде.

— Әнә, минем сүземне үзең дә җөпләп торасың, кодагый,— диде новатор килен.— Сине хәзер үк медпунктка озатырга кирәк.

Гайшә урамга күз ташлады. Анда буш чанага аягүрә баскан үсмер малай Ишмырза атын юрттырып үтеп бара иде. Килен, тәрәзәгә кагып, Ишмырзаны туктатты. Ишмырза йөгереп өйгә керде.

— Өч чакрым арада атыңның алтыны коелып калмас,

Ишмырза, менә Шәмсинур кодагыйны Армакка медпунктка гына илтеп килче, салмасалар, алып ук кайт.

Ишмырза тыңламый булдыра алмады. Чөнки Гайшәнең ире Иштимер абый — бригадир. Ә Гайшә — бригадир хатыны.

Кодагыйның ике ягына ак халат кигән яшь кенә ике кыз утырып алган. Карчыкның сул култык астына градусник куйганнар, ахрысы. Уң кулы белән ул сул беләген бастырып тора. Шулай тотсам, тизрәк савыгырмын, дип уйлый ул.

Кызлар алмаш-тилмәш сорашалар:

— Ничә яшьтәсең?

— Алтмыш тугызда. Шөкер, җитмешкә дә аяк басабыз.

— Өегездә барысы да сәламәтләрме?

— Шөкер... Исәнбез. Йорт-җир төгәл. Мал-туар да исән генә кыш чыгып килә. Курмы булгач, чыга инде ул. Курмыны әйбәт бирделәр быел. Әйтер хәл юк, терлекләр көр кышлый. Бәрәннәр дә, туп кебек, тупылдап торалар. Ала сарыгыбыз быел өч бәрән китерде. Имин алай, бик имин...

Кара кыз чак кына елмаеп куя:

— Өегездә бәләкәч балалар бармы? — дип сорый ул. Шулкадәр ах итеп хәл-әхвәл сорашуларына кодагый чиктән тыш канәгать. «Нинди тәрбияле, инсафлы, белдекле балалар...» — дип уйлый ул эченнән.

— Шөкер, итәк тулы. Баласыз өйдә кот буламыни ул!.. Ике улымның сигез баласы бар. Болай шуграклар да... Ир балалар бит. Шулай да зарланыр хәлем юк, дәү әни, дип үлеп баралар. Югыйсә әнә күрше Миндиярның балалары дәү әниләрен һич кенә дә санга сукмыйлар...

— Бала чакта нинди чирләр белән чирләдегез, дәү әни?

— Телкәйләрең балдан-майдан өзелмәсен, балакаем. Бала чакларыма кадәр сораша бит, рәхмәтләр яугыры! Бала чакта мин чирләшкә булмадым. Бик теремек идем. Җиде яшьтә җеп эрләдем, тугыз яшьтә киндер суктым. Мине кияүгә дә уйнап йөргән җиремнән генә тотып бирделәр. Сөйләмә инде ул заманнарны...

Ишмырза дәшмичә бер читтә утырып тора. Тик кодагыйга үзенең дөньяда барлыгын, тышта ат көтеп торганын белдерер өчен генә йөткергәләп куя. Әмма кодагый моңа игътибар итми.

Сипкелле кыз Шәмсинур әбинең култык астындагы градусникны алып карый.

— Нинди мәкерле, астыртын чир! — дип борчыла ул.— Х.ртта температура да бирми, 36,9. Кай җирегез авыртасоң?

— Буыннарым сызларга иткәндәй тора.

Кара кыз борынын җыерып куя:

— Мондый чирне без дәвалый белмибез шул, әби. Сине район больницасына җибәрергә туры килә.

— Башка чара юк,— дип җөпли сипкелле кыз.

Шәмсинур кодагый бәхәсләшеп тормый:

— Сез әйткәннән узып булмый инде. Сез укымышлы кешеләр бит,— ди ул,— юл йөрергә хәйран әвәсмен болай үзем. Әйдә, Ишмырза, дөнья күреп кайтыйк. Кышкы сәхрә — үзе бер тамаша ул.— Шулай дип әйтеп тә өлгерде, ике алымга булеп, биш мәртәбә төчкереп тә алды. Башта өч мәртәбә төчкерде, аннан тагын икене өстәде.

Кодагый тунын киде, шәлен бөркәнде. Ишмырза, күн бияләйләрен киеп, шапылдатып, бер-берсенә сугып куйды. Янәсе: «Без теләсә кайда барырга әзербез»,— димәкче инде. Үзе кызларга карап алган була.

Кызлар кодагыйга язу язып тоттырдылар.

Армактан чыккач, юл икегә аерыла. Уңга киткән юл районга бара. Очлы тактага «12 км» дип язылган. Сулга суктырганы шәһәр юлы. Анысына «15 км» дип язылган.

Шушы юл чатында Ишмырза ала бияне шып туктатты.

— Кодагый,— диде ул,— өс-баш та ару гына, кесәдә калачлык акча да бар. Әллә шәһәрнең үзенә үк җилдерәбезме? Аермасы — нибары өч километр. Ала бия өчен чүп кенә ул. Профессорның үзенә туп-туры барып керербез.

— Шәһәрнең юлы да такыррактыр... Адәм йөрмәгән җир түгел ләбаса.

Ала бия сулга тартылды.

Врач кабул итә торган бүлмәнең ишек төбендә, култык астына градусник кыстырып, Шәмсинур кодагый һәм, ГТО значогын ялтыратып, гамьсез Ишмырза утыра. Аның бер нәрсәгә дә исе китми, янәсе. «Күрмәгән шәһәрме?»

Сестра кыз кодагыйның яшен, кай җире авыртуын, элек чирләгән чирләрен, өй эчендәгеләрнең сәламәтлеген сораша. Шәмсинур кодагый һәр сорауга бәйнә-бәйнә җавап бирә. Күрше-күләнне, нәсел-ыруны да телгә алып үтә. Балалары турында сүз кузгалгач, ул бөтенләй җәелеп китә:

— Балалар таза ул. Монау кече оныгым Әпкадыйр гына күзен бүсер белән изаланды. Әллә сөннәткә утырту

килешмәде инде үзенә. Сөннәтчеләренең дә юне китте бу заманда. Утыртмыйк тамы әллә, дигән идек тә... Анау Хәсби карчык теңкәгә тиде. Үзегезнең соң, кызым, йорт-жирегез, терлекләрегез иминме? Әти-әнием тигез гомер итәме? Үзең әле башлы-күзле булырга өлгермәгәнсеңдер? Бик матур булып буйга житкәнсең болай...

Сестра термометрны алып карый:

— 37,4. Чак кына эссегез бар, әби.

— Булыр шул. Әле юлда жил кагылгандай итте. Аркам чымырдап куйды.

Шәмсинур кодагыйны врач чакыртты. Сестра да аның белән керде. Ишмырза, ялгыз калгач, өй эченә тиз-тиз генә күз йөртеп чыкты. Әмма урыныннан кузгалмады. Шулай да сары калай савытындагы тарагын суырып алып, чәчен тарап куймый чыдамады.

Кодагый байтак торды. Башта сестра чыкты, аннан кодагый күренде. Карчыкны ишеккә кадәр доктор үзе озата килде. Доктор рус икән, ләкин башкортча да ару гына сукалый. Ишек төбендә баскан көе ул киңәшләр бирә:

— Мунча бар?

— Бар, бар. Былтыр гына салдык. Пары шартлап тора.

— Каен миндек бар?

— Бар, бар. Майда ук әзерләп куйганмын.

— Толып бар?

— Бар, бар. Картымнан менә дигән толып торып калды.

— Мәтрүшкә бар?

— Бар, бар. Сораган бер кешегә дә биреп торам.

— Бал бар?

— Бар, бар. Төшендем. Минем Баллыбанат күрше кебек зиһенле кеше икәнсең. Һай, малатчина! — Кодагый докторның аркасыннан сөеп ала.— Тымау төшсә-нитсә, үзең дә миңа хәбәр иттер. Киленемнән мунча яктыргач та, малайка жибәртермен.

Ул Ишмырзага күрсәтә. Әмма Ишмырзаның моңа хәтере кала. Нинди малай булсын ди ул сезгә?

ДИНИС ИСЛАМОВ

(1921—1973)

Динис Фәтхи улы Исламов 1921 елда Башкортстанның Чишмә районы Яңа Муса авылында туа.

Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң Уфада «Востоксталь» металлургия рабфагында һәм берьеллык укытучылар курсында белем ала.

Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан хәрби хезмәткә чакырылып, 1942 елда фронтка китә. Рота командиры, полк инженеры Д. Исламов сугышта күрсәткән батырлыклары өчен биш орден, күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

1947 елда демобилизацияләнеп, Уфага кайта һәм журналист эшенә тотына. 1953 елда аның «Беренче көн» исемле хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Моннан соңгы елларда әдипнең «Кызлар», «Еллар һәм юллар», «Гөлбәдәр юлы», «Еллар тавышы» исемле повестьлары, «Юмарт җир», «Мәскәү юлы» дигән романнары басылып чыкты.

СССР Язучылар союзына Д. Исламов 1965 елда кабул ителгән иде.

СОҢЛАГАН ҮКЕНҮ

Мин көзге урманда йөрергә яратам. Аның иң гүзәл чагы сентябрь беткәндә, октябрь башланганда була торгандыр. Бүгенге кебек, зәңгәр күктә иренеп кенә пәрәвез мамыкчалары йөзгән җылы аяз көнгә дә туры килсәң, аның төрле бизәк хәзинәсенә сокланып туя алмыйсың. Тирән тынлык. Җиргә түшәлгән йомшак алтын яфраклар аякларыңны иркәли. Ә агачлар? Ниндидер олы карагай яки имән ышыгында үзенең кызыллы-сарылы чуар киемендә купшыланып утыручы яшь чаган миңа һәрчак туена әзерләнүче кызны хәтерләтә. Чуар бизәкле яфракларга сарылган ачык кызыл җимешләре белән кызыштырып торучы миләшне әйтәсеңме. Көзге миләштән матуррак агач юктыр. Усакның усагына кадәр, карагыз, менә мин

нинди дә була алам дигән сымак, салават күперенеке кебек буяулары белән күзләрне камаштыра...

Көзге урманның гүзәллегенә күңелеңне рәхәтләндереп йөрисең-йөрисең дә, кечкенә аклан табып, аның тирән тынлыгын тыңларга утырасың. Утыра торгач, үзең дә татлы хыялга күмелеп киткәнеңне сизми каласың...

Әле кайчан гына сайрар кошлар җырына тулган, дуамал яшәргән язгы урманга соклана идек! Шул чак, телисеңме-юкмы, кавышылмаган тәүге мәхәббәт хәтергә килә. Рәхәт сызланып, ерак яшьлекнең татлы истәлекләренә күмелеп утырасың да, бу дөньяда тәүге мәхәббәт дигәннәренең кавышуга китергәне очрамый торгандыр ул, дип тирән көрсенеп, үзеңне юаткан буласың...

Әле кайчан гына күкрәүле яңгырлар юып үткән, чәчәкләр чуарлаган, биек куе үлән арасында бөҗәкләр кайнашкан саф һавалы җәйге урманда рәхәтләнә идек...

Эчтән генә тирән сагышлы ләззәтләнү белән шигырь юлларын кабатлыйсың:

Адашып калган яшьлек еллары,
Үкенер дигәннәрдер...
Күп тападык мәхәббәт юлларын —
Безне дә сөйгәннәрдер...

Әнә шулай ерак яшьлек елларым белән хыялланып утыра торгач, әле генә мине сокландырган көзге урманның ни арададыр үги ана булып китүен сизми дә калганмын. Агыйдел ягыннан салкын дуамал җил купкан. Күк гөмбәзенә соры болытлар үрмәли башлаган. Усаллаша барып, урман шаулый. Агачлардан, күз яше сымак, кызыллы-сарылы яфрак коела. Ул арада йөдәткеч вак яңгыр сибәләргә тотынды...

Мондый чакта күп уйлап торырга ярамый. Татлы хыялларым белән хушлашып, якында гына булырга тиеш олы юлны шәйләп, турыга сыпырттым. Урман эчендә ярыйсы ук ышык иде әле. Аның читеннән үк башланган, ясмага салынган бодай басуына чыккач, көзге табигать үзенең «гүзәллеген» бөтен куәтенә күрсәтергә тотынды. Җитмәсә, юка киенгәнмен. Үзәк өзгеч салкын җил куалаган әлеге вак яңгыр кирәкне бирә генә!.. Ярый әле ярты чакрым чамасы читтәрәк ялан вагоны күзгә чалынды. Башкача әмәлем юк, камыл төбенә абына-сөртенә, шунда карап чаптым. Мин аны ташландык корылмадыр, озак кына вакыт ялгызлыкта интегермен, дип уйлаган идем дә, килеп кергәч, яңгыр тамчылары юган тәрәзәгә ризасыз карашын төбәп торган мөлаем йөзле яшь хатынны күргәч, җиңелрәк булып китте.

— Кеше бар икән... Мөмкинме? Саумысез...— дип кыюсыз гына эндәшкән булдым.

Ул миңа сәер генә карап торды һәм исе китмичә:

— Мин үзем дә монда чит кешемен,— дип үзен таныттыда, юка иреннәрен кысып, тәрәзәгә төбәлде...

— Яңгыры да тапкан вакытын...— дип сукрандым мин.

Ул теләмичә генә җаваплады:

— Безнең кайсыбызгадыр бүген юл йөрергә ярамагандыр, ә яңгыр үч ала...

— Әллә тагы, мәсәлән, минем алай үч алырлык бер гаебем дә юк сымак...

Ул эндәшми калды.

Минем белән сөйләшергә аның бер дә теләге юк икәнлекне күреп, мин дә кысташмадым. Үзем дә монда кемнедер очратырмын, ләчтит сатып утырырмын, дип кермәгән идем. Бары тик яңгыры гына тизрәк туктасын...

Искерә төшкән вагон көчәя барган җилдә дер селкенә. Күңелгә шом салып, якында урман шашынып шаулый. Кинәт мине түзеп торгысыз күңелсезлек чолгап алды. Ирексездән вагон эченә күз йөртеп чыктым. Зур һәм кечкенә авыллардан еракта, җир башларына кунаклаган башка бик күп шундый ук хәйләсез корылмалардан бернәрсәсе белән дә аерылмый иде ул. Шулай да ул, мин тәүдә уйлаганча, бөтенләй ташландык булып чыкмады: бер буена, ике катлы итеп, тар гына агач сәке куелган. Анда, мазут исе бөркеп, кием-салым ята. Каршы якта кечкенә өстәл тора. Шунда ук ике утыргыч. Ишек төбенәрәк ысланган бидрә белән су куйганнар. Савыт-саба өелгән. Идәнгә калын булып басу туфрагы каткан...

Ханым элекке рәвешендә кала бирде. Тиргәшеп арыган ир белән хатын сымак, әлеге безнең хәлдә сөйләшми тору шәп нәрсә түгел, әлбәттә. Ярый әле, минем бәхеткә:

— Вәт каһәрең, кичкә кадәр яумыйрак торса, ни була инде, бүген бу басуны башкарып бетә идек бит...— дип яман тиргәнә-тиргәнә, ярыйсы ук юешләнеп өлгергән искерәк комбинезон кигән ир уртасы кеше атылып керде дә, яңгыр хөрмәтенә тагы бераз «мактау сүзләре» әйтергә дип чак авызын ачкан иде, безне күреп, шунда ук сүзне икенчегә борды.— Ят кешеләр бар икән монда!

— Саумысез, менә әле генә сез каргаган яңгыр мине дә монда куалап кертте,— дидем мин.

Әлеге яшь хатын куркынганрак, ялварулы карашы белән аңа төбәлгән иде инде.

— Ә син, Асия, нишләп килеп чыктың? — дип гаҗәпләнебрәк сорады аннан ир кеше.

Тегесенең зур соргылт күзләре тагы да киңәя төште. Ул акрын гына пышылдады:

— Менә синең яныңа килдем... Бүген синең туган көнең бит... Күчтәнәч китердем...

Ул әле ничектер зур җинаять эшләгәннән соң, шәфкать сорап, атасы алдында торучы баланы хәтерләтә иде.

Ир кешенең бер дә исе китмәде:

— Юкка мәшәкатьләнгәнсең...

— Бәлки, юккадыр да. Шулайдыр инде. Башкача булдыра алмагач, нишлим соң... Гафу ит, Шәрифҗан,— диде Асия калтырый башлаган тавыш белән.

Шәрифҗан, киресенчә, нык торды.

— Мин сиңа үткәнендә, кабат килеп йөрмә, дип әйткән идем бит,— диде, бер дә исе китмәгәнгә салышып,— син вәгъдә биргән булган идең... Сүзеңдә торырга кирәк иде. Ярый әле менә иптәш монда булып чыкты.— Ул минем якка ымлап алды.— Югыйсә, Шәрифҗан ике хатын белән тора, тегеләй дә болай, дип әллә нинди гайбәт чыгарулары мөмкин. Йөрәкләрне нигә үртәндерергә?.. Йөрәк белән шаярмыйлар, ул бала-чаганың курчак уены түгел... Кара аны, соңгысы булсын, яңгыр басылгач та, кит моннан!..

— Сөйләсәләр дә, тиргәсәләр дә, гөнаһы да, ояты да үземнеке бит! — дип ярым пышылдап, олы үкенеч тулы карашларын Шәрифҗанга текәде Асия.— Уникенче хатының булып картаерга да ризамын, бары тик намусны гомерлек җәбердән генә коткар...

— Андый ният белән булгач... Мин башкача сөйләшмәячәкмен дә! — Шәрифҗан кулын селтәде дә тынды.

Асия карашына урын таба алмыйча азапланды. Нечкә иреннәре җиңелчә кыймылдады. Шулай да авызын ачып сүз әйтә алмады. Әле аның, чая ныкышмалылык салып, күз яшьләре белән көрәшүен сизенү өчен әллә ни зирәклек кирәкми иде...

Тагын әчпошыргыч авыр тынлык урнашты. Тышта җил котырып улый да урман шаулый. Шәрифҗан һаман эндәшми, киресенчә, өстәлдә яткан ниндидер ташландык китапның катыргысын куптарып алды да тәрәзәнең ватык өлгеләрен дуамал җилдән, яңгыр тамчыларыннан ашыкмыйча гына томаларга тотынды.

Алар арасында нәрсә булган? Кавышып аерылышканнармы? Берәр сәбәп белән кавыша алмый интегәләрме? Башкача берәр нәрсәме? Нишләп әле Шәрифҗан аның белән шулай рәхимсез кылана? Болар бөтенесе дә минем өчен төнге кара урман эче кебек серле һәм караңгы иде.

Мин астыртын гына Асияне күзәтәм. Менә сиңа кирәк булса! Ни арададыр аның куе керфекләре еш-еш сирпелделәр. Шунда ук керфек очлары эре яшь тамчыларына тулышты. Ничек кенә булмасын, әле яшь, сылу бу хатын чиксез жәл булып китте. Иң иркә, ышандырырлык, өметле сүзләр белән юатасы килде. Тик ул арада Асия, очарга әзерләнгән кош сымак, чак кына талпынгалап торды да, үкереп елап, ишеккә ташланды.

— Җүләрләнмә, салкын тидерерсең, яңгыр басылганны көт! — дип кычкырып калды Шәрифҗан.

Мин аның артыннан ачык калган ишеккә күз салдым. Ул, яңгыр белән үчекләшкәндәй, хәтта көзге табигатьнең әлеге шашынуыннан да ниндидер ләззәт тапкандай, чак кына алга иелә төшеп, ашыкмыйча гына атлый бирә иде.

Шәрифҗан, үзалдына нәрсәдер мыгырдана-мыгырдана, ишеккә килеп тагын:

— Асия, борыл! — дип кычкырды.

Тегесенең кире килергә нияте юк икәнлеге күренеп тора иде. Шәрифҗан, аның горур сыны соры яңгыр чаршавында буталып бөтенләй югалганчы, еш, авыр сулап торды да, кире килеп, мазутка каешланып каткан табуреткага утырды, минем һаман басып торуымны күреп, кинәт ягымлыланып китте:

— Нәрсә басып торасыз, монда урын җитәрлек, әйдә, теләгән җирдән кунаклагыз!..— диде.

— Рәхмәт...— Мин дә ишек төбеннәнрәк сәке читенә утырдым да аптырабрак: — Бу нәрсә булып чыкты соң әле? — дип сорадым.

Ул ипле юантык гәүдәсе белән борылды да:

— Бумы? Бу, иптәш, башка бер нәрсә дә түгел, эндортериит дигән нәрсә бәласе,— диде.

Һич колакка ятмаган бу сүздән мин аптырабрак калдым. Ул арада Шәрифҗан, дөрбердәтә-шатырдата, уң аягын янында ук торган икенче буш табуреткага салды да чалбар балагын күтәреп:

— Бүген иртә белән кабалан җыенып, бичә-чәчә сымаграк җиккәнмен, тугарылып йөдәтте... Гафу итегез инде,— дип сөйләнә-сөйләнә протез каешларын тартыбрак эләктереп азапланды.

— Монысы тагы нәрсә бәласе? — дип куркыбрак сорадым мин.

— Монысы да шул ук эндортериит бәласе.

Чынлап та, колакка ятмаган бу чит сүзне мин тәүге кат ишетә идем.

— Анысы ничек була инде? — дип кызыксындым.

— Анысымы? Аның нәрсә икәнлеген гомер буенча бөтенләй белмәвең хәерле, кем, иптәш,— диде ул, йөгерек коңгырт күзләрен сизелер-сизелмәс елмайтып.— Бу дөньядагы иң әшәке чирләрнең берсен шулай дип йөртәләр. Аның нәрсә икәнлеген үз башына төшкән бәндәләр дә врачлар гына белә. Латин сүзедер. Русчасын белмим, болай үзебезчә генә әйткәндә, аяк үләте... Андый бәхетсезлекне дуска түгел, иң явыз дошманга да күрсәтмәсен!..— Ул, куе киң кашларын җимереп, һаман вак яңгыр сибәләгән тәрәзәгә караш ташлап алды да миннән: — Тартырга юкмы? — дип сорады.

— Мин тартмыйм шул.

— Кайсылай бәхетлесез,— дип куйды ул.— Мине дә врачлар ташлаткан иде... Әлеге дә баягы каһәр суккыры эндортериит эшен очлагач, яңадан башладым... Бугазда тәмәке төтене йөргәндә, җиңелрәк сызланасың кебек тоела... Бу арада безнең монда тәмәкесенә дә әллә нишләп кытлык булып китте... Бәла! — Ни арададыр аның күзләренә әле генә Асия өстәлдә калдырып киткән төенчек чагылды.— Берәр пачка папирос-фәлән китергән булса, ни әйттең иде дә бит! — дип аны үрелеп кенә алды да, итәгенә куеп, чишә башлады.

Аннан бүселдерә тутырган тавыкны, бер ярты аракыны, помидорын, алмасын бер-бер артлы алып өстәлгә куйды да, башкача нәрсә чыкмагач, үртәнебрәк чүпрәген өстәлгә ташлады.

— Юк икән шул! — Шәрифҗан көчтәнәчкә бер дә исе китмәгән кыяфәт белән карап торды да: — Бигрәк тартасы килә, менә әле булса бу нәрсәләрнең бөтенесен күз дә йоммыйча бер пачка папироска алмаштырыр идем! — дип куйды.

Анда тәмәке кайгысы. Юк нәрсәне монда яңгырлы басу уртасында кайдан табасың инде. Ә мине Асия борчый. Шулкадәр тупас сөйләшеп, аны шундый усал, салкын яңгырлы көнне моннан чыгып китәргә мәҗбүр иткән өчен Шәрифҗанга ачуым килә.

— Аңа кайтырга еракмы? — дип сорамый түзмәдем. Ул тәүдә, бер дә исе китмичә:

— Алты чакрым чамасы,— дигән булды, ә чак кына уйлап торгач: — Бик әйбәт, аны беркем дә чакырып китермәгән, йөрмәсен юкны бушка аударып!

Мин, аның тынычланганын көтеп, җайлап кына:

— Тыйнаксызлыгым өчен гафу үтенәм, шулай да кем иде ул сезгә? — дип сорадым.

Ул нәкъ мин уйлаганча җавап бирде:

— Хатыным иде, элекке хатыным.

Минем кызыксынуым арта гына төште.

— Тагы да матурракны, яшьрәкне таптыгызмы?

— Киресенчә, әй, ямьсезрәгенә, картрагына барып сгылырга туры килде...

Мин, тагы да ныграк гаҗәпләнеп, аңа карыйм.

— Миңа яшәргә кирәк иде, аңлыйсызмы, яшәргә! — дип ычкындырды ул, минем шулай төпченүемә үртәлеп, нәрсәдер исбат итәргә тырышкандай.— Ә гомер турында сүз барганда, матурлыкка да, башкасына да бөтенләй икенче төрле карыйсың. Чын матурлык кеше тәненең моторы — йөрәк матурлыгыннан башлана икән ул!.. Тышкы матурлык, кәрт уены сымак, яшьлекне ахмакландыру өчен генә шәп! Ә йөрәк — күңел матурлыгы... Ә Асиянең көче җитмәде... Минем язмышка тап булган бәхетсезлек арбасын тартышу өчен бөтенләй яраксыз булып чыкты... Хәер, анысын мондый бәхетсезлекне үз башыннан кичергән кеше генә аңлый...— Шәрифҗан, сиңа сөйләп, син нәрсә аңлыйсың да нәрсә беләсең, дигән мәгънә белән кулын селтәп, тынып калды.

Җил-давыллы бу янгыр басылганчы, ничек булса да вакытны үткәрергә кирәк. Ят кеше белән башкача сөйләшер сүзем юк, бер башлагач, әлегене сораша бирдем.

— Эндортериит диденме әле, һаман шуның бәласеме?

Аңа да ничек булса да бу янгырны үткәрергә кирәк иде бит, алай бик кызыксынгач, рәхәтләнеп тыңла, дигәндер инде. Кайсы тирәсеннән башлыйм икән дигән сымак, яссы куе кашларын салындыра биребрәк, уйлап торды да:

— Нәкъ үзе, шушы аяк үләте бугаздан алмаса, әллә минем тормыш та бөтенләй башкача агар иде,— дип сөйләп китте.— Бик яратышып, бөтен шартына китереп йөреп өйләнештек. Матур яшәп киттек. Бер ел дигәндә, үзебезгә менә дигән йорт юнәтеп, башка чыктык. Икәүләп тырыша торгач, йорт-кураны да, өй эчебезне дә курчак кебек иттек... Шулай булмаска хакы да юк. Икебез дә эшлибез... Мин эти карт юлыннан киттем. Җиденчене тутыргач та аның тракторы артына сабан тазартучы булып утырган идем, шуннан бирле менә ундүртенче ел инде, колхозда мин йөртеп, эшләтеп карамаган машина калмагандыр. Басу тузанына пычранмасам, мазут исен иснәмәсәм, эчем поша башлый... Күнегелгән. Асиянең үз һөнәре. Гөнаһына керә алмыйм, шикәр чөгендере буенча кыз чагында да аңа тиң юк иде, әле дә махы бирми. Алары булгач ни, мәхәббәтебез дә язгы сулар кебек ташып бара, куанычлары да ләйсән булып ява!.. Яңа өйләнешкәннәр табак-са-

вып кыра башласа, әнә, Шәриф белән Асиядән үрнәк алыгыз, дип үзләрен оялта торган иделәр... Әнә шулай дөнья куанычларына чумып, рәхәтләнеп яшәп ятканда гына, мә сиңа!.. Ул чакта ремонтта эшли идем әле. Уң аягымның чәнчә бармагының очы кинәт авырта башлады, түзеп кенә тор! Аякны карыйм, бармакның иң очында гына кеч-кенә кара төердән башка бер нәрсә дә юк. Шундый өтек кенә төер шул кадәр авырттыра! Пүчтәк, түзәргә кирәк, үтәргә тиеш. Бер көн түздем, ике көн түздем... Атна түздем... Инде дә рәтем калмагач, Уфага больницага киттем... Анда миңа саклык белән генә яман дөреслекне әйттеләр. Әлеге аяк үләте булып чыкты... Төрлечә кыландырып карадылар. Юк, чигенергә җыенмый явыз чир. Сыңар аяктан үз ирегем белән баш тартырга туры килде. Бая әйттем инде, андый әшәке чирне иң актык дошманга да күрсәтмәсен...— Шәрифҗан, тукталып калып, тәрәзәгә күз салып алды да: — Әнә яңгыр туктады! — дип куйды.

— Барыбер ул тезмәләрегезне хәзер суга алмыйсыз бит инде,-- дидем мин.— Шуннан?..

Ул күңелсезләнебрәк:

— Моңавы яңгыр эшне бозып куймаган булса, әкият сатып утырыр чак түгел дә бит,— дип тагы сукранып торды да, кемнедер үртәргә генә теләгәндәй, усал дәрт белән елмаеп, әлегене сөйли бирде.— Менә шунда инде минем мактаулы Асиям үзен танытты. Больницага килсә, елаудан башканы белми. Янып торган түгәрәк йөзле кеше үзе, чирләшкә сымак, как сөяккә калды. Башкаларның хатыннары килсә, минем язмышка дучар ирләрен юаталар, тынычландыралар, ә бу суга батып чыккан чебеш кыяфәте белән болай да кайгылы башка хәсрәт кенә өсти. Җитмәсә, мине һушсыз килеш операция өстәленнән палатага илткәнне күргәч, ул да егылган. Бик ачуны китергәч, куып кайтардым... Ә ул шул уңайдан төянгән дә атасы йортына кайтып киткән. Бу көе барыбер рәткә керә алмас, җиләк кебек чагымнан гомеремне заяга үткәрер хәлем юк, имеш!.. Алай икән, әнә бара юлың! Ә Шәриф, шул сатлык җанга үч итеп, ярты ел дигәндә хәтта протезда биергә өйрәнеп, тагы да чәмләнебрәк эшкә тотынды: — Шәрифҗан, тынып, көнгә уңган шакмаклы кепкасын өстәлгә ыргытты.

— Шул тәңгәлдә аралар өзелдеме? — дип сорадым мин, түземсезләнеп.

— Әнә шул тәңгәлдә араларны бөтенләй өзәргә баш җитмичә, зур хата ясадым да шул инде,— диде ул, җиңелчә көрсенеп.— Сыңар аяк белән генә дә Шәрифҗанның дөбердәтеп яшәвен күреп, өстәвенә икенчегә өйләнергә

йөрүен ишетеп, бу тагы килеп җиткән!.. Аякка егылып гафу үтенә. Нишлисең, мин, игелекле җан, вакытында бик хәтерне калдырган булса да, күндем. Үткән кылануыңны гафу итәм, онытыйк, әммā соңгысы булсын, дим... Ант итте. Гөнаһына керә алмыйм, тагы матур яшәп киттек... Үткән көзгә кадәр... Үткән көз уракны төгәлләгәч, колхоз мине курортка җибәрде. Кара диңгез буенда көньяк коя-шының шифалы нурлары астында кызынып, рәхәтләнеп ял итеп яткан җирдән кинәт икенче аякның да чәнчә бар-магының очына әлеге каһәрле төер калкып чыкты... Та-ныш нәрсә! Шул ук җан өшеткеч авыртуы белән... Аяксыз калу гына әҗәл түгел бит әле. Тәҗрибә бар... Хирурглар карамагына ятар алдыннан, зиһенне тынычландыру өчен, төн буена Павел Корчагин дус белән киңәшләшеп чыктым да, аллага тапшырдык, дим... Шулай итеп, өч ай дигәндә, икенче аяктан да язып кайтып кердем...

— Үтә кыен язмыш сагалаган икән үзегезне! — дип сүз ташладым мин.

— Әҗәл бугазыңа ябышкач, ул турыда әллә ни уй-лап тормыйсың, башыңа төшсә, чыдам булырга өйрәнә-сең икән.— Ул теремек күзләрен кыса биребрәк, нәрсәдер хәтерләп торды да сөйли бирде.— Иң кыены кайтып кер-гәч башланды. Ярый, анысы соңыннан... Бу тәңгәлдә чак кына чигенү ясап алмасам, аңлап җитмәссез. Аннан мине поликлиниканың сестрасы Мария Ивановна озата килде. Әйтер хәл юк, авылдашлар да, туган-тумача да, станция-гә үк чыгып, шәп каршылады. Колхоз председателе үзе дә «Волга»сына утырып килеп җиткән. Әйтерсең космос каһарманын каршылыйлар. Асия дә килгән булган икән. Тик шунда ук үзен сынатты. Мине носилкага салып ва-гоннан чыгарганны күргәч тә, кычкырып бузларга тотынды, агаем, мин сезгә әйтим, чыдап кына тор! Мәйтәм, ха-тын, йортка кайткач та анысына өлгерерсең, тик монда ха-лык җыймыйк. Мария Ивановна да, башкалар да ипләп тә, тиргәп тә әйтеп карыйлар. Юк, әй, көйсез баладай ярсый гына бара. Ул сөйләгәне... Эт ашамас... Шул инде, мондый бәхетсезлек күрердән булгач, нигә тудык та нигә яшибез икән!.. Тегеләй дә болай. Ул сөйләгәнне чынга ал-саң, дөньясында бер минут яшисе килмәс... Ярый, өйгә кайтып төштек бит инде. Каршылау мажарасы бетте. Кичен өчәүдән-өчәү генә торып калдык. Мария Ивановна-ны үзем үтендем. Мәйтәм, күреп торасыз, хатын яңа об-становкага күнегә төшкәнче, ике-өч көнгә генә булса да, зинһар, калыгыз инде. Күнде. Мемә аны кеше дисәң дә ярый. Хәер, дөньяның ачысын-төчесен татып үскән шул

Нужа дарьясында баштан ашу йөзгән. Ун яше тулар-тулмастан япа-ялгызы торып калган. Әтисе сугыш яланында хәбәрсез югалган. Әнкәсен фашист танкысы сытып киткән. Барыбер бирешмәгән. Үскән, кеше булган. Тик бер тискәрегә китсә, китә бирә бит ул. Бик яратып кияүгә чыккан булган. Ире, ничектер, эчкелеккә салышып, аракыдан янып үлгән. Ике бала белән торып калган. Менә дигән ике малай үстерә... Менә аны игелекле җан дисәң дә ярый. Больницада минем иң кыен мәлемдә төннәр буена янымда күз дә йоммыйча чыга иде. Ә иртә таңнан балаларын ашатып, укырга озатырга фатирына чаба. Кечкенә йомшак куллары белән сөеп, ике-өч җылы сүз әйтсә дә, чиксез рәхәт булып китә. Бердәнбер көнне бу, кайдандыр безнең башкорт моңнарын табып, патефон күтәреп килгән. Хисмәтуллин агаем «Урал», «Азамат» көйләрен сузып җибәргән иде, күздән яшьләр килде. Туган якларның язгы ташулары, сандугачлы таңнары, басулар исе, башка хәзинәсе күз алдыма килеп, җанымны өзгәли башлады, очып кайтасы килә! Өстәвенә, китап... Әйбәт китап — җан азыгы, дип белмичә әйтмәгәннәр икән ул. Бер кичне Мария Ивановна Джек Лондонны укыды. Исемен хәтерләмим. Анда берәү юлдашының хыянәтчел куркаклыгы аркасында мең әҗәл тырнагына эләгеп тә исән кала. Усал язган...— Шәрифҗан башын чайкап куйды.— Чак кына куркыныч, ә шулай да үлем бөтенләй котылгысыз булып күренгәндә дә, бәндә үзенә җеназа укый башламый, бөтен зиһенен җигеп, көчен салып, аңа каршы көрәшә һәм җиңеп чыга. Үземнең бәхетсезлекне шулкадәр зурлаганым өчен оят булып китте...

Сөйләгән арада Шәрифҗан тәрәзәгә торган саен еш-рак күз салгалый башлады. Ул сөйләп бетермичә чыгып китәр, дип курыкканмындыр инде, түземсезләнеп:

— Иң кызыгына җиттек булса кирәк,— дип сүз куштым.

— Кызыгы-фәләне өстендә инде,— диде ул, көрсенүле елмаеп.— Әнә шул кайтып кергән төнне бөтенесе дә ахыргача хәл ителде дә. Мария Ивановнаны түр якка түшәккә салдык. Мин алгы якта, җылыгарак, мич янындагы сәндерәгә кунакладым. Дөресрәге, шунда күтәреп салдылар. Хатын үзенә шунда ук минем аяк очыннан идәнгә урын җәйде. Берчак йокы аралаш хатынның һаман акрын гына шыңшып ятуын ишетәм бит. Йөрәгем жу итеп китте. Җитмәсә, болай да аруның соңгы чигенә җиткән зиһенгә шом өстәп, тышта буран купкан. Кинәт җанымны яман эчпошу чолгап алды. Син елаудан туктый беләсен-

ме, дип каты гына эндәштем тегеңә. Куркам, ди. Нәрсәдән куркасың, минем гариплектәнме, дим. Эндәшми, һаман шыңшый гына. Нәрсә, әллә гомерлек имгәк булыр, дип хәвефләнәсеңме, димен. Эндәшми. Мәйтәм, алай икән, көчлек юк, Асия, әнә бара юлың, мин синнән башка да әрәм булмам. Шулай диюем булды, бу тагы ярсып еларга тотынды. Мине дә вөҗдан газабы сызландыра башлады. Мәйтәм, әллә аныкы дөрестер. Әллә ул дөрес юрыйдыр, әрәмгә икмәк черетеп гомер туздырырга калса, шул уңайдан әллә үземә кул салыйммы, дип тә уйлыйм. Күз яшьләре буа. Шулчак түр бүлмәдә Мария Ивановнаның да йоклап ятуы кинәт хәтергә килмәсә, белмим, бу төн ничек бетәр иде. Яман кычкырып җибәрдем. Аны ярдәмгә чакырдым. Ул яныма килеп, тәнемдә аның ышанычлы иркә кулларын тойгач кына бераз тынычландым. Шул чакта минем башка, чынлап та, иң гадел фикер килде. Хәзер минем өчен аннан да кирәгрәк кеше юк икәнлеген аңладым. Иртәгесен хатынны җай гына искәрттем, мәйтәм, гаепләштән булмасын, Асия, болайга киткәч, син йә үзеңне, йә мине, йә икебезне дә гүргә кертәсең, яхшы чакта әйберләреңне төя дә әүвәлгечә этиең өенә тай! Ул, шуны гына көткәндәй, бер каршы сүз әйтсә, гафу үтенергә дә онытып, китек кашыгына кадәр үзенә тиешен төяпеп, аерылып кайтып китте. Мария Ивановна тагы өч көн торды. Озак, ачыктан-ачык сөйләштек. Киңәш биргән була. Син көчле, нык кеше, тиздән аякка басарсың, бары тик акыллы, матур күңелле хатынга өйләнергә кирәк, ди. Мин, күзләрем мөлдерәтеп, аңа текәлдем. Мәйтәм, бөтен өметем, ышанычым сездә! Мин синең өчен чак кына картыракмын, ди ул! Үзенең бөтен йөзе кинәт әллә ничек тимгелле-тимгелле кызарып, кабынып китте. Мин, яшәү белән үлем арасында тыпырчынганда яшь тикшермиләр, дидем булса кирәк. Мин ямьсезрәкмен, ди. Минем хәлдәге гарипкә бөтенесеннән дә элек, үзегез әйтмешли, күңел матурлыгы кирәк, миңа калса, бу дөньяда сездән дә матуррак күңелле кеше юктыр!.. Ул балалары турында хәтерләде. Мин этиләре булырга ант иттем. Ул өзеп җавап бирмәде. Үземә дә ныклап уйларга, дус-ишләр, таныш-белешләрем белән киңәшләшергә кушты. Чынлап та, миннән башка кыенга килсә, телеграмма җибәрерсең, диде.— Шәрифҗан, сөйләүдән туктап, тагы нәрсәсен әйтим икән дигән сымак, чак кына уйлап торды да, очларга вакыттыр дигән мәгънә аңлатып, ашыгып сүзен тәмамлады.— Менә дөбердәтеп яшәп ятабыз... Балалар үстерәбез... Үземне күреп торасыз, хәзер шап-шактыймын. Сыңар аяк белән генә дә яшәргә

бер өйрәнеп алгач, икәүсе булмаса да, ул кадәр кыен түгел икән ул!..

— Сабак булырлык вакыйга,— дип куйдым мин, аңа сокланулы караш ташлап.

Ул җавап бирмәде, тәрәзәгә төбәлеп торды да:

— Әнә, эшне бозып өлгергәч, көне дә аязыта, нигәдер минем Мариянең дә юлы төшкән,— дип куйды.

Мин дә тәрәзәгә үрелдем. Чынлап та, түбәнәя баручы көзге ерак кояшның алҗыган кылый нурлары, ашыгып җилдерүче соры болыт ертыкларын кысрыклап, яңгыр тамчылары кунган камыл төбен, тезмә тасмаларын, сарылы-кызыллы урман өстен көчсез генә иркәли иде инде... Әнә, басу уртасында тукталып калган күшеккән комбайн ягыннан болайга таба юантыграк гәүдәле хатын атлый. Шәрифҗанның Марияседер инде...

Ул арада Шәрифҗан, алюмин кружкага аракы салып, миңа сузды!

— Сөйләндереп соңлата яздыгыз, әйдә, күтәрегез!

Мин, тыйнаклык саклап, баш тарткан булдым. Ул шунда ук тавыктан өлеш тә ботарлап минем алга куйды да, ашыктырып:

— Күчтәнәчтән авыз итмәскә ярамый, кеше китергәч, чыгарып ташлап булмый бит,— диде.— Тизрәк кыландырыйк, Мария килеп җиткәнче, эзе-юлы калмасын.— Миннән соң үзе дә эчеп, тавык итеп капкалады да калганын ашыгып җыештыра башлады. Үзе сөйләнә: — Шулай да Маша күрмәсен әле,— ди,— ул дөресен белсә дә, бер сүз әйтмәс. Күп дигәндә, минем иремне алай аракы белән дә, тавык ите белән сыйларга акылы җиткәч, рәхмәт инде, дип көлемсерәп кенә куяр. Ә күңел дигәннең астыртын гына рәнҗүе бар бит. Анысы да булмасын... Мин аңа адәм баласының иң кыйммәтле байлыгы — гомерем өчен бурычлымын. Бурычка чумгансың икән, аны намус белән түли белергә дә кирәк.— Шәрифҗан, күчтәнәчне төенләп, ерак почмактагы аскы сәкедәге кием-салым арасына тыкты. Үзе хәзер инде җайлап кына тагы Асияне тетә башлады: — Кара әле син аны, башкача булдыра алмагач, хәзер күчтәнәч ташып, үзенә каратмакчы була. Исем китте, ди!.. Синнән башка тора алмыйм, имеш! Аны тәүдәрәк уйлыйлар. Зиһене буталган, имеш! Беләбез!.. Шәрифҗанның яңадан кеше рәтенә керүенә ул чакны ышанычың буталган иде синең! Ә без аның киресен исбат иттек! Бөтенләй бушка күңелне уртәп, оелмим, нигә йөри торгандыр?!

— Ә сез аның шундый кыланышларына бөтенләй игътибар итмәгез,— дип киңәш биргән булдым мин.

— Бик итмәс идем дә, менә монда нәрсәдер юк-юк та тырнап куя бит! — Шәрифҗан йөрәк тәнгәленә күрсәтеп алды.

Мин аңламаганга салыштым:

— Нәрсә соң ул?

— Әллә тагы...— дип сөйләнде ул, җиңелчә моңсуланып,— анысы безнең ир-ат халкына буыннан-буынга, гомер бакыена тагылган мәңгелек җырдыр инде. Ни генә әйтмә, тәүге мәхәббәт!.. Тик сез әллә ниләр уйлый күрмәгез. Анысы менә әлегедәй эш юкта тел азыгы гына...— Аяк тавышлары ишетеп, Шәрифҗан ишеккә төбәлде.

Киң маңгайлы, аксыл зәңгәр күз тирәләрен вак сырлар телгәләгән йончыган озынча йөзле, чак кына моңсурак карашлы, олыга тартымлана башлаган хатын кояш нурлары нуртеп килеп керде дә, ягымлы елмаеп:

— Әнә ул кая кереп чумган, мин аны комбайн яныннан эзлим тагы!..— дип эндәште.— Ят кеше дә бар икән... Саумысыз?

Без исәнләшкән арада, Шәрифҗан аннан гаҗәпләнебрәк:

— Шундый яңгырда нишләп йөрисең? — дип сорады.

Тегесе юешләнә төшкән сырма кесәсеннән «Беломор» пачкасы чыгарып сузды:

— Менә, сиңа тартырга китердем. Тәтәтереңә беткәндер, йә ачудан комбайның өзгәләп ташлар, дип курыктым!..

Шәрифҗанның кырлар җиле, җәй кояшы карайткан тузанлы йөзе шунда ук ачылып китте.

— Әйбәт булган! — дип Шәрифҗан, сөйгән кызының кулларына тәүге кат үрелүче егет сымак, кадер һәм саклык белән бер папиросны чыгарып, тәмләп көйрәтә башлаган иде инде... Үзенең бөтен йөзе канәгать елмая. Моны күреп, хатынының да төпкә баткан зур күзләре әйтеп аңлата алмаслык изгелек белән балкый.

Озакламый Шәрифҗан белән без аны озата чыктык. Яңгырдан соң җил-давыл басыла төшкән. Ярыйсы ук салкынайткан. Җир өстенә авыр куе дым сылашкан...

— Их, быелгы яңгырларның чиреген генә булса да запаска калдырып торасы иде!..— дип сукранып алды Шәрифҗан.

Мария Ивановнаның үз хәстәре:

— Өченче атнага китте бит инде, киемең керләнгән-

дер, мунча рәхәтен дә сагынып беткәнсендер... Кайчан кайтасың? — дип сорады аннан шыпырт кына.

Шәрифҗан, гадәтенчә, кычкырыбрак сөйләште:

— Соңгы тезмәләргә тотындык,— диде, аны аркасыннан җиңелчә генә сөеп,— монавы яңгыр дошманлашмаса, әллә иртәдән соңга очлап та куярбыз. Күбесенә түзгәнне, азына калгач, бирешмик инде...

— Йончыбрак киттең,— диде тегесе.

Ире кояшка күз салып алды да:

— Көн кичегүгә бара, кайт инде,— дип аны кыстый башлады,— балалар да көтәдер, менә уракны очлагач, ныгынырбыз...

Мария Ивановна ерагая төшкәнче Шәрифҗан аны сокланулы карашлары белән озатып торды да:

— Биш айлык авыры бар, йорт эше дә җитәрлек, медпунктка дежурга да йөри,— дип тезеп китте.— Папирос район үзәгендә генә бар дигән иделәр, иренеп тормаган бит, папирос өчен дә күпме җир йөреп кайткан!..

— Малай көтәсезме?

— Алай малайга, кызга аерып торырга ният юк,— дип сөйләнде ул, күзләрен уйнатып,— иң кызыгы — дөньяга үземнең бала туа!.. Югыйсә, Асия, мин больницада әҗәл белән сугышып ятканда, авырын төшерткән... Ятим бала тотып, тол калудан курыккан. Мария андый түгел. Табыйм, Шәриф, картайганда юанырга уртак балабыз да булсын, дип үзе үк куанып тора. Сукырның теләгәне ике күз дигәндәй, бу тәңгәлдә мин үзем дә бик хәвефләнә идем, ничегрәк аңлатыйм икән, дип аптырабрак йөргәндә, ул үзе ярдәмгә килде. Шундый сизгер җанлы кеше инде!

Яңгыр котырганда бушап калган бодай басуы тагын җанлана башлаган иде инде. Җирнең аргы башындагы комбайн янына йөк машинасы килеп җитте. Бункерын бушаткач, комбайн зур юлга карап кузгалды. Ул арада бу якка табан җилдерүче җайдак күренде.

— Минем күрше кая юл тота тагы? — дип үзалдына сөйләнде Шәрифҗан.— Әнә, бригадир да монда килә. Мөгаен, Торналар басуында яңгыр булмагандыр, шунда күченәбездер. Быел шулай бит, яңгыр безне үчекли, ә без аны алдыйбыз...— Ул, күрүемчә, махсус эшләнгән киң авыр итекләре белән, күпереп торган юеш җирдә тирән эзләр калдырып, атлыга каршы атлады.

Көне дә кичегеп бара. Мондый җил-давыллы яңгырдан соң көзге урманның да кызыгы бетте. Миңа да калага кайту турында хәстәрләргә бик вакыт иде. Шәрифҗанга иярдем. Әлеге изрәгән, кабарынкы туфракны ерып ат-

лавы аңа үтә кыен икәнлеге күренеп тора. Сулышы ешая төште, нык тырышудан чигә тамырлары бүртеп чыкты. Мин аңа караганда җиңел атлыйм. Оялып киттем. Үземне аның хәлен аңлаган кеше итеп күрсәтергә тырышам:

— Таяк та алмагансыз бит!..

— Билгеле, таяк белән җиңелрәк атлана,— диде ул миңа борылыбрак,— юрамал алмыйм, үземне этлеккә өйрәтергә теләмим. Култык таякларына салышсаң, тагы да җиңелрәк. Аннан соң гариплар арбасына утырырга да бер адым гына кала... Алай җиңелдән-җиңелгә күчә башласаң, эчкелеккә салышып, тимер юл буенда хәер сорашып йөрер хәлгә барып җиткәнеңне сизми дә калырсың. Юк, тезгенне нык тотабыз әле!..

Шәрифҗан дөрес юраган икән. Бригадир дигәне (яңарак солдаттан кайткандыр, ахрысы), ярым хәрби киемдәге егет, килеп җитте дә аңа:

— Агаем, Торналар яланында бер тамчы да яумаган, кыенсынмасагыз, шунда күчәргә кирәк...— диде.

— Әнә, минем күрше шунда сыпырта түгелме соң, нишләп мин кыенсынып торырга тиешмен әле? — дип сорады Шәрифҗан, җитдиләнеп.

Бригадир җайлап кына аңлата башлады:

— Ярдәмчегез дә һаман эшкә чыга алмый, чирләп азаплана. Бер кешегә генә таза көенә дә бик кыенга...

Шәрифҗан аны ачуланып бүлдерде:

— Нәрсә тагы син, бригадир, минем аякларны китереп кыстырасың әле?! Йөгерешергә түгел бит!.. Их, егетләр, ничә тапкыр мин сезне искәрткәнем бар: җыелыш-фәлән булса да, берәрсен тиргәсәләр дә — тотыналар... Менә Шәрифҗан ике аяксыз көе... тегеләй дә болай... Ташлагыз әле шул гадәтегезне!.. Башкаларга ни — миңа да шул...— Ул минем белән ымлашып кына хушлашты да, һаман шулай сукранып сөйләнә-сөйләнә, комбайнына таба китте.

Бригадир чак кына аптырабрак торды да, аны куып җитеп, атыннан төште, нәрсәдер үзенекен исбат итәргә тырышып, янынннан бара башлады.

Мин, тиз генә кузгалып китә алмыйча, аның җиргә нык-нык басып баруына, чатанлавы уңаена селкенүче киң аркасына озак кына карап тордым. Ярыйсы ук матур килеп чыга. Үзем уйлыйм: ә бөтен әгъзалары исән-сау булып та, гомер юлын килделе-киттеле атлап үткән кешеләр дә азмыни бу дөньяда!

ЯРУЛЛА ВӘЛИЕВ

(1921—1985)

Ярулла Носратулла улы Вәлиев 1921 елда Башкортстанның Нуриман районы Бикмырза авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа.

Җидееллык мәктәпне тәмамлап, укуын Уфада рабфакта һәм укытучылар белемен арттыру институты курсында дәвам итә. Бернича ел халык мәгарифе өлкәсендә эшли, 1942 елда партия сафына кабул ителгәннән соң, район матбугаты һәм партия органнарына җибәрелә, ә 1947 елдан башлап озак вакыт республика газета-журнал редакцияләрендә эшли.

Читтән торып педагогия институтында укый һәм 1957 елда КПССның Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый.

1963 елда аның «Үз кеше» дигән шаян һәм сатирик хикәяләр җыентыгы басылып чыга. Әдип шулай ук «Хәерле иртә, Исмәгыйль!», «Көчле кошчык син, сыерчык!», «Гомер дәвам итә» дигән повестьлар һәм «Бөркетләр оя ташламый» исемле роман авторы. 1966 елдан — СССР Язучылар союзы члены иде.

ГОМЕР ДӘВАМ ИТӘ

Таң бөркегән күкшел яктылык тәрәзәләргә сирпелү белән, Гайникамал әби, ашыгыч эше бар шикелле, кинәт торып утырды. Нәрсәдер эзләгәндәй, өй эченә күз йөгертеп алды. Рәхиләнең кроватьта изрәп йоклап ятуын күргәч, йөзенә борчылу билгесе чыкты. Урыныннан җәһәт кенә төшеп, килене янына килде. Кипкән балык сымак каты кулы белән аның аркасыннан сөеп, уятырга тотынды:

— Торчы, килен, тор! Соңлап киткәнбез ләбаса, балам.

— Иртә бит әле,— дип мыгырданды Рәхилә, йокы аралаш. Әмма Гайникамал әби һаман үзенекен сөйләде:

— Кайсылай иртә булсын, ди? Соңлаганбыз, дим дә.

Рәхилә тәмам уянды. Каенанасының борчулы йөзен күреп, аптырап калды.

— Кайда, нәрсәгә ашыгабыз соң, каенам?

— Сөйләдең син дә сүз! Кунак көткән кеше һаман йоклап ятадыр шул.

— Нинди кунак ул?!

— Бәй... Уянып җитмисең, ахры. Газизуллам кайта лабаса бүген! — Гайникамал әбинең җыерчыклар белән капланган йөзе ачыла төште.— Тор да казан аса башла. Коймагыңны изеп куй. Озакламаслар инде, ходай кушса.

Каенанасының гаҗәп кыланышларына күнегеп бетсә дә, Рәхилә сәерсенеп куйды. «Төш-мазар күргәндер инде, бахыр»,— дип уйлады. Авыр итеп көрсенде. Әмма сүз куертып тормады. Йокысы качкан иде инде. Өстеннән юрганын сыпырып ташлады да киенергә тотынды.

Моны күреп, Гайникамал әби бик канәгать төс белән сәкегә менеп китте. Стена буйлап элгән ситсы пәрдәне почмакка табан шудырды. Анда ирләр пальтосы элүле тора иде. Карчык, бая киленен сөйгән кебек итеп, саклык белән генә аның иңбашыннан берничә мәртәбә сыйпап алды. Аннары, кемнеңдер күкрәгенә сыенганга охшатып, пальтога башын салды. Үрелеп якасын үпте.

— Кара әле, килен, кысыграк булмас микән пальтосы? Анысы, яшь кеше дә ул, тик барыбер калыная төшкәндер, дим. Киңәйтебрәк, тектереп куймадык шунда.

Кашаяк тирәсендә уралган Рәхилә каенанасына текәлебрәк карады һәм хәйран калды: Гайникамал әбинең йөзендә әйтеп аңлата алмаслык гаҗәеп нур уйный иде. Битендәге җыерчыклары да языла төшкән хәтта. Иреннәреннән елмаю китми. Нәрсә кичерә, нәрсә көтә ул? Рәхилә ни дип уйларга да белмәде.

— Юк, каенам, таман гына булыр,— диде ул, карчыкның кәефен бозарга теләмичә. Гайникамал әби, килененең җавабыннан кинәнеп, балаларча беркатлылык белән куанды:

— Менә рәхмәт төшкере! Шулай гына булсын инде, ходаем!

Кулына бәйләмен алып, тәрәзә төбенә килеп утырды. Ләкин бер-ике генә күз бәйләде дә эшен читкә куйды. Ике терсәге белән тәрәзә төбенә таянып, тышка төбәлде.

Тора-бара урамны шундый ихлас күзәтергә тотынды, бәйләмен бөтенләй онытты.

Оек энәләре урындыкка сибелде, ә йомгагын, идәнгә сөйрәп төшереп, песи баласы уйнатырга тотынды.

Тышка төбәлгән Гайникамал әбинең күзләре. Ә анда, елмаеп, офыктан мөлаем кояш күтәрелә иде. Аның иркә нурлары, тәңкә-тәңкә кар бөртекләренә кунып, алсу яшькелт төскә кереп уйный. Тирә-юнь елның шушы мизгелендә генә була торган үзенә күрә бер күркәмлеккә төренгән. Әмма табигатьнең бу матурлыгын күрми Гайникамал әби. Басу капкасына һәм аннан бормаланып тауга үрмәләгән олы юлга гына төбәлгән аның күзләре. Арба тәгәрмәче тәгәриме аннан, чана табаны шуамы — барыбер...

Гайникамал әби, урыныннан калкына биреп, талпынып куйды. Рәхиләгә таба борылды:

— Кара әле, килен, анавы килгән Газизулла түгелме? Аркасында биштәре дә бар бугай. Бире табан уңайлый шикелле.

Рәхилә бу сорауга күнеккән инде. Шулай да ул каенасының соравын җавапсыз калдырмады:

— Юк, каенам, ул түгел шул,— диде, карамый гына.

— Ай, хәерсез, өметләнеп үк беткән идем тагы да.— Карчыкның йөзенә борчылу сөреме чыкты. Әмма тиз таралды. Шунда ук, тагы күңелләләнеп, үзен-үзе юатты:— Йә, күп көткәнне азын көтәрбез инде. Кайтам дигәч, кайтмый калмас!

...Сигезенче дистәсен куа инде Гайникамал әби. Аның соңгы егерме елын менә шулай тәрәзә янагына сөялеп утырып үткәрә. Иртә таңнан торып утыра да, кичке эңгер төшкәнче, тыштан күзен алмый. Улын көтеп утыра ул.

Әйе, Газизулласын, бердәнберен көтә. Ирен — колхоз басуында беренче буразна сызган, колхозның беренче председателе, коммун Гыйзулланы — көзге караңгы төннәрнең берсендә кулаклар тәрәзә аша атып киттеләр. Газизулла ун яшендә атасыз калды. Гайникамал бөтен мәхәббәтен, йөрәк җылысын улына бирде. Атасы кебек үк шат табигатьле, әдәпле һәм итагатьле булып үсте Газизулла. Аңа кәләш алып, куанышып кына гомер итә башлаганда, сугыш гарасаты купты. Газизулла шул көнне үк китеп барды. Гайникамал әби, менә-менә кайтып килер дип, көтә дә көтә улын. Бик озакка сузылды ул көтү. Ел ярым да, унбиш ел да, егерме ел да үтте. Газизулла кайтмады.

Шул дәһшәтле көзне солдатның улы туды. Бөтен кайгысын онытып шатланган Гайникамал:

— Гыйзулла дип исем кушыйк, килен. Картәтисе кебек олы йөрәкле булыр,— диде. Рәхилә риза булды. Газизулланың да теләге шундый иде.

Гыйзулла бер айлык булганда, атасыннан өч почмаклы хат килде.

«Каты сугышлар бара,— дип язган иде Газизулла.— Көн-төн ут эчендәбез. Чигенер урын юк, артта — Мәскәү. Төрле хәл булуы бар. Берүк улымны саклагыз. Шагыйрь әйтмешли:

Үзем үлсәм, улым калыр,
Урынымны алыр,
Солдат булыр килер көрәштә».

Шуннан хат-хәбәр тукталды. Озакламый кара кәгазь килеп төште:

«Газизулла Галиев хәбәрсез югалды...»

Егерме бер яшендә тол калган сылу Рәхилә, сыны катып, урындыкка егылды. Гайникамал әби тавыш-тынсыз гына калтыранып яткан килененең аркасына кулын салды.

— Нигә өзгәләнәсең, балам? — диде, тыныч булырга тырышып. Ә үзе, өстенә ябырылган хәсрәт авырлыгыннан бөгелмәскә тырышып, канатканчы аскы иренен тешләде.— Сыкрама! Күңелем сизә, исән-сау ул. Шундый чая егет, шундый батыр хәбәрсез югала димә?! Хас дошманның башына җиткәч тә, кайтып керер. Сине сагынып, улын, мине сагынып кайтып җитәр. Көтик! Аннан соң, васыятен онытмыйк Газизулламның: «Елап, күз нурыгызны корытмагыз»,— дип язган иде бит.

Кайгы уртаклашырга, юатырга дип кергән күрше-күләнне дә коры гына борып чыгарды:

— Буш сүз! Батыр югалмый ул! — Бәгъре ничек кенә телгәләнмәсен, үзәге ничек кенә өзелмәсен, тешен кысып түзде ана. Берәү дә күрмәде аның күз яшьләрен. Төннәрен генә баш астындагы мендәр лычма су була торган иде...

Каенанасын Рәхилә тәүдә аңлый алмый азапланды. Аңа карап, азактан үзе дә иренең исән-имин йөрүенә ишанды. «Хат-хәбәре юк икән,— дип үзен-үзе ышандырырга тырышты ул,— һич тә гаҗәп түгел. Сугышта нинди генә хәлләр булмас. Ихтимал, партизаннарда йөридер». Шуңа күрә Рәхилә, әнкәсе чакырса да, каенана йортын ташламады. Гайникамал әби аңа үз әнкәсе кебек якын булып китте. Көтте Рәхилә. Өзелеп көтте.

Газизулла кайтмады.

Тын гына, тавышсыз гына агып яткан сулар кебек, сиздерми генә вакыт үтә торды. Еллар, календарь битләре шикелле, бер-берсен алмаштырды. Ниһаять, көтеп алынган җиңү язы килде.

Озакламый, төркемләп-төркемләп, сугышның утын-суын кичкән батырлар кайта башлады. Авылда бөтен җан иясе — яше-карты, бала-чагасы аларны каршылау өчен басу капкасы төбенә җыела. Гайникамал әби белән Рәхилә дә шунда чыга. Каенана белән килен, кадерлеләрен эссе күкрәкләренә кыскан аналарның, хатыннарның, балаларның бәхетенә ымсынып, бер читтәрәк ятимсерәп басып торалар. Халык шаулап-гөрләп тарала башлагач, авыр уйлардан кургаштай авырайган башларын иеп, сүзсез-өнсез генә кайтып китәләр. Телдәр Гыйзулла гына тынгы бирми:

— Әнкәй, картинәй, минем әтием нигә кайтмый?!

— Кайтыр, бәпечем, кайтыр, сабыр ит,— дип юата Гайникамал әби.

Шулай яз үтте, җәйне озатып, көз килде. Тормыш, акрынлап, үзенең гадәттәге эзенә төште. Кешеләр дөнья мәшәкатьләре, хуҗалык хәсрәте белән мәшгуль булып китте. Гайникамал әбинең генә йөрәк ярасын төзәтерлек, аны улын югалту белән килештерерлек көч, дәва юк иде. Ул һаман да, онытын иартеп, басу капкасы төбенә чыгып утыра. Туптый җигәрле булып үсеп килгән Гыйзулла үләндә аунап йөри. Ана басу юлын күзәтә... Улын көтә...

Газизулла кайтмады.

Көз, соңлап калырмын дип курыккан шикелле, ашыгып килде. Кинәт чыраен сытты, күк йөзен болытлар белән каплады, йончыткыч вак яңгырлар сибәләргә тотынды. Яңгыр бер көн, ике көн, бер атна барды. Азак килеп, хәлсезләнеп туктады. Җир тетрәтеп, соңгы тапкыр күк күкрәде, яшен яшьнәп үтте. Ул әйтерсең күк йөзен урталай ярып җибәрде. Аның бер ягында ерткаланган тонык болытлар торып калды. Икенче ягыннан зур һәм якты кояш чыкты. Җир өсте иркен сулап алды. Һавага урмәкүч оясы күтәрелде.

Әбиләр чуагы башлана иде...

Гайникамал әби тагы басу капкасы төбенә чыгып утырды. Басу юлын, Газизулланы бик-бик еракка, дәһшәтле яу кырына алып киткән юлны, кояш нурга күмгән иде. Сул кулын күкрәгенә куеп, уң кулы белән иягенә таянып, Гайникамал әби шушы хозурлыкны күзәтеп утырды. Озак утырды. Кузгалмый, бер ноктадан күзен алмый утырды. Мәрмәр таштан катырылган сынны хәтерләтә иде ул.

Кояш, төшлектән авышып, тау битләвенә уңайлады.

Гайникамал әби, йокыдан уянгандай, сискәнеп куйды. Башын күтәрде. Кояш нурлары юлга туры төшми иде. Алар тау битләвендә уйныйлар, анда ялгыз кабер өстендәге йолдызга чагылып җемелдиләр. Гайникамал әби урыныннан сикереп торды һәм бөтен көченә шул кабергә карап йөгерде. Сөренте җир аның аякларын үзенә тартты, тау буендагы түмгәкләр юлын бүлде, агач куаклары битен сыдырды. Ул егылды, тагы торды. Тагы йөгерде, тагы егылды. Үзе әйтерсең боларның берсен дә сизми иде. Арыпалҗып, хәлдән таеп, ул кабер рәшәткәсе янына килеп ауды. Шул мәлдә аның күзләреннән эссе һәм ачы яшьләр түгелде. Дүрт ел буена җыелып килгән яшьләр, бер юл яргач, тукталырга теләмәгән кебек, актылар да актылар.

— Нигә үз яныңа алмыйсың мине, Гыйзулла? — дип сорады Гайникамал әби, елап арыгач.— Шушы урында, колхоз җирендә тәүге буразнаны салганда, «бу — безнең бәхет ызаны», дигән идең. Кайда соң ул миңа тигән бәхет? Үзең шунда кабер таптың. Улыбыз Газизулла әллә кайда ят җирләрдә ятып калды. Ал мине үз яныңа! Монавы ялгыз каен кебек ялгыз бит мин хәзер!

Гайникамал әби, тәмам арып, тынып калды. Шулчак ул ниндидер бер тавыш ишеткәндәй булды:

— Ялгышасың, әнкәсе! Бәләкәй Гыйзулла бар бит әле.

Кайдан килгәндер бу тавыш: аны кемдер әйттеме, әллә инде Гайникамал әбинең үз йөрәгеннән чыктымы — анысын әйтүе кыен. Ул, торып, тураеп басты. Тынычланып дигәндәй, кайту ягына юнәлде.

Киленe эштән кайткач, аны үз янына чакырып утыртты.

— Кил әле, балам, сүзем бар,— диде ул, аерата ягымлы итеп. Бәлки, еллар буенча улына саклап килгән мәхәббәтен салгандыр шушы сүзләренә. Рәхилә аңа сыена биреп утырды.— Үлгән артыннан үлеп булмый, балам,— диде Гайникамал әби, килененең чал төшә башлаган чәчләреннән сыйпап.— Терeләргә яшәргә кирәк. Мин сине ирексезләп тотмыйм. Күңелең яткан кешең булса...

Рәхилә аның сүзен бүлде:

— Юкны сөйләмә, каенам,— диде, куркынган кыяфәт белән.— Кума мине! Әллә исәндер дә әле.

Гайникамал әби чиксез рәхмәт белән мөлдерәмә тулы күзләрен килененә төбәде. Бүтәнчә бер сүз дә әйтмәде ул. Киленен, кочагына алып, кысып сөйде. Шушы килеш озак кына сүзсез утырды алар — ике ятим, ике тол хатын.

Шул көннән бирле Гайникамал әби өеннән чыгып йөрмәс булды. Теге вакытта үзе килененең күңелендә зәгыйфь

кенә булса да өмет чаткысы кабызса, бу юлы Рәхиләнең: «Әллә исәндер дә әле»,— дип үзен-үзе алдау өчен генә әйткән сүзләре улының кайтачагына ананың ышанычын тәмам ныгытты.

Нидер булды Гайникамал әбигә бу көнне. Икенче көнне ул, сандыгын актарып, аннан Газизулланың китәр алдыннан гына алган пальтосын чыгарды. Аны, кояшка элеп, озак җилләтте, тазартты. Шуннан түр башындагы чөйгә элеп куйды. Өстенә ситсы пәрдә япты.

Йокыдан тору белән Гайникамал әби пәрдәне почмакка шудыра да, сөйгән кебек итеп, пальтоның иңбашларын берничә мәртәбә сыйпап ала. Аннан, кемнеңдер күкрәгенә сыенганга охшатып, аңа башын сала. Үрелеп якасын үбә. Менә шулай, көн саен. Егереме ел буена...

Бу йоланы үти дә тәрәзә төбенә утыра. Күзләрен тыштан алмый. Басу капкасыннан кулына чемодан тоткан яки аркасына биштәр аскан берәр ят ир-ат күрендеме, ул калкынып куя.

— Кара әле, килен, анавы килгән Газизуллам түгелме? — дип сорый. Рәхилә тәүге елларда үзе дә тәрәзәгә каплана иде. Ят кешене күреп:

— Юк, ул түгел әле,— ди торган иде.

Тора-бара, өметен бөтенләй өзеп:

— Хыялыйланма инде, каенам, үлгәннәр кайтмый ул,— дип кисәтә башлады. Гайникамал әби мондый җавапны ишетергә дә теләми иде инде. Кемнедер куган кебек, ике кулын селти дә:

— Сөйләмә бушны! Минем улым үлә буламы?! Батыр үлми ул, — ди.

Соңга табан Рәхилә бәхәсләшми башлады. Карчыкның ышанычын какшату мөмкин түгел иде. Шуңа күрә ул, карап та тормыйча:

— Юк, каенам, ул түгел,— дип җавап бирә. Карчык бала шикелле күңелсезләнә, көйсезләнә. Ләкин тәрәзәдән һаман күзен алмый. Менә Гыйзулла да, үсеп, егет булды. Икенче ел инде армиядә хезмәт итә. Гайникамал әбинең telendә һаман Газизулла гына. Ул улын көтә. Аның кайтачагына, «Саумы, әнкәй!» дип, бер көн килеп үзенең алдына тып итеп басачагына бөтен барлыгы, җаны-тәне белән ышанып көтә. Газизулланың үлемен башына сыйдыра алмый ул. Имәндәй нык, сөлектәй сылу егет үлә димә! Шундый көчле ананың ышанычы: җирнең бер почмагы кителеп төшкән икән, дисәң, ышаныр, ә улының үлеменә — юк! Ана шул ул. Аналар гына шулай көтә беләдер...

Гайникамал әби янә калкынды. Калкынды, талпынды һәм чиксез шатлык белән кычкырып җибәрде:

— Кара әле, килен, карачы! Газизуллам бит бу. Кайтты, кайтты балакаем!

Бу юлы Гайникамал әбинең тавышында шундый ышаныч бар иде, Рәхилә тәрәзәгә күз салмый булдыра алмады. Карады һәм... кулындагы самавырын чак кына идәнгә төшереп җибәрмәде. Капка төбендә аркасына биштәр аскан солдат басып тора иде.

Гайникамал әби зур җитезлек белән урындыгыннан күтәрелде. Абына-сөртенә ишеккә табан атлады. Ул арада таза гәүдәле, киң иңбашлы, түгәрәк битле солдат килеп керде. Бу — Гыйзулла иде.

Гайникамал әби, оныгының күкрәгенә башын салып, җилгә чайкалган җилбәгәдәй дерелди иде. Гыйзулла, аның аркасыннан сөеп, юатырга тырышты.

— Елама, картинәй! Менә, кайттым бит!

— Кайттың шул, Газизулла балакаем, кайттың! — дип такмаклады Гайникамал әби яшь аралаш. Гыйзулла, үзенә чират җитүен көтеп, читтә басып торган әнкәсенә карап күңелсез генә елмайды. Ул картинәсенең буталуын аңлый иде.

— Кайсылай озак йөредең, балакаем,— диде Гайникамал әби.— Көтә-көтә арып беттем ләса! Иә, ярый, кайткач, рәхмәт инде. Бөтенләйгә кайткансыңдыр бит?

— Ялга гына кайттым әле, картинәй. Тагы бер ел бар.

Гайникамал әби ыңгырашып куйды. Шуннан, бераз уйлангандай итеп торды да:

— Бер ел, дисеңме? — дип сорады.

— Әйе, картинәй!

— И-и-и,— балакаем, күпне көткәнне, бер елга гына түзәрбез. Исән булуың әйбәт әле.— Гайникамал әби Гыйзулланың битләреннән, чәчләреннән сыйпарга тотынды. Кипкән иреннәре белән үрелеп, маңгаеннан үпте.— Кайсылай матурланып кайткансың! Шулай булыр дип уйлаган идем дә.

Ул йөгерә-атлый сәкегә менеп китте. ·Аннан чөйдәге пальтоны алып төште.

— Кая, Газизулла балакаем, чишеп ташла әле монавы солдат көпесен. Ялкытып беткәндер ул. Менә пальтоңны киеп кара. Бәләкәйләнмәдеме икән?

Гыйзулла карышмады. Шинелен элде дә атасыннан калган пальтоны иңенә салды.

— Тап-таман,— диде ул. Гайникамал әбинең йөзе кинәт яктырып китте.

— Менә рәхмәт төшкере! — диде ул зур кинәну, канәгатьләну белән. Аннан килененә борылды: — Күрдеңме, балам? Әйттем бит, таман гына булыр, дидем.

Гыйзулла бер кулы белән картинәсен, икенчесе белән әнкәсен кочаклап күкрәгенә кысты. Киткән чакта Газизулла нәкъ менә шулай хушлашкан иде.

— Нинди әйбәт! — диде Гайникамал әби, сабыйларча иркәләнеп.— Кайтмас та кайтмас дигән булалар. Бик беләләр инде. Кайтты бит әле менә. Көтә белсәң, кайта ул. Хәбәрсез югалган, имеш. Үлгән, имеш. Минем улым, Газизуллам, югала буламы?! Юк, батыр югалмый да, үлми дә ул.

Гайникамал әби оныгының кулларын иңеннән алды да кабаланып киенә башлады.

— Мин җәһәт кенә барып килим әле,— диде ул. Рәхилә белән Гыйзулла аптырап калды.

— Кайда бармакчысың, каенам?

— Куй, картинәй, йөрмә!

— Ярамый! — диде Гайникамал әби, кырт кына.— Сөенче алыйм үзеннән. Хәтере калыр югыйсә.

Чыгып та китте. Басу капкасына таба юнәлде. Яшь кар өстендә уйнаган кояш нурлары көчсезләнгән күзләрен чагылдырды. Шәле белән битен каплап, туп-туры тау битләвендәге йолдызлы кабергә табан атлады.

Гайникамал әби, үзенә калса, очып барган кебек иде. Чынында исә, ул җай гына кузгалды. Читтән караганда җилгә чайкалып утырган камышны хәтерләтә. Аяк асты тигезсез шул. Сөренте җир өстеннән бару җиңел түгел. Әмма шатлыктан канатланган карт ана бер нәрсә дә шәйләми. Кырпак карны кыштырдатып, ялгыз кабер өстендәге йолдызга табан атлый бирә.

Менә ул кабер рәшәткәсенә килеп сөялде. Үзенең сулышы кысылган. Көчкә-көчкә генә тын ала.

— Сөенче, атасы, сөенче! — дип пышылдады, йолдызга карап.— Көткәнем бушка китмәде, шөкер, атасы. Түзә белгәч, безнең йортка да куаныч килде. Бөтен кешедәге кебек, бездә дә бәйрәм бүген.

Берьюлы күп сөйләп ташлауданмы, хәле бетеп китте. Рәшәткәгә күкрәге белән сыенды. Йөзенә борчылу билгесе чыкты.

— Нигә эндәшмисең, атасы? — диде бераздан, үпкәләгәндәй итеп. Шунда ук йөзе тагы да нурланды.— Ә-ә-ә, теге вакытта: «Нигә үз яныңа алмыйсың?» — дип көяләнгәнемә хәтерең калгандыр. Югыйсә син миңа харап игътибарлы була торган идең. Сөйләшеп сүзләрең бетмәс

иде. Рәхәт иде миңа синең белән. Күпме гомер иттек, бер авыр сүзеңне ишетмәдем. Бер куаныч идең син миңа. Рәхмәт инде, атасы. Үземнең уйламыйрак зарлануымны кичер, атасы. Васыятеңне үтәрмен, йә, хуш! Улым янына ашыгам.

Башын күтәрсә, алдында Гыйзулла елмаеп басып тора иде.

— Әйдә, картинәй, кайтыйк! — диде ул, култыклап алып. Гайникамал әби карышмады.

— Әйдә, балам, әйдә,— диде онычына сыена-сыена. Янә кабатлады.— Кайсылай әйбәт! Син исәнсең, балакаем! Әйттем ләсә: батыр ир-егет үлми дә, югалмый да ул.

Мөгаен, ана хаклыдыр. Батырлар эзсез-хәбәрсез югалмый. Гомер дәвам итә...

ГАЯН ЛОКМАНОВ

(1923—1988)

Гаян Локман улы Локманов 1923 елда Башкортстанның Караидел районы Яугилде авылында туа.

Бөек Ватан сугышына кадәр Бөре шәһәрендә педагогия училищесын тәмамлый һәм 1942 елда Кызыл Армия сафына алына. Фронтта полкның идарә взводы һәм топографик разведка командиры булып сугышларда катнаша, 1944 елда инвалид булып мобилизацияләнә.

Кайткач, мәктәптә эшли һәм шул ук вакытта читтән торып Бөре укытучылар институтын тәмамлый.

Аның тәүге хикәяләр җыентыгы («Аккош күле») 1962 елда басылып чыга. 1969 елда Г. Локманов СССР Язучылар союзына кабул ителә. Соңгы елларда аның «Кояш чыгар алдыннан» исемле романы, «Агым су» дигән зур күләмле повесте, «Ана йөрәге» исемле һәм башка җыентыклары дөнья күрә.

ОЧРАШУ

Ап-ак кар юрганы ябынган кырлар өстендә, җәйге иген басуында берсен-берсе куышкан дулкыннарны хәтерләтеп, җәяүле буран уйный. Бу тоташ агым Зирекле авылына табан бормаланып сузылган юлны да кисә, тырышыптырышып аның чокыр-чакыр урыннарын кар белән тигезли...

Ә арырак, тау буйлап киткән җирдә, ул, үз вазифасына тугрылыгын тагын бер исбатлагандай, карны уратыпуратып шул уйсулыкка тутыра бирә. Нәкъ шунда, Ташкүпергә төшкән тәңгәлдә, бер «Запорожец» кырын ята.

буран, аны тизрәк чит күзләрдән яшерергә теләгәндәй, шул тирәдә тагы да көчлерәк өерелә сыман. Йөзенә гажизлек һәм газап күләгәсе төшкән, өс-башын, каш-керфеген кар сарган олы яшьтәге бер кеше култык таякларында бата-чума машинаның әле алдына, әле артына чыга, тыелгысыз бер өмет белән әледән-әле юлга күз сала.

...Мөстәкыйм соңгы елларда фермада төнге каравылда тора. Карт шунда үткәргән берничә сәгать эчендә дә туган учагын тансыклыймы, әллә гомер иткән карчыгын юксынырга өлгерәме — һәр иртә саен өйгә озак айлар читтә йөргән кеше кебек атлыгып кайтып керә. Карчыгы аны кунак көткән кебек көтеп ала: мич әллә кайчан ягып уздырылганга күрә, өй эче май кебек җылы, идәннәр ялт иткән, тәрәзә төбендәге гөлләр һәммәсе сөртелгән, урынжир пөхтәләп җыештырылган. Бар нәрсәдән ниндидер күркәм нур сибелгәндәй, өй эче балкып тора. Таба ашы исе тамакны кытыклый...

Мөстәкыйм чишенеп, юынып, өстәл янына утыруга, аш-суга юмарт карчыгы Бибиәсма, гадәтенчә, сый-хөрмәтне өстәл тутырып тезде, каршыга үзе дә утырды. Аннан-моннан ил-көн хәлләрен сөйләнгәләп, чөкердәшә-чөкердәшә иртәнге чәйне эчтеләр. Шул арада Мөстәкыйм карчыгына берничә кабат игътибар итте: аның әчке бер яктылык сирпеп торган күзләре ниндидер яңалык барлыгын сиздерә иде. Шулай булып чыкты да. Мөстәкыйм рәхмәт әйтеп өстәл яныннан кузгалуга, аңа открытка китереп тоттырды:

— Бу — сиңа,— диде.— Күрше Вәлимә кызы кичтән үк кертеп чыккан иде. Сине мәктәпкә чакыралар, атасы.

Картның башыннан уйлар дулкыны йөгереп үтте. Нигә чакыралар икән? Ни булган? Инде балаларын укытып, үстереп, үзаллы тормыш юлына бастыруына да биш был тыр. Һәркайсы үз гаиләсе, үз шөгыле белән көн итә. Өлкәне — колхозда зоотехник. Икенчесе — Уфада инженер. Өченчесе — тракторчы. Дүртенчесе — төпчеге — армиядә. Язга кайтырга тиеш. Моңа чаклы балалары йөзенә кызыллык китермәде. Моннан соң да...

Карт күзлеген киде, Җиңү ордены сурәте төшерелгән открытканы әйләндереп-әйләндереп карады. Открытканың ак ягына шушы сүзләр язылган иде:

«Кадерле Мөстәкыйм бабай Гайнетдинов! Без, Зирекле урта мәктәбе пионерлары һәм комсомолецлары, сезне, Ватан сугышы ветеранын, зур хөрмәт һәм ихтирам белән Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган очрашуга чакырабыз...»

Менә ничек икән?! Карт язуны кат-кат укыды. «Кадерле», «зур ихтирам белән» дигән сүзләрдә аеруча бер җылылык, шәфкатьлелек тоеп, күңеле нечкәрде. Аны берчә горурлану, берчә каушау сыманрак тойгы биләде. Әйе, каушады ул. Болай да нык тәэсирләнүчән кеше тәмам тынычлыгын югалтты. Шул минуттан алып, очрашу турында гына уйлана башлады. Урта мәктәп моннан унбиш чакрымда. Әмма аңа транспорт мәсьәләсендә борчылырга түгел. «Запорожец»ы бар. Кабызды — китте. Ә мәсьәлә башкада: иң мөхтәрәм, иң укымышлы кешеләр — укытучылар һәм йөзләгән укучылар алдына чыгып басу уен эш түгел иде, билгеле. Үзен ничек тотар? Ничек сөйләр? Аптырап, югалып калмасмы? Менә кайда хикмәт.

Чакырылган вакытка чамалап, карт юлга әзерләнә башлады. Өстенә энәдән-җептән генә чыккан костюмын киде, карчыгы сандыктан бик кадерләп саклана торган төргәкне өстәлгә алып куйды:

— Наградларыңны тагарга онытма, карт,— диде.— Кеше алдына барасың.

Мөстәкыйм орденнарын һәм медальләрен өстәлгә таратып салды. Кайсыларын тагарга соң? Һәр орден, һәр медаль үзе бер тарих... Аларга караган саен, утлы сугыш еллары, каты алышлар аермачык булып күз алдына баса.

Менә Кызыл Йолдыз ордены... Хәтердә, бүгенгедәй күз алдында. Һөҗүм итүче гаскәрләр Сейм елгасының ярына житеп туктап калды. Мөстәкыйм хезмәт иткән саперлар взводы алдына житди бурыч куелды: елга аша күпер салырга! Бер төн эчендә өлгертергә!

Взвод эшкә тотынды. Бозлы суда, әле унда, әле сулда төшеп ярылган снарядлар һәм өзлексез яуган пулялар яңгыры астында ал-ял белми эшләде алар. Сызылып таң атып килгәндә гаскәрләрнең алдынгы частьлары каршы ярга чыга башлады. Мөстәкыйм күңелендәге шатлык һәм горурлыкны сүз белән әйтеп бетереп булмый иде бу минутта. Тик байтак иптәшләре бу татлы хисләрне кичерә алмады, дошман пулялары гомерләрен өзде, һәм салкын дулкыннар аларны үз кочагына алды. Мөстәкыйм, аяк өстендә басып торырлык хәле калмаса да, күпердән китмәде, дошман снарядлары зарарлаган урыннарны төзәтте, шуның белән күпердән гаскәрләрнең өзлексез хәрәкәтен тәэмин итте.

Менә Кызыл Байрак... Бу орденны Буг елгасы аша үзе эшләгән салда танкка каршы ата торган орудиене алып чыккан өчен биргәннәр иде.

Әйе, көпә-көндез, снарядлар төшеп ярылудан кайнап торган елга аша алып чыкты ул аны.

Тагы Кызыл Байрак...

«Батырлык өчен» медален учына салгач, Мөстәкыймнең мәгънәле, уйчан карашы бу бүләккә озаграк тукталды. Кырык ел үткән... Кырык ел... Ә барысы да кичә генә булган кебек.

Безнең алдынгы отрядлар Одерны чыгып плацдарм биләде һәм каты сугышлар белән аны шактый киңәйтүгә иреште. Әмма икенче көнне дошман һөҗүм артыннан һөҗүмгә ташланды, безнекеләрне ярга кысрыкларга һәм кырып салырга исәп тотты. Шулай да сизелерлек уңышка ирешә алмады, разведканың соңгы мәгълүматларыннан дошманның һөҗүмгә танклар ташлаячагы билгеле булды.

Командир ике саперны, шул исәптән Мөстәкыймне, үзенең күзәтү пунктына чакырып алды да кичке эңгер-меңгердә күгәреп күренгән калкулык аша бормаланып сузылган күгелҗем тасмага күрсәтте.

— Немецлар танкларын һичшиксез менә шушы юлдан тарттырачак. Чөнки башка мөмкинлекләр юк. Күреп торасыз, сул якта елга, ә уңда сазлык. Сезнең бурыч: төнлә дошман тылына чыгу һәм шушы юлга миналар тезү.

Рязань егете Антонов һәм Мәстәкыйм, аркаларына күтәрә алган чаклы миналар салып, куе караңгылык эченә кереп югалды. Һәр шылт иткән тавышка да колак сала-сала зур саклык белән шуыша торгач, алгы сызыкны хәвеф-хәтәрсез үттеләр. Көне буе каты алышта йончыган немецлар, егетләр мина куйганда, берни сизмәде. Әмма кайтканда...

Алар, искәрмәстән, дозорда яткан ике немецның нәкъ өстенә барып чыкты. Чигенергә форсат калмаган иде инде. Тегеләр исләренә килеп, коралга тотынганчы, Антонов белән Мөстәкыйм мәче җитезлеге белән аларга ташланды. Тегеләр ансат кына биреләргә теләмәде. Муеннарыннан буып кысып алгач та әле ычкынырга, өстенлек алырга тырышты. Шулай да дөмектерделәр. Әмма Антонов, әллә ни арада, дошман пычагыннан яраланган иде. Мөстәкыйм аны аркасына салып алга шуышты. Снаряд чокырына төшеп ярасын бәйләде. Икесе бер взводта, хәтта бер отделениедә хезмәт иткәнгә күрәме, әллә икесенең дә холык-фигыльләре бер үк булгангамы (икесе дә төпле уйлы, басынкы) — алар бер-берсенә аеруча якын, җылы мөнәсәбәттә иде. Ял мәлләрендә гел бергә. Антонов үзе яшәгән Рязань якларын мактый һәм, сугыш беткәч, Мөстәкыймне кунакка чакыра. Мөстәкыйм, үз чиратында, ту-

ган Башкортстанын сагынып сөйли һәм дөньялар тынычлангач, Антоновның үзенә килүен үтенә.

Алар тагы да алга кузгалды. Әмма Антоновның хәле мөшкелләнә барды. Бераздан ул туктарга кушты. Окоп сыман бер уйсулыкта Мөстәкыйм аны тагы да җиргә төшерде.

— Бир әле кулыңны,— диде Антонов, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән.— Миңа табан иелә төш. Менә шулай... Тагы бер карыйм үзеңә... Яшәргә иде... Их, яшәргә иде! Нинди дә гүзәл, соклангыч тормыш булачак бит сугыштан соң!

— Ә син яшәячәксең! — диде Мөстәкыйм, дустының кулын йомшак кына кысып, башкача булуын ул уена да китерә алмый иде.— Сугышлар бетеп, без әле кунакка йөрешәчәкбез.

— Әйе...

Мөстәкыйм ничек кенә тырышмасын, ничек кенә үрсәләнмәсен, үзебезнекеләргә җиткәндә Антонов аңын югалткан иде инде. Ул кабат исенә килә алмады, Мөстәкыйм кочагында мәңгегә күзләрен йомды.

Дошманның танклары кыйратылды. Безнекеләр, плацдармны күпкә зурайтып, зур һөҗүмгә күчте.

Әйе, «Батырлык өчен» медален аңа дошман тылына чыгып миналар куйганы өчен биргәннәр иде.

Күпме күпер салды, үзе ясаган көймә һәм салларда күпме гаскәрне сулар аша чыгармады да, күпме юлларны, сугыш яланнарын дошман миналарыннан тазартмады Мөстәкыйм. Минер тик бер генә ялгыша. Аны һәр адымда үлем сагалый. Мөстәкыйм командирлар куйган һәр бурычны барлык тырышлыгын, ихласлыгын салып, төгәл һәм җиренә җиткереп үтәргә тырышты.

Ул тегеләй дә, сабыр, басынкы кеше, сугыштан каты яра алып (Берлинга җитеп барганда уң аягын тубыктан өстә дошман снаряды өзде), култык таякларына таянып, күкрәк тулы орден-медальләр белән кайтса да кайберәүләр кебек һаваланып: «Мин фәлән! Мин төгән!» — дип күкрәк какмады, өч-дүрт көннән үк бүләкләрне бик пөхтәләп төреп сандыкка куйды да колхозда эшкә тотынды. Тыныч хезмәткә нык сусаган иде. Яшьтән балта остасы ул. Аның урыны төзелеш бригадасында иде, билгеле. Мал өчен абзарлар, ашлык салырга келәт-кура төзеде, искеләрен ремонтлады. Кулыннан балта төшмәде. Тик соңгы елларда, сыңар аякка бүрәнә күтәрү авырга килә башлагач, фермага каравылчы эшенә күчте. Инде пенсия яшендә булса да шөгылен ташламый.

Орден һәм медальләр аның күңелен кузгатты. Ә «Батырлык өчен» медале аеруча тәэсирләндерде. Ул тагы да җан дусты Антоновны исенә төшерде һәм йөрәктә сагыну, юксыну хисе уянды. Мөстәкыйм гвардияче билгесен һәм шушы «Батырлык өчен» медален тагарга карар итте. «Батырлык өчен»... Димәк, үзе турында үзе әйтеп тә тора. Карчыгы ни кыстауга, ни үгетләүгә карамастан, башкаларын кире куйды. Такса, әлеге дә баягы, мактану, масаю булыр сыман тоелды аңа.

Җыенып беткәч, Мөстәкыйм тутырып, ихлас итеп карчыгына карап торды. Йомыш төшеп машинасы белән кая бармасын, район үзәгенәме, ун чакрымдагы Бәдрәшкәме — карчыгын калдырмый ул. Ни әйтсәң дә, икәү күңеллерәк, юл сизелми дә кала. Әмма бу юлы карчыгын кузгатмаска булды.

— Йә, мин китәм инде, анасы.

— Исән йөре, карт. Юлларың уң булсын!

...Яланда җәяүле буран иде. Юлга төшкәч, киңлек, иркенлек тәэсир иттеме, машинаның үзенә бер көй белән эшләве йогынты ясадымы — картның кәефе тагы да күтәрелә төште. Юлга кар яткан урыннарда да машина тизләгән киметми.

Әмма җилнең көчәя баруы (бу — тәрәзәдәге ыжылдау тавышыннан ук билгеле) Мөстәкыймне шомландырмый кала алмады. Алда киселгән тауны үтәсе бар. Ә мондый җил-буранда карны нык сала анда.

Шулай булып чыкты да. Менә шул урында бәлага тарыды да инде карт. Кызу килгәндә үтсә, үтеп тә китәр иде, бәлки. Җитмәсә аска табан. Карны ярдырып бераз барган да иде инде. Әмма алда менеп килгән тагы да бер автомобильне күргәч, ирексездән тормозга басарга мәҗбүр булды: кире чигәргә, такыр урында туктап, каршыдан килүчене үткәреп җибәрергә карар итте. Тик, әмәлгә калгандай, машина инде буйсынырга теләмәде, тәгәрмәчләр бер урында зырылдап әйләнде дә әйләнде. Менеп килүче дә юлын ырата алмады, үтәргә тырышты-тырышты да, азак өметен өзеп, ахры, чигенде (тау астына ансат) һәм китеп, борылышта күздән югалды.

Буран карны юлга өстәгәннән-өсти... Мөстәкыйм машинаны артка да, алга да омтылдырып карады. Әмма бер урында әйләнгән тәгәрмәчләр батканнан-бата гына барды.

Кабыргадагы көзгедә арттан килүче «Жигули» күренгәч, картның түбәсе түшәмгә тия язды. Менә бәхет! Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына. Болай булгач, ычкына инде ул бу тозактан.

«Жигули» кар салган урынга берничә метр җитмичә туктады. Ян ишекләр берьюлы ачылды да аннан ике кеше чыкты. Икесе дә яланбаш... Пинжәкләренең дә төймәләре ычкындырулы. Яшь-җилкенчәкләр... Берсе озын буйлы, икенчесе тәбәнәгрәк, әмма нык. «Таза егетләр...— Карт канәгать елмайды.— Болар белән машина кузгату гына түгел, тауны күчерергә була».

Әмма хаталанды Мөстәкыйм. Аларның яңа карда якъякка чайкалганын, кулларын сәер болгап, очынып килүләрен күргәч үк, тәне эсселе-суыклы булып китте. «Хәерлегә була күрсен...» дип борчыла башлады.

Тегеләрнең килеп җитүләре булды, озын буйлысы ишекне каерып ачып җибәрде дә чәчләре тузгыган, карланган башын эчкә сузды:

— Юлны бүлеп торган менә кем икән ул! — Суган катыш аракы исе картның танавына килеп капланды.— Нишләп утырасың, картлач? Әллә йокладыңмы? Валяй тизрәк!

Бу сүзләр кинәт баш өстендә күк күкрәгәндәй тәэсир итте Мөстәкыймгә. Тәмам каушап, югалып калды ул. Эндәшергә дә теле әйләнми торды хәтта.

— Мин...— диде, ниһаять.— Ни бит, балакайлар... Күреп торасыз.— Ул юлга төртеп күрсәтте.

— Давай, давай, валяй,— диде таза гәүдәлесе, гайрәт чәчеп.— Синең әкиятеңне тыңлап торырга безнең вакытыбыз юк!

Карт кабаланды, машинаны омтылдырырга, урыныннан кузгатырга тырышып, тизлек рычагын бер тегеләй, бер болай күчерде, газны арттырды. Тегеләр һаман ашыктыруларын белде. Азак йончыды, буталды. Муфта педаленә басмыйча, кинәт газга бастымы, әллә бүтән берәр хата эшләдеме — машина лып сүнде дә куйды. Мөстәкыйм ничек кенә тырышмасын, ничек кенә үрсәләнмәсен — кабат кабынмады.

Мөстәкыйм кабинадан чыкты. Култык таякларында бата-чума барып, арткы капотны ачты, двигатель өстенә иелде. «Нинди генә гөнаһ шомлыгы булды соң бу?» Ә узгынчылар, инде күлмәкләреннән чыгардай булып, яман сүгенергә тотындылар. Тәбәнәк буйлысы хәтта картның җиңеннән тарткаларга тотынды:

— Йә, тиз буласыңмы, картлач? Синең чокчынганыңны күпме көтәргә тиеш без!

— Хәзер, хәзер... Мин...— Карт тирләп чыккан иде. Бүреген күтәрә төште, пальто төймәләрен ычкындырып җибәрде. Аның маңгаеннан да, тәненнән дә пар күтәрелә иде.

— Менә бит... Ахры, свечалар...

Шулчак озын буйлысы, яман да сүгенеп, карт янына төкереп куйды:

— Кулыңнан килмәгәч, утырып чыкмыйлар аны.

— Син, улым, бик әтәчләнеп тә барма әле, яме,— диде Мөстәкыйм, үзен бераз кулга алып.— Күзең маңгаеңда булса, юлның нинди икәнен күреп торасың бит. Мин дә уйнап йөрмим.

— Кара, кара, ничегрәк сөйләшә, ә? Бәй, медаль таккан түгелме?! Күрегез, күр, аның медале бар! Нәрсә, шул медалең белән шаккатырырга уйладыңмы? Медаль күргәннәре юк диденме? Берәүләр медаль таккан! Ха-ха-ха!..

Мөстәкыймне эчке калтырау алды. Көчле ялкын, кайдандыр күтәрелеп, миенә китереп сукты.

— Син кагылма минем медальгә! — диде карт, ярсый баруын үзе дә сизмичә.— Кагылма, телеңне корт ерган бәндә.

— Нәрсә, нәрсә?!

— Китегез моннан! Китегез! — диде карт, инде ачудан комачтай кызарып.— Минем сезнең ярдәмгә калган көнем юк.

— Ишетәсеңме?! — диде таза гәүдәлесе икенчесенә.— Нигә шуның белән вакланып торабыз соң әле? Әйдә, алыйк та ташлыйк юлдан шушы нәрсәкәен! Тот!

Мөстәкыйм капотны да ябып өлгермәде, машинаны бер як читеннән күтәрделәр дә юл читенә аударып та куйдылар. Карт, авызын ачып, катты да калды.

Тегеләр барып «Жигули»ларына утыру белән кузгалдылар һәм буран очыртып, «машинаны менә шулай йөртәләр аны!» дигәндәй, авызларын ерып, нәрсәдер кычкырып узып та киттеләр.

Алар китте, озакламый күздән дә югалды. Әмма карт, сугып исәнгерәтелгәндәй, басып торды. Исенә килгәч тә әле бу хәлнең чынлыгына ышана алмады. Бата-чума машинаның бер алдына, бер артына чыкты. Ян яктан этеп, торгызырга тырышып карады. Әмма «Запорожец» селкенмәде дә. «Ярый әле карчыкны да алмаганмын,— дип үзен-үзе тынычландырырга тырышты,— аның алдында оят булыр иде. Әле ни күрсәм дә үзем...»

Уйланды карт, газапланды. Юк, үзләре эшләп, тир түгеп тапкан акчага алынмаган ул «Жигули»! Йә этиләре көче, йә бөтенләй хәрәмнән килгән.

Мондый затлар дөнья гел рәхәт чигүдән, кәеф-сафа корудан гына тора дип исәпли, ахрысы. Аларга барысы да

житеш, күп кирәк. Кемнәрдер эшләсен, тырышсын — тик алар түгел. Олы буынга кимсетеп, йөз җыерып карый, алар инде искергән, яшәүгә хокукын югалтып барган итеп исәпли сыман.

Нигә алай? Сәбәп нидә?

Әллә артык иркә, иркен үсәме хәзерге яшьләр? Иркә бала итәкне буйый. Артык үсендерәбезме? Әллә табигый хәлме бу? Кандагы тыелгысыз дәрт, көч-куәт шулай тилертәме аларны?

Хәер, Мөстәкыймнең дә яшь, көч-куәт ташып торган заманнары булмады түгел. Сугыш алды еллары иде. Тормыш шартлары әлегедән күпкә кайтыш иде әле ул чакта, кием-салым да, ашау-эчү дә такы-токырак мәлләр. Әмма күңелләр бай, хис-тойгылар саф, кәефләр шәп! Мөстәкыйм көнозын җаткада урак урыр, ә кич, өйгә кайтып, юынып, тамакны туйдырып алгач, авыл читендәге Ташлытауга атлыгыр иде. Ә анда егетләр, кызлар, гармун, җыр, бию, сөю, мәхәббәт!.. Мөстәкыйм, таң йокысы гына эләксә дә, иртүк торып, дәртләнеп уракка китә, ару белмичә, Стахановча (ул елларда бу сүз телдән дә төшми иде) эшли. Ул олыны-олы, кечене-кече итәргә, инсафлы, әдәпле булырга тырышты. Балаларын да аксөяк итеп үстермәде. Алар эшләп, иң олы нәрсә — икмәкнең күпме тозлы тир түгеп нитикле авырлык белән табылуын үз иңнәрендә татып буй җиткерде.

Ә болар...

Мөстәкыймнең борчылуы артканнан-арта барды. Мәктәптә аны инде көтәләрдер. Ихтимал, төнгә чаклы көтәрләр... Их, ничек уңайсыз килеп чыкты бит. Каршыдан килгән машина тоткарламаса, ыжламый да үтә иде ул. Әллә кайчан мәктәптә булачак кеше иде. Теге әзмәверләр аз гына булышса да ычкына иде бу тозактан. Юк, җикеренүдән башканы белмәде, игелексезләр. Ашыгалар, имеш. Шул, тизрәк авылга җитеп, тамакларына коярга үрсәләнәләр инде, анысы хак. Их, утыр менә хәзер тилмереп.

Уйга чумып, астан, юлны сыдырттырып, бульдозер менеп килүен дә күрмичә торды. Ә күргәч... шатланырга да, шатланмаска да белмәде. Тагы да берәр гөрбиян булып чыкса руль артында утыручы? «Юлны бүлгәнсең, үтәргә дә җай калмаган!»— дип монысы да өскә ташланса?

Кабинада, чынлап та, яшь, мыеклы бер кеше икәнлеге ачыклангач,— монысы да яланбаш! — картның шикләнүе бермә-бер артты.

Егет килеп җитәр-җитмәс туктады, сикереп төшеп, Мөстәкыйм янына ашыкты.

— Ни булды, бабай?— дип эндәште аптыраган бер кыяфәттә.— Бу ни эш?

— Сорама инде, улым.— Бу кешенең чын-чыннан борчылып, хәленә кереп сорашуыннан картның күңеле йомшарды.— Сөйләргә телем әйләнми хәтта. Зинһар шуны торгызыша күр әле, бәбкәм. Мәктәпкә соңлыйм. Укучы балалар чакырган иде.

— Борчылмагыз, бабай, хәзер булдырабыз аны,— диде егет, картны тынычландырырга теләгәндәй.— Башта танышыйк. Мин Әхнәф булам.

— Бик рәхмәт,— диде Мөстәкыйм.

Әмма зиһене таралуданмы, үзенең кем икәнлеген әйтергә онытты.

— Гаражда тоткарланырга туры килде. Шуңа күрә юлны тазартырга соңладым бүген.

Егет бульдозерның чүмечен күтәртте дә алга узды. «Запорожец» белән тигезләшкәч, елт кына борылып, артка — машинага таба чигеп туктады. Тартмадан трос алып, аның ике очын машинага, урта тапкырын бульдозерга эләктерде. Шуннан тагы да кабинага сикереп менде, бульдозер әкрен генә алга кузгалды, «Запорожец»та, түбәнәя барып, җайлап кына төшеп утырды.

— Менә хәзер кабызып карарга да була,— диде егет.— Аккумулятордагы сыекча гына агып бетмәгән булса.

Кешегә күп кирәкмени? Мөстәкыйм канәгать иде. Ул Әхнәфнең әле капотны ачып двигательдә чокчынуын, ул да булмый, кабинага кереп стартерны әйләндертүен, җитез, ятыш хәрәкәтләрен сокланып та, кызыгып та күзәтте. Егетнең шул рәвешле бик теләп ярдәм кулын сузуы, эчкерсез ихласлыгы картны дулкынландырды.

Унбиш минут та үтмәгәндер, машина, кар катыш төтен бөркеп, гөрләп эшли башламасынмы!

Мөстәкыймнең күзләреннән яшь бәреп чыкты хәтта.

— Менә, инде җилдертергә дә була!— диде Әхнәф, балалар кебек саф, мөлаем елмаеп машинадан чыкты.— Әйләнеп кайткач, аккумуляторга сыекча өстәргә онытма, бабай. Бераз аккан. Әлегә куркыныч түгел түгелен. Йә, кереп утыр, бабай. Кайтыр якка борчылма. Юлны шундый итеп тазартырмын, исең китеп торыр. Уңышлы юл телим.

— Рәхмәт, улым,— диде карт, күңеле нечкәрүдән калтыранган тавыш белән, егетне кочаклап алырдай булып.— Игелек күр. Кулың-аягың сызлаусыз булсын. Бәхетле яшә!

Мөстәкыйм моннан соң бер урында да тоткарланмады.

...Менә ул кайтып килә. Буран басылган. Юл таза. Ә машина, кайтыр якны сизенгән яхшы ат кебек, җилдерә генә. Картның тәэсирләнүе йөзенә чыккан. Иә, тәэсирләнмәслек тә дулкынмаслыкмы соң? Шулай олылап каршылармар, кадер-хөрмәт күрсәтерләр дип ул уена да китермәгән иде. Мәктәпнең капка төбенә барып туктау белән аны каршыларга чыккан көләч йөзле малайлар һәм кызлар уратып алды, кулларын алга сузып, шат балкып, укытучылар якынлашты.

— Хуш килдесең, бабай!

— Әйдүк, рәхим итегез!

Мөстәкыйм укытучылар белән берәм-берәм күреште, баш иеп укучы балаларны ихлас сәламләде, якынрак торганнарның аркасыннан сөйде, кечкенәләрнең башыннан сыйпады. Бу яңа мәктәпкә кергәне юк иде әле аның. Озын иркен коридор, якты таза класслар аны таң калдырды.

Пионер бүлмәсе дә искитмәле иде. Стеналарда эленгән герой-пионерларның портретлы биографияләре дә үзе бер дөнья. Музейга кергәч, тагы да сокланмый калмады. Нәрсәләр генә юк анда! Чын тарих! Иң түрдә «Колхозның алдынгы кешеләре» дигән бүлектә тезеп куелган зур-зур фотосурәтләр арасында үз сурәтен дә күргәч, үз күзләренә үзе ышанмый торды.

Мәктәп белән танышкач, зур залга үттеләр. Укучылар һәм укытучылар аны көтеп утыралар иде. Барып керү белән укучылар аягөсте басып, тагы да сәламләде. Аны иң түргә, сәхнә сыман урынга куелган өстәл артына утырттылар. Мәктәп директоры очрашуны ачык дип игълан итте. Шуннан пионер һәм комсомол оешмалары башлыклары берсе артыннан берсе алга чыгып басты: «Хөрмәтле сугыш һәм хезмәт ветераны Мөстәкыйм бабай Гайнетдинов, без сезнең алда рапорт бирәбез...»— дип башлап, үткән эшләре, яулаган уңышлары хакында җентекләп сөйләгәннәрен карт бик бирелеп, ихлас тыңлады. Аны берчә куаныч, берчә горурлану хисе биләде. Алар санаган барлык саннарны хәтеренә сендерә алмаса да, шуңа ачык төшенде: укулары, тәртип мәсьәләләре дә өлгеле куелган. Укучылардан төзелгән махсус бригада фәләнчә гектарда чөгендер үстереп алып, колхоз келәтенә тапшырган. Мәктәп яны участогында да тырышып, ихлас көч түккәннәр. Җитди тәҗрибәләр үткәреп, игенчелекнең, яшелчә-җимешчелекнең тирән серләренә үтеп керергә тырышканнар. Димәк, тормышка җиңел-җилпе караучы җилкуарлар, аксөякләр түгел, ә чын хезмәт сөючеләр тәрбияләнә монда! Ә бу — куанычның да куанычы!

Үзенә сүз бирелгәч, Мөстәкыйм, баштa әйтерсең ниндидер дулкын килеп бәрелде — чайкалгандай итте, тавышы да сәерләнеп, калтыранып чыкты шикелле. Сүзләрен дә рәтен-чиратын таба алмады сыман. Әмма бу хәл озакка бармады, мондагы гадилек, табигыйлек тәэсир иттеме, укучыларның ихласлыгы, бирелеп, мавыгып тыңлавы йогынты ясадымы — Мөстәкыйм үзе иркен сизде, фикерләр инде үз эзенә төшеп, җай гына агыла башлады. Юк, тыныч күңел белән сөйли алмады карт. Хәер, ул дәһшәтле елларны искә төшергәндә кем генә тыныч була алыр икән? Дошманның мәкерлеген, явызлыгын ачып салганда чырае кырысланды, йөрәгендә ачу һәм нәфрәт кайнашканлыгы тавышыннан ук сизелә иде. Ә сугыш эпизодларын сурәтләп, безнең сугышчыларның батырлыгын тасвирлаганда, киресенчә, дулкынланды, горурлануы йөзенә чыкты. Әле кызлар кулы тотарга да өлгермәгән никадәр яшь егетләрнең, өйдә хатыны, газиз балалары калган бик күп ирләрнең сугыш яланында мәңгегә ятып калуын теленнән кичергәндә тавышы калтыранды.

— Безнең буын, балалар, төрлесен күрде,— дип дәвам итте ул.— Ачлыгын да, юклыгын да татыды. Чөнки илнең мөмкинлекләре шулай гына иде әле ул чакта. Бүгенге тормыш өчен зур көч түгәргә, көрәшергә, хәтта күп корбаннар бирергә кирәк иде. Шулай булды да. Фронтта минем җан дустым Антонов бар иде. Ул, каты җәрәхәтләнгәч, минем кочагымда җан биргәндә: «Яшәргә иде, их, яшәргә иде! Нинди дә гүзәл, сокландыргыч тормыш булачак бит сугыштан соң!»— дигән иде. Аның сүзләре дөрескә чыкты. Тормыш чынлап та күркәм, матур хәзер. Күкләребез саф, көннәребез якты. Муллык, иркенлек. Радио, телевизор, газ — һәр йортта. Сабан туйларында кия торган киемне хәзер көше эшкә кия. Һәр эшчән гаиләнең өстәлендә кунак ашы. Мин, балалар, сезгә карыйм да сокланып бетә алмыйм. Бәхетле сез. Нинди якты мәктәптә укыйсыз. Һәркайсыгыз курчак кебек киенгән. Күңелләрегез көр, йөзләрегез шат. Болар барысы да Бөек Җиңү аркасында бит. Тынычлыкны саклыйк без! Белик кадерен, балалар, бу матур тормышның, белик!

Мөстәкыйм монда килгәндәге хәл-вакыйганы сөйләргә, ямьле тормышның ямен җибәреп йөрүче затсыз кешеләр дә барлыгын искәртергә теләсә дә, шул мәгънәсезләр өчен генә балаларның саф күңеленә кер төшермим әле, дип ул хакта сүз кузгатмаска булды.

— Мин сезнең тырышып, күңел биреп укуыгызны, Туган илнең чын патриотлары булып үсүегезне телим,—

диде, фикерен йомгаклап.— Туган ил газиз ул, бик газиз. Чөнки иле барның гына көне бар.

Күп ир-егетләр бу якты көннәрне күрә алмады. Онытмыйк без аларны, балалар, онытмыйк! Дан, мәңге дан аларга!

Картның соңгы сүзләре залдагыларның көчле алкышына күмелде.

Азактан очрашуга багышланган концерт булды. Мөстәкыйм укучыларның бер-бер артлы чыгып җырлавын, биюен, шигырь сөйләвен мавыгып, исе китеп карап утырды, ихлас кул чапты. «Нинди оста, нинди сәләтле алар!» дигән соклану йөзеннән китмәде.

...Менә Мөстәкыйм машинасында җилдерә. Тизрәк кайтып җитәргә, барлык тәэсирләрен карчыгы белән уртаклашырга ашыга һәм, йә, исәр түгел диң инде мине, дип үзалдына сөйләнә ул, бер-ике җилкуар, мәгънәсез бәндәгә карап, яшьләр турында ялгыш фикергә кереп барам бит, ә? Юк, әйбәт яшьләр үсә бездә! Әйтәсе түгел, лаеклы алмаш килә!

ГАБДУЛЛА БАЙБУРИН

Габдулла Гыйндулла улы Байбурин 1925 елда Чишмә районы Сафар авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, армиягә алына, Бөек Ватан сугышында катнаша. Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Батырлык өчен», «Венаны алган өчен» һәм башка күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

Башкортстан дәүләт педагогия институтын тәмамлый, шулай ук Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый.

Г. Байбурин әдәбиятның төрле өлкәләрендә эшли — шигыйрь, прозаик, драматург. Әдәби тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. 1973 елда Будапештта тәрҗемәчеләрнең халыкара конференциясендә катнашты. Ул — егермедән артык китап авторы, Аның «Иртәгә бабай» исемле әкият-поэмасы буенча Мәскәүдә диафильм да чыгарылды.

Әдәбият һәм матбугат өлкәсендәге хезмәтләре өчен аңа РСФСРның атказанган культура работнигы дигән почетлы исем бирелде.

Габдулла Байбурин — 1953 елдан КПСС сафында. 1963 елдан СССР Язучылар союзында әгъза булып тора.

КӨМЕШ АРБА, КӨМЕШ АТ

I

Гыйниятулла Яубасаров поездның кинәт каты итеп тормоз салуыннан дертләп уянып китте. Битләреннән иртәнге кояш нурлары иркәли иде. Ләкин ул торырга ашыкмады, күзләрен йомган килеш, сабый бала шикелле һаман изрәп ята бирде. Паровоз, күрәсең, ярыйсы ук ярсыган: вагон тәгәрмәчләре, так-ток, так-ток итеп, рельс очларына шулкадәр еш сугыла — аның тавышына хәтта колак яр-

ми. Ә вагон үзе шушы бертөрле ритм уңаена, хәйран зур бишек сымак, өзлексез селкенә-чайкала. Ачык тәрәзәдән татлы саф һава бөркелеп керә. Рәхәт!

Кичә аруы да җиткәндер шул Гыйниятулланың. Иртәнге аштан кайтү белән рота командиры демобилизация турында приказ укыды.

— Һәйбәт хезмәт иттең, сугышта курку белмәдең, дошманга аяусыз булдың,— диде ул Яубасаровка.— Шуның өчен рәхмәт белдерәм! Гомерең буена горурланып яшә: син — фашистлар оясын туздырган, Берлинны алган солдат!

Шушы минутта ук Гыйниятулла өчен үзенең уй-моңнары, хәстәрлекләре белән бөтенләй яңа тормыш башлангандай тоелды. Әйе, җырдагы кебек, үзе монда, күңеле — анда, авылында, Миңлебәдәре янында иде инде. Тиз-тиз генә ул тиешле документларын, паекларын алды да соңгы мәртәбә шәһәр буйлап йөреп кайтырга булды.

Капка төбенә чыгып баскач, Яубасаров кайсы якка китәргә белмичә аптырабрак калды, ахрысы, күпмедер алан-йолан каранып торды. Гыйниятулла монда өченче ай инде хәзер, шушы вакыт эчендә Берлин урамнарын аз кыдырмады. Әмма шәһәргә чыккан саен, ни гаҗәптер, рейхстагка сугылмый калмагандыр. Бу юлы да сәфәрен ул шуннан башламакчы итте.

Менә Унтер-ден-Линден урамы. Шәһәр үзәгендәге иң зур урамнарның берсе ул, шуңа күрә халык монда аеруча ишле. Яубасаров хәтсездән игътибар итеп, сынап йөри: немецларның күпчелеге аңа, димәк, совет солдатына, ихтирам белән карап үтә, күзләрендә җылылык сизелеп тора. «Болары безнең дуслар булырга тиеш»,— Гыйниятулла эченнән шулай фараз кыла. Ә бәгъзеләренең йөзеннән, аны күрү белән, бөтенләй котлары кача. Совет халкы турында гитлерчылар тузга язмаган әшәке хәбәрләрне аз таратмады шул. Гыйниятулла үенча, болары исә шушы агулы сөремнән әле һаман айнып җитмәгән бәндәләр булса кирәк. Әнә, бөрешеп беткән бер карт, уртын чәйни-чәйни, Яубасаровка астан гына акаеп карап узды. Монысы инде, мөгаен, капкынга эләкми калган берәр фашист көчегедер. Мондыйлар каршында Гыйниятулла олпат, озын гәүдәсен турайта биребрәк, күкрәкне киерә төшеп үтә. Башны да югарырак чөя.

Атлый торгач, мәшһүр Бранденбург капкасына барып җиткәнен Яубасаров сизми дә калган. Ә ары таба — Тиргартен паркы. Бу якларга килеп чыккан саен Гыйниятулла шушы бакчага хәйран кала. Иге-чиге юк төсле аның. Чын

булса, ике йөз илле гектар, диләр, үзен. Шәһәр уртасында шушы кадәр зур парк җәйрәп ятсын әле — ис китмәслекмени!

Рейхстаг та шушы төбәктә иде. Илле-алтмыш адым җитмәсрәк, Яубасаров, аякларын киерә басып, кулларын ике бөеренә салган килеш, тукталып калды. Гыйниятулла бүген аны, рейхстагны, бихисап ядрәләрдән авыр яраланып, кансырап егылган гаҗәп зур соры бүрегә охшатты. Ә ул, Гыйниятулла Яубасаров, җиңүче солдат, мәңгелек һәйкәл сымак, менә аның каршысында күкрәк киереп басып тора!

Мондый чакта ни генә уйламас та, ни генә кичермәс дисең утны-суны узган яугир! Гыйниятулла каты итеп бер кулын селтәп куйды, «э-эх!» дип, нәрсәгәдер үкенгән сымак та итеп алды. Аннан, җай гына кузгалып, эре, олпатлы адымнар белән парад ишегенә таба туп-туры килде дә унга борылды. Стенадагы язулар тагы да ишәйгән сымак. Төрле кул, төрле төстәге буяулар белән сызгаланган исемнәр, фамилияләр... Ул да икенче майда, рейхстагны алган көнне, карабин штыгы белән чокып, башкортча «Яубасаров Гыйниятулла» дип, үзенең тамгасын калдырган иде. Истәлеккә! Әле менә кинәт, ни өчендер, улының, Тимербулатының, исемен дә шунда язып куясы килде. «Бәлки, берәр вакыт үзе дә күрер»,— дип уйлады микән? Белмим, ни уйлагандыр, әйтүе кыен. Ләкин шунысы: ничек, нәрсә белән язарга? Уйлана торгач, келт итеп аның исенә төште: аларның взводындагы бер солдат сурәт ясау белән мавыга бит...

Күрәсең, Гыйниятулланың теләге бик көчле булгандыр, тәки иренмәде, әллә кайдагы казармага кайтып, кире урап килде. Кулында башланмаган тюбик, мул гына кыллы пумала иде. Һәм ул тырышып-тырышып, матур итеп, үзенең исеме янына кызыл буяу белән «Тимербулат» дип язып куйды.

Аннан китте Шпрее буена, Трептов-паркта хәтсез генә йөрде, ул да булмый, ниндидер тап-тар, караңгы урамнарга барып чыкты. Монда, ничектер, һава җитмәгән сымак, буылган сымак тойды үзен, шуңа күрә тизрәк ул иркенгә, яктыга ашыкты.

Яубасаровны күбрәк архитектура истәлекләре, һәйкәлләр кызыксындыра иде; хәер, Берлин кебек мәшһүр шәһәрдә чит күзне җәлеп итәрдәй нәрсә аз дисеңмени? Ә Гыйниятулла — крестьян баласы, авылда туган, авылда үскән. Алтын манаралары күккә ашкан чиркәүләргә, зиннәтле сарайларга, тугызар-унар катлы берсеннән-берсе

мәһабәтрәк биналарга күзләрен төбәп тора да адәм затының акылына, адәм кулының осталыгына шакката.

Ә менә шуларның күпмесен генә сугыш гарасаты аяды икән дә күпмесе генә бер дә зарарланмыйча имин-аман көе калды икән? Йортларда да солдат язмышы: кайсысы, снаряд тиеп, авыр яраланган, кайсысы, фугас бомбаларыннан нигезенә кадәр җимерелеп, бөтенләйгә юкка чыккан иде. Шушы хәрабәләргә карый да, җаны тетрәнеп, гади бер таякның гына да кадерен белә торган Гыйниятулланың крестьян йөрәге шашып дуларга керешә. Ә бит кеше дөньяга килә дөньяны ямьләр өчен, матурлык тудыру өчен, төзү, кору өчен. Булганны җимерү, вату, кыру өчен түгел!.. «Әй сез, сугыш чукмарлары, карагыз әнә Берлиныгызга, менә нәрсәгә ирештегез, менә ни хәлгә аны дучар иттегез!» — дип бөтен шәһәргә ишетелерлек итеп Яубасаровның кычкырасы килде.

Әнә шулай бер сокланып, бер көрсенеп йөрде Гыйниятулла. Ә кичен үзен бөтен рота җыелышып озатып калды. Шатлыклы да, моңсу да аерылышу иде бу, бигрәк тә старшинаның хәстәре аны нык дулкынландырды.

— Улыңа, Тимербулатыңа, миннән бүләк, — диде дә Яубасаровның кулына яңа туган колын зурлык уенчык ат китереп тоттырды.

Старшина аны элек-электән якын итә иде, Гыйниятулла моны гелән сизеп йөри. Язмыш аларны кырык беренче елның көзендә, Мәскәү янындагы үлемечле алыш мәлендә, ут эчендә очраштырган иде. Дөрес, аерылышып торган чаклары да булгалады: йә старшинаны снаряд ярчыгы аяктан ега, йә Гыйниятулланың юлын пуля кисә. Госпиталь койкаларында күпмедер аунаганнан соң, янә килеп кавышалар.

Нарком йөз граммына әзрәк немец шнапсын да өстәп җибәргән чакларында старшинаның:

— Без бит, брат, синең белән бер башкаладан икенче башкалага кадәр табанлап үтүчеләр. Бөтен ротада ике генә бөртек бит без! — дип әйткәне бар Яубасаровка.

Бер шулай Гыйниятулла хат укып утыра иде, старшина аның янында тукталып:

— Нәрсә язалар? — дип сорады.

Миңлебадәре Тимербулатының аягын, кулын ак кәгазьгә сызып җибәргән иде. Яубасаров, әлеге сурәтләрне күрсәтеп:

— Иң зур, иң шатлыклы хәбәр менә шул, — диде.

Сүзгә сүз ялганды, хәтсез генә әңгәмәләшеп алдылар. Шушы сөйләшүдән соң старшина, җае чыккан саен:

— Тимербулат ни хәлдә? Үсәме? — дип сорар иде.

Әле килеп менә ул нинди зур ихтирам күрсәтте. Гыйниятулла ни, солдат кеше, чос кеше, югалып калмады, бүләккә каршы бүләк итеп, беләгендәге сәгатен чиште дә старшинага сузды.

Старшина мыегын бора-бора елмайды:

— Минем бар бит, кара циферблатлысы, швейцарский, — диде ул, үзенекен күрсәтеп. — Рәхмәт, иптәш Яубасаров, кирәкми. Әмма хәтер калыштан түгел, кара аны, — дип, бармагын селекте һәм: — Немец штамповкасы булса да, үзенә дә ярап торыр шунда, — дип көлеп өстәп куйды.

— Ярый алайсаң, әйткәнеңә күнәм, ләкин, иптәш старшина, бер шартым бар, — Гыйниятулла да, мут кына елмаеп, командирының күзенә туры карады.

— Йә.

— Үзең Чиләбенекесең, юлың — безнең аша, Башкортстан аша. Кайтышлый мотлак миндә тукталып китәсең. Кунак булып, Тимербулатымны күреп!

Старшина, чак кына да икеләнмичә, Яубасаровка кулын сузды:

— Егет сүзе бер булыр!

...Поезд юнәлешен үзгәртте, ахрысы, Гыйниятулланың битенә кояш төшми башлады. Ул менә әле генә күзен ачты, һәм старшина бүләк иткән теге ат кинәт аның исенә төште. Кичә аны юньләп карарга да өлгермәгән иде, буйлы матрас тышына шаулаша-гөрләшә тыктылар да үзен, киттеләр күмәкләшеп вокзалга. Старшина, отделение командиры һәм котелокташ дусты аны поездга утыртып, озатып калдылар.

Гыйниятулла, җәһәт кенә кузгалып, матрастан атны чыгарды да идәнгә бастырды. Нәкъ шул вакыт, тәрәзәдән үрелеп карагандай, тагы кояш балкып китте.

Кайчы колак, дуга муен, куе бөдрә ял, бәкәлләренә төшеп торган озын койрык. Таңкәләр белән бизәлгән йөгән... Үзе саф көмеш төсле ап-ак. Тоганы әкиятләрдәге акбуз ат инде! Өстәвенә, күзләрне кинәндереп, өстендә аның чагу нур уйный.

Яубасаров, йотылырдай булып, карашын бер ноктага төбәде дә бөтен дөньясын онытты. Ирен очлары гына сизелер-сизелмәс ара-тирә кыймылдап куя иде. Менә ул, хас тере хайванны сөйгәндәй итеп, көмеш атның аркасыннан йомшак кына сыйпап алды.

— Вәт, ичмасам, бу мал! — диде шулчак бер солдат, аның янында туктап.

Аңа икенчесе өстәде:

— Дөлдөл инде, дөлдөл!

Ә өченче берәү — төскә яшь кенә танкист — танау буеннан гына беравык карап торды да:

— Әй исәр баш, тапкансың трофей! — диде һәм кукыр гына атлап китеп барды.

Ялт итеп, Гыйниятулла башын шул якка борды, бик әче итеп аның нәрсәдер әйтәсе килде, ләкин өлгерә алмады, янәшә басып торган бер карт мичман яңгыравыклы бас белән:

— Мөрәвәтсез! — дип кычкырды. Аннан азрак торгач: — Салага! — дип тә өстәде.

Шулчак вагонның аргы очында кемдер карлыккан тавыш белән сөрән салды:

— Әйдәгез, братва, немец шнапсына рәхим итегез! Жәл түгел, миндә ул менә тулы канистр!

Чынмы бу, буш сүзме дигәндәй, халык каранышып, елмаешып куйды, ләкин берәү дә шунда ук кына урыныннан кубып китмәде. Шулай да, азрак торгач, берәм-берәм, әкрен-әкрен генә шнапс ягына шуыштылар. Күп тә үтмәде, аргы очта кемдер гөрелдәтеп баян тартып җибәрде. Икенчесе ана җыр белән кушылды:

Бьется в тесной печурке огонь,
На поленьях смола как слеза.
И поет мне в землянке гармонь
Про улыбку твою и глаза...

Ә Яубасаров исә һаман шул атына карап-сокланып утыра бирде. Менә ул өенә кайтып керү белән аны, көмеш атны, Тимербулатының алдына гына туп иттереп китереп бастырыр. Нишләр икән шул чак сабый? Шатлыгыннан көлеп җибәрерме? «Ат, ат!» — дип кычкырырмы икән әллә? Үскәндер инде хәзер, шунда ук менеп тә атлануы бар. Әй, куаныр да соң! Бала кеше генә түгел, олыларның да исе китәр әле. Бигрәк матур бит, тере кебек, җаны гына юк. Анавы елны арба алып кайткандагы сымак, бөтен күрше-күлән таң калыр.

II

Ир-ат халкы борын-борыннан шулай: өйләнергә өлгерми — кәләшеннән малай давайлый башлый. Гыйниятулла исә тәүге баласын аеруча ашкыну, түземсезлек белән көтеп алды. Үзенә күрә сәбәбе дә юк түгел иде шул: дүрт кыз арасында бер малай, әнисе әйтмешли, дүрт солы арасында бер арыш булып үсте ул. Төпчек малай, иркә малай булып. Кызык, ә аңа Миңлебәдәре кемне бүләк итәр икән?

Туасы җан иясе үз чамасын үзе белә, күрәсең, менә аның да вакыты җиткәндер, ахрысы, әле генә кыштыр-кыштыр йөреп яткан Миңлебәдәр бер кечне йөрәк тавышы белән кинәт «аһ» итеп куйды да сәкегә барып ауды. Шул арада иреннәре күгәреп китте. Сүзен дә чак-чак кына кысып чыгарды:

— Әбигә... йөгер...

Миңлебәдәрнең «әбигә» дигәне Хафиса карчык иде, исемен атап әйтмәсә дә, һәркемгә билгеле ул, чөнки авылның бу төбәгендәге бөтен бәбәйләрнең кендеген ул кискән.

Кендек әбие урам аша гына тора иде, Гыйниятулла аны «әһ» дигәнче җитәкләп тә керде. Хафиса карчык Миңлебәдәргә күз генә сирпеп алды да Гыйниятулланы чыгарып ук җибәрде:

— Бар, балакай, безгә кереп ят. Алла боерса, исән-сау гына котылгач, үзем әйтермен.

Гыйниятулла, әлбәттә, ихатадан беркая да китмәде. Абзар-кура тирәсендә арлы-бирле тулгана да ишеккә барып колак сала. Аннан берәм-берәм тәрәзәләргә күчә... Болай мәгънәсезгә киләп салу ялкытып җибәрде булса кирәк, январь суыгы да кытыклый башлагандыр, күрәсең. менә бермәлне ул утынлык янында тукталып калды. Балта шунда — түмәргә чабулы, күктә тулган ай. Тотынды дөп тә шап утын ярырга... Аннан көрәккә күчте, көрт мул иде ул елны, теләсәң күпме көрә — җитәрлек.

Шулай тирләп-пешеп абзар артындагы мунчага юл яра иде, кинәт Гыйниятулланың колагына «ай-ай!» дигән тавыш чалынгандай булды. Ул, ук шикелле атылып, түр тәрәзәгә килеп капланды.

— А-ай! Ән-кәй! Әнкәй генәм!!.

Маһибәдәрнең шулай өзелеп-өзелеп кычкырган сүзләре Гыйниятулланың йөрәгенә килеп кадалды. Баскан җирендә хәтта сыгыла биреп куйды. Инде төн урталары җиткәндер, ә аның кәләше әнә ничек һаман җәфалана икән!

Гыйниятулла моннан ары тәрәзә төбеннән бер генә адымга да кымшанмады. Ләкин инде аңа әллә ни озак тунарга туры килмәде бугай, чолан ишеге шыгырдап ачылды. Өйдәгеләр, күрәсең, йорт тирәли аның бәбәй көтеп йөрүен сизеп торган, Хафиса карчык болдырга чыгып басты да:

— Гыйниятулла улым!— дип тавыш бирде. Кендек әби мыштырдаганчы, Гыйниятулла инде ишек төбенә йөгереп килеп җиткән иде.

— Әйе... мин...

— Әй-әй... күзеңә ни әйтим, күрми дә торам. Монавы салкында төне буе сакладың, нәселең затлы шул, рәхмәт, балакай. Ходай боергач, иншалла, менә исән-сау котылды. Тәүге бала кайчак шулай авыррак була инде... Әйе... Ә син нишләп сорамыйсың әле... кемең барлыгын?

Миңлебәдәрнең баягы үзәк өзгеч тавышы Гыйниятулланың йөрәгеннән һаман китмәгән иде, шуңа күрә ул бу турыда белешергә дә уңайсызланды. Шулай да кызыксынуы җиңде барыбер:

— Кем соң?— диде, кәләше ишетмәсен дигәндәй, әкрен генә.

— Куан, балакай... кызың бар! Шундый матур, шундый чибәр!.. Әй-й, мин исәр, кайчаннан бирле монавында лыкылдыйм. Өйгә кер әйдә тизрәк, җылыга, кызың янына,— дип, Хафиса карчык һаман сөйләнә-сөйләнә Гыйниятулланы үзе белән ияртеп кереп китте...

Икенче балалары да кыз булды. Өченчегә дә кыз тугач, күрә Гыйниятулла: кәләшенең төсе бөтенләй үзгәрде бит. Иренә, хәләл җефетенә дә, туры карарга кыенсынган сымак. Егетлек түгел, әгәр мондый чакта Гыйниятулла да аны юатмаса. Әйе, кем табар дисең аның китек күңелен? Гәрчә үзенең дә эчен кара песи тырнап-тырнап алса да:

— Башыңны имә, җаным, сиңа алай килешми,— диде ул, Миңлебәдәрнең аркасыннан сөя-сөя.— Күрәсең, безнең якка, безнең нәселгә тарттык. Исең китмәсен, менә әйткән иде диярсең, дүртенче балабыз да кыз булырга тиеш. Ә бишенчесе инде — мотлак малай!

Гыйниятулла, шулай итеп, бөтен гаепне үз өстенә аударды. Ирләрнең бер матур сүзе, якты йөзе хатын-кызны канатлы итә. Әле менә Миңлебәдәр үзенең Гыйниятулласы өчен утка керергә дә, аның алдында чәче белән җир себерергә дә әзер иде!

Ә шулай да Миңлебәдәр дүртенче балаларын да Гыйниятулланың кызга юравы белән килешергә теләмәде. Уйлап-уйлап торды да китте Хафиса карчыкка. Киңәшиә. Им-том белән дә шөгыльләнә, үзе харап дигәнчә галим, авызында гел китап сүзе, бәлки берәр төрле акыл бирер. Туптай малай табып куйса, карап та торыр аннан Гыйниятулласы! Мул гына садакасын карчыкның учына салды да үтенечен сөйләп бирде.

— Ходай әше инде бу, балакай,— диде Хафиса әби, зур мәгънәле итеп башын селкеп.— Тиздән изге рамазан ае җитә, багышлап ураза тот. Иртән, таң алдында, кыйблага карап, ходайдан үтен.—Шуннан ул самавырдан чүмечкә кайнаган су агызып алды да, аны озак кына өшкергән-

нән соң, шешәгә тутырып, Миңлебәдәрнең кулына тоттырды.— Монысы Гыйниятулла өчен. Тыным харап шифалы. Сөт яратамы? Эчәме?

Миңлебәдәр нигәдер көлемсерәп куйды.

— Бирсәң — эчә.

— Җылы сауган сөткә тамчылап кына сал. Һәр көнне.

Хафиса карчыкның кушканнарын Миңлебәдәр бик җиренә җиткереп үтәгән иде югыйсә, ләкин ходай аның ялварып сорауларын ишетмәде, өшкертелгән суның да шифасы тимәде. Ә менә иренең сүзе, чынлап та, дөрескә чыкты: рәткә дүрт кыз тапты ул. Ә инде бишенчесе турында Гыйниятулла хаталанган. Бишенчесе дә кыз булды бит!

Бу юлысы Гыйниятулла үзе дә шактый нык уйга калды: әллә югыйсә, чынлап та, насыйп түгел инде аңа малай йөзе күрергә? Бүрегең янына бүрек элүче дә булмагач күңелсез бит әле. Җирдә дәвамың калмаса, хәтта фамилияң да калмаса — бу дөньяда нигә яшәргә? Үкенечле... Бер шулай аштан кайткач, кызмача баштан, күпме сабыр акыллы Гыйниятулланың Гыйниятулласы, шаярткан булып кына:

— Син әй, тора торгач, безнең энкәйне дә уздырдың,— дип әйтеп куйды.

Миңлебәдәр дә табында авыз йомып кына утырмаган иде, әче балның тәмен ул да әзрәк татып караган иде, әле батыраеп китеп, ирен үзе кочаклап алды да кычкырып елап җибәрде. Үзе елый, үзе такмаклый:

— Әй Гыйниятуллакаем, бәгырькәем, синең өчен җаным жәл түгел! Ни чаралар гына кылыйм соң? Күрәсең, ходайның язганы шулдыр. Мин сиңа арыслан кебек малай табып бирер идем дә бит... Нишлим соң, нишлим?..

Җитмәсә, бер тишек авызы магазинда бөтен миргә сөйләгән: янәсе Гыйниятулланың бичәсе ел саен язын бәбәйли, көзен бүлтерекли, имеш. Хәзер, имеш, кызлар белән өе тулган!

Шулай да Гыйниятулланың хатасы зур түгел иде: бер генә санга ялгышкан, алтынчысы бит малай булды! Ул көнне Гыйниятулласы бичәсенең яныннан да китмәде: әле маңгаеннан чуп-чуп үбеп ала, әле ияреннән, әле күзләреннән... Ә Миңлебәдәрнең бер бите ай, бер бите кояш! Үзен бәбәй мунчасына да ире кул очында гына күтәреп алып барды, күтәреп алып кайтты...

Көн дә бәйрәм, көн дә туй дигәндәй, шуннан агыла башлады бәбәй бәлешләре. Йоласы шул: дөньяга килгән баланы, аның ата-анасын котлыйлар, кардәш-ыру, дус-иш, күрше-күлән — берсе дә калмый. Гыйниятулла белән Миң-

лебәдәребез, элеккеге мулла белән абыстай шикелле, ай буена дип әйтерлек һәркөнне майлы бәлеш ашадылар.

— Сизденме, бичәкәй, малайның малай инде, кызларга караганда бу юлысы бәлеш тә күбрәк килде,— дип, бер кичне, авыз ерып, сөйләнеп торды Гыйниятулла да.

Әлбәттә, тамак өчен генә әйтелгән сүз түгел иде бу, чормада каклаган каз, казылык, бурасы тулы иген, он, ярма — шөкер, хәзинәдә бөенесе дә җитәрлек. Аннан шунысы да һәркемгә билгеле: бер бәлеш белән генә табын түгәрәкләнми, хуҗабикә исә аның янына, өстәл тутырып, аллә никадәр сый-хөрмәт әзерли. Дус бар, дошман бар, дигәндәй, кеше арасында аны санлап-олылап килүләренә рәхмәт, шуңа куанды ул.

Ә көннәрдән бер көнне Гыйниятулла исем туе хакында сүз чыгарды.

— Әллә, атасы, гомердә кыланмаганны, булышмыйбызмы? — дип, Миңлебәдәр бу юлы аңа каршы төште.— Тавык тутырып, фәрраш бабайны чакырырбыз да... Кызларга да шулай иттек бит.

— Бит тутырган тавык бер сарык кадәр буладыр ул, әй,— диде Гыйниятулла, көлеп.

Миңлебәдәр аның кинаясен аңлап җиткермәде, ахрысы:

— Нәрсә дисең? — дип кайтарып сорады.

— Сарык, дим. Тавык нәрсә... Кош та булдымы мал. Сарык суябыз!

Шуның белән сүз бетте. Печән вакытында кирәге булыр дип, күптән әче бал койган иделәр, әле, әнә мич башында җырлап утыра. Кысыр сарыклары бар — арада иң зуры, иң көре. Тагы ни кирәк? Шулай итеп, бер көнне уйлаштылар, икенче көнне гөрләтеп табын да җыйдылар.

Күренүенчә, тәүдә иренең сүзен Миңлебәдәр каш җыерыбрак тыңлаган иде дә, әмма азак, аш узгач, үзе үк куанып бетә алмады.

— Гаҗәп тә күңелле булды, адәм арасында сүзе ни тора, әле дә үткәрдек! — диде кат-кат.

Хуҗабикә шулай канәгать калгач ни, кунакларга инде әйтергә дә түгел. «Вәт, ичмасам, Тимербулат сыйлады дисәң дә сыйлады!» — дип, бик озак сөйләп йөрделәр.

«Тимербулат ашы» турындагы сүзләре әле тынып та өлгермәгән иде, Гыйниятулла бөтен авылны янә «аһ» иттерде. Тагы бер сарыгын егып суйды да бу, базарга чыгарып сатты һәм, акчасын учына йомарлап, китте Уфага. Нигә киткәнен хәләл җефетенә дә әйтмәде.

— Бу нинди эш тагы? Кара син, сер яшерә!.. — дип, Миңлебәдәр кызыбрак та караган иде, юк, Гыйниятулла-

ның теш арасыннан ярты сүз дә чыкмады. Елмаеп тик тора. Әнә шул елмаюы гына хатынының шөбһәле күңеленә берникадәр сабырлык бирде. Әмма шулай да, сәер иде бу хәл, бик сәер...

Ә Гыйниятулланың бөтен сере шул гына иде: кинәт бер ханым исенә төште аның. Уфада Якут бакчасында очраткан иде ул аны. Аллея буйлап китеп бара шулай. Тәүдә аның эшләпәсенә игътибар итте. Кош каурыйлары кадап, әлләниләр кыландырып беткән. Кызыксынып, йөзенә дә карады. Янәсе, мондый эшләпәләрне кемнәр кия икән? Күрүе булды, менә хикмәт, аяклары тышауланды да куйды. Ярый әле шушы ханымга каршы гына эскәмия бар иде, чүкте шунда.

Өч көнлек ай төсле сызылып-дугаланып торган кашлар, сихри озын керфекләр, аккош мамыгы кебек йомшак-нәфис битләр (үзе аңа, аңлашылуынча, тырнак очы белән генә кагылмаган булса да, нигәдер Гыйниятуллага нәкъ менә шулай тоелды), ә иреннәре инде... Хәер, аның бөтен чибәрлекләрен сөйләп тә, тасвирлап та бетерерлек түгел иде. Моның өчен мотлак аның үзен күрергә кирәк. Юкка дисеңмени, әнә, Гыйниятулла эскәмиядә һушы китеп утыра. Үзенең күзләре шардай, ә авызы ачылган.

Ходайның шушы илаһи заты, әлбәттә, берәүнең хәләл җефетедер. Ул аны шашып-рәхәтләнеп сөядер, иркәлидер, үбәдер... Ә менә Гыйниятуллага, аның матурлыгына кинәнеп, бөтен дөньясын онытып, туйганчы бер сокланырга да насыйп итмәгән. Чибәр ханым, күрәсең, кемнеңдер аңа комсызланып текәлеп торуын сизгәндер (чит карашны кайвакытта җилкәң белән дә тоясың), әйе, сизгәндер дә, мөгаен, өнәп җиткермәгәндер — җай гына урыныннан кузгалды.

Ханымның янәшәсендә генә балалар арбасы тора иде, менә әле ул аңа барып кагылгач кына Гыйниятулла нык-лап игътибар итте. Монысы да бер могҗиза: борынгырак заманнардагы көймәле фаэтоннар сымак, ә үзе тоткасына, тәгәрмәчләренә кадәр ап-ак металлдан. Менә ханым аны ике кулы белән этәреп, Гыйниятулланың борын төбеннән генә үтеп тә китте. Әллә нинди исерткеч хуш исләр аның танау эчен хәтсез генә вакыт рәхәт кытыклап торды...

...Тәүге кызлары тугач, бишекне Гыйниятулла үзе ясап, төбен дә киндердән үзе тегеп биргән иде. Биш кыз үстергән шушы бишек, бүген килеп, малай атасына нигәдер охшап җитмәде. Саерак та, бәләкәйрәк тә төсле тоелды. Кызлар да бит егылып төшкәләгән иде, ә малай ул тын-

тысызрак та була. Кыскасы, шушы көнне үк менә дигән иттереп, тирәче ике катлы яңа бишек ясап та әлде!

Аннан күзе төште балалар арбасына. Вакытында анысын да үзе әмәлләгән иде. Әле шуны әйләндергәләп күпмедер карап торды да бер як читкә этеп үк куйды. Болай итүенең сәбәбе әнә шул чибәр ханымга барып тоташа да инде: аның үзе кебек хәйран купшы арбасын Гыйниятулла һаман онытмаган икән, әнә шул күз алдына килде дә басты. Тимербулаты өчен, күпме гомерләр кәтеп алган малае өчен, җәлмени шундый бер арба! Нәкъ менә шул көнне икенче сарык суелды да инде.

Шулай итеп, Гыйниятулла кинәт кенә уйлады да, поездга утырып, Уфага китеп тә барды. Кесәсендә акча, күзе, әнә, тәрәзәдә, ләкин уе Миңлебәдәре тирәсендә иде. Бик боек карап калды, хәтерен калдырмаган гына булса ярар иде. Серне чишәргә укталып та куйган иде ул, тагы тукталды. Арбасы да, аның хуҗасы чибәр ханым да бер хәбәр бит, ничек инде аны бүлеп сөйләмәк кирәк? Ни яме дә, ни тәме кала аның. Ә шушы ханымга карап һуштан язуыңны кайсылай итеп хатыныңа әйтәсең? Әллә ни уйлавы бар. Болай да урыныннан купкан йөрәгенә шом өстәү генә була бит ул.

Гыйниятулла, трамвайга утырып, вокзалдан кала өстенә күтәрелде дә магазинга түгел, туры Якут бакчасына китте. Ни өчен? Теге чибәр ханымны очратмаммы дипме? Ай-һай, алай нәфесне бик зурга сузу була түгелме? Нишлисең, теләгән — елан ите ашаган. Ә шулай да, иң хәерлесе — белер-белмәс кәйгә, бүрәнә аша бүре күреп, алдан ук кешегә әллә нинди гөнаһлар такмыйк әле. Кирәге чыга икән — вакыты җиткәч тә өлгерербез.

Бакчага барып керү белән Гыйниятулланың күзе биш булды. Тегендә дә арба тоткан ханым, монда да арбалы ханым. Әле берсенең янына ул мыштым гына килеп баса, әле икенчесенең. Адәм затының фантазиясенә исе китте: шул балалар арбасының ниндиләре генә юк икән! Бакчаны бер аркылы, бер буй төшеп, хәтсез генә йөрде Гыйниятулла. Тик шунысы гаҗәп: теге чибәр ханымныкы ише арба очрамады. Шуңа азрак кәефе кырылып, өянке күләгәсендәге эскәмиягә барып утырды да кесәсеннән чигүле тәмәке янчыгын чыгарды.

Ләкин бит калага ул бакча буйлап күз атып йөрү өчен килмәгән. Тәмәкесен төбенә кадәр дә тартып бетермичә Гыйниятулла, кабаланып, урыныннан күтәрелде. Аягына басты, әмма тиз генә кузгалып китә алмады. Бакчаның теге очындагы берәүгә күзе төште. Менә хикмәт: Гыйния-

тулла шулай тора бирә, ә йөрәге аның торган саен катырак тибә. «Йа хода, шул үзе, чибәр ханым килә түгелме соң?» Чагу кояш нурында ялтыр арбасы ялт-йолт итеп китә. Валлаһи, шул, башында кавырсынлы кадимге эшләпәсе. Гыйниятулланың моннан ары түземлеге бетте, эреэре адымнар белән китте ул аңа каршы.

Бара торгач, ап-ачык күрә Гыйниятулла, арбасы да шул, эшләпәсе дә шул, тик ханым үзе генә бөтенләй башка иде. Нихәл итәсең, кабат очратырга язмаган, күрәсең.

Хәер, Гыйниятуллага бит ханым үзе түгел, арба кирәк! Ә ул, әнә каршысында гына, теләсәң күпме кара, соклан.

Карашы каты, ахрысы, Гыйниятулланың, аның йотылып төбәлеп торуын бу ханым да сизде.

— Әллә бик ошадым инде үзенә,— диде ул, энҗедәй тешләрен матур елтыратып.

Менә шунда безнең Гыйниятуллабыз сынатты. Хатынкызның күңелен табу өчен күп кирәкмени, әйтмәде бит өздереп шунда йөрәген җилкендерерлек бер сүз!

— Үзең түгел, арбаң охшады,— диде.

Чалт аяз көнне ханымның йөзеннән болыт шәүләсе йөгереп үтте. Ярый әле кылтымбый түгел, үпкә сакламады, янә аның энҗе тешләре елтырады.

— Сатам.

Күрер күзгә ханым Гыйниятуллага караганда күпкә яшь иде, шулай да, шәһәр халкына ихтирам йөзеннән:

— Авыл кешесе дигәч тә, шаяртма, апай,— диде ул житди генә.

Сөйләшә торгач, бу ханым харап ачык күңелле, телдәр кеше булып чыкты. Гыйниятулланың Уфага нигә килүен белгәч:

— Үзең дә егетнең асылы икәнсең! — дип, аны, җиде кат күккә күтәреп, мактап та ташлады. Аннан арбасын күрсәтергә кереште. Кирәк икән — өстен, артка шудыртып, ачып куясың. Кояш төшмәсен дисәң — түбәсен бөтенләй үк каплатып та була. Ә шушы әгъләә көймә үзе пружиналар өстендә генә тирбәлеп утыра. Кыскасы, ханымның сөйләвенчә, моңа тиң арба дөньяда бүтәнчә юк икән.

Гыйниятулланың кызыгуы хәттин ашты:

— Ә кайда саталар аны? — дип, кабаланып сорады ул.

Телдәр ханым бик җентекләп магазин юлын өйрәтте дә:

— Мин дә кичәгенәк кенә алдым, бар, йөгер, бәлки өлгерерсең,— диде.

Дөресен әйткән ханым, йөрәге дә сизгер икән үзенең, бердәнбер генә арба торып калган иде. Өстәвенә, рәхмәт яугыры, сатучы кыз да аны куандырды.

— Аласыңмы, бәбәй бүләге дә бар, приданый,— диде ул, үзе тәкъдим итеп.

Менә шундый уңган юлга чыккан Гыйниятулла бүген. Очып барды шәһәргә, очып кайтты авылына. Кызларының зурраклары, Раузасы белән Венерасы, поезддан аны каршы алырга менгән иде, әтиләренең вагоннан килеп төшүе булды, икесе берьюлы:

— Көмеш арба! — дип кычкырып та җибәрде.

Гыйниятулла арбаны кызларына тоттырды да үзе олпат-салмак адымнар белән җай гына аларның артыннан атлады. Кояш инде баю ягына тәгәрәгән иде, көтү кайтыр вакыт җитеп килә, капка төбе саен әби-сәби, хатын-кыз, һәм һәркайсысы дип әйтерлек Гыйниятулланы мотлак туктата. Арбаның адәм кулы тимәгән урыны калмагандыр, шулай җентекләп тикшерәләр, карыйлар. Уфадан авылына кайткан вакытка караганда — ә бит бик бәләкәй ара түгел, җитмеш чакрым җир — разъезддан өенә кадәр, валлаһи, озаграк үткәндер.

Юлда нинди генә мактау, соклану сүзләре ишетмәгән иде, тик Миңлебәдәре генә:

— Шуның өчен сарык башына җиттеңме? — дип, Гыйниятулланың кикриген бераз шиңдерде.

Әлбәттә, сизде ул, хатынының бу сүзе әйбер танымаудан түгел, иртәнгенең ачуын кайтаруы иде. Әмма шунысы әйбәт Миңлебәдәрнең: авыз турсайтып йөри торган гадәте юк. Яңа гына ни әйткәнен онытты да, ахрысы, балаларның чыр-чуына кушылып, үзе үк арбаны мактарга кереште:

— Әй, Гыйниятуллакаем, осталыгын әйт син бу хөкүмәтнең, коеп кына куйганнар бит!

Аннан бәбәй бүләген сәке тутырып таратып ташладылар. Бигрәк тә кызлар нык куанды, әйтерсең әтиләре аны үзләренә алып кайткан. Әле кендек күлмәген тотып-тотып карыйлар, әле башлыкларны. Раузасы мамыктай йомшак фланель юргәкне[1] башына каплады да:

— Бу бит яулык кебек, Тимербулатның астына салырга да җәл, пычратып куйса...— ди, үзе шырык-шырык көлә.

Менә шулай өй эче кинәт кенә мөлдерәмә шатлык

---

[1] Юргәк — бала искесе.

белән тулды. Гыйниятулла балаларына кинәнеп карап торды да:

— Киендер әле егетемне, күрик,— диде хатынына.

Миңлебәдәр, Тимербулатны бишектән алып, итәгенә салды да күгәрчен сымак гөрләп тә җибәрде:

— Бик тә ярата икән атасы улымны. Нинди тәтәй киемнәр алып кайткан. Кара ничек килешеп тора үзенә. Һай, чибәр дә егет соң безнең Тимербулатыбыз. Чибәр дә егет соң!..

Тимербулатны яңа киемнәренә киендереп, сөт шикелле ап-ак яңа япмага урап, арбага салдылар да идәннең уртасына гына китереп куйдылар. Гыйниятулла бер як читтән карап сокланып тора. Аның янына Миңлебәдәр дә килеп басты. Ә кызлар, чыр-чу итенешеп, арба тирәли сырпалана.

— Бигрәк матур булды Тимербулат! — ди, чәбекәй итеп, Рауза.

Апасының сүзен Венера да куәтли:

— Хас та курчак кебек! Курчак кебек!..

— Алай бик тә чибәр булгач, егетебезгә күз тиеп куюы да бар,— диде Миңлебәдәр һәм улының иске башлыгына тегелгән ахакларны сүтеп алды да яңасына тагып куйды. Аннан такмаклый-такмаклый башына кидерде:

Күзегез улыма тимәсен,
Тисен зәңгәр ахакка!
Күзегез улыма тимәсен,
Тисен кызыл ахакка!
Күзегез улыма тимәсен,
Тисен яшел ахакка!

Нәкъ шул вакыт укытучы апа килеп керде.

— Гыйниятулла көмеш арба алып кайткан икән дип бөтен авыл шаулый,— диде ул, ишектә күренү белән.— Әле Хафиса әби тотып алды да үземне, сөйли дә сөйли шуны, һушларың китәрлек, ди. Тукта әле, мин әйтәм, алай булгач, мин дә бер һуштан язып чыгыйм.

Укытучы арбага уңнан да торып карады, сулдан да. Тимербулатны тирбәтеп тә алды.

— Чынлап та, затлы әйбер икән шул,— диде ул аннан.— Балаларыгызга игътибарыгыз әйбәт, рәхмәт сезгә! — Ә ишек төбенә җиткәч, борылды да хуҗага карап: — Үзең дә фартавай икәнсең, һәрвакыт шулай бул әйдә! — дип, Гыйниятулланың күңелен тагы бер иллегә үстереп җибәрде.

Укытучы чыгып киткәч, Гыйниятулла Миңлебәдәрнең бөеренә төртеп алды.

— Ишеттеңме?

— Ярый, ярый, бик шашма да син! — Шулай дисә дә, бу минутта Миңлебәдәр үзен бик бәхетле итеп тоя иде.

Ә иртәгәсен сугыш чыкты.

Төп-төгәл бер айдан Гыйниятулланы армиягә алдылар. Биш кызын ияртеп, Миңлебәдәр аны разъездга кадәр озата барды. Тимербулат исә, бер нәрсә белмичә, мыш-мыш килеп арбада ятып калды. Дүрт ел буена шушы күренеш Гыйниятулланың күңеленнән чыкмады, көмеш арба һәрчак йөрәгендә йөрде.

III

Ярсу паровоз Гыйниятулланы үзләренең разъездында төшереп калдырды да, аның белән хушлашкан сымак, аксыл-соры төтен тасмаларын зәңгәр күктә болгый-болгый ары китте. Әй туган җир! Кинәнеп, үз аякларың белән бер басып торуың гына да, аңлаган кешегә, бер гомер бит! Әй туган як! Рәхәтләнеп, үз күзләрең белән бер карап тору өчен генә дә утлар-сулар кичәргә риза булырсың. Гыйниятулла шулай йотылып-онытылып, комсызланып байкады әйләнә-тирәсен. Чагу кояш нурларында күкрәгендәге ике Ватан сугышы ордены, Мәскәүне саклаган һәм Берлинны алган өчен бирелгән медальләре ялт-йолт итеп китә. Ә уң ягында аслы-өсле биш тасма: икесе сары, өчесе кызыл төстә.

Менә Гыйниятулла яшел чирәмдә яткан солдат капчыгын иелеп алып кулбашына элде, аннан көмеш атны култыгына кыстырды да салмак, эре адымнар белән авылына таба юл алды. Разъездда да беркем очрамаган иде, әле урамга килеп кергәч тә кеше-кара күренмәде. Ниндидер сәер тынлык, авыл бөтенләй буш сымак. Хәер, көн үзәгендә мондый мәлдә кем йөрсен, яланда эштәләрдер.

Тәүге караштa гына, ничектер, җансыз кебек тоелган икән авыл. Басудагысы — басуда, мондагысы — монда, гомер бакый шулай инде ул. Әнә, читән төбендә, какы ашап, дүрт-биш яшьлек бер малай утыра.

— Тәмлеме? — диде Гыйниятулла, аның янында тукталып.

— Тәмле. Тик бетте инде анда. Калмады...

— Ә кайдан җыйдың соң?

— Абзар артыннан.

«Тимербулат та хәзер шушы бала зурлыктыр инде. Әле

кишләп торган була икән үзе?» Гыйниятулла, кесәсеннән чыгарып, малайга бер кисәк шикәр тоттырды.

— Кап.

— Тәүдә нәнәемә күрсәтәм,— диде дә сабый, йөгереп, өйләренә кереп китте.

Ике-өч йортны үтүгә капка төбендә янә бер җан иясе пәйдә булды. Кулына таяк урынына тәпке тоткан, бәрәңге утаган җиреннән Гыйниятулланы күреп чыккандыр, ахрысы.

— Саумы, балакай... Кем дип әйтим...

Гыйниятулла да тәүдә танымыйрак торды, бакты исә — Гөлнәфисә әби икән лә. Кара син аны, шул дүрт ел эчендә бөтенләй төс ташлаган: чәчләре ап-ак, битләрендә җыерчыклар, гәүдәгә дә бәп-бәләкәй генә булып калган.

— Бу — мин, күпер төбе Идиятулла улы,— диде Гыйниятулла, аның чыбыктай каты кулларын кысып.

— Ә-ә, шулаймыни...— Гөлнәфисә әби төпкә баткан ясмыктай гына күзләрен бер генә төбәп алды һәм башын, нигәдер, аска иде.— Исән-сау гына кайтып җиткәнсең, анысы шөкер...— Тавышы аның өзелгән скрипка кылы кебек калтыранып куйды да тынды, һәм ул, иелә биреп, яулык очы белән күзләрен сөртеп алды, аннан кинәт кенә үзләренә табан борылды.

Гыйниятулла гаҗәпләнебрәк тә калды: нигә алай бөгелеп төште соң әле ул? Аны исән-аман күрү шатлыгыннанмы? Хатын-кыз шулай инде, кайгысын гына түгел, кечкенә генә куанычын да яшькә чылатучан. Гөлнәфисә әбинең олы улы, аның яшьтәше Нуриәхмәт белән военкоматка бергә барган иделәр, сорый да алмады, ни хәлдә икән ул? Әллә... әллә Нуриәхмәт һәлак булды микән...

Атлый торгач, әнә, үзләренең дә йортлары күренде. Капка төбендә җигүле ат тора, димәк, өйдә кеше бар. Урам аша үтеп, аларга бер хатын да кереп китте. Хафиса әби булса кирәк. Әле Тимербулаты килеп чыкса, таныр иде микән үзен? Таныр, әлбәттә, үз сөяге бит. Ә менә сабый аны тиз генә төсмерли алмас. Башта ятсынып торыр әле...

Йортларына җитәрәк, Гыйниятулла, үзе дә сизмәстән, адымнарын кызулата төште. Капка да, өй ишеге дә ачык иде. Ул бусага аша бер генә адым атлады да — шунда, баскан урынында, телдән-өннән язып, катып калды. Култыгындагы аты, гөрселдәп, идәнгә килеп төште. Өй тулы халык, ләкин берәүсе дә аңа туры карарга кыймады, гаепле кеше сымак, башларын түбән иделәр.

Кабер тынлыгын кисеп, Рауза белән Венераның тавышы яңгырады:

— Әти!

— Әтием!

Сәке өстеннән кызлар сикерешеп төштеләр дә икесе аның ике кулына килеп ябыштылар һәм такмаклый-такмаклый елап җибәрделәр:

— Без көттек, әти, сине... Бик нык көттек... Ә син кайтмадың.

— Тимербулатыбыз үлде бит... үлде-е...

Өйдә үлем-җитем барлыгын Гыйниятулла күреп тора иде: өстәлне идән уртасына куйганнар да гәүдәсен сузып салганнар. Тик аның кем икәнлеген хәзергә белми иде. Белергә дә теләми иде! Ата өчен балаларының кайсысы да газиз...

Гыйниятулла кинәт чайкалып китте дә, авыр атлап, улы янына килеп басты. Йөзе болай тулы гына... Көлемсерәп яткан сымак...

Өстәл тирәли тезелешеп өч-дүрт карчык утырган, әле шуларның берсе, Гыйниятулланың уен белгәндәй:

— Шешенгән шулай сабый... ачтан...— диде, көрсенеп.

Аңа икенчесе өстәде:

— Былтыр сыерлары да зыянлады шул, сыер агы да күрмәгәч ни...

Өченчесе исә, нәфрәтләнеп:

— Шушы бала да сугыш корбаны бит... Сугыш... Алланың ачы каһәре генә төшсен бу мимечкә!..— дип куйды.

Гыйниятулла яңа күрде: Тимербулатның үле гәүдәсе белән бер тәңгәлдә, каршы як стена буенда, көмеш арба торган икән. Әле аның янәшәсенә кече кызлары Гөлсем, чак күтәреп, ишек төбендә аунап яткан көмеш атны китереп бастырды. Үзе шуңа карап риза-канәгать, шат, кайгы дигән нәрсәне, күрәсең, белми әле бу сабый.

Дүртенче карчык та телгә килде:

— Авыруы озаккарак сузылды шул... Миңлебәдәрнең... Үз аягында булса әллә...

Шушы сүздән Гыйниятулла сискәнеп китте дә башын кинәт уңга борды, сәке ягына. Күзләр күзгә очрашты. Урында яткан Миңлебәдәрнең сулган сары битләре буйлап ике эре яшь бөртеге тәгәрәп төште. Гыйниятулла да үзенең кадерле Миңлебәдәренә бер сүз әйтә алмады, бугазына ниндидер утлы төер килеп тыгылды да, баскан урынында аның сыны катты...

ШАКИР ЯНБАЕВ

Шакир Махиян улы Янбаев 1925 елда Башкортстанның Күгәрчен районы Бикбулат авылында туа.

1943 елда, мәктәпнең унынчы классында укыган чагында, ул Кызыл Армия сафына чакырыла. Өч айдан соң яшь солдат, шофер булып, фронтка китә һәм Беренче Украина фронты гаскәрләре сафында Берлинга кадәр барып җитә.

Сугыштан соң Ш. Янбаев мәктәптә балалар укыта. Музыка училищесында һәм М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укый.

Язучының «Үлән өстендәге чык» дигән хикәяләр китабы 1966 елда басылып чыга. Моннан соңгы елларда әдип «Җирем — җиде кат», «Туган моңнар» исемле повесть һәм хикәяләр җыентыклары, «Зәңгәр чатыр», «Бүә буйкайлары сары тал» дигән романнар иҗат итте.

Ш. Янбаев 1968 елда Коммунистлар партиясе сафына кабул ителгән. 1972 елдан СССР Язучылар союзы члены. Аңа Башкортстанның атказанган культура работнигы дигән почетлы исем бирелгән.

САЙРАР КОШ

Без җиде малай үстек. Хәзер, балачак искә төшкәндә, әнкәемнең:

— Ичмасам, арагыздан берегез кыз булсачы! — дип сукрануы колагымда сарлыгып тора. Иртәннән алып йоклап киткәнче пыр тузып көрмәкләшкән җиде малайны аралавы җинел булмагандыр әнкәемә. Өстәвенә, җиде малайның очлы терсәк-тезе изрәткән күлмәк-ыштанны ямә, кыш булса, пима төплә, оек-бияләй бәйлә. Әнкәемнең кулына

энә тотмаган көнен хәтерләмим. Күлмәк изүендәге саплам җеп үткәрелгән энәсе без ертып кайткан киемнәрне бөтәйтергә, ямарга һәрвакыт әзер була иде.

Безгә еш кына кереп йөргән Ырысбикә әби, әнкәемнең күңелен күтәреп:

— Бер михнәтнең бер рәхәте була. Хәзер ызалансаң да, җиде улың үсеп җитсә, олыгайган көнеңдә игелекләрен күреп рәхәтләнерсең,— дип юата торган иде.

— Әй, җиңги, алар кеше булганчы җитәрлек саргайтырлар әле. Җиде малай бит, әйтүе генә җиңел. Сугышмасалар да ул кадәр булмас иде, чак күздән яздырдыңмы, кырылышып баралар. Нәрсә бүләләрдер инде! — дип, әнкәем Ырысбикә әби сүзләренең чын булырына ышанмый, арыган күзләрен безгә төби.

Әтием белән әнкәем арасындагы ызгыш та безнең аркада гына килеп чыга иде шикелле.

Әтиемне сирәк күрә идек. Яз — сабанда, җәй — печәндә, көз — ашлык сугуда иртәдән кара кичкә кадәр эшли иде ул. Өйгә йокларга гына кайткан арада аны җидебез җиде яктан сырып алабыз, нишләсәк тә тыймасын белеп, өенең астын-өскә китереп шаярабыз, көрмәкләшеп хәлдән таябыз.

— Шаштырма шуларны, карт бәбәй! Син юкта башны катырганнары да җиткән,— дип әнкәем ачулана.

Әтием, безнең белән көрмәкләшүдән арып, еш-еш тын ала, аның күзләрендә дә җиде малайның күзләрендәге кебек шаянлык чак тыелып тора.

— Бетте! Бетте! Хәзер барыбызга да чыбык төшә! — дип безне берәм-берәм түшәккә салып, юрган белән каплый, тынычландыра.

Кайберләр, әнкәем өрлеккә кыстырып куйган чыбыкны кулына алса, әтием:

— Балаларны артык куркытасың. Әйдә, теремек булып үссеннәр! — дип яклап алып кала иде.

— Шулай аркаландырып яман өйрәтеп бетәсең! — дип әнкәем сукрана, ә үзе безгә сукмый, чыбыкны кире урынына кыстырып куя иде. Мондый чакта әтием безгә күз кысып шым гына көлә. Аның битендәге шадралары язылып киткәндәй була.

Мин бәләкәй чакта «әтиемнең бите нишләп шома түгел икән» дип аптырый торган идем. Чәчәк авыруы шулай шадралаган икән аны. Ырысбикә әбинең сөйләвенә караганда, элек чәчәк авыруы, чалгы белән чапкан шикелле, кешеләрне кыра торган булган. Әтиемнең дә бөтен туганнары шул чәчәк авыруыннан үлеп беткән.

— Яшен суккан агачның исән калган бердәнбер тамырыннан шытып чыккан җиде тармаклы имән кебек сез. Әтиең шуңа бала җанлы, инде тәүфыйклы булып үсегез,— дип, Ырысбикә әби әтиемнең ничек чәчәк беләп авырганын, ничек, үлә-үлә дип, өметсезләнеп беткән җирдән исән калганын әкият сымак сөйли.

Берсеннән-берсе вак җиде малайның үсеп, килəчәктә кем булулары турында сүз чыкканда бигрәк тә миңа карыйлар иде. Баш бала булгангадырмы, әтием, минем тизрәк үсеп, укытучы булуымны тели. Нәсел-нәсәбе борын-борыннан мал асрап көн иткән кеше ни уйлап мине укытучы итәргә теләгәндер, белмим. Ул килгән бер кеше алдында миннән төрле китаплар укытып карый да:

— Улымны, үскәч, укытучы итәм,— дип мактана.

— Зур үскән саен мәшәкатьләре дә зурая! — дип сукранган әнкәемнең дә шулвакыт күзләрендә өмет, ышаныч нурланганын күрә идем.

Авылдагы башлангыч мәктәпне тәмамлагач, күп иптәшләрем укуны ташлады. Ә мине район үзәгендәге урта мәктәпкә алып барып бирделәр. Читтә укый башлагач, әтиемдә генә түгел, күрше-күләндә дә минем укытучы булып чыгарыма ышаныч артты. Атна саен аркама буш капчык асып ялга кайткан чагымда:

— Бик тырыш, зиһенле малай! Безнең авылдан да бер кеше чыга! — дип артымнан карап калалар иде.

Бишенче классны тәмамлап каникулга кайткан җәйне сугыш башланып китте. Август урталарында әтиемне фронтка озаттык. Китәр алдыннан әтиемнең:

— Авыр булса да, балаларны укытырга тырыш! — дип әнкәемә кат-кат тукыганы һаман истә тора.

Әллә без юашлыктан, әллә әнкәемнең күңеле йомшарды: әтием сугышта йөргәндә, бик авыр чакларда да, әнкәй безгә җикермәде, җиде малайны берүзем асрап киләм дип кешеләргә зарланмады. Әтиемә хат язарга утырсак, бөтен күрше-күләннән сәлам беткәч тә:

— Инде, балам, үзегезнең ничек укуыгыз турында яз,— ди торган иде. Безнең, укуны ташламыйча, класстан-класска күчеп килүебезне әтиемә хәбәр итү олы шатлык була иде әнкәемә.

Ниһаять, мин җиденче классны тәмамладым. Һичбер уйланып тормый, педагогия училищесына документларымны җибәрдем. Экзаменнарга чакыру кәгазен алгач шатланганны күрсәгез! Әнкәемнең маңгаендагы җыерчыклары язылып киткәндәй булды. Әтием өйдә булса нишләр

иде икән? Ул бит әле мин беренче класка кермәс үк укытучы булуымны тели, хыяллана иде.

Әтием Харьков өчен барган сугышларда яраланып госпитальдә ята иде. Борчылып училищедан җавап көткәнебезне, чакыру алгач, куанганны, кайчан юлга чыгарымны аңа бөртекләп хатка язып җибәрдем.

Әнкәемнең башына тагы да уй төште. Шәһәрдә укуны район мәктәбе белән тиңләп булмый бит инде. Авылда өстеңә ни кисәң дә ярый. Шәһәргә адәм рәтлерәк кием белән барырга кирәк. Ә минем өстәге киемнән әнкәемнең тырышлыгы аркасында гына тән күренми. Сугыш вакытында яңа киемне кайдан сатып аласың? Һаман шул өй эчендәге чаршау, тәрәзә пәрдәсе кебек нәрсәләрдән кораштырасың. Әнкәем, байтак уйлаганнан соң, әтиемнең сугышка кадәр Мәскәүгә күргәзмәгә барганда алып кайткан костюмын сандык төбеннән чыгарды.

— Зур агачны ексаң, йомычкасы кала дигәндәй, калдык-постыгыннан энеләреңә берәр нәрсә рәтләрмен, аларның да җеп тотарлык киемнәре калмады. Үзе сау кайтса, мал табылыр әле,— дип сөйләнә-сөйләнә миңа үлчәп кисә дә башлады.

Чүпрәне аз салган камыр кебек, буйга күтәрелмәгән какча гына малай идем мин ул чакта. Миңа таман гына пинжәк-чалбар тегәр өчен гәүдәгә таза булган әтиемнең ике чалбар балагы да җитте. Ат менгәндәй сөендем яңа киемнәремә! Төймә такканны да көтми, Ырысбикә әбиләргә күрсәтеп килергә йөгердем. Ырысбикә әби яхшы сүзеннән беркемне дә мәхрүм итми торган кеше.

— Киленнең кулы алтын, килештереп теккән бит әле. Коеп куйган кебек! — дип мине әйләндереп карый-карый әнкәемне мактады.

— Чын мөгаллимгә охшап ук киткәнсең, улым. Каладан зур гыйлем иясе булып кайт,— дип минем дә күңелне күтәреп җибәрде.

Әйтерсең сугышка китәм, озатырга әллә никадәр кеше җыелды. «Шәһәргә барып төшкәч кенә киярсең»,— дип яңа киемнәремне әнкәем такта чемоданымның төбенә салды, юлга искеләремне киенеп утырдым. Моңа кадәр район үзәгеннән ары чыккан булмагач, ничектер йөрәк җилкенеп тибә. Өтәләнеп йөргән әнкәемә, арбага миннән алда менеп утырган энеләремә карасам, күңел тула. Ничек тә, күз яшемне йотып, елаганны сиздермәдем.

...Укырга килгәннәр арасында буйга иң бәләкәе мин булып чыктым. Аның каравы миннән дә шәбрәк киенгән берәү дә юк, әллә ничек башкалардан аерылып торам.

Бөтенесе дә миңа карыйлар. Бер сары чәчле, зәңгәр күзле малай пинжәгемне тотып карады да:

— Минеке дә бар иде, нәкъ шушы төсле, өч чиләк бәрәңгегә алмаштырып ашадык,— дип күрсәнде.

Килгән көнне үк училищеның астын-өстен карап чыктым. Бөтен нәрсә дә ошады.

Гомумторакка кайтып керсәм, малайлар, укып утырган китапларын ташлап, Агыйделгә су керергә китәргә торалар. Мин дә иярдем. Авылда йөзү буенча алдыма берәүне дә чыгарган юк иде. Сөйләүләренә караганда, яңа танышларым арасында мине узардайлары булмас төсле. «Буйга бәләкәй булсам да, ничек йөзәргә кирәкне күрсәтим әле!» — дигән уй белән юл буе кинәнеп бардым. Чишенеп, киемнәребезне бер урынгарак салдык та, су чәчрәтеп, ярышып елгага чумдык. Агыйдел безнең тәндәге юл тузанын юарга җылынып торган диярсең! Шәһәргә иялəшеп китүе кыен була дигәннәр иде, һич кыенлыгы күренми, ятсынырлык бер нәрсә дә юк. Әнә, баш очында кыздырган кояш та, дулкыннар өстендә күзне камаштырып чагылган шәүләсе дә таныш, әйтерсең авыл очындагы күлдә су кереп йөрим!

Юка тәнле малайлар тиз өшеделәр. Теге зәңгәр күзле сары малай белән икәү, суны сагынган үрдәк кебек, рәхәтләндек кенә. Ул Димдә үскән, яхшы йөзә, миннән калышмый. Судан чыгарга исәп юк иде, иптәшләр сөрән салып кычкырып чыгардылар. Бөтенесенең дә күзләре шар булып миңа төбәлгән.

— Кая чишенгән идең? — дип сораулары булды, буыным таралып төште. Ком өстендә пинжәгем белән чалбарым күренми. Шаярталар дип уйлар идем, иптәшләремнең миннән дә бигрәк котлары очкан. Башыма күсәк белән сукканнан да яман үкереп елап җибәрдем. Шул минутта кояш сүнгән төсле булды. Ничек еламый түзәсең? Ашарга бер кабым икмәк юк чакта да сандык төбеннән чыкмаган нәрсәне күз ачып йомганчы гына югалт инде!

Кешеләр җыелып китте, мине җәллиләр, киемнәрне эзләшеп караган булалар.

— Әллә монда чишенмәгән идеңме? — дип тә сораучылар булды.

Кайда чишенгәнне хәтерләмәскә мине исәр дип уйладылар микән?

Яр буендагы комны тырнап күпме еласаң да урлаткан нәрсәне кире китереп бирмиләр икән. Шыр ялангач дип әйтерлек гомумторакка кайтып кердем.

— Шәһәрдә авыз ачып йөрсәң, шулай була ул! — дип

кайберәүләр көлделәр. Дим егете миннән дә яманрак кайгырды.

— Их, малай, әрәм булды! Синекен алмаштырганда дүрт чиләк бәрәңге алып була иде,— дип күпме байлыкны югалтканымны стипендиягә кушканда дүрт бидрә бәрәңгене ничә айга җиткереп булырын сөйләп, кайгымны гына арттырды.

Иртәгә имтиханга нәрсә киеп барырга? Юлда кигән иске чалбар бигрәк беткән. Бер бүлмәдә торган иптәшләр, аны кимәскә киңәш итеп, кемнеңдер запас чалбарын алдыма китереп салдылар. Бу чалбар үзе киң, үзе кыска гына. Итәккә охшап тора.

Комиссия алдына нинди кыяфәттә килеп басканмындыр. Уйга чумып утырган апалар мине күрү белән елмаешып бер-берсенә караштылар. Алар мине кызганган да, җәлләгән дә төсле күренде.

— Ничә яшь сиңа? — дип бер олы гына апа үтә җентекләп сорады. Җавабымны ишеткәч, күзен чалбарымнан алмый:

— Буйга бик бәләкәйсең бит әле, туганым, балалар укытырга үзең бала гынасың,— дип күңелгә шик салды.

Мине кинәт кенә борып чыгарып җибәрмәделәр, башкалар белән бергә имтиханнар биреп йөрдем. Пинжәк-чалбар кайгысы баштан чыкмыйча чөй сымак өйкәп торгангамы, этә-төртә генә җавап бирдем. Мине укырга алмадылар. Бала кулындагы матур шар кинәт шартлаган кебек, хыялларым юкка чыкты. Минеке генәме? Еракта госпитальдә яткан әтием ишетсә нишләр? Энеләрем күзенә ничек күренермен? Юкны бар итеп киендереп, юллык акча табам дип өзенеп-йолкынган әнкәем алдына ни битем белән барып басармын? Ә Ырысбикә әби? Ә авылдашлар?

Ул чакта кайгырганымны хәтерләсәм, хәзер дә тәнем чемердәп китә. Кая куйыйм башымны, кайтып киттем инде авылга. Көндез кеше күзенә күренмәс өчен, кояш баеганны көтеп, каен төбендә яттым. Урамга керү кайда, киртә артыннан поса-поса гына кайтам, үзем, әнкәемә ни дип сөйләсәм ачуланмас икән, дип баш ватам. Чолан ишегенә килеп төртелгәнче, гаебемне җиңеләйтерлек берни уйлап таба алмадым. Өйдәге тавышка колак салып тыңлап торам. Нинди бәхетле күренде энеләрем! Алар, элеккечә чикылдаша-чикылдаша, йокларга ятарга җыеналар. Әнкәем ара-тирә аларга эндәшеп куя. Минем ишек төбендә басып торганны белмиләр инде алар, укытучылыкка укып йөри дип уйлыйлар.

Керосин юклыктан, лампага ут кабызмый торган идек. Өй эче караңгы. Ишекне ачып кердем дә ары китми туктадым.

— Кем ул? Түргә узсаңчы! — дип әнкәем караңгыда танымый эндәште.

Байтак торганнан соң, чак тавышымны чыгарып:

— Әнкәй, бу мин,— дигән булдым. Юрган астыннан баш калкытып яткан энеләрем сикерешеп тордылар. Әнкәемнең күңеле хәвефне шунда ук сизенде шикелле, саклап кына тота торган шырпыны сызып, лампаны кабызды. Өстемдәге ят чалбарга аптырап:

— Нишләп кайтып кердең? Керә алмадыңмы әллә?! — дип алдыма килеп тә басты.

— Әнкәй, пинжәк-чалбарымны урладылар! — дидем дә үксеп елап җибәрдем. Әнкәем ни дип әйтергә дә белмәде. Җан ачуы белән сугып җибәрде. Кабат сугарга күтәргән кулы белән күлмәгенең изүеннән тотып, хәлсезләнеп урындыкка лып утырды. Сукыр лампадан сөрем күтәрелә, ә әниемнең йөзе шул лампа сөременнән дә караңгырак күренде. Мин әкрен генә елыйм. Энеләрем аптырашып киткән. Бөтенебезнең дә башына төшкән авыр кайгы булды бу.

Әтием сугышка киткәннән бирле, әнием миңа тәүге кул тидерде. Бала чактан укытучы булам дип йөргән хыялыма шул сугу әйтерсең соңгы нокта булды. Өч көн беркайда чыкмый өйдә утырдым. Дүртенче көн әнкәем эштән кайтып керде дә:

— Нигә балтаң суга төшкән сымак утырасың? Авылга геологлар килгән, эшкә кеше җыялар. Барып кара, бәлки аларга ярарсың. Кул кушырып утыра торган вакыт түгел,— диде. Нишләргә, кая барырга белми утырган кешегә җитә калды, шул минутында йөгереп идарәгә киттем. Кичергән хурлыгымны юар өчен таш кисәргә, тау актарырга әзер идем. Килгән кешеләр геофизиклар булып чыкты. Безнең якларга нефть, газ эзләргә Ишембайдан килеп чыкканнар. Мине топография отрядына эшче итеп алдылар. Шул көнне баскан сукмагым олы юлга алып чыгар, бөтен тормышым, киләчәгем нефтькә бәйләнер дип ул чакта һич уйламаган идем. Җирнең күзгә күренмәгән тирәнлекләрендә нефть эзләү мине мавыктырды. Адым саен кыенлыклар сагалап торган разведчик тормышы, кыю кешеләр күңелемдә икенче хыял утын кабыздылар. Әтием, Берлинда сугышны тәмамлап, түше тулы медальләр белән әйләнеп кайтканда, мин инде, җәен-кышын йөреп, оста геофизик булып өлгергән идем. Үземне узып үсеп килгән

ике туганым да артымнан иярделәр. Әтием безнең эшне үзсенми генә сорашты да:

— Ярый инде, берегез дә укытучы булырга теләмәгән икәнсез, нефть исе сеңеп өлгергән үзегезгә. Сез соңгысы түгел, энеләрегезнең берсе булыр әле укытучы,— дип ризалашты. Тик җиде малайның берсенә дә укытучы булырга язмаган икән. Авыл янында гына күтәрелгән нефть вышкалары, җир астыннан нефть чыгаручы кешеләр калган энекәшләремнең дә күңеленә ошады. Әтием белән әнкәемнең бөтен өмете төпчек сеңлебез Киньябикәгә күчте. Әнкәем юкка гына кыз теләмәгән икән. Киньябикә тормышыбызга аеруча бер ямь алып керде. Әтием хәзер аның укытучы булуын көтә. Аның хыялы тормышка ашар төсле, Киньябикә сеңлем педагогия институтына укырга керде. Ә минем укытучы булырга йөрүемне хәзер авылда беркем дә хәтерләми төсле. Туксан яшьтән узса да, һаман теремек, тик күзгә бераз начарлана башлаган Ырысбикә әби генә, мин ялга кайткан саен:

— Әй, килен, җиде улның рәхәтен күрермен микән, ди торган идең, менә үсеп җиттеләр. Дөньялар имин булгач, читтә йөрсәләр дә шатлык. Кеме кайтып төште? Мөгаллим улым, синме? — дип сөйләнә-сөйләнә килеп күрешә. Шулчак бала вакыттан күңелемне нур белән тутырган, сугыш заманында да укырга дәртләндереп торган хыялым исемә килеп төшә. Ул хас төягенә кайткан сайрар кош сымак татлы да, әченүле дә моңнарын суза. Үзем генә ишетәм мин аларны. Ә Ырысбикә әби күптән түрдә. Әнкәем аны «мөгаллим» улының күчтәнәчләре белән сыйлый. Өйгә сөйлүн чәенең хуш исе тула...

ВӘЗИХ ИСХАКОВ

(1927—1985)

Вәзих Мөхәммәтша улы Исхаков 1927 елда Башкортстанның Чакмагыш районы Тайнаш авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң колхозда һәм МТСта шофер булып эшли.

1948 елда Совет Армиясенә чакырылып, шунда хезмәт иткәндә гомуми урта белем ала һәм хәрби училище тәмамлый. 1954 елда партиягә кабул ителә.

В. Исхаков башлыча тарихи-революцион эчтәлекле документаль әсәрләр, мәсәлән, татар халкының данлыклы уллары Мулланур Вахитов, Хөсәен Мәүлетов, күренекле хәрби эшлеклеләр, гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы каһарманнары Якуб Чанышев, Әхтәм Бәхтизин турындагы китаплар авторы. СССР Язучылар союзына ул 1966 елда кабул ителде. Әдип шулай ук «Комиссар сеңлесе», «Көнгер малае», «Җәйге сынау», «Тәгәрмәч эзләре», «Күңел моңнары», «Умырзая — яз чәчкәсе» дигән җыентыклар иҗат итте.

В. Исхаков — республика комсомолының Г. Сәләм исемендәге премиясе лауреаты, Башкортстанның атказанган культура работнигы иде.

СОЛТАН АГАЙ

Башымны иеп, тирән уйга батып, опера һәм балет театры белән сәнгать институты арасындагы урам аша чыгып бара идем, чак автобус бәреп екмады.

— Күзең чыкмагандыр лабаса, машинаны күрмәскә! — дип шофер тәрәзәдән башын тыкты да йодрык селтәп үтте. Ләкин ул да булмады, автобусын бераз алгарак илтеп

туктаткач, кабинасыннан төшеп, йөгерә-атлый мина таба уңайлады.

Каушавымнанмы, шоферның әле генә тиргәвеннәнме, һаман һушыма килә алмый, урам чатында басып тора идем.

— Син нәрсә шаккаттың, кил болай! — диде шофер. Ул, кул болгап, мине тротуарга чакырды.

Өлкән яшьтәге, калын гына мыеклы, какча гәүдәле бер агай иде бу. Кигән киеме дә гади генә: башында кепка, өстендә таушала төшкән кара костюм.

— Танымыйсыңмы әллә?

Сәерсенүемне аңлатып, кулбашымны сикертеп куйдым.

— Бә-әй, оныттыңмыни шулай?! Менә сиңа... Исеңдәме, без сугыштан кайтканда, син шуфер идең!

Агайга ялт итеп күтәрелеп каравымны сизми дә калдым. Хәйләкәр генә елмайган кысык күзләр, төймәләнеп торган ямьшек танау һәм яртылаш агарган куе соры мыек...

— Солтан агай, дисәм?..— дидем мин кыюсыз гына.

— Нәкъ үзе! — Агайның авызы ерылып китте һәм ул кулларын сузды.— Зирәк икәнсең, таныдың бит тәки!

Әйе, әйе. Бу агайны нык хәтерли идем мин. Бик тә нык...

* * *

Сугыш беткән ел иде бу. Өченче көн инде МТС директоры безне бер нефтебазадан икенчесенә куа. Басуларда тракторлар, комбайннар тик утыра: МТСта ягулык бетте.

Менә бу юлы да:

— И-их, егетләр, нинди көннәр әрәм була бит! — диде ул эчке әрнү белән. Чынлап та, үч иткәндәй, күктә кояш көлә, явым-төшем дә юк — уңыш җыю өчен иң кулай чор иде хәзер. Көтеп алган матур көннәр!..

— Ягулык тапмый торып, кайтасы булмагыз! — дип директор бик каты кисәтеп куйды.

Башны ястыкка текәмәгәнгә дә өченче тәүлек китте. Көндез әле ярыйсы — түзеп була, әмма кич булдымы, үтереп йокы килә. Бу хәлне белгән директор яныма килде дә:

— Синең белән Нәсибуллин барыр,— диде.

Нигъмәй Нәсибуллин утыздан узган буйдак егет. Сугыш вакыты булса да, аны бронь белән алып калдылар. Чөнки Нигъмәй—МТСның иң уңган механигы. Озын буйлы, юка сары чәчле бу кеше белән минем дуслык та яхшы гына: беркайчан да аның җирле-юкка күтәрелеп бәрелгәнен

күрмәссең, йомшак табигатьле — шуңа да бөтен халык ярата үзен.

Благоварга җиткәнче, байтак юл узылды. Гадәттә, без машина ягулыгын — керосин-бензинны йә Кушнареннан, йә Дүртөйледән ташыйбыз. Ләкин аннан берничә машина буш кайтты. Менә шуңа күрә, Благовар нефтебазасында бензин күп, имеш, дигән хәбәргә ышанып, шунда юл алдык та инде.

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, монда да юл уңмады. Бүтән вакытта сүгенүнең ни икәнен белмәгән Нигъмәй: «Мать якасын!..» — дип авыз эченнән генә мыгырданып куйды. Ул, нефтебаза мөдире белән кат-кат сөйләшеп, хәтта ялварып та карады. Әмма барыбер тәртәне кирегә борырга туры килде.

— Әлеге шул, үзебезнең Кушнарең кала инде,— дидем мин, кабинага утыра салып.— Киттек!

Сугыш елларында юллар тәмам тузып эштән чыктылар. Аларны төзәтергә көч тә җитми иде, әлбәттә. Кайда күпер юк, кайда язгы ташкыннар юлны ерып-җимереп бетергән.

Кузовтагы буш мичкәләр даңгыр-доңгыр килә. Автомашинабызның да, шул мичкәләр сымак, шыгырдамаган, шалтырамаган җире юк.

Селкенә торгач, көн азагына көчкә Кушнаренга барып кердек. Монда безне һич уйламаган бер хәл каршылады.

Урам уртасында, райсовет каршысында гына, яңа шлагбаум куелган. Аның янында ике милиционер тора. Алар икесе машинаның ике ягына килеп бастылар да:

— Бор машинаңны, әйдә! — дип райсовет ихатасына табан күрсәттеләр.— Ашыгыч задание бар сезгә.

— Без болай да кабалан эш белән, старшина иптәш,— диде Нигъмәй.— МТСта бөтен техника туктап калды.

Әмма бар, сөйләшеп кара син милиция белән! Алар Нигъмәйне шып туктатты:

— Син нәрсә сатулашасың, понимаешь! Әйткәннәр икән, борыл, давай! — Милиционер, югары чөеп, сумкасын күрсәтте.— Монда без хөкүмәтнең карарын үтибез. Әнә фронттан җиңүчеләр кайта, шуларны илтергә транспорт кирәк. Кешеләр ничәмә ел гаиләсен күрмәгән...

Шунда гына мин ихата тулы хәрбиләргә игътибар иттем. Ул заманда, билгеле, автомобильләр бик аз иде. Һәм бу кешеләр иртәдән алып, милиционерлар әйтмешли, транспорт көтә икән.

Үзебезчә нык кына тарткалашкан булсак та, безнең ай-вайга куймастан, кузовтагы мичкәләрне алып ыргыт-

тылар да норма буенча уналты кеше сыешлы машинага йөге-ние белән егерме ике кешене мендереп тә урнаштырдылар. Рессорлар, сыгылып, кузов тәгәрмәчкә сылашты.

— Агайлар, бу килеш мотор тартмый! — дип ялынып карасак та, тыңлаучы булмады. Алай гына да түгел, безне ашыктырырга тотындылар.

— Безгә ерак түгел, Рәсмәкәйгә генә.

— Әйдә, кузгал инде.

— Без Бәширнекеләр, туган...

Полуторка гыжылдап алга үрмәли. Таулырак урыннарда, агайларны төшереп, арттан этәбез. Шулай килә-килә, ярыйсы гына бушандык — Чакмагышны чыкканда, кузовта ун-уникe кеше бар иде. Аларның да берничәсе Яңа Котыда төште, һәм бары Имәнлекулга кайтучылар гына калды.

Күзгә караңгы төн. Күзгә төртсәң күрерлек түгел. Фаралардан төшкән сыек кына ут көлтәсе юлны яктырта. Ләкин, артык арыгангамы, юлны юньләп күреп тә булмый. Аптырагач, Нигъмәй күз кабакларын шырпы белән терәп куйган булды — тик ул да ярдәм итмәде.

— Юк, булмый, әй! — диде ул, ахыр чиктә.— Туктап, азрак черем итик.

Мин инде күптән оеп килә идем. Машина туктау белән, тык итеп башны алгы тәрәзәгә бәреп тә алдым.

Һә-әй! Ничәмә ел буена сугышта йөреп, очып кайтырдай булып талпынган кешеләрне, авылына җиде-сигез километр юл калгач, тыеп була диме инде?! Алар шаулаша, кабина түбәсенә сугып дөбердәтә башладылар. Безнең тарафка тозлы-борычлы сүзләр яудырырга тотындылар.

— Без фронтта моның ишене генә күргәнме?

— Әйтерең бармы! Өйрәнгәннәр иркәлеккә...

Ул вакытта мин әле яшь идем. Буйга да бәләкәй, йончу. Шуңадыр инде, ахрысы, бу сүзләрнең угы Нигъмәйгә юнәлтелде:

— Башта ук алып кайтасы килмәгән иде аның...

— Сугышта булмагандыр, мөгаен.

— Андыйлар күптер әле ул: тылда посып ятканнар!..

Менә шунда таныштык та инде без бу агай белән. Аның куе соры мыегы да, Солтан дигән исеме дә шул көннән күңелемә сеңеп калган иде...

Ул, беренче булып: «Шауламагыз әле, һәй! Нәрсәсенә гауга күтәрдегез? Алар чынлап та арыгандыр»,— диде. Аңа тагы берничә кеше кушылды. Алар да безне яклашкач, тавыш тынды.

Юл буенча, уен-көлке сөйләп, кешеләрнең күңелен

күреп килде ул. Алда гына утырганлыктан, муенын суэып, кабинага башын тыга да ара-тирә безгә дә кызыклы хәбәрләр әйтеп ала иде. Ә үзе ашыктыра: «Тизрәк, тизрәк, егетләр!» — ди. Күрәсең, аны зарыгып көтәләрдер инде. Күзгә янә бер әйбер ташланды, ул да булса, бу агай бер-үзе йөксез — бары бәләкәй генә биштәре бар иде. Ә калганнар авыр-авыр чемоданнар алып кайталар.

Әле менә, туктап, моторны сүндерү булды, кузовтан җиргә җиңел генә сикерде дә:

— Әллә, мәйтәм, үзем алып барыйммы? — диде ул, рульгә ымлап.— Минем дә азрак техника белән танышлык бар: автосын да, танкысын да күргән булды.

Без Нигъмәй белән куанычтан бер-беребезгә карашып алдык.

— Мен кузовка! — дип боерды Нигъмәй миңа. Аннан агайга эндәште:

— Кил, агай, утыр рульгә.

Ләкин агайның техника белән танышлыгы шулкадәр чамалы булып чыкты — утыру белән, тизлек рычагын тоташтыра алмый изаланды, ә аны тоташтыргач, машинаны кинәт кенә бер сикертте дә чак-чак канауга илтеп капламый калды — мотор сүнеп өлгерде.

— Солтан, нишлисең, төш!

— Һәлак итәсең бит, белмәгәнеңә! — дип өстә ду килеп кычкырыш китте.

Нигъмәйнең дә, минем дә берьюлы йокы качты. Чөнки машина канауның читендә тора иде.

— Һә-әй, агай-агай! — диде Нигъмәй ачулы гына.— Син бит рульне тота да белмисең, ичмасам!

Агай акланырга теләмәде. Ул бары:

— Халык бик ашыккач, алып барып булмасмы әллә дигән идем дә,— дип җаваплады.

Юлда, вентилятор каешы өзелеп, байтак изаланырга туры килде.

Имәнлекулга исә иртәнге көтү куганда гына кайтып җителде. Бу вакытта кузовта бөтенесе җиде кеше калган иде. Урам буйлап аларны тарата киттек.

Солтан агай машинаның кабинасына таянган да, һәрбер гаилә белән исәнләшеп, сәлам биреп бара:

— Нихәл, Ямал килен, балалар исәнме?

— Бәй, Солтан агай икән ләбаса! Төш әйдә, чәй эчәрбез, кунак булырсың. Яңа гына сауган җылы сөтем дә бар.

Икенче өй турына җиткәч, тагы сүз таба бу:

— Ә-ә-ә, Мәфтуха, шатлан әйдә, Кәлиеңне алып кайт-

тым бит! Киткәндә елап калган идең, менә ул — әзмәвердәй көенә.

Авыл читендәгерәк бер йорттан машинага каршы алтыҗиде бала йөгерешеп чыкты. Аларның киемнәре дә начар гына, хәтта бәләкәйрәкләренең ыштаны да юк иде. Шул вакыт Солтан агай капчыгын чиште дә:

— Мә әле, Нурмөхәммәт, монауны балаларыңа бир! — дип ярты буханка икмәк, ике консерв тоттырды.

— Кирәкмәс иде, Әхмәтсолтан...

— Ал, ал. Кемгә әйтәләр!

Бу агайларның күбесе погонлы булсалар да, Солтан агай погонсыз иде. Шулай да мин аның командир икәнлеген абайлап алдым. Минем уемны раслагандай, ишле бала-чагалы агай да:

— Син мине гел шулай үз иттең инде, Әхмәтсолтан кордаш,— дигән булды.— Кайда гына булсак та, ярдәм итеп килдең. Рәхмәт инде...

Капка саен туктап, өй борынча йөри торгач, авылның бер башыннан икенчесенә барып чыктык. Инде барыр җир дә бетте сымак, карасак, Солтан агай кузовта берүзе торып калган иде.

— Син нигә төшмисең, агай? — диде Нигъмәй, кашларын җыера биреп. Чынын гына әйткәндә, мин дә хәзер бу агайга кырын карап килә идем. Әмма Солтан агай кинәт кенә җавап кайтарырга ашыкмады. Бу минутта ни өчендер аның йөзе җитдиләнеп киткәндәй булды. Бераз эндәшми торганнан соң:

— Кешеләрнең куанышуларын күрәсем килде, туганнар! — дип башлады ул.— Ничәмә ел фронтта йөреп, күңелләр катып бетте инде. Гаиләсен, балаларын күрүдән дә нинди зур шатлык бар икән кешегә?..

Безнең гаҗәпләнүебезне сиздеме, ул янә тынып калды. Ә бераздан:

— Әйдә, борылыйк, энекәшләр,— диде.— Минем өй әнә теге-е-е очта калды бит!..

Авылның икенче очына җиткәч, Солтан агай, машинаны туктатырга кушып, кабинага сугып алды. Ул кузовтан ашыкмый гына төште дә аркылы-торкылы китереп, тәрәзәләре такта белән кагылган алты почмаклы йортка күрсәтте:

— Минем нигез менә шушы инде, энекәшләр,— диде Солтан агай ят бер тавыш белән. Аның дулкынлануы сизелеп тора иде.— Әйдәгез, ихатага керик әле. Монда минем бәләкәй генә күчтәнәч тә бар.

Аның капкага барып төртелүе булды, капка ихата эченә ауды.

— Ярар, соңыннан рәтләрбез,— диде ул.

Ихата эче куе үлән белән капланган. Солтан агай шинелен салып җиргә җәйде:

— Утырыгыз, егетләр!

Ул, капчыгын чишеп, нәрсәләрен чыгарып салды: монда ике консерв, тозлаган дуңгыз мае, бая теге балаларга биргәннән калган ярты буханка икмәк белән бер фляга аракы бар иде.

— Башка сый юк инде, туганнар, гаеп итмәгез,— диде ул, табынга ишарәләп. Үзе капчыгыннан алюмин кружка алып шуңа аракы койды да Нигъмәйгә сузды.

— Без юл кешеләре бит әле, агай! — дигән булды Нигъмәй, аракыны алырга да, алмаска да белмичәрәк. Үзе күз кырые белән миңа карап куйды. Ә мин тиз генә күз кыстым: «Сыйлан!»,— янәсе. Агай да моны абайлады, ахрысы.

— Бу егет машина йөртә беләдер бит? — дип сорады ул, миңа табан борыла биреп.

— Шушы машинаның шоферы ла ул! — диде Нигъмәй.

— Алайса, тот! — Агай, күрәсең, тәвәккәл кеше иде.— Аңа бирмәбез.

Ул икмәк белән ит консервысын миңа табанрак этәреп куйды.

— Син ашап утыр, энем.

Шунда гына аның гимнастеркасына тегелгән берсе кызыл, берсе сары тасма һәм түшендәге орден-медальләренә күзем төште. Аның түше тулы орден-медальләр иде: берәү, икәү, өчәү...— бөтенесе тугыз орден белән медаль таккан иде ул.

— Гаиләң юкмыни, агай! — дип сорады Нигъмәй сак кына.

— Бар иде дә ул...— Солтан агай бермәлгә тотлыгып торды.— Сугышка киткәндә, ике балам белән бичәкәй озатып калган иделәр дә соң...

Солтан агай никадәр генә түзәргә теләсә дә, күзләре яшьләнеп китте. Без, аның авызына карап, тын алырга кыймыйча утыра идек. Бераздан ул тынычлангандай булды.

— Рәхим итеп, барыннан житешегез әле, туганнар! — дип Солтан агай һаман безне сыйлавын белде. Тик бу минутта авызга капкан ризыкны чәйнәү кыен иде.

— Шуннан? — дидем мин, ничектер беркатлылык белән

Солтан агайның гаилә язмышын белергә теләп. Ул да булмады, Нигъмәй мине арттан чеметеп тә алды: шундый сорау була димени, юньсез!..

Агай калган аракысын кружка төбенә койды да:

— Шуннан дип ни, энем,— диде ул уйчан гына.— Хатынкаем бик уңган, бик һәйбәт кеше иде. Гөл кебек яши идек. Былтыр кырда кышлаган башак ашап үлеп киткән. Ә улым белән кызымны Дүртөйле балалар йортына тапшырганнар булса кирәк...

Нигъмәй шунда ялт итеп миңа карап алды да:

— Агай, бәлки, сине Дүртөйлегә илтеп куйыйк,— дип әйтә салды. Мин дә аңа кушылып баш кагып куйдым.

— Юк, кирәкмәс,— диде Солтан агай. Ул уң кулының сырты белән мыегын сыпыргандай итте.— Сез бит эш кешеләре, туганнар, ә мин үз авылыма кайтканмын... Бер уңай күрәсе, сөйләшәсе кешеләрем бар.

* * *

Шушы очрашудан соң минем әлеге агайны күргәнем булмады. Бары аның куе соры мыегы белән исеме генә хәтеремдә калган иде.

— Мин бит сине, энекәш, күрү белән танып алдым,— диде Солтан агай, елмаеп.— Бер көн телевизорда сөйләвеңне дә тыңлаган идем. Шунда балаларга әйтәм: мин бу агаегызны яхшы беләм ләбаса!..

— Рәхмәт, Солтан агай...

— Рәхмәт дип, нәрсәсенә рәхмәт булсын? Сүзем шул, туганкаем, исән калганнар яши бирә, ил иминлеге, дөнья тынычлыгы гына кирәк.

Ул арада автобустагыларның шаулавы ишетелде.

— Мине кыздыралар,— диде Солтан агай, автобусы торган якка баш кагып.— Ярый, туган, хуш. Мин бит шофер. Унбиш ел инде. Озакламый пенсиягә чыгам. Кунакка кил, яме.

ФӘРИТ ИСӘНГУЛОВ

(1928—1983)

Фәрит Әхмәдулла улы Исәнгулов 1928 елда Башкортстанның Кырмыскалы районы Карлыманбаш авылында туа. 1945 елда урта мәктәпне, аннан Уфада педагогия институтын тәмамлый. Туган районында ике ел балалар укытканнан соң Башкортстан китап нәшриятына эшкә чакырыла. Шуннан байтак еллар республика Язучылар союзы идарәсендә эшли.

Ф. Исәнгулов әдәбиятка балалар язучысы буларак килде һәм бер-бер артлы «Тәүге сынау», «Хәмит күпере», «Быел җәй», «Илак йолдыз», «Хәлимә белән Хәлим», «Башкортстан кызы Нәзекәйбил» һәм башка хикәя, повесть китаплары чыгарды. Шулай ук ул олылар өчен язылган «Арыш башагы», «Һәйкәлләр тереләр өчен» дигән романнар һәм башка күп кенә повестьлар авторы.

Әдип республиканың Салават Юлаев исемендәге премия лауреаты.

Ф. Исәнгулов 1954 елда Коммунистлар партиясе сафына кабул ителгән. Ул 1956 елдан СССР Язучылар союзы члены иде.

КЫШКЫ ҖӘЙГОР [1]

Бу хәл булырын бер минут элек кенә белсәм әгәр, телемне кыртлата үтә тешләп тә тыелыр идем... Бары шул ике сүзне ычкындырмас өчен генә!..

Мәҗлес, тәрбияле табыннарга хас рәвешчә, җай гына бара иде. Өстәлне ешлап ураткан халыктан читтәрәк, кунаклар сүзенә кушылу түгел, алар ягына борылып карарга

[1] Җәйгор — салават күпере.

да кыюсызланып, караңгырак жирдә утырган Заһир — абыемның уртанчы улы — ни арададыр тезенә баянын алып, көй сайламак булып, баян төймәләре өстеннән бармакларын бер-ике мәртәбә әдәпле генә биетеп чыккан иде инде.

Менә шул аккорд җиңелчә гөрләшә башлаган кунакларны бер минутка тын калырга мәҗбүр итте.

...Сызылып кына күңел нечкәрткеч моң түгелде. Тик ул баян моңы түгел иде. Аны ишеткәч, киресенчә, Заһирыбыз үзе бармакларын төймәләрдән аерды.

Моң, җәйнең хуш исләрен ташучы төнге җиләслеккә кушылып, түр як тәрәзәдән тыйнак кына агылып керде.

Скрипка моңы иде бу. Әллә кайда — сугыш елларында, безнең балалыгыбыз, абыемнарның яшьлек белән хушлашкан чорында, билгесез берәү тарафыннан чыгарылып, бөтен тирә-якка таралып өлгергән, мөлдерәмә сагыш тулы «Ялкыннар» исемле көй иде бу. Инде онытылып беткән көйдән, еллар тузанын кагып, нинди скрипкачы шулай оста итеп уйный икән аны?

Башта мин скрипканың кайдадыр урам ашасындагы бер өйдән, радиоалгычтан килгәненә шикләнмәдем. Чөнки үземне белә-белгәннән бирле бүгенге көнгә кадәр авылыбызда скрипкачы булганын хәтерләмим. Әүвәлрәк курайчылар бар иде. Гармунчыларның бик-бик осталары булды. Хәзер хәтта баян сынлы баянны өй саен диярлек белгәне-белмәгәне ларылдата. Әмма скрипкачы булмады да, юк та...

Ә шулай да:

> Еракларда газиз башым
> Җирси дә ямансулый...—

дип якында гына уфтана-уфтана, шәфәкъләр баткан мәлдә скрипка иңри...

Табында кунакларны, гадәттә, буып кыстарга әвәс абыем, шушы моңга әсәрләнеп, кыстарга дип ачкан авызын ябарга онытып, утырган җирендә каткан да калган.

Кирәк чагында чын ихластан алчак елмая, бәгъзе бердә уенчак кына мут көлә дә белгән илгәзәк Гүзәл җиңгәм, каклаган каз китергән җиреннән, өстәл янына бер адым калгач җитә алмый, баскан урынында туктап калган. Аның йөзе алчак та түгел, мут та түгел. Ә уенчакланып-ихласланып, минутына биш сурәткә кергән күзләре — әле торганы белән шом көтеп тынып калган ике түгәрәк күл иде...

— Төрембәттән килгән Мөхтәр кода сыздыра,— дип аңлаеш кертте көй тылсымына артык бирешмәгән бер энекәш кеше.— Фәнис кияүләрендә утыралар...

Алай-й... Димәк, җыр радиоалгычтан түгел икән.

Табындагы яшь киленнәр арасыннан берәүсе белдекләнеп:

— Шул төрембәтләр әллә нинди генә халык: берсе шагыйрь, икенчесе скрипкачы...— диде.

«Төрембәт?! Скрипка?!»

Ә скрипка йөрәкне бер өздереп айкап алды да тынды.

Шунда, үз ихтыярымнан тыш, телем барысына да ишетелерлек итеп, ике сүз әйтте:

— Кышкы җәйгор...

Кинәт Гүзәл җиңгәмнең кулындагы фарфор табак идәнгә төшеп ватылды. Өстәл артында утырганнар һушын җыйганда, ул мәҗлес залында юк иде. Минем колагыма аның күкрәк ертып чыккан: «Аһ!» — дигән өне чалынып калды.

Исен җыеп өлгергән ике килендәше аның артыннан ташланды. Бер зирәге, ирләргә чыгарга рөхсәт бирмичә, ишеккә аркылы басты...

...Сугышның икенче елы иде. Авылда иңнәрне инә торган төп авырлыклар башланган мәл. Китәр ир-ат китеп беткән диярлек. Унҗиде тулганнар үз чиратын көтә. Көзге кичләрдә алар җыйнаулашып җырлап уза:

...Китәм инде — каласың...

— Бәлки, әле аларны быелга алмаслар да... Бигрәк яшьләр бит! — дип куя өлкәнрәкләр, йә тегеләрнең ата-аналары, үзләрен юатырга теләп.

Тик җырлап үтүчеләрнең моны ишетәселәре дә килми. Аларның күңеле күптән яу яланында фашист белән алыша.

Кырпак төшкән мәлдә, эңгер вакытында, олы урам буйлап җырлап узуларга бер олы яңалык өстәлде. Өйләрдән барча халык колак тырпайтып тәрәзәләргә ябырылды.

Җырлаучыларга скрипка кушылган иде.

Бу — безнең өчен тансык музыка иде... Саратскийлар, тальянкалар бар авылда, олыракларның берничәсе курай да тарта; кызлар арасында мандолинаны ару килештереп чиртүчеләр дә бар. Ә скрипкачы юк иде.

Менә клубка яисә җыйнаулап уйнар өчен аулак өйләргә керер алдыннан җырлап үтүчеләргә скрипка кушылды. Бик матур итеп сыздырып уйный иде. Ул кушылуга җырлар аеруча моңлыга, аеруча дәртлегә әйләнде дә куйды.

Яшь егетләргә кушылып көзге кырпакта урамга чыккан скрипкачы кем ул? Кайдан килгән безнең авылга?
Моны иң алдан мин белдем. Чөнки ул беренче башлап безнең өйдән чыкты, аның уены безнең капка тапкырыннан башланды.

Җәйгор дигән сәер исемле егет иде ул. Исеменең сәерлегенә артык исебез китмәде. Чөнки ул елларда хәтта Революция, Баррикада, Маузер, Комбайн дип кушылган исемнәрне дә ишетергә мөмкин иде. Замана аһәңе. Унҗидедә иде Җәйгор. Башкалар белән бергә «Китәм инде — каласың»ны җырлап, кичләрен урам кыдыручыларның берсе — минем абыем аңа «гадук» дип эндәшә.

Җәйгор моннан бер атна элек кенә Төрембәттән килгән иде. Ул быел район үзәгендә унынчыны тутырган икән дә аны безнең авылга аз белемле өлкәннәрне укытырга җибәргәннәр.

Өлкәннәр укытучысы Җәйгорны фатирга безгә куйдылар. Урта буйлы, таза гәүдәле, тырпаеп торган шырт чәчле, шешеңкерәк кабаклы, кысыла биребрәк торган кара күзле, коңгырт битле егет иде ул.

Килеп төшү белән эшкә тотынып китте Җәйгор. Култыгына папка кыстырып, авылны йөреп чыкты. Үзенең булачак укучыларын барлады, белем дәрәҗәләрен сынады, шул кичтән үк башлап мәктәпкә килергә чакырды.

Укытырга барачак тәүге кичен яшь укытучы Җәйгор бик дәртләнеп, бик дулкынланып көтте. Икесе бер иштән булган пинжәк-чалбарын бик яхшылап үтекләде. Укытуга китәчәк өлкән улларына ата-анасы юнәтеп биргәннәрдер инде. Минем абыйга андый элеккәне юк әле.

Күлмәге, күрәсең, берәү иде. Аны ул олы яктан чаршау белән бүленгән мич артына кереп, якасын сабынлап юып алмакчы булган иде. Әнкәем, шунда ук сизеп калып, ай-ваена куймый тартып алды. Үзе юып, җәһәтләп үтүк белән бастырып, киптереп китерде.

Тик тәүге сабагына ыспайланып, дәртләнеп чыгып киткән укытучы Җәйгорыбыз төн урталарында үтә дә төшенке кайтып абыем янына менеп ятты.

Укучылары җыелмаган. Иртән ул янә дә авыл буйлап йөрергә чыгып китте. Ахры, өлкәннәр киңәш иткәннәрдер: Җәйгор башкача аларны кич мәктәпкә чакырып изаламады, көне буе өйдән-өйгә сабагын бирергә керешеп китте. Бик тырыш, бик таләпчән укытучы, дип шунда ук мактап сөйли дә башладылар.

Фанердан бөгеп, ялтыр яшелгә буяп, кулдан гына ясал-

ган чемоданын бер атна эчендә ачты да япты, ачты да япты ул. Шул ук фанердан эшләнгән, тик кызылга буялган озынча икенче тартмасына бер дә кагылмады. Аныңы абыем белән икесе йоклый торган киң агач караватбашында стенада элүле торды.

Һәм менә бүген кич беренче башлап ачылды ул. Җәйгор аннан нечкә билле ялтыр лаклы скрипкасын чыгарып кулбашына терәп алды да таныш озын көйләрне бик матур итеп сыза башлады. Моңлы көйләр скрипкада тагы да моңлырак, сагышлырак чыга икән ләбаса.

Әнкәем, казан ягыннан чыгып, яулык очы белән күзләрен сөртеп алды. Әтием, бер сүз эндәшми, байтак тыңлап утыргач кына:

— Вәт син аны, ә, һөнәрле баланың!..— дип сокланды да янә телдән калды.

Өйдә аз сүзле булды Җәйгор. Кич белән яткач кына абыем белән пышылдашалар иде. Скрипкасын алгач та, маңгае җыерылулы калды яшь егетнең, тик шешенке кабаклы күзләрендә төпкә яшерелгән дәрт очкыны гөлтләп кабынды.

Яшь скрипкачы өйне тарсынды, моң дүрт стена арасына гына сыеп тора алмады. Абыем белән Җәйгор капканы шыгырдатып ачып чыктылар һәм бүген таңдамы, иртәгәме кар төшәчәк дип көтеп яткан туң җирне тукылдата басып атладылар.

Безнең өйдән арырак киткәч, скрипка кыскарак, безнең колакка таныштак көйне башлады. Абыем шунда ук аңа кушылды:

...Китәм инде — каласың...

Өйләрдән берәм-сәрәм чыккан сыннар аларга кушыла тора, җыр көчлерәк яңгырый бара. Скрипка да аның саен дәртлерәк сыза. Авылның аргы башыннан әйләнеп килгәндә, кушылып җырлаучылар төркеме гадәттән тыш зурайган була. Скрипка, яшь җилкенчәкне өйләреннән магнит сыман суырып чыгарып, үзе янына укмаштыра торды.

Уналты-унҗиде яшьлекләр клубка борылды. Өлкәнрәк абыйлар, җиткән кызлар җыелган җиргә барырга без, унөч-ундүрт яшьлек кырыкмышлар да, хокук алдык.

Бүген биредә бар нәрсә җанлангандай. Тавышлар да яңача — яңгыравыклы. Иске уеннар яңарып киткәндәй. Иске клуб үзе җанланып киткән кебек хәтта. Аңа өр-яңа моң керде.

Әмма Җәйгорның теле ачылып китмәде. Чырае да әү-

вәлгечә җитди калды. Ул почмакка басып алды да уйнады да уйнады. Бию көе дә уйнады, әйләнеп уйнаганда такмакларга да бик оста кушылды. «Наказ» сыман уеннар уйнаганда үзенә кушып җырлатты да. «Фәлән көйне уйна әле»,— дип олыраклар аерым үтенсәләр, минут көттереп тормыйча, шунда ук рухланып сызды да җибәрде. Гармунга да бик оста кушылды. Мең көй беләдер ул, болай булгач!

Олырак апалар — сугыштагы улларын уйлап, яшь киленнәр — йә сугышып йөргән, йә инде җир куенында булган ирләрен юксынып, өзлексез күзләрен сөртәләр, хәтта түземлекләре җитми, күршеләренең кулбашларына башларын салып, үксеп-үксеп тә алалар.

Икенче көнне дә шулай булды. Укытучы көне буе өйдән-өйгә йөреп сабагын бирде.

Яшь кенә көе колхоз бригадиры булган абыем үзенең санап бетергесез кырыкмаса-кырык эше белән ферма, кура тирәсендә зык кубып йөрде. Абыемнан бер генә яшькә кече Гүзәл апа ниндидер йомыш белән безгә кергәләп чыкты. Мин ул кергән саен шатланам: авылдагы иң чибәр кыз кайдадыр абыем белән тап булышып, елмаеп-шаярып бер-ике авыз сүз сөйләшеп торганда, рәхәтлектән күңелем җилкенә, клубта Гүзәлнең абыем белән әйләнеп биегәнен күргәндә, түбәм күккә тия. Чөнки мин шушы Гүзәл апага гашыйкмын. Чөнки Гүзәл апаның абыемның кәләше булып, безнең өйгә төшкән көнен җиткерә алмый күзем тона. Мин аны икенче берәр егеткә кызыгып китмәгәе дип, көнләшеп, аның артыннан күзәтеп йөрим. Юк, юк, эшкә дә, төскә дә авылда бер булган Гүзәл апа бары әллә ни арада тазарып-үсеп киткән минем бригадир абыемныкы гына булырга тиеш!

Гүзәл көндезләрен эше арасында кояштай балкып килеп кергәндә әнкәемнең дә йөзе ачылып, алсуланып китә. Тегесе шунда ук көянтә, чиләкләрне үз өендәге кебек кыю рәвештә шалтыратып ала салып, өзә басып чишмә ягына чыгып киткән чагында, аннары, күп тә тормый, зифа сынын уйнаклатып, чиләкләр авырлыгыннан юргалап тыкрыктан килеп кергәндә, аннан күзен ала алмый, сихерләнгәндәй түр тәрәзә алдында басып тора.

Әйе, олыгайган көнендә өйгә төшәр беренче киленне зарыгып көтә әнкәем, суга барып:

— Уф, билем!..— дип ыңгырашып кайткач, әтием:

— Үзең тупырдатып малай тапкач ни...— ди.

Юк, әнкәем өйдә гел ир балалар гына булуына көйгәнгә охшамый.

— Йорт иркен, тәгәрәшеп үссеннәр. Барысына килен алсак та сыярлык,— дип җибәрә. Суга барганында ул килен килер көнне җиткерә алмавына уфтана. Асылда, биле авырткангa да охшамый. Ул килен тели. Тик теләсә ниндиен түгел, нәкъ минем кебек үк, бары урам ашасыннан шушы чибәр дә, уңган да, илгәзәк тә Гүзәл апаның гына төшкәнен тели. Көнчелләнеп Гүзәл апа артыннан күзәтә, чосаеп аның хакында сүз аулый. Берәр апа мут кына итеп берәр нәрсә килеп шыбырдаса, йөзе яктырып, яулыгын колагы артына кучереп чөеп бәйләп, самавырны шалтыратып сөйрәп ала. Чынлап та, бригадир егет хакында да, авылда бер булган чибәр хакында да, аларны бер итеп тә сүз тиз йөрүчәндер инде. Әниемнең дә бу арада рәхәт итеп серле елмаюдан авызы еш ерыла, берәр апа хәбәр белән кергәндә, самавыр ешрак шалтырап сөйрәп алына...

Кыш башының кыска көннәре менә шулай үтә. Ә киченһәркем үз эшеннән кайтып тамакка ашагач, бу арада аеруча дуслашып киткән Җәйгор белән бригадир абыем капканы шыгырдатып ачып чыгалар. Скрипка дәртле итеп өр-яңа көйләрнең берсен сыздырып җибәрә. Ана әвәс кушылып җыр күтәрәләр.

Әйе, сугыш елларында берсеннән-берсе моңлы көйләр аеруча күп чыкты. Әлеге шул «Ялкыннар» дисеңме, «Кошлар кебек», «Дим-дим», «Рамай» дисеңме... «Сәрмән»не әйтеп торасы да юк инде — олысының да, кечесенең дә теленнән төшмәде. Күпләре бер-ике ел җырланды да онытылды. Кайсыберләрен әле дә җырлап-җырлап җибәрәләр...

Кичке уеннарга, аулакка җыелырга әвәс безнең авыл яшьләре. Тик анда укытучылар йөрми. Алар бары клубтагы тантаналы утырышларга, спектакльләргә, концертларга гына чыгалар. Гармуны булганы халык алдында концертка катнашып сәхнәдән генә уйный, мандолинасы да шулай ук эшли. Калган вакытта укытучылар гармунны үз өендә генә уйный, мандолинаны өйдә генә аулаклап чиртә.

Шулайдыр. Аларга авыл яшьләре унаена көн дә уенга чыгу килешмидер. Урам буйлап гармун тартып җырлап йөрү яки аулак өйгә бару хакында уйлыйсы да юк. Укытучы кеше халык алдында абруй сакларга тиеш.

Тик өлкәннәр укытучысы Җәйгор бу язылмаган канун белән үзен чикләмәде. Урам буйлап скрипкасын күтәреп, яшьләрне ияртеп чыгып китте. Авылның әле бу башында сызылды моңлы кыллар, аргы башта шымрак, әмма уйчанрак төстә ишетелде. Яшьләр клубка барып тулгач, баштан алып ахыргача уйнады скрипка. Инәлтеп тормый-

ча, нәзек озынча бармакларының арыганын сиздермичә уйнады да уйнады Җәйгор. Клубта уйнап туйгач, озын төннәрне кыскартыр өчен, яшьләр бер-берсе белән ымлашып, үзара сайлашып, шым-шым гына аулак өйләргә таралганда да калмады скрипкачы Җәйгор.

Бу укытучының шулай авыл яшьләре белән аралашуы, хәтта башлыклары булып әверелүеннән абруе төшәдер дип беркем дә уйламады. Төшмәде дә ул. Бәлки, өлкәннәр укытучысын халык чын укытучы итеп тә карамагандыр.

Шулай бер ай узды, икенче ай башланды. Авылның олы урамы аркылы кар көртләре ятты. Кайдандыр ялан ягыннан — Төрембәттән килгән Җәйгор көне буе, бер көрт өстенә менеп, икенчесеннән төшеп, өйдән-өйгә аз белемлеләрнең белемен арттырырга тырышып, сабак биреп йөрүендә булды; урамнарда эңгер карасы хөкемен җәелдергәч, скрипкасын иңрәтә-сулкылдата авыл буйлап җырга әвәс яшь-җилкенчәкне ияртеп китте.

Безнең авылда кешене кушаматсыз озак йөртмиләр. Кушамат, йә нәселдән килеп, кешегә тумыштан тагылган була, йә берәр кылыгына карап, үсә төшкәч чәпәлә. Чәпәлә һәм, тапкыр әйтелсә, гомерлеккә купмаслык булып ябыша.

Клубта бер кичне аеруча күп уйнады скрипкачы Җәйгор, күбрәген борынгы озын көйләрне аеруча моңлы уйнады. Яшенең дә, олысының да, ир-егетнең дә хатын-кызының да күзе-колагы анда гына булды. Әллә өлкәнрәкләр күп булганга, яшьләрнең күңеле бүген нигәдер күмәк уеннарга тартмады. Җәйгор укытучыдан сабак алучылар да күбәйгәннән-күбәеп, уенга җыела башлаган иде хәзер.

Үзеннән-үзе Җәйгорның ялгыз концерты төсен алды бүгенге кичә.

Бер көй туктап, икенчесе башланмас арада ат караучы чатан Нигъмәтҗан абыйның сокланган тавышы ишетелде:

— Харап бит, бу егетнең кулы тылсымлыдыр. Исемен дә белеп кушканнар икән шул. Балкый бит! Җәйгор булып нур уйната!..

Шуннан, сугышның башындарак тол калып, йөрәк ярасы иртәрәк уңалган Гөлбәгыйдә җиңги бер көлеп алды да мут кына әйтеп куйды:

— Җәйгорын — җәйгор да бит. Балкуы гына бар шул. Без мескеннәргә җылысы тәтеми. Хас кышкы чилләдә калыккан җәйгор.

Тол хатыннар, билләренә төртешеп, йә җиңелчә генә бер-берсенең беләген чеметешеп астыртын көлештеләр.

Шул көннән униҗиде яшьлек кунак егеткә — өлкәннәр укытучысы скрипкачы Җәйгорга — «Кышкы Җәйгор» дигән кушамат җилемләп чәпәгәндәй ябышты да куйды.

Булсын. Хурлыклы кушамат түгел бит. Хәтта исеме белән катыш. Шунысы гына әзрәк хәтер калдыра: салкын кушамат. Хас та кояш колакланган чатнама суык кыш көнен хәтерләтә.

Кышкы Җәйгор!

Балкый, әмма җылытмый. Юк, мин моңа каршымын. Җылыта аның музыкасы, таш йөрәкләреңне дә эретер кайнарлыкка ия Җәйгорның уйнавы.

Кышкы Җәйгор!

Бәлки, тол җиңгиләрнең үз карашы бардыр... Аларга музыка җылысы гына җитеп тә бетмидер...

Скрипкасы үтә талымсыз булса да, Җәйгор килгән көнендәгечә басынкы егет булып калды. Сүзчәнләнмәде, әрсезләнмәде ул. Йөзендәге салкынча җитдилеккә чамалы гына мөлаемлык өстәлә төшсә төшкәндер. Хәер, башкаларга ничек булгандыр, ул миңа тәүдәгегә караганда шактый матурайгандай күренде. Мин аны ныклап яратып өлгергән идем.

Безнең авылга килеп Кышкы Җәйгор кушаматы тагылуда дучар булган скрипкачы егетнең үз өебездә торуына, яраткан абыем белән якын дуслар булып китеп, бер караватта пыш-пыш серләшеп йокыга китүләренә чын-чыннан горурлана идем мин.

Бер кичтә диярлек телләрдән-телләргә күчеп, бар авыл кабатларга керешкән кушаматына аның артык исе китмәде. Шуны ишеткәч, башка вакытларга караганда, тавышланыбрак бер көлде дә — вәссәлам, башкача моңа бер мөнәсәбәтен белдермәде, скрипкасының тәфсилләп канифолләгән кылларын дәртле итеп сызды да сызды.

Кызлар күп безнең авылда. Бу заманда, билгеле инде, егетләргә кытлык. Тик байтак вакыт үтсә дә, Җәйгор абый аларның берсенә дә аерып күз салмады шикелле. Оялчан да түгел ул, әмма басынкы иде. Тик басынкы егет тә, берәрсенә өзелеп гашыйк булса, берәр төрле әмәлен табар, бәләкәй авылда бу хәл сәгатендә-көнендә кешеләргә мәгълүм булыр иде.

Тик сабыр күңелле бу егет, бөтен хисен скрипка моңнарына салып, бар кызларыбызга да бер төсле карап, аларның уенга сусаган күңелен табуга бөтен ихласлыгын, осталыгын салып, ялгыз йөри бирде.

Юк, ул бик үк телдән калган адәм дә түгел сымак. Абыем белән кичке уеннан йә аулактан кайтып ятсалар,

тотыналар шыбыр-шыбыр... пышылдарга. Алар авызыннан үземә таныш кызларның исеме дә еш-еш ишетелеп кала. Гүзәл апа исемен абыем әйтсә, миңа рәхәт булып китә. Ә менә, күпме яратсам да, Җәйгор абый авызыннан барыбер әйттерәсе килми.

Җәйгор үзе аерым бәрәүгә дә хисен белдермәде. Бик кимгә куйганда да, ярты авыл кызы гашыйк иде аңа. Тол апалар тоташы белән гашыйк иде. Игътибар белән караган бер генә күздән дә яшерен түгел иде бу. Күзләрен аерып ала алмауларыннан, тирән көрсенүләреннән, аның скрипкасына биергә әвәс ыргып төшүләреннән, мөлдерәп карап, алдына озак-озак бөгелә-сыгыла тыпырдап торуларыннан... Сылтаулы-сылтаусыз үтә назлы итеп эндәшүләреннән... Хәтта теге, үзләренә җылылык күрсәтмәгәч, кылтымланып:

— Әй шул Кышкы Җәйгорны!..— дип, иреннәрен матур гына турсайтып, читкә киткән булуларыннан... Безнең өйдә агач караватт тапкырында элүле торган скрипка тартмасы эчендә күз явын алырлык чәчәкләр чигелгән кульяулыкларның, кершәндәй ак мамык перчаткаларның әллә ни тылсым көче белән беркемгә сиздерми кереп ятканы булуыннан...

Бөтенесе дә гашыйк күзләре белән карый иде аңа һәм хәтта... Гүзәл апа да... Абыемнан башкаларның күз салуыннан да мин үлеп көнләшкән Гүзәл апа да...

Клубта мин һәрчак аннан күземне аерып ала алмыйм... Ә ул әлектән вәгъдә куешкан абыем белән әүвәлгечә күз сирпешеп ала да, карашындагы җылы нурларны Кышкы Җәйгорга юнәлтә. Үзебездә булган бер аулакта да мин шуны сизгәндәй булдым. Үзе абыем янында сәке буенда утыра, үзенең күзләре скрипкалы Җәйгорда...

Шул кадәрле көнләшәм... Хәтта көндез әнкәемә берәр ярдәм күрсәтергә дип кергәндә дә Гүзәл хәзер абыем өчен түгел, шушы Җәйгорны тагы бер күрергә тилмереп, сылтаулап кергәндер төсле тоела.

Әмма абыем белән өлкәннәр укытучысы Җәйгорның дуслыгы ныгыганнан-ныгый барды. Җәйгор үзе Гүзәлгә аерып кына бер ишарә дә ясамады. Теләсә кемнең күзеннән саклап йөргән Гүзәл апам ягыннан да бертөрле ым күренмәде. Мөгаен, курыкканга куш күренә дигән сыман, бер миңа гына шулай тоелгандыр.

Өч ай эшләде безнең авылда Төрембәт егете Җәйгор абый. Өч ай кич саен диярлек аның скрипкасы авылның әле бу башында күңелле сыздырды, әле, ераклашып, икенче яктан ишетелде. Өч ай толларның күз яшен сөрттерде.

Өч ай кызларның назлы карашларын үзенә тартып торды. Өч ай клуб идәннәрен сындырырлык итеп тыпырдатты аның дәртле бию көйләре.

Шуннан абыема, аның яшьтәшләренә һәм алар белән бергә өлкәннәр укытучысы Җәйгорга да повестка килде...

Кояш тирәсенә, чынлап та, кышкы җәйгор калыккан салкын февраль көне иде. Туганнары, сөйгән ярлары белән хушлаштылар. Чаналар кузгалды. Шуларның берсенә, атка артын куеп, кашавайның кучерына утырып алган Җәйгор, кершәндәй ак перчатка кигән кеенчә, көйләренең иң моңлысын, иң нечкәсен сызды. Авыл очында скрипка үзенең соңгы моңын сипте дә ишетелмәс булды...

«Гадуклар» җидәү китте. Авылга өчәүсе кайтты. Алар арасында абыем да булуы нинди шатлык! Ә калганнары үлемечле алышта ауган. Безнең авылга өлкәннәрне укытырга дип килеп, бөтен яшь-җилкенчәкнең йөрәген иләсләндереп, скрипка моңы белән барча йөрәкләрне өч ай эчендә айкап, хисләренең астын-өскә китергән, үзе дә Кышкы Җәйгор дигән һичбер мыскылсыз кушамат алырга өлгергән егет ни безнең авылга, ни Төрембәтенә әйләнеп кайтмады...

...Мин саксыз әйткән ике сүздән йөрәгенә әллә ни булган Гүзәл җиңгәм бик тиз арада тынычланып, кунаклар тулы залга кире чыкты, сый-хөрмәт күрсәтүен дәвам итәргә үзендә көч тапты.

Тик хәзер ул уйчан иде. Хәтта аның алчак булырга тырышып эндәшкән тавышыннан да төптән килгән сагыш ишетелә.

Утны-суны кичеп, түшен орден, медаль белән тутырып кайткан, сөйгәне белән кавышып менә утыз елдан артык бәхетле гомер кичергән абыем уйчан.

Кунаклар уйчан.

Җәй уртасының төнге хуш исләре белән кушылып, урам ашасыннан агылып кергән скрипка моңы безнең иләсләнгән күңелләргә хәтәр еллар төпкеленнән килгән кебек иде...

ФӘНИЛ ӘСӘНОВ

Фәнил Абдулһади улы Әсәнов 1929 елда Башкортстанның Кырмыскалы районы Бозаяз авылында туа.

Урта мәктәпне тәмамлагач, район газетасының җаваплы секретаре булып эшли, район комсомол оешмасы белән җитәкчелек итә. Бераздан партиянең Югары мәктәбендә укып чыга. «Кызыл таң» газетасының әдәби хезмәткәре, бүлек мөдире, Башкортстан Журналистлар союзының җаваплы секретаре вазифаларын башкара.

Ф. Әсәновның «Юкәләр чәчкә атканда», «Чапай командасы», «Мөгаллимә апа» дигән хикәя җыентыклары, «Урманчы малае», «Торналар кире кайта», «Яралы мәхәббәт», «Гөлләр яфрак яңарта», «Йолдызлар яуганда», «Калды утлары гына» дигән повесть китаплары һәм «Өмет» романы басылып чыкты.

Әдип 1953 елдан партия сафында, 1966 елдан СССР Язучылар союзы члены. Ф. Әсәнов РСФСРның һәм БАССРның атказанган культура работнигы.

АЛГЫ ТӘГӘРМӘЧ

— Акъяланга барып, парторг Мәрзия белән сөйләшеп кара әле,— диде председатель Галәви агай миңа.— Бригада партия оешмасының эше турында сөйләшкәндә, ничек Мәрзияне читләтеп үтәсең?

Мине Галәви агайның шоферы озата барды. Авылга көтү кайткач килеп төштек. Мәрзия авыл очында иң беренче йортта тора икән. Без килгәндә, киң итәкле ситса күлмәгенә кара алъяпкыч буган бер апа ишегалдында сыер сава иде.

— Парторгны күрергә иде,— дидем мин.— Йомышым бар иде.

— Хәзер,— дип җавап кайтарды сыер савып утырган апа.— Өйгә керә торыгыз, хәзер.

Тышта гына да көтеп утырырга мөмкин иде. Көн җылы, матур. Ләкин Мәрзиянең тормышын күрәсем килде. Өйгә кердем. Түрдә җыештырып куелган никелле тимер кровать, уртада клеенка җәелгән түгәрәк өстәл. Аның өстендә ак самовар, шундый ук поднос өстендә бизәкле чынаяклар. Китап шкафында да, савыт-саба шкафы өстендә дә, тәрәзә төбендә дә китаплар тузып ята. Аларны ашыгып актарган бугай хуҗа.

Йорт алдында миңа очраган апа, сыер савып кергәч, сөтен бәләкәй җиз иләктән үткәрде дә тагы чыгып китте. Какча гәүдәле, йөзен тирән җыерчыклар баскан, яулыгын аркасына ук төшереп бәйләгән бу апаның әрләшә-әрләшә бозау мунчаклап азапланганын, сыер куып йөргәнен мин тәрәзә аша кызыксынып карап тордым.

— Сезне көттердем инде, гафу итегез,— диде ул, өйгә әйләнеп кергәч. Мич артында кулын чайкап, минем яныма килеп утырды. Күксел тамырлары беленеп торган ябык куллары белән чал төшкән чәчләрен яулык эченә яшереп куйды һәм, миңа сынау белән карап: — Тыңлыйм сезне,— диде.

Мин, үзем дә сизмәстән:

— Сезнең кызыгызда иде минем йомышым, апа,— дип ычкындырдым.

— Парторг Мәрзия кирәк дигән идегез түгелме соң?

— Ул сезмени?

Миңа уңайсыз булып китте. Үземнең оялганымны сиздермәс өчен тизрәк сүз башларга ашыктым:

— Мин сезнең эшегез белән танышмакчы идем.

— Алай икән,— диде Мәрзия апа.— Эшләр ни, акрын гына бара инде...

Һәм тынып калды. Мин дә башка сүз тапмадым. Бераз эндәшми утыргач, түзмәдем:

— Коммунистлар ничегрәк эшли соң? Бәлки, шул турыда сөйләрсез? — дидем.

— Болай әйбәт кенә эшлиләр. Һәрберсе үз урынында кыймылдап ята.

Әңгәмә барып чыкмады. Тагы сораган булдым:

— Ә политик тәрбия мәсьәләләре?

— Әлегә кадәр авылыбызда тәртип бозган кешеләр булмады.

Тагы икебез дә тынып калдык. Блокнотыма бер генә

фамилия дә яза алмадым. Минем ачуым килде. Юк, Мәрзия апага түгел, вакыт әрәм итеп мине монда җибәргән Галәви агайга ачуым килде. Тапкан мактар кеше!

Шулай бераз бер-беребезгә карашып утырдык та, рәхмәт әйткән булып, саубуллашып чыгып киттем.

— Сез мине шаярткансыз бит, Галәви абый,— дидем мин, икенче көнне председательне очраткач.— Ул бит сүзен дә рәтләп сөйли алмый.

— Китчәле? — Галәви абый миңа карап елмаеп алды һәм, кинәт җитдиләнеп: — Әйе, Мәрзия бик тиз ачылып китүчән түгел шул ул. Аның йөрәгенә ачкыч таба белергә кирәк,— дип өстәде.

Мин, ризасызлыгымны яшермичә, Галәви абыйның йөзенә төбәлдем:

— Сез шуны, чыннан да, алдынгы парторгка санап йөрисезме?

Председательнең бу сүзләргә дә исе китмәде. Минем соравыма каршы:

— Биек таудан ташлар шуышып төшкәнен күргәнегез бармы сезнең? — дип сорады.

— Юк.

— Юктыр шул. Ә минем күргәнем бар. Бик тә гыйбрәтле күренеш бу. Иң баштан бәләкәй генә бер таш, урыныннан кузгалып, акрын гына тәгәри башлый. Юлында ул, икенче ташка бәрелеп, аны да кузгата. Икенче таш — өченчене, өченчесе — дүртенчене үзе артыннан ияртә. Беренче башлап тәгәрәгән таш кисәгенең ватылып бетүе дә, югалып калуы да мөмкин. Ләкин шушы бәләкәй таш башлап җибәргән хәрәкәт, үскәннән-үсә барып, зур-зур кыяларны урыныннан күчереп куя, тигез җирдә яңа таулар барлыкка китерә. Безнең Мәрзия дә таудан ин элек тәгәри башлаучы таш төслерәк. Карама бәләккә, кара йөрәккә, диләр бит. Тәү карашка гади генә, хәтта мескен генә күренсә дә, тауларны җимерерлек көч бар ул хатында.

— Парторг булып күптән эшлиме?

— Күптән инде. Партиягә сугыш елларында ук кергән иде. Сез аны сүзен дә рәтләп сөйли алмый, дисез. Дөрес, сүзчән хатын түгел. Ләкин әйтсә, йөрәккә җиткерерлек итеп әйтә. Бер эшне алдымы, азагына җиткермичә туктала белми.

Галәви абый, папирос кабызып, ашыкмый гына икеөч тапкыр суырып алды да:

— Сугыш елларындагы бер вакыйга истә калган,— дип сүзен тагы ялгап китте.— Кырык бишенче елның язын безнең колхоз орлыксыз каршылады. Дөрес, дәүләт

колхозны орлыксыз калдырмады, бирде. Тик рөхсәт кәгазе бик соңлап, юл өзелер алдыннан гына кулга эләкте.

Орлыкка рөхсәт язуын алып кайткач, баш катты минем. Уртага суккан елан кебек, ары сугылам, бире сугылам; орлыкны станциядән колхозга ташу җаен табалмыйм. Машина юк, атлар күтәртә. Ә станция белән колхоз арасы утыз чакрым. Аптырадым-йөдәдем дә колхозчыларны җыеп сөйләшеп карарга булдым. «Йә, мин әйтәм, апалар, җиңгиләр, киңәш бирегез: орлыкны ничек ташыйбыз? Чәчүне ничек үткәреп җибәрәбез?» Алар ни, нәрсә дисен инде. «Син җитәкче, син беләсең инде»,— дип тик торалар. «Белсәм, мин әйтәм, сезнең белән киңәшләшеп тә тормас идем. Тотар идем дә, һә дигәнче орлыкны амбарга кайтарыр идем. Белмим шул, белмәгәнгә сезне киңәшкә чакырдым. Бер баш әйбәт, ике баш яхшырак. Күмәкләшеп уйлашыйк әле. Күмәкләгән — яу кайтарган, дигән борынгылар».

Шунда Мәрзия, урыныннан күтәрелеп, өстәл артына чыкты.

— Сугыш бетә бит, ахирәткәйләрем, сизәсездер, дошман дөмегә,— дип дулкынланып сүз башлады ул.— Быел ирләребез кайтмый калмас, кайтырлар. Икмәк тотып юлларына чыкмасак, ни йөзебез белән каршыларбыз үзләрен? Икмәккәй белән калдырып киткән иделәр бит алар безне, ач-ялангач калдырмаганнар иде. Уйлашыйк әле. Ил төкерсә, күл булыр дигәндәй, барыбыз да сыерларыбызны җигеп чыксак, ике-өч көн эчендә ташып бетерәбез бит ул орлыкны. Күбенә чыдаганны, азына түзәрбез. Аларга да, ирләребезне әйтәм, җиңел түгел бит анда!

Хатын-кызның җиңүчеләрне икмәк белән каршыларга теләге бик зур булса да, сүз бөтен гаилә белән күз терәп торган соңгы сыерга барып төртелгәч, җыелыш икеләнеброк калды. «Әй илаһым, тагынниләр генә күрәселәребез бар икән бу дөньяда?!» — дип балавыз сыгучылар да булды. Гаҗәп тә түгел, колхозчыны туйдырган да, киендергән дә шул сыер иде бит ул заманда. Шулай да җыелыш: «Колхоздагы бөтен мөмкинлекләрне файдаланып, юл өзелгәнче, орлыкны ташып бетерергә»,— дигән карар кабул итте.

Карарга каршы килүче булмаса да, тәүге көнне сыерын җигәргә теләүчеләр табылмады. Тик Мәрзия генә әйткән сүзендә торды. Икенче көнне, Мәрзиядән күреп, Батыргали бабай белән Зәйтүнә сыерларын җиктеләр, ә азак бөтен авыл аларга кушылды. Шулай итеп, орлыкны юл өзелгәнче колхоз келәтенә ташып та бетердек. Халыкны бит аны кузгатып җибәрергә генә кирәк.

Галәви агай, сүнгән папиросын яңадан кабызып, бераз тын утырды. Аннан ары тагы сөйләп китте:

— Мәрзия башлап җибәргән мондый эшләрне яза китсәң, үзе бер китап булыр иде ул. Авылда беренче булып сугышчыларга бүләк җыеп җибәрүче дә, заемга башлап язылучы да, колхозның бәрәңге орлыгы җитмәгәч, үзенә ашарга дип калдырган бәрәңгесен басуга чыгарып чәчүче дә Мәрзия булды. Печән чабу, урман кисү кебек ирләр эше дә читтә калмады аннан.

Акъялан авылының клубын күргәнсеңдер. Якын-тирәдә юк андый матур клуб. Аны да әлеге шул Мәрзия төзетте. Язгы чәчү тәмамлангач килгән бу. «Галәви, ди, безнең авыл яшьләре тагы кайчанга кадәр шулай ятимсенеп яшәр икән?» — ди. Мин аптырабрак калдым. «Нигә алай дип әйтәсең, Мәрзия, безнең яшьләр кемнән ким?»

«Кино карау өчен генә дә эштән соң биш чакрым юл йөргәч, ким булмыйча, ким инде. Клуб юк бит»,— ди.

«Анысын беләм дә бит, мин әйтәм, колхоздагы ун останы кайда гына бүләбез соң? Үзең уйлап кара!»

«Безгә шунда өйрәтеп торырга бер-ике оста булса җитәр, калганын яшьләр белән үзебез эшләрбез»,— дип чат ябышты бу.

«Тукта әле, Мәрзия, мин әйтәм, уйлабрак сөйләшик, клубны бит аны коры кул белән генә салып булмый: бүрәнәсе кирәк, тактасы, кирпече...»

Минем бу сүзләргә каршы Мәрзиям тузып ук китте: «Картая башладың, ахры, Галәви, колакка катылана башладың! Яшь чакта болай түгел идең! Халык сүзенә колак сала торган идең»,— дә, фәлән дә фәсмәтән. Ярсыган ат сымак, тыеп та булмый үзен, давыл куптара. Мәрзиянең тавышын ишетеп, парком секретаре белән агроном да бүлмәгә килеп керделәр. Алары да аны яклый. Җыелышып почмакка кысып алдылар болар мине, түзеп кенә тор. Тәки сыер абзары төзүдә эшләгән осталарның дүртесен Акъяланга җибәрергә туры килде. «Ну, кара, мин әйтәм, Мәрзия, әгәр очлап чыга алмасаң, үзеңә үпкәлә!»

Юк, сынатмады, шайтан хатын. Балта-пычкы тотып, үзе өмәгә барган, бөтен авыл яшьләрен күтәргән. Өч ай дигәндә, клубны төзеп тә куйдылар. Хәзер инде, клуб тирәсенә парк ясыйк, дип хыялланып йөри...

Шул җирдә Галәви агайның сүзе бүленеп калды. Бүлмә ишеген шар ачып, аягына резина итек, өстенә фуфайка кигән, мамык шәлен маңгаена төшереп ябынган хатын килеп керде. Мин башта аның йөзен күрмәдем.

— Бу ничек була инде, Галәви? — дип сүз башлагач

кына, бу хатынның Мәрзия апа икәнен таныдым.— Кушбүләк басуына сортлы бодай чәчү турында парткомда сөйләшеп килешкән идек бит инде. Планга да шулай дип язган идек,— дип тезеп алып китте Мәрзия апа.— Әле агроном, анда быел яңадан чөгендер чәчәбез, дип сөйләнеп йөри. Чөгендер җиренә ашлама чыгарырга барган хатыннарны, ашламаны Кушбүләк буена илтегез, дип борып кайтарды. Нигә алай итә ул! Кем бирде аңа мондый правоны? Синме, Галәви? Нигә халык белән киңәшләшмичә эшлисез?..— Китте кызып Мәрзия апа, китте кызып. Галәви агай мыек астыннан елмаеп тыңлап утырды да, Мәрзиянең тынарга уе юклыгын күргәч, аны бүлдерде:

— Тукта әле, Мәрзия, кызма! Андый башбаштаклык булса, төзәтербез. Мин бит берни дә белмим.

— Тик, кара аны, онытма, Галәви! Кабат үзеңә китереп йөртмә! Башка эшләр дә бетмәгән,— Мәрзия апа кергәндәге кебек кырт кына борылды да җил уйнатып чыгып китте.

Бүлмәдә икебез генә калгач, Галәви агай минем күзләремә сынаулы гына бер карап алды.

— Менә шундый инде ул безнең Мәрзия: арый да, картая да белми. Моннан егерме ел элек ничек булса, әле дә шулай. Арбаның алгы тәгәрмәче кебек, келтер-келтер туктаусыз тәгәри бирә. Ә алгы тәгәрмәч кайда барса, артлары шунда. Алгы тәгәрмәчтән аерылмый, аның эзеннән чыкмый алар.

МАРАТ КӘРИМОВ

Марат Нәби улы Кәримов Башкортстанның Зианчура районы Күгәрчен авылында укытучы гаиләсендә 1930 елда дөньяга килгән.

Педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, мәктәптә балалар укыта. ВЛКСМның район комитеты аппаратында эшли. 1950—1953 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Аннан кайткач, республиканың яшьләр газетасы «Ленинсы» да эшли. Мәскәүдә Үзәк комсомол мәктәбендә, М. Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Озак еллар «Пионер» һәм «Һәнәк» журналларының редакторы була. Хәзерге көндә Башгостелерадиода өлкән редактор вазифасын үти.

М. Кәримовның беренче шигырьләр җыентыгы («Бөреләр») 1956 елда басылып чыга. Моннан ары аның «Җырның дәвамы», «Якты дөньям», «Тормыш — гашыйкларга» исемле һәм башка күп кенә шигъри китаплары дөнья күрде. М. Кәримов сатира һәм юмор жанрында да эшләп килә. Аның берничә хикәяләр китабы чыкты.

М. Кәримов — 16 китапның авторы. 1958 елдан СССР Язучылар союзы члены.

КОРТЛЫ АЛМА

Шәһрияр иртә белән будильникның зыңлавына уянырга гадәтләнгән. Әмма бүген ул, будильник зыңласа да, күзен ачарга ашыкмады. Отпуск! Эшкә дип йөгерәсе түгел. Күпме теләсәң, шулкадәр ауна караватта. Үз ихтыярында. Ул яңадан йокыга китеп кенә барганда, тагы звонок тавышы колагын ярды. Бу юлы ишек звоногы икән. Кемдер кнопкага өзлексез баса да баса. Пижаманы иңгә салганны да көтми хәтта. Шәһрияр йокылы күзләрен уа-уа ишекне барып ачты.

— Ну бу шәһәр халкын! Йокларга дисәң, аларны куш! — дип, сукрана-сукрана, авылча киенгән өлкән яшьләрдәге агай исәнлек-саулык та сорашып тормастан, эчкә үтте: — Шәһрияр туган син буласыңмы?

— М-мин...— диде Шәһрияр, аптыраудан бераз арткарак чигенеп. Ул бу кешене гомерендә беренче тапкыр күрә иде сыман.

— Авылдашыңны танымыйсыңмы әллә? Исәнләш, юньсез!

Көтелмәгән кунак киемнәрен элгечкә элә дә башлады.

— Мин сезне төсмерләмим бит әле. Кем дип әйтим икән? Авылдан киткәнемә байтак шул.— Шәһрияр үзен акларга маташып карады.

— Ничек инде төсмерләмисең? Әгъзам агаең булыр бу. Хәтерләргә тиеш син. Мин Кершәник базарыннан кайтып килгәндә, бәләкәй генә бер малай авыл капкасын ачкан иде. Шуның өчен Әгъзам агасы аңа бернәрсә биргән иде. Йә, әйт, нәрсә иде ул?

Исемен әйткәч, авылдашын таныды Шәһрияр, әмма аңа авыл капкасын ачуын да, аның өчен нәрсә алганын да, хәтер җебен күпме сүтеп караса да, исенә төшерә алмады. Шулай булмый тагын. Хәзер бит аның авылдан китүенә дә чирек гасырдан артык вакыт үткән. Ә менә Әгъзам дигән агайның хәтере аның исен китәрде.

— Вәт сездә хәтер! — диде ул, соклануын яшерә алмыйча.

— Алай димә. Минем хәтер хәзер бернәрсәгә дә ярамый, иске иләк кебек. Кичә нәрсә ашаганны бүген оныттам. Менә шуңа врачларга күренергә дип килдем әле. Шәһәрне син шәп беләсең, алып йөрерсең. Ә хәзергә — чәй давай!

Әгъзам агай чәй эчкәндә дә хәтеренең начарлыгыннан зарланып утырды. Баксаң, ул кайвакытта үзенең исем-фамилиясен дә оныта икән.

— Ярый әле үзем белән паспорт йөртәм. Шул коткара. Алып карасам, үземнең үзем икәнлеге искә төшә. Шулай, туган, эшләр шәптән түгел,— дип кунак соңгы чынаягын каплады да Шәһриярне ашыктыра башлады.

Шәһрияр өстәл җыештыргалаганчы, ул киенеп тә беткән иде. Бәй, бәй, өстендә нинди кием моның?

— Әгъзам агай, минем пальтоны кигәнсең бит.

— Шулаймыни? Ай әттәгенәсе! Үземнең киемнең нинди икәнлеге бөтенләй онытылган. Ярар инде, бер кигәч кире салып тору уңайсыз. Булгач-булгач, әйдә, шәһәрчә булсын, эшләпәңне дә бир, туфлиеңне дә үзем киярмен.

Нәрсә эшлисең инде, Шәһрияргә авылдашының иске сырмасын, кирза итеген кияргә туры килде.

— Түләүле поликлиникага барыйк, энем,— дип кисәтте Әгъзам агай чыгып барышлый.— Мондыена ышанычым бетте. Юньләп тә карамыйча кире борып җибәрә торган алар. Ә акча бирсәң — бөтенләй башкача караш...

Поликлиника янына җиткәч, ул борчылып туктады:

— Ай, хәтер! Акча капчыкта калган икән.

Шәһрияр кесәсенә тыгылды. Анда отпуск өчен алынган акча ята иде, бер тиене дә әле тотылмаган.

— Шушы җитәрме?

— Ну бу шәһәр халкын! Саранлыкка кем өйрәтә үзләрен? Биргәч-биргәч, кызганма. Савабы зуррак булыр.

Шәһрияр, чөгендер кебек кызарып, авылдашына тагын берничә кәгазь акча сузды. Саран булып күренәсе килмәде аның авылдашы алдында.

Әгъзам агайның чыкканын байтак кына көтте ул аллеяда. Кунагы алдында уңайсыз хәлдә калганы өчен үзен тиргәп озак йөрде ары-бире. Ниһаять, Әгъзам агай, бик канәгать булып, аның янына килеп басты.

— Йә, хәтереңне ничек диделәр?

— Хәтер? Нинди хәтер?.. Ә-ә... Хәтер! Хөрт, диделәр. Бик хөрт, диделәр. Менә шуңа алтын теш куярга булдылар әле. Иртән тагы килергә куштылар.

Хәтер юклыкны алтын теш куеп дәвалыйлар микәнни? Абсурд бит. Бу агайның хәтеренә генә түгел, зиһененә дә зәгыйфьлек килгән, ахры. Шәһрияр авылдашын кызганып куйды. Бахыр! Күзеннән ике бөртек яшь тәгәрәде.

— Әйдә, кайтыйк, Әгъзам агай. Ятып ял итәрсең. Бәлки, җиңеллек килер.

Өйгә җитәрәк, магазин яныннан узып барганда, авылдашы Шәһриярнең җиңеннән тотты:

— Тукта әле, энем. Бу магазинда ала торган берәр әйберең юкмы?

— Юк шикелле...

— Уйла әле, уйла. Минем хәтер начар, бик начар инде. Синеке дә начараймасын. Кунак килгәч, берәр нәрсә алалар түгелме соң?

— Анысы өйдә бар, агай, борчылма!

Ярыйсы гына эчеп, кәефләнеп алгач, кунак кеше чирек гасыр элек булган әлеге капка ачу тарихын Шәһриярнең исенә бер-ике тапкыр төшереп алды:

— Һай, үтә гомер! Әле генә Кершәник базарыннан кайтып килгәндә миңа капка ачкан бер малай идең бит.

Шулчак нәрсә биргән идем әле мин сиңа, ә? — Аннан мөңгерәп җырлап җибәрде:

> Калса калсын сезнең хәтер,
> Безнең хәтер калмасын...

Шәһрияр кунагының дөрес җырламавын шәйләп, аны төзәтергә чамалады:

— Киресенчә бит, агай, «калса калсын безнең хәтер, сезнең хәтер калмасын». Халык шулай җырлый бит.

— Ә мин болай җырлыйм! Миңа үземчә җырлавым ошый! — Ул тагы мөңгерәде:

> Калса калсын сезнең хәтер...

Җырны ул ары таба дәвам итә алмады, башын өстәлгә салып, йоклап та китте.

Ярыйсы гына йомшарган авылдашын Шәһрияр, сөйрәп дигәндәй, караватына илтеп салды. Үзенә урынны кухня идәненә җәйде. Бер кичкә кер мичкә, дигәннәр бит, чыдар әле.

Әмма аның бер кичкә дигәне озакка сузылды. Берничә көн кунагын шәһәр буйлап озатып йөреп үтте. Поликлиникага бардылар, магазиннарда йөрделәр, рестораннарга керделәр. Шәһрияр, әлбәттә, кунагыннан бер тиен дә чыгартмады. Үзе түләде. Хәтта аның алтын тешенә дә акча Шәһрияр кесәсеннән чыкты.

Болай булды ул. Медсестра теш куйдырган өчен түләү квитанциясе биргәч тә, Әгъзам агай тагын үз-үзен сүгәргә кереште.

— Хәтереңә төкерим! Акча бит капчыкта калган.

Хурлыкка калмас өчен, Шәһрияргә шактый юкарган пачкадан тагын берничә кызыл кәгазь алырга туры килде.

— Онытмам,— дип тынычландырды кунак. Аннан алтын тешен елтыратып елмайды.— Хәтер генә кире кайтсын.

Теш куелган, акча түләнгән, шуңа кунакның кәефе күтәренке иде. Кайтышлый юл буенча ул Шәһриярне мактап килде.

— Шәһәр кешесе булсаң да, шәп син, энем! Хәтерем начараюны искә алмаганда, мин дә шәп кеше. Иртәгә кайтып китәм. Сагынырсың әле шундый шәп авылдашыңны. Бер истәлегем калсын, әйдә, үзеңә бирәр бүләк алып бирим.

— Куй, мәшәкатьләнмә, Әгъзам агай, кирәкми!

— Юк, юк, әйтмә дә, сөйләмә дә.

Ул Шәһриярне, ай-ваена куймый, «Сувенирлар» магазинына алып керде. Витринадагы товарларга озак ка-

рап торды. Ниһаять, бармагы чылбырлы мөгезгә төртелде.

— Бу нәрсә?

— Мөгез. Грузиннар шуннан шәраб эчә.

— Әһә! Бата бу! Үзеңә шуны алып бирим, булмаса. Менә дигән истәлек.

— Кирәкми, дидем бит инде, Әгъзам агай! Юкка акча әрәм итеп.

— Күп сөйләнмә! Алып бирәм дигәч алып бирәм! Бар, акчасын түлә!..

Шәһрияр күңелсез генә яңадан кесәсенә тыгылды. Нишләптер бу авылдашы ошамый башлады аңа. Туйдырды. Кунакның кадере өч көн инде аның. Шуннан артса, кызыгы китә. Ә бу Шәһриярның атнага якын вакытын алды. Вакытын гынамы соң! Ярый инде, түзгәч түзәргә кирәк. Иртәгә кайтып китәм ди бит.

Кичке чәй алдыннан ул кунакның алдына тагы акбаш утыртты. Әйдә, озату билгесе булсын.

Акбашны күргәч, Әгъзам агайның авызы колагына житте:

— Кая, китер әле теге мин бүләк иткән мөгезне. Шуннан эчеп карыйк.

Ул шешәне мөгезгә бушатты да голт-голтлап чөмерә башлады.

— Тәме икенче! Тәме!..— Шулай сөйләнә-сөйләнә ул берүзенә бер шешәне бушатып бетерде. Буш савытны күргәч, башына сукты:

— Ай эттәгенәсе, бу хәтерне! Сиңа калдырырга бөтенләй истән чыккан!

— Юк, юк, агай, мин барыбер эчмим бит.

— Дөрес эшлисең. Эчү зиһенне югалта. Хәтер йомшара.

Тора-бара аның репертуары тәүге кичтәге эзгә төште: башта үзенең чирек гасыр элек капка ачкан өчен нәрсәдер бирүен сөйләде, аннан әлеге «Калса калсын сезнең хәтер...» дигән жыры белән йоклап китте.

Иртәгесен ул Шәһриярнең эшләпәсен, пальтосын, туфлиен кигән хәлдә юлга чыгарга әзер тора иде. Пальто кесәсеннән кичәге мөгезнең очы күренә.

— Минем киемнәр...— дип башлады Шәһрияр, ни дип әйтергә дә белмичә.

— Ай, хәтер дигәнең! — дип акланды Әгъзам агай.— Ничәмә көн киеп йөреп өйрәнгәч, үземнеке дип торам. Ярар инде. Бер кигәнне кире салып тормыйм. Посылка аша гына кире жибәрермен дә куярмын.

— Ә акча капчыгыгызны алдыгызмы соң? Поликлиникада «өйдә калды» дигән идегез бит.

— Өйдә калды шул. Авылда.

— Ә-ә-ә...— дип суздьт Шәһрияр.— Ярый, сау булыгыз.

Кунак артыннан ишек ябылгач та, Шәһрияр аны шартлатып бикләп алды. Берәр нәрсәсен онытып, кире әйләнә күрмәсен тагын!

Кем булды соң әле ул аның авылдашы? Ике учы белән башын тотып сәгать чамасы шушы сорауга җавап эзләп утырды ул. Газаплы уйлардан аны ишек звоногының чылтыравы бүлде.

— Кем анда?

— Бу мин, Әгъзам агаең!

— Китеп булмадымыни?

— Хәтерeңә төкерим. Автобус расписаниесен бутаганмын. Иртән китәсе бөтенләй истән чыккан. Хәзер иртәгә кала инде.

Йа, хода!

Икенче көнне Шәһрияр авылдашын автовокзалга кадәр озата барды. Касса алдында халыкның күплеген күргәч, Әгъзам агай кулын селтәде дә кире борылырга итте:

— Тагын бүген китеп булмас, ахры! Әнә, нинди зур чират. Якын барырлык түгел.

Авылдашының тагын бер көнгә калырга ниятләгәнен ишеткәч, Шәһрияр бөтен осталыгын эшкә җигеп, кирәк кешеләр белән танышып, дуслашып, ниндидер вәгъдәләр биреп, арткы ишектән бер билет алып чыкты.

— Мә, тот.

— Һәй, шәһәр кешесе булсаң да, шәп икәнсең. Югыйсә кичә озатырга килмәгәч, күңелем ару гына кителгән иде. Ярый, бар! Хәзер кайтып китсәң дә була инде.

Шәһриярнең коты очты:

— Юк, юк, үзем утыртып җибәрәм!

Ул арада платформага автобус килеп туктады. Кәефе күтәрелгән Әгъзам агай, йомшак урынга барып утыру белән, авыз эченнән мөңгерәп җибәрде:

Калса калсын сезнең хәтер,
Безнең хәтер калмасын...

Автобус әкрен генә кузгалды.

— Китте! — диде Шәһрияр җиңел сулап.— Котылдым.

Бу минутта аңа авылдашы киеп киткән киемнәре дә, туздырылган отпуск акчасы да җәл түгел иде. Әйе, котылды! Башкалардан алырга гына яраткан, ә бирергә булганда хәтере таушалган бәндәдән котылды. Юк, үзенә

дигәндә хәтере таушалмаган аның. Хәтта чирек гасыр элек бәләкәй генә малайга нәрсә биргәнен дә хәтерли. Ә нәрсә биргән иде соң әле ул? Кинәт Шәһриярнең күз алдына ап-ачык булып әлеге картина басты. Капкадан пошкыра-пошкыра пар ат уза. Тарантаста утырган кызыл битле агай капка ачкан малайга, алдындагы капчыктан сайлый-сайлый, бер алма ташлый. Малай алманы тешләүгә, аның эченнән корт килеп чыга. Кортлы алма!

Үзе дә, биргән алмасы кебек, кортлы лабаса!

Шулай уйлый-уйлый Шәһрияр йокыга китте. Таң алдыннан «зың-ң! иткән тавышка ул сискәнеп сикереп торды. Тагын ишек звоногымы әллә? Автобусның киткәнен үз күзе белән күрде бит!

Юк, бу юлы будильник шылтырый иде...

ШАБЛОННЫ ШАРТЛАТКАНДА

Көлкеле хикәя

Саматның аягы җиргә тими, ул бүген авылда иң ышанычлы кеше — авыл Советы бинасына күз-колак булып торырга куштылар аңа. Куштылар, дип, бераз шыттырабыз инде. Ә дөресе шул: секретарь Банат күрше райондагы энисенең хәлен белергә киткәндә, әйтеп калдырды:

— Авылда гына түгел, бөтен тирә-якта күз терәп торган бердәнбер ышанычлы актив син, Самат,— диде ул елмаюы белән йөрәк тамырларына кадәр үтеп. Әллә юрамал әйтте, әллә чынын, яртылаш кысылган күзләреннән бернәрсә дә күрерлек түгел. Әйе, шулай ди шул. «Бердәнбер ышанычлы актив», ди.

Самат ни, дөньяда кызлар да барлыгын яңарак кына күрә башлаган үсмер, бу сүзләрне ишеткәч, колагына чаклы кызарды да китте... «Син дә авылда күз терәп торган бердәнбер апа»,— дип әйтергә дә уйлаган иде, кайда ул! Теле тамак төбенә ябышты да калды, һич әйләнми.

Банат исә егетнең уңайсызланганын сизмәде, әллә сизмәмешкә салышты, комплиментын болай дип тәмамлады:

— Мин кайтканчы, шушында дежурить итеп тор инде. Ул-бу була күрмәсен.

Шулай мактый-мактый йомыш кушсыннар әле, кем риза булмас. Самат, әлбәттә, ризалык белдереп, баш какты.

— Кара аны, телефонограмма бирсәләр, язып алырга онытма!— дип кисәтте секретарь кыз машинага утыргач та. Кабинадан аның кул болгаганы озак кына күренеп барды.

Юк, бердәнбер ышанычлы актив, дип шаярып әйтмәгәндер, әнә бит, ничек кул болгый! Актив дигән сүзне икенче сүз белән, әйтик, егет сүзе белән алыштырса да була иде дә, ярар инде. Бары белән — бәрәкәт. Хәер, актив диюендә дә мәгънә бар — җыештыручы Тәлига әби булмаганда, йомыш-юлга ул гел Саматны җибәрә. Форсаты булган саен, сельсовет тирәсендә уралган Саматка шул гына кирәк: Банатның бәләкәй генә йомышы өчен дә кырыкка ярылырга әзер. Активлыгы аның әнә ничек!

Әлбәттә, Саматны күргәч, председательнең «Карачкың тагы монда!» — дип секретаренннан көлгәнен белми. Белмәгәне яхшы. Белсә, ул бүген авылда иң ышанычлы кеше булыр идеме дә сельсовет бинасында телефон төбен саклап утырыр идеме?

Телефон эндәшми. Нигә эндәшми соң әле ул? Районда бу авылның барлыгын оныттылармы икәнни? Телефонограмма бирмәсәләр, һич югында, шалтыратып берәр нәрсә сорасыннар иде. Ә Самат аны язып алыр да иртәгә Банат апасына тоттырыр иде. Банат апасы аны янә мактар иде. «Сине үземнең урынга калдырып ялгышмаганмын. Син, Самат, чынлап та, авылда күз терәп торган бердәнбер ышанычлы актив... юк ла... кешем»,— дияр иде.

Егетнең татлы хыялын урамдагы машина сигналы бүлде. Аның артыннан ук әмер биреп өйрәнгән калын тавыш түземсез яңгырады:

— Берәр тере кеше бармы анда?

— Бар, мин тере! — дип болдырга йөгереп чыкты Самат, ниһаять, үзенең кирәкле кеше икәнен тоеп.

Киерелә биребрәк утырган күн тужуркалы зур гәүдәле агай аңа ышанмыйчарак карады:

— Мин председательне әйтәм.

— Председатель ялга китте.

— Алайса секретарь чыксын!

— Ул чыга алмый... Э-э-э...— Самат, ни дип аңлатырга белми, тотлыга башлады.— Ул... Ул...

— Нәрсә, бәбилиме? Ул таптымы?

Самат шундый тупаслыкны көтмәгән иде. Юк, ул Банат апасын күрәләтә мыскыл итәргә юл куймас! Әллә кем булмагае, чурт булсын!

— Ә сез... телегезне тыегыз! Ул әле кияүгә чыкмаган.— Аннан, әйтергәме-юкмы дип чамалап торды да үзенчә иң әче сүзен ишеттерергә булды: — Күн тужуркалы ишшу...

Зур гәүдәле агай да үзенең арттырыбрак җибәргәнен сизде бугай, тавышын йомшарта төште:

— Ә син, көзге әтәч... кем буласың?

— Мин — актив! — диде Самат горур рәвештә.

Актив сүзен ишетүе булды, Күн тужуркалы яңадан элекке хәленә кайтты:

— Безобразие! — дип җикеренде ул.— Форменное безобразие! Күргәзмә агитациягә сездә игътибар — ноль! Вывескалар юк. Лозунгылар — шаблон! Халыкчанлык, тагы бер тапкыр халыкчанлык! Аңлашылдымы?

— Аңлашылды,— диде Самат, авылларында шулкадәр җитешсезлек булганына коты очып.

— Бүгеннән үк алыштырыгыз! Иртәгә кире үткәндә тикшерәчәкмен. Эшләмәсәгез, карагыз аны, председатель белән секретарегызга еларга туры килмәгәе...

Күн тужуркалы киткәч тә, Самат болдырда озак басып торды. Аның авылда күз терәп торган берданбер якын кешесенә бәла киләчәк. Кайчан? Иртәгә! Юк, Самат моңа юл куймас! Ул Банат апасын Күн тужуркалының усал тырнагыннан коткарып калачак. Ул кич буе, төне буе утырачак, әмма яңа вывескалар, лозунглар язып эләчәк. Аның язганы, әлбәттә, шаблон булмаячак. Шаблонны шартлатачак Самат. Ә Банат апасы моның өчен аңа карап тагын бер елмаячак. Кем белә, бәлки, үбеп тә алыр. Үпмәсә, иренен генә тидереп алса да җиткән Саматка.

Тәлига әби кич себерке тотып килеп кергәндә, ул инде муеныннан эшкә чумган иде. Ап-ак буяулы пумала белән чәче бер дәрәҗәдә. Аерырлык та түгел. Идән-өстәлгә такталар, кызыл тукымалар җәеп салынган.

— Ни кырасың, Самат улым? — диде әби, берни дә аңламыйча.

— Шаблонны шартлатам! — диде Самат башын да күтәрмичә.— Күн тужурканың күзе шар булачак.

— Нинди тужурка? Нинди шабылун?

Самат әбигә аңлатып бирде:

— Шабылун түгел, шаблон. Ягъни бер калыпка салу. Әйтик, сиңа ботинка тексәләр дә бер калып, миңа тексәләр дә бер калып. Ферштейн? Ә Күн тужурка...— Егет артыгын аңлатып торуны кирәксез тапты.— Бер сүз белән әйткәндә, авылның күлмәген алыштырам.

— Анысын дөрес әйтәсең, бер калып ярамый. Һәр кешенең үз калыбы, үз күлмәге булырга тиеш,—дип хуплады әби.— Тик ничек ерып чыгарсың икән бу эшне?

— Синсез булмый, Тәлига әби,— дип сөйләнде Самат, «Рәхим итегез» дигән җөмләнең азагына өндәү билгесе куеп.— Син бит халык вәкиле. Ә безнең язулар халыкчан булырга тиеш. Син әйтеп торырсың, мин язам. Ферштейн?

— Фәрештә-ен, фәрештә-ен,— дип җаваплады әби, бу

мөһим эштә үзенә зур өмет багланганын белгәч.— Сора, сора, белгәнемне әйтермен.

Самат аның саен дәртләнебрәк китте:

— Әйтик, менә ашханәне алыйк. Аның ишек башында нинди язу?

— «Ашханә».

— То-то! Район үзәгенә барсаң да «ашханә», шәһәргә барсаң да «ашханә». Шаблон.

— Ашханә дигәннән, әйтим әле, кичә камыр алырга керсәм, ис-акылым китте,— әби үзен борчыганны сөйләргә тотынды: — Үтеп баручы шоферлар ярты-йорты гына капкалаганнар да ашларын шул килеш өстәлдә калдырып киткәннәр. Күпме нигъмәт зерә әрәм була. Ярты кашык яхшы аш калганчы, яман корсак ертылсын, ди торган иде минем картинәй мәрхүм.

— Стоп! Ничек ди торган иде? Яман корсак ертылсынмы? — Самат уйга калды.— Юк, юк, булмый икән. Артык тупас. Башкачарак лозунг кирәк.

Ул арада Тәлига әби мәрхүм дәү әнисе турындагы хатирәләргә бирелде:

— Көненә биш-алты өйгә кунакка алырлар иде үзен. Табында аннан да тамакка таза кеше булмый торган иде, валчыгын да әрәм итми иде, җыеп каба иде, мәрхүмкәем. Аш — ашка, урыны — башка, ди торган иде...

— Стоп! Аш — ашка, урыны — башка... Ашханә ишеге өстенә шулай дип язып куябыз.— Самат, учларын уып, ишекле-түрле йөреп алды.— Иң мөһиме — халыкча. Бер объект булды. Икенче объект — почта.

Тәлига әби, шуны гына көткәндәй, сүзен почтага борды:

— Бүген почтальон Сәмигулла улымнан хат китереп тоттырды әле. Озакламый кайтам, дип яза да яза. Хаты килә, үзе юк та юк.

— Стоп! Почта башына язып элергә шуннан да шәп вывеска булмас: «Хаты килә, үзе юк». Ну, Тәлига әби, үзеңдә баш! Бәлки, почта янындагы сберкассага да берәр лозунг уйлап табарсың.

— Теге акча саклый торган урынны әйтәсеңме?

— Әйе, әйе. Нәкъ үзе.

— Аларда акча бер букча инде. Безнең генә ул, бозау ялаган. Бер зарплатаны икенчесенә ялгый алмый җәфаланабыз.

Саматның шатлыгы күзгә күренеп үсте. «Бездә акча — бер букча!» Сберкассага моннан да шәп язуны көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың.

Ары таба вывескалар табу эше тагын да ырамлырак

дәвам итте: Самат, Тәлига әбисен сөйләндерә-сөйләндерә, аның хәбәрендә ялтырап калган «алтын бөртекләрне» кәгазенә төшерә барды. Магазин сүзе чыккач, «Тиен — сезнеке, сум — безнеке!» дип язып куйды ул. Фельдшер пунктына исә «Чирен яшергән — үлгән» дигән сүз кулай күренде. Хәтта участковыйның бәләкәй бүлмәсенә дә язу табылды — «Керереңнән алда чыгырыңны уйла!» Тик менә бая язган «Рәхим итегез»не кайда эләргә? Ярар, иртәгә урыны табылыр әле.

Самат, кабаланып, пумалага тотынды. Төне аның, әлбәттә, йокысыз үтте.

Күн тужуркалы иптәш сүзендә тора торган кеше икән. Иртәнге сәгатьләрдә аның машинасы янә сигнал бирде. Аның афтында ук, нәкъ кичәгечә, тупас тавыш ишетелде:

— Әй, кем бар анда?

Бу юлы баскычта секретарь Банат күренде. Ул әле генә әнисе яныннан кайтып тора иде. Хәтта өстеннән юл тузанын да кагып өлгермәгән иде.

— Безобразие! Хулиганство! — дигән сүзләр каршы алды аны.— Издевательство!

— Ни булган, Хәсән Назарович? Кемне тиргисез?

— Авыл буйлап нинди язулар эленгән, шуны беләсезме?

— Юк... Нинди язулар?..

— Утырыгыз, алайса. Күрсәтеп чыгыйм. Үзегез белән келәшчә дә алырга онытмагыз!

Алар, тиздән биш-алты вывеска төяп, яңадан авыл Советы янына килеп туктадылар.

— Кемнең эше бу? — дип төпченде Күн тужурка, әлеге язуларга төртеп.

— Белмим,— дип акланырга тырышты Банат.— Башыма да китерә алмыйм.

— Ә мин беләм. Кичә монда нинди активистың утыра иде?

— Активист? Нинди активист? — Банат бераз аңламый торды. Аннан көлеп җибәрде: «Нинди активист булсын ул, җиденчене быел гына бетергән малай».

— Малай башы белән миннән көлмәкче — күрсәтермен мин аңа! Хәзер үк табып китерегез үзен.

Саматны авыл буйлап эзләделәр, әмма таба алмадылар.

— Качкан! — диде Күн тужурка.— Гаебен сизеп качкан.— Ул тәмам чыгырыннан чыкты: — Җир астыннан булса да табыгыз!

Төрле тарафка төрле кеше җибәрелде. Ахырда мили-

ционер аны зират капкасына «Рәхим итегез!» дигән язу кадаклап торган җиреннән эләктереп алып килде.

— Менә теге сез әйткән активист!

Күн тужурка, йокы кермәүдән күзләре кызарган, баштанаяк ак буяуга буялып беткән Саматны күрү белән, тавышын йомшартып, сорау алырга күчте:

— Боларны син яздыңмы?

— Мин! — диде Самат горур гына. Үзе бер күзе белән Банат апасы ягына карады. Хуплау көтте ул аннан.

— Ни дип яздың инде? — диде Банат апасы, тыныч кына итеп.

— Кичә менә бу иптәш сездә күргәзмә агитация начар куелган дип тиргәде дә язуларны алмаштырырга кушты. Шаблон булмасын, диде, халыкчан булсын, диде. Мин инде ул кушканча эшләдем.

— Ахмак! — дип кинәт кабынып китте Күн тужурка.— Бездән, чынлап та, күргәзмә агитациянең шаблон булмавын, халыкка якын булуын таләп итәләр. Ә син нәрсәләр язгансың? Адәм мәсхәрәсе! Халык рәвве шулай сөйли? Халык «Алга, җиңүләргә!» дип сөйли, «Яшәсен!» дип сөйли. «Даешь!» дип сөйли. Ә ул: «Бездә акча — бер букча»,— имеш. Тьфү!..

— Йә, нишләтергә боерасыз бу хулиганны, Хәсән Назарович? — дип сорады милиционер, бөршәеп, тагы да кечерәеп калган Саматның җилкәсеннән алып.— Бу килеш калдырырга ярамыйдыр бит?

— Ярар, калып торсын инде бер юлга,— диде Күн тужурка, басыла төшеп. Аннан секретарь кызга борылды: — Сельсовет янына якын йөртмәгез үзен. Активист, имеш, тьфү!

Ул башка сүз әйтмәде, машинасына утырды да, беркемгә дә карамый, шоферына эндәште:

— Киттек!

Милиционер машина артыннан бер-ике метр ияреп барды:

— Хәсән Назарович, ә теге зират капкасындагы «Рәхим итегез!» дигән язуны нишләтергә боерасыз?

Күн тужурка башка бер нәрсә турында да уйларга теләмәде, бугай. Кулын гына селтәде:

— Ярый, калсын!..

Самат Банат апасына арты белән борылды. Юк, шаблонны шартлата алмады ул. Бары үзенең тәүге мәхәббәтен генә шартлатты.

Бәлки, шулай кирәк булгандыр да...

НОГМАН МУСИН

Ногман Сөләйман улы Мусин 1931 елда Башкортстанның Ишембай районы Колгына авылында туа. Урта мәктәптә һәм Стәрлетамак укытучылар институтында белем ала. Берничә ел үз авылында балалар укыта, район мәгариф бүлегендә мәктәпләр инспекторы булып эшли.

Язучының «Зөһрә» исемле тәүге повесте 1960 елда дөнья күрә. Хәзер инде Н. Мусин «Җир бизәге», «Авылым юлы», «Кеше елмая», «Синең мәхәббәтең», «Заман җилләре», «Чәчкәләр керфеген ача», «Төпкелдән төшкән килен», «Мәңгелек җыр», «Җиз кыңгырау», «Күңел нуры» һәм башка повестьлар, шулай ук «Сайлап алган язмыш», «Мәңгелек урман», «Зәңгәртауда — аю болан», «Яралы кеше тавышы» дигән романнар авторы.

Н. Мусин балалар өчен дә байтак кына әсәрләр иҗат итте. «Сугыш төш түгел», «Ак бураннар», «Әтиемнең оч сәнәге», «Ак юл сиңа, укытучым!», «Мин дә ата баласы» дигән повестьлары һәм дистәләгән хикәяләре яшь укучыларның ихтирамын яулады.

Н. Мусин 1958 елда Коммунистлар партиясенә кабул ителгән. Ул — 1963 елдан СССР Язучылар союзы члены. БАССРның атказанган культура работнигы.

МАЗАСЫЗ КӨН

Хәмит, һәркөндәгечә, сәгать җидедә уянды. Бу гадәт анда еллар буенча шулкадәр нык калыпланган, җыелыш-фәләннәрдә озак утырып йә командировкадан соңлап кайтып, төн уртасы аугач кына йокларга ятса да, ул төгәл шушы вакытта тора. Менә ул әле дә җиңел генә урыныннан күтәрелде, аягын койкадан сәлберәтеп, киерелде, иллегә җитмәс борын ук чәче коелып, уч төбедәй ялтыры тимгелләнгән башын сыйпап алды.

Ачык ишекләр аша, күңелгә җылы төяк рәхәтлеге биреп, кухня ягыннан бакырча капкачын чыңгырдатып чәй кайнаганы, табада нинеңдер чыжлап кызганы ишетелә. Рәхимәсе алтыдан ук торып, һәр чактагыча, иренең күңелен табардай итеп иртәнгелеккә ашарга әзерләп йөридер инде.

Кызының бүлмәсе ягында да тып-тын, күрше бүлмәдәге улының да тавыш-тыны ишетелми. Күрәсең, бүген институтта лекцияләре соңрак башланадыр, югыйсә, улы бу вакытта гантельләр белән физзарядка ясарга тотына, кызы да кыбырдый торган иде.

Ирекле көрәш буенча секциягә йөргән, ярышларда катнашып, спорт мастерлыгына кандидат дәрәҗәсен алган улы атасын иртәнге зарядка ясарга димли, аның корсагы үсүен, кайсы чакта тыны кысылуын, йокыдан торуга күз төпләрендә күксел тимгел барлыкка килүен, хәтта атасының чәче коелып, түбәсе ялтырый башлавын да спорт белән шөгыльләнмәүнең бәласе дип карый иде. Хәмит улының мондый фикерләренә каршы бер сүз дә әйтми.

— Дөрес сөйлисең, улым,— дип, аның сүзләрен хуплап ук куя, шуннан өсти: — Минем алай кыйланыр чакларым үткән шул инде, улым.

Хәмит бүген дә берничә тапкыр иелеп-бөгелеп тәнен язгандай итте дә саргылт буйлы атлас пижамасын киде, бүлмәне иңләп җәелгән келәмнән тавышсыз гына атлап зал ягына чыкты. Залга түшәлгән келәм тагы да зуррак һәм бөтен иркен бүлмәне иңләп ята иде. Хәмит шул ук тавышсыз адымнар белән барып, һәр көндәгечә, балкон тәрәзәсенә тыш яклап куелган термометрга күз салды — салкынайта төшкән икән бүген; шуннан стенага элүле, заманча матур итеп эшләнгән барометрга карады — анысы көн бозылуын күрсәтә иде.

— Дә-әәә...— дип, май утырудан көрәя төшкән җилкәсен ышкыды Хәмит, кухня ягына үтеп, янә һәркөндәгечә:

— Хәлләр ничек, бичәкәй,— дигән булды, шаяру катыш ягымлылык белән, Рәхимәнең аркасына учын куеп.

Рәхимә сүзен дә нindидер тыйнаклык, сабырлык белән әйтә белә торган әдәпле хатын иде.

— Шулай иртәнчәк кенә хәл белешәсең инде син,— диде үзе эше белән булашкан арада, басынкы гына итеп.

Хәмит кичә уникe җитә язгач кына кәефсезләнеп кайтып керүен, тыншаеп утырып ашагач та урынга барып ауганын, хатынына аркасын куеп йоклап китүен хәтер-

ләде дә, үзендә гаеп барлыгын сизеп, күрсенде, әлеге шул калынаеп барган җилкәсен угалады.

— Һы... Нишлисең инде, бер нәрсәсе табылып тора бит,— дип мыгырдый-мыгырдый ваннага кереп китте.

Ванна бүлмәсе дә иркен, стеналары ап-ак кафель белән капланган, юыну кирәк-яраклары салынган пыяла киштәнең өс ягына зур көзге беркетелгән; ванна да, раковина да чынаяктан таза итеп юылган, нindидер наз, күңел тынычлыгы бирүче пакьлек белән балкып тора. Әйе, Рәхиләсе дөньяны матурлап тота белә шул, ә Хәмитнең, эштән бушап, өйдә кыл да кыймылдатканы юк диярлек. Аны башы-тоягы белән эш йоткан, хәтта шимбә, якшәмбе көннәрдә дә юньләп ял итә алмый.

Зур, куәтле төзелеш трестына җитәкчелек итә ул. Ә төзелеш эшенең очы да, кырые да юк: берничә объект төзелеп ята, кайсыберләренә нигез салына, бик күпләренә заказчылардан проект китерелгән... Һәрберсен төзеп бетерү, файдалануга тапшыру сроклары акка кара белән язып куелган. Шул вакытына өлгермәдеңме, эшләр харап: югарыдагы җитәкче оешмалардан да, заказчылардан да ишетмәгән сүз калмый. Төзетеп тапшырылган объектларның да әле еш кына мәшәкать тудырган чагы була. Кичә әле моннан бер ай элек тулы компетенцияле комиссия тарафыннан кабул ителгән торак йорт өчен күпме гауга купты. Имеш, сантехника эшләре аннан-моннан гына башкарылган, тәрәзәләр, ишекләр ябылып бетми, идәннәр калтайган... Квартира алучылардан жалоба күп. Нишлисең, шәһәр советы председателенең урынбасары, райсовет председателе, капиталь төзелеш идарәсенең вәкиле белән шул йортка барырга, япсаң да су өзлексез аккан яки ачсаң да бөтенләй акмаган краннарны, чатнаган яки ярык унитаз һәм раковиналарны, торбага юньләп тоташтырылмаган җылылык батареяларын карап, ишек, тәрәзәләрнең ябылу-ябылмавын тикшереп йөрергә туры килде. Квартира хуҗаларына нәрсә — давайлыйлар, тиргиләр, каһәрлиләр, таптыралар, ә ел саен дистәләгән йортлар төзеп тапшыручы Хәмит Әхмәтович Әхмәтов кимчелекләрнең сәбәбен белә, тик аңа бу җитешсезлекләрне бетерү, ай-һай, кыен! Аннан килеп, трест бу йортны бер тапкыр тапшырган, актка кул куелган. Шуңа күрә ул хәтер калдырырлык сүзләрне дә башын иеп, кашын җимереп, сүзсез тыңлый, ләкин җитешсезлекләрне бетерергә вәгъдә бирергә дә ашыкмый. Күз алдындагы кимчелекне күрмәмешкә салышудан да кыены юктыр ул!.. Ләкин Әхмәтов түзә, түзә дип, мондый хәлләргә гадәтләнеп беткән ул, хәтта мондый

шау-шуны һичсүзсез булырга тиешле күренеш дип карый. Шулай да, ялгызы калган чакларда, аның йөрәген намус корты да кимергәли, саруы кайный, төзелеш эшендәге шундый кимчелекләрне бетерергә үзенең көчсезлеген тоеп, пошынкылыкка бирелә...

Кичә дә әнә шундый кәеф белән кайтып кергән иде бит ул, ә хатыны төртмә телләнеп маташа...

Ашап бетеп, киенүенә, сәгать сигез туларга төгәл ун минут калганда, тәрәзә каршысына кара «Волга» килеп туктагач, Әхмәтов ишеккә уңайлаган иде, хатыны, кухня ягыннан чыгып:

— Карале, кичә Уразмәт янына баргансыңдыр бит? Хәле ничек? — дип сорады.

Хәмит туктады, гаепле кешедәй, хатынына борылып карарга базнат итми торды.

— Барып булмады шул, Рәхимә...— Хәмит ишекнең йозагын ача башлады, ләкин, карышкан шикелле, аның тәгәрмәче әйләнми, дымлы бармак бите шуып тик тора.

Шул арада Рәхимә басынкы гына итеп аңа сукранды:

— Харап икән, гомерлек дустым, дисең, янына барып әйләнергә атна буе вакыт тапмыйсың.

Хатыны, аның җавап биререн дә көтми, кызы йоклаган бүлмәгә кереп китте. Хәмит, ишекне ачып чыккан чакта, йомшак кына итеп:

— Кызым, торасыңдыр бит,— дип эндәшкәнен ишетте.

Һай, хатынының менә шулай йомшак кына итеп сөйләшүләре. Ачуың килгән чакта да телеңне аркылы тешләтә дә куя.

Шулай да бүген Хәмит Әхмәтовичның күңел китеклеге тиз генә ямалмады. Чыгып, машинасына утыргач, шоферы белән дә исәнләшмәде хәтта. Чыгып китәр чакта хатыны әйткән сүзләр аның күңеленә эремәс төер булып тыгылган иде.

Хәмитнең Уразмәтне гомерлек дустым дип әйтүе дә, көн саен «бүген барып хәлен белешәм», дип чыгып китсә дә, больницада яткан Уразмәтнең янына кереп әйләнү өчен ун-унбиш минут вакыт тапмавы да дөрес. Бер уйласаң, үзен-үзе әллә ни гаепләп, күңелен әллә ни юатмаса да ярый инде Хәмиткә. Эшеннән чынлап та бушый алмый, тын алырга да вакыты юк. Шул ук вакытта аның Уразмәтне онытырга да хакы юк. Аның аркасында Хәмит Әхмәтов бүгенге югарылыгына күтәрелде, аның аркасында дөньяның артына тибеп яшәп ята түгелме? Хатыны да әнә шуңа күрә сөйләнә бит инде.

Һай, бу дөнья! Уразмәт Баязитов яшь кенә көенчә

төзелеш идарәсенең баш инженеры булып эшләгән чагында Хәмитне зур бәладән коткарып, аның ары таба үсешенә юл ачармын дип уйламагандыр да, бәлки.

...Төзелеш институтын бергә тәмамлап кайтып, Уразмәт белән Хәмит бер үк төзелеш идарәсендә эшкә тотындылар. Тәүдә Хәмитне — прораб, Уразмәтне мастер итеп куйган иделәр. Үзенең шулай бергә укып чыккан иптәшеннән аз булса да дәрәҗәлерәк эшкә куелганы өчен, Әхмәтов эчтән генә куанып та йөрегән иде. Әллә эшкә ихласлыгы, талымсызлыгы, әллә кешеләр белән танышлыгы булуы аркасында инде, Уразмәт хезмәт баскычлары буйлап тиз үк үрләде дә китте: участок начальнигы, идарәдә бүлек начальнигы, баш инженер... Ә Хәмит һаман шул прораблык эшендә таптанды, үзләренең төзелеш участогы эшләгән җирдәге такта будкадан башка рәтле бүлмәдә утырып эшләү бәхетенә дә ирешә алмады. Ләкин Уразмәт Баязитов, һаваланып, үзенең сабакташын онытмады, тел ярдәме дә күрсәтте, киңәшләрен биреп, ул төзеткән объектларны күз уңыннан ычкындырмый торды. Бәлки, тора-бара, Хәмитне идарәгә эшкә алыр, йә участок начальнигы итеп үрләтүдә дә ярдәм итәр иде Уразмәт. Көтмәгәндә килеп туган бәхетсезлек аның бөтен уй-хыялларын, ары таба хезмәт һәм тормыш юлын бутады да куйды.

Ул чакта Хәмит Әхмәтов прораб булып эшләгән участок заводта яңа продукция бирергә тиешле корылманы төзи иде. Аның корпусы салынып бетеп барганда гына, бер як нигез җиргә бата башлагач, төзелеш эшләрен туктаттылар. Бу хәл өчен проектлаучылар гаепләме, геодезистлармы, төзүчеләрме икәнен тикшереп чыккан арада, ярты стена җимерелеп тә төште. Аннан китте эшләр катлауланып: төрле урыннардан төрле дәрәҗәдәге кешеләр катнашлыгында әллә ничәмә комиссия төзелде, идарә начальнигы белән Уразмәт Баязитовны көн дә әллә ничәмә урынга чакырттылар.

Килеп туган гадәттән тыш хәлне турыдан-туры төзелеш эшләрен алып баручылар ныграк аңлата алырга, аның чын сәбәпләрен белергә тиеш иде. Шуңа күрә төзелеш объектының дүрт күзе булырга тиешле прораб Әхмәтовны берничә тапкыр чакырып алып, мәсьәләне ачыклау өчен, бик ихлас, дусларча сөйләшеп тә карады Уразмәт. Ләкин тегесе уфтанудан, көрсенүдән, «һич ни дә аңламыйм, без бөтенесен дә проект буенча эшләдек» диюдән башканы белмәде.

Гомумән, мондый чакта җаваплылыкны беркем дә үз өстенә алырга теләми бит инде. Геодезистлар да, проект-

лаучылар да, төзүчеләр дә аклану өчен кырык төрле дәлил тапты. Ләкин шундый зур, сирәк була торган бәла өчен гаепле кешеләрне табарга, аларны җавапка тарттырырга, тиешле җәзасын бирергә дә кирәк иде. Тора-бара югарыдагы җитәкчеләр, һәртөрле комиссияләр таякның авыр башы төзүчеләргә, иң беренче чиратта участок җитәкчеләренә төшә, дигән нәтиҗәгә килә башлагач, Уразмәт Баязитов сабакташы Әхмәтовны бу бәладән аралап калу өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләде. Ә нәтиҗә ул бөтенләй көтмәгәнчәрәк килеп чыкты: төзелеш идарәсе начальнигын, баш инженер Баязитовны эшеннән алдылар, участок начальнигын түбәнрәк вазифадагы эшкә күчерделәр, ә Хәмит һаман үз урынында торып калды.

Алай гынамы соң әле: шуннан азак Хәмитнең дәрәҗә дә, шуның белән бергә вазифа да гел үсә барды, ә Уразмәт кая барса, нишләсә дә, бер ябышкан «кара сакалы» артыннан калмады. Гомеренең иң шәп өлеше гади инженер-төзүче булып үтте әнә. Дөрес, Хәмит Әхмәтов тәү карашка, аны онытмаска тырышкан сымак иде: дустан өздереп сөйләште, берничә тапкыр кунакка да чакырып алды, кирәк чакта «Волга»сын да биргәләп тора иде...

Трест алдына урнашкан йорт каршына килеп туктагач, Хәмит Әхмәтовичның уйлары өзелде. Шулай да ул, башка чактагы кебек, машинадан ашыгып төшеп, ишегалдында очраучыларга хуҗаларча баш кагып исәнләшә-исәнләшә, эшлекле атлап, икенче каттагы зур, якты кабинетына ашыкмады, биленә таш таккандай, урыныннан кузгалмый утырды.

Аны байтак еллар йөрткән, аның гадәт-кылыкларын һәр хәрәкәтеннән, күз карашыннан белеп беткән шоферы аңа аптырабрак карады. Ахырда түзмәде, сорады:

— Барасы җирегез бармы әллә? Кайда?

Хәмит Әхмәтович көрсенде, урыныннан кыбырдый биреп куйды, ләкин һаман төшмәде.

— Сәгать бишкә больницага барырбыз.— Шулай диде дә, үзенең сүзендә тора алырына шикләнгән сымаграк, уйлап куйды. Әллә шушы шиген тарату өчен инде, кесәсеннән акча алып, шоферына сузды.— Менә, базарга барып, алма, виноград, карбыз, кавын кебек нәрсәләр алырсың.

Ул төште дә, җилкәсенә авыр йөк яткандай иелә биреп, ишеккә таба атлады.

* * *

Төн буена керфек тә какмаган Уразмәт Баязитов бу мәлдә, каты сызлануыннан кинәт кенә айнып киткән сымак, тәннәре җиңеләеп, зиһене ачылып, әллә нинди уйларга тарып ята иде.

Палатада аннан башка тагы өч кеше бар. Аларның авыруы әллә ни каты түгел, шуңа күрә, йомышлары булса да, булмаса да, керел-чыгып йөриләр, бер койкага җыелышып утырып, Уразмәтне борчымаска тырышып, көңгер-каңгыр сөйләшәләр. Уразмәт исә аларга игътибар итми, аны очсыз-кырыйсыз уйлар камап алган.

Кичә хатыны төнгә аның янында калу уе белән килгән иде.

— Янында утырсам, җиңелрәк булыр,— дип тә карады.

— Куй, монда ничек төн үткәрәсең. Хәлем ул кадәр мөшкел түгел бит әле,— дип, җайлап-майлап дигәндәй кайтарып җибәрде, хәсрәтләнеп йөргән Гатифәсен йончытасы килмәде. Болай да көн дә ике-өч тапкыр йөгереп килә торгач, атна буена арып бетте инде.

Менә әле дә: «Тагы килеп җитәр инде, бахырым. Килмәсә дә ярар иде, хәлем аруланып тора, ләкин ул түзәмени соң?» — дип, Гатифәсе хакында уйлады ул. Шуннан, ничектер, атна буе ятып та, моңача һич уйламаган хәл исенә төште: аның янына хатыны белән балаларыннан башка берәү дә килеп әйләнгәне юк бит әле. Хәер, ике энекәше ял көне килеп киткән иде. Башка бер кем дә булмады...

Шушы хәлне хәтерләгәннән соң башланды да инде әллә нинди авыр, күңел газаплагыч уйлар. Бер карасаң, чирләп егылган һәр кешене бимазалый торган, мыжык, бик үк нигезе булмаган уйлар кебек иде алар. Адәм баласы больницага эләктеме, бөтен кешенең үзенә игътибарлырак булуын таләп итә, ачыктан-ачык таләп итмәсә дә, аны шушы теләк чолгап ала башлый. Янына хәл белергә килүләрен көтеп, күзе тона; берәрсе килдеме, аның кем булуына да карамый, бала шикелле куана, хәтта үзен шәбәя төшкән кебек хис итә. Алай гына да түгел, чирле чагында янына килүчене иң якын, иң тугрылыклы кешегә санынсың.

Уразмәт тә бүген, чире йомшарып, зиһене ачыла төшкәч, шушы хакта уйлый. Чынлап та, нигә бер дусты, таныш-белеше дә килми әле аның янына? Әллә аның якын дусты да юкмы икән?.. Бу уеннан Уразмәт сискәнеп үк китте. Ничек булмасын ди? Ул бит гомере буена кеше-

ләргә ярдәмчел иде, авырлыкны үзенә алып булса да, кешше күңелен кырмаска тырышты. Шуңа күрә аны да үз итәләр сымак иде. Кемнәрдән генә рәхмәт сүзе ишетмәде, кайсыберәүләре хәтта ачыктан-ачык: «Кабергәчә онытмам, Уразмәт дус»,— дип хәбәр сала иде. Ә менә аны эш өстендә йөрәк өянәге сугылып, «ашыгыч ярдәм» машинасында больницага китереп салуларына атнадан артык вакыт үтте, шуларның, ичмасам, берсе дә килеп күренми. Монда ятканын белмиләр диярсең, килергә теләге булган кешегә аны сорашып белүе кыенмыни? Кайсы больницада икәнен идарәдә дә беләләр, сорашырга Уразмәтнең өендә телефоны да бар.

Шулай уйланып ята торгач, моннан байтак еллар элек — үзе идарәнең баш инженеры булып эшләгән чактагы бер хәл келт итеп хәтеренә төште.

Баязитов, командировкага барган җиреннән салкын тидереп, чирләп киткән иде. Уразмәт үзе: «Әллә ни юк мондә, болай да үтәр әле, эшнең бик күп чагы»,— дисә дә, врачлар, бюллетень биреп, һичкайда чыгып йөремәскә, ятып кына торырга куштылар, гомерең белән шаярма, дип кисәттеләр. Өстәвенә, Гатифәсе дә: «Бер көн ял иткәнең юк, синсез эшләре җимерелмәс әле»,— дип, каравыллап дигәндәй, аны койкадан торгызмады. Шул чакта бит аның авырып киткәнен бөтенесе әллә кайдан белеп беткән иделәр. Идарәдән, аңа караган төзелеш участокларыннан, тагы әллә кайлардан өенә килделәр. Идарәнең постройком председателе, профсоюздан сезгә күчтәнәч, Уразмәт Гаязович, дип, әллә никадәре ашамлыклар күтәреп килгәч, аңа хәтта уңайсыз булып киткән иде. «Күчтәнәчне» алмаска итте ул, ә постройком председателе, телен тасмадай итеп: «Без һәр чирләгән кешегә дә шундый ук игътибар күрсәтәбез, профсоюзның мөкатдәс бурычы бит бу»,— дип, ай-ваена карамый калдырып китте... Хәмит дусты исә иртәнчәк эшкә киткәндә дә сугыла, кичен тагы килеп керә, янында озак итеп сөйләшеп утыра иде...

Хәзер берсе дә юк. Нинди хәл бу? • Шушы соравына җавап эзләп ята торгач, аның йөрәген кинәт бер ачы тойгы тетрәтеп үтте: ул чакта бит Уразмәт — кулында власть булган, җаваплы җитәкче иде, хәзер гади бер инженер.

«Китче, чирләгән чакта да кешеләргә булган мөнәсәбәт дәрәҗәгә карап билгеләнмидер»,— дип, бу коточкыч уйны үзеннән куарга маташты ул. Менә, мәсәлән, институтның беренче курсыннан башлап гомер юллары бергә бәйләнгән Хәмит дусты, мөгаен, бу хакта уйламыйдыр. Трест белән җитәкчелек итү уенмыни, эше күптер, буша-

ган чагында килеп житәр әле. Гатифә, үткән атнада ук шылтыратып, Уразмәтнең авырып китүе хакында Рәхимәгә әйттем, дигән иде бит...

Ярый, Хәмит килми калмас, ә соң бергә эшләп йөргән таныш-белешләре нигә юк? Әллә Уразмәтнең, гади бер инженерның, чирләп китүеннән дөньяның почмагы кителмәс әле, дип карыйлармы? Чынлап та, Уразмәт больницада ятканнан, хәтта ул үлеп китсә дә, эшкә ни зыян килә? Аның кебек белгечләр хәзер буа буарлык... Шулай да, Уразмәт урынына Хәмит Әхмәтов — трест управляющие — больницага эләксә, ничегрәк тотар иде микән алар үзләрен? Мөгаен, көнәлгәре, берсеннән икенчесе алданрак барырга тырышып, янына йөгерерләр иде. Чөнки ул, Хәмит Әхмәтов, сәламәтләнеп чыккач та, аларга житәкчелек итәчәк, больницага килеп хәл белешкән өчен, кайчан да булса бер «игелеген» күрсәтәчәк...

«Фу-уу-у... Әлләниләр уйлый башладым. Үлем түшәгенә егылган кешегә дә кулындагы властька карап ихтирам күрсәтелмәс инде...»

Иплән кенә палатаның ишеге ачылган тавышка Уразмәт ниндидер өмет белән (берәр хезмәттәше түгелме!) башын калкытып карады. Анда кулына төенчек тоткан кызы басып тора иде. Ярата Уразмәт хәзер инде буйга житкән, университетның икенче курсында укып йөргән бәләкәй кызын. Әле дә, аны күргәч, атна эчендә сулыгып, саргаеп киткән чырае яктырды.

— Килеп життеңме, кызым? Үт, әйдә, кил яныма,— дип куанды, хәтта, торырга теләгәндәй, калкына биреп куйды.

— Әнием кичкә килермен диде. Әле базарга алма, виноград алырга китеп калды,— диде кызы, аның янына утырып, шуннан илгәзәк һәм хәстәрлекле тавыш белән аның хәлен сорашырга тотынды.

Рәхәт, күңеленә жиңел булып калды Уразмәтнең, әле генә камап алган күңелсез уйлары да таралды. Күңеленнән: «Әллә кемнәр килмәгәнгә борчылып, юк-бар уйлап ятам. Үземнекеләр барда кем кирәк миңа?» — дигән уй үтеп китте.

— Мин бөтенләй аруландым инде, кызым. Бүген бер жирем дә авыртмый, врачлар кушса, менә хәзер торып, йөгереп китә алырмын сымак,— диде ул, кызының аркасыннан яратып. Өйдә чакта яратыйм дисә, кызы: «Әй, куй әле»,— дип, читкә тайпыла, үзен бәләкәй бала итеп күрсәтәсе килми торган иде. Әле атасының хәленә кереп, аның күңелен кырмау өчендер инде, күндәм генә утыра.— Алай

еш килеп йөрмәсәгез дә ярар,— дип дәвам итте Уразмәт.— Әйт, әниеңә, әле син килгәч, бүгенгә өйдә генә торсын, юкка борчылмасын. Болай шәбәйгәч инде, кичкә табан торып, үзем телефоннан да сөйләшермен әле.

Әтисенең чырае ачылуын, сәламәт кешеләрчә шулай алчак сөйләшеп ятуын күргәч, кызының да күңеле күтәрелеп киткән иде. Әтисенең чал төшкән куе чәчләреннән сыйпап, битеннән үпте дә:

— Миңа икенче парга лекциягә барып өлгерергә кирәк,— дип, бөдрә чәчен җилфердәтеп чыгып китте.

«Әйе, бала өчен әти булу — иң зур дәрәҗә, синең кулыңда власть булу-булмавын алар гына исәпкә алып тормыйдыр»,— дигән уйлардан Уразмәтнең йөрәге тагы бер тапкыр авырттырып чәнечте. Бу уйларының янә катлауланып китүеннән котылыр өчендерме, әллә кызы килеп киткәнгә күңеле булып инде, ул күзләрен йомды.

* * *

Бүгенге көн Хәмит Әхмәтович Әхмәтовка, иртәнчәк бичәсе әйткән хәбәрдән соң күңеле боега биреп алса да, күтәренке кәеф алып килде. Квартал планы арттырып үтәлгән, димәк, елны уңышлы тәмамлауга да ышаныч бар. Былтыргы шикелле, план үтәлмәгән өчен партиянең шәһәр комитетында, Главбашстройда тикшереп, аның артабангы язмышына бәйле, уйланырга һәм җигелеп эшләргә мәҗбүр итүче кипаяле шелтә сүзләре дә әйтмәсләр.

Хәмит Әхмәтовичка болай да иркен кабинеты тагы да зураеп, яктырыбрак киткән төсле тоела бүген. Иртәнчәк эшкә килгәндәге күңелсез уйлар әллә кайда очып таралды. Һиндидер кинәнеч белән ул почмакка куелган пыяла чехол эчендәге бердәнбер байракка — моннан ун ел чамасы элек КПСС Өлкә Комитеты һәм Министрлар Советы эштәге уңышлар өчен мәңгелек саклауга биргән Кызыл Байракка карап ала, бу кварталның йомгаклары буенча, мөгаен, тагы берәр байрак эләгер әле, дигән өмет күңелен балкытып җибәрә. Менә Хәмит Әхмәтович стена як эргәгәрәк куелган зур гына өстәл янына килеп баса. Өстәлдә — бишьеллыкта төзеләчәк объектларның макетлары. Анда торак йортлар да, культура һәм көнкүреш биналары да, промышленность объектлары да бар. Төзелеп бетеп, эксплуатациягә тапшырылганнарына — яшел, төзелеп ятканнарына — кызыл, әле башланмаганнарына, бары проектта гына яшәгәннәренә сары тамга сугылган.

Управляющий, әнә шуларга карап, алга кәкшәйгән зур,

йомры ияген кысып тотып, авызын бөрештереп, дөньясын онытхан кыяфәттә фикер туплап торырга ярата. Ләкин бүген ул өстәл янында озак тормады. Нинди дә булса олы максатка ирешкәннән соң адәм баласының берникадәр вакытка йомшарып, ваемсызлыкка бирелеп алу холкы бар бит. Хәмит Әхмәтов та шушы җитешсезлектән азат түгел. Айлар буе үзен-үзе камчылап, менә шушы план үтәлсен дип, бишкә ярыла язып эшләгәннән соң, ичмасам, бер генә көнгә тезгенне бушатырга, җиңелчә генә кәефләнеп алырга хакы юкмыни аның? Үзен өзлексез эшләргә мәҗбүр иткән шушы кабинеттан, хәтта шәһәрдән берничә сәгатькә булса да чыгып китәргә, үзен иректә, бөтен эштән азат итеп тоярга теләде ул. Күп уйлап тормый, эш өстәле янына барып, кнопкага басты. Шунда ук ишектә секретарь күренде.

— Машенька, постройком председателен чакырыгыз әле.

— Анда утырыш бара шикелле.

— Азактан дәвам итәр. Чакырыгыз.

Постройком председателе кабаланып килеп керде дә ишек төбеннән үк хәбәрен сөйләргә тотынды.

— Идарәләр, бүлекләр арасындагы социалистик ярышка йомгак ясый идек, Хәмит Әхмәтович. Бу кварталда бөтенесе дә бик тырышып эшләде, хәтта...

Управляющий, канәгать көлемсерәп, аны бүлдерде:

— Хәтта беренче урынны кемгә бирергә дә белмисезме?

— Әйе, Хәмит Әхмәтович, чөнки...

— Ярый, гадел итеп йомгак ясарга кирәк.— Әхмәтов каршындагы урынга ымлады.— Аны бүген очлап куярсыз, иртәгә бергәләп карап чыгарбыз. Ә хәзер утыр әле, бер эш хакында сөйләшеп алыйк.

Постройком председателе узып утырды да, күзлеген ялт-йолт иттереп, түземсезләнеп, управляющийга карады.

— Йә, сөйләшик соң, Хәмит Әхмәтович.

— Эш дип... эш тә түгел инде ул. Безнең ял базасында сезон ябылды бит инде?

— Ябылды, Хәмит Әхмәтович. Хәзер андагы бөтен әйберләрне җыештырып, кышка әзерләнергә кушылган.

— Ашханәң дә бикләме?

— Бикле, Хәмит Әхмәтович...— Шушы урында постройком председателе управляющийның тел төбен кинәт сизеп алды һәм аңа берничә секунд сораулы карашын төбәп торды да:— Аны ни... теләсә кайсы вакытта ачтырып була. Савыт-саба шунда,— диде.

Әхмәтов аның зирәклегенә — үзенең тел төбен сизеп алуына канәгать елмаеп куйды.

— Алайса, кичке сәгать җиделәргә шунда берәр нәрсә оештыр әле. Кемнәрне алып бару турында үзең уйлап кара. Артык-портык кеше кирәкмәс. Гомумән, үзең чамала.

— Аңлашылды, Хәмит Әхмәтович. Ни... әлбәттә, кирәк. План үтәлде, күңелләр күр. Ни... теге... башка якларын үзем карармын.

Председатель җитез басып чыгып китте. Бүтән чакта Әхмәтов аны үтә өтәләү булганы өчен яратып җитми, дуамаллыгы өчен шелтәләп тә алгалый иде. Әле исә аның бу кыланышы ошап ук куйды.

Хәмит Әхмәтович сәгатенә күз салды — озакламый өч тула икән. Кичкә кадәр вакыт байтак әле, аны кабинетта утырып үткәрәсе килми иде. Өлкә комитетның төзелеш бүлегенә барып әйләнергәме әллә? Кайбер йомышлары да бар иде. Эшләр әйбәт барган чакта начальство белән очрашып сөйләшүе дә җиңел, сүзең дә үтемле була бит ул. Барырга кирәк әле. Юл уңае! Главбашстройга сугылып, башка трестларның өченче квартал планын ничек үтәүләрен белер!

Өлкә комитетның бүлек мөдире аны ихлас күңелдән елмаеп каршы алды.

— Сүзегездә тордыгыз, Хәмит Әхмәтович, молодец,— дип мактап та алды, аның йомышларын игътибар белән тыңлады, ике яңа күтәргеч кран алуда, объектларны төзелеш материаллары белән тәэмин итүдә ярдәмләшергә сүз бирде.

Сүзләре шулай бик тә берегеп киткәч, Хәмит Әхмәтович, бүген кичкә ял базасына барып әйләнәбезме әллә, дип, бүлек мөдиренең кылын тартып карамакчы булган иде, бу уеннан шунда ук кире кайтты. Вакытлы-вакытсыз нинди күңел ачу ул, дип салса, әйбәт уйланган эшнең чәлпәрәмә килүе бар. Йомышы беткәннән соң азрак җиңел-җилпе хәбәр сөйләшеп утырды да кабалан атлап тышка чыкты.

Октябрь башы булса да, көн чуак, кояш җәйге шикелле җылыта. «Хәзер көзге урман гаҗәп шәптер инде, барып, рәхәтләнеп йөреп кайтырга кирәк»,— дип, уйлый Әхмәтов. Әйтерсең, кичәге күңелсез хәлләр дә булмаган, иртәнчәк Рәхимәсе дә кылтымбый сөйләшеп озатмаган. План үтәлеше бөтенесен дә хәл итә шул: әйбәт үтәлдеме, дөньяның бөтен ваклыклары онытыла...

Машинасына утыргач, Әхмәтов, ни өчендер, мәгънәсез елмаеп:

— Башстройга, Никитич,— диде шоферына.

Шоферы хуҗаның күтәренке кәефтә булуын күрә иде, әлбәттә. Тик менә ул иртәнчәк алырга кушкан әйберләре турында нигә бер дә сорамый? Больницага барасын оныттымы икән әллә? Хәзер бит инде сәгать бишенче. Шушы хакта исенә төшерсә, хуҗаның әйбәт кәефен бозып куймасмы? Әйтмәсәң, нигә хәтергә төшермәдең, дию бар. Һай, кыен зур начальникның шоферы булып эшләүләре! Һәрчак чамалап, аның кәеф-сафасына туры китереп кеңәш сөйләшергә кирәк.

— Йә, кузгалдык, Никитич.— Әхмәтов икеләнгән сымаграк утырган шоферына карады.

— Сәгать бишкә больницага барырга дигән идегез. Мин сез әйткән әйберләрне алдым.— Ни булса да, әйтте Никитич хәбәрен, үзе хуҗага сынаучан караш ташлады.

Хәмит Әхмәтовичның яссы кара кашы кинәт җимерелде, карашы корыланды, чыраенда җитдилек чагылып калды.

— Һы... Дә-әәә... Шундый уй бар иде шул. Ярый, әйдә Башстройга кереп чыгыйм әле.

Шоферы, чынлап та оныткан булган бит, ярый әле әйткәнмен, дип, куангандай итсә дә, больницага бару мәсьәләсе Әхмәтовның күңелен кыра биреп куйган иде. Анда барып, чирле Баязитовны күреп сөйләшү әйбәт кәефен бозар кебек тоелды аңа. Әллә нидә бераз гына ял итәргә уйлаган иде... Больница хакында шоферына нигә алдан ук сөйләнде икән?..

Главбашстройда бу квартал йомгаклары буенча ул җитәкчелек иткән трестның беренче урынны алуын белгәч то, Әхмәтов бу көнен азагынача яхшы кәеф белән үткәрергә дигән фикер белән чыкты. Ярый, больницага эләккән һәр хезмәткәре артыннан йөри башласа...

— Больницага иртәгә барырбыз,— диде ул, машина ишеген шартлатып ябып.— Алган әйберләрең бозылмас бит?

— Бозылмас та...

— Әйдә, Никитич, трестка сугылабыз да, аннан — үзебезнең ял базасына.

Кабинетына кереп утырыр-утырмастан Әхмәтов телефонга тотынды. Соңлабрак кайтырын хатынына искәртеп кую кирәк иде.

— Рәхимә, кәеф-сафаларың арумы? Нинди эшләр бетерәсең?

Трубкада Рәхимәнең тыйнак тавышы ишетелде:

— Эшне син бетергәч, миңа нәрсә калсын.

Их, менә шулай йомшак кына сөйләп катыга утыртулары! Әхмәтов кинәт кенә ары таба ни әйтергә белми торды.

— Алай дип... ни бит әле, бүген тагы соңлабрак кайтырмын инде.

— Монысы минем өчен яңа хәбәр түгел, Хәмит. Бүген вакытында кайтып җитәм, бичәкәй, дисәң, әллә аптырап та калыр идем.

— Уйламаган эшләр килә дә чыга бит, Рәхимә.

— Кайчан кайтуыңда эшем юк. Әмма бүген Уразмәтнең хәлен барып белмичә, тупсадан атлап кермә. Аңладыңмы? Менә шул.

Рәхимә трубканы салып куйды. Хәмит исә аптырап калды, ык-мык итте дә лып итеп креслосына утырды. Менә әй, гомердә дә болай каты сөйләшкәне юк иде бичәсенең. Уразмәт янына керергә чыкмыйча булмас микәнни? Кайткач, янә, бардыңмы, дип сорар, нигә бармадың, нигә иң якын дустым дисең аны алайса, дип тецкәгә тияр. Хәер, ни дип шушы хакта күп баш ватты әле? Аңа кереп чыгарга күп вакыт кирәкмени?

Менә ул больницаның фойесындагы исемлектән Уразмәтнең фамилиясен эзли. Әһә, унҗиденче палатада икән, хәле авыр дип язылган. Менә әй, шулай ук нык чирләп китте микәнни? Ярый килгән әле, дөнья хәлен белеп булмый. Менә хәзер, ичмасам, ул дусты алдында бурычлы булып калмас. Бу уйдан күңеленә рәхәтлек йөгерде Хәмитнең. Ул, иңбашына ак халат эләктерде дә, кулына төенчеген тотып, икенче катка күтәрелде.

Уразмәт аның, палатага кереп:

— Саумысез. Баязитов шунда ятамы? — дигән тавышына кинәт башын калкытты. Хәмитнең шушы аеруча гадәти генә сүзләре дә аның күңеленә ниндидер җылылык өргән иде.

— Һай, Хәмит дус, килдеңме? Әйдә үт,— дип тавыш бирде ул.

Әхмәтов аның җылы, хәлсез кулын йомшак кына кысты, чыраена карап ташлады. «Хәле авыр дип язганнар, ап-ару күренә ләбаса»,— дип уйлады да, күңелендәге Уразмәт сизүдән курыккандай:

— Нигә алай кинәт кенә бирешеп киттең, дус? — диде, көчәнеп елмаерга тырышты.— Безнең самай теттереп яшәр генә чак бит әле.

— Кинәт дип, җайлап-җайлап китереп бәрде инде ул...

Ярый, ул хакта сөйләшмик, хәзер арулана башладым шикелле инде. Үзеңнең хәлләр ничек?

— Хәлләр болай начар түгел. Квартал планын арттырып үтәдек, трест беренче урынны алыр төсле. Син эшләгән участок та...

Уразмәт койка янындагы утыргычта утырган Хәмитнең тубыгына коргаксыган җылы учын салды.

— Эш барадыр инде ул. Үзеңнең хәлең ничек, дим?

— Минем хәлем ничек булсын? Менә бит — йөреп ятам. Чирләргә дә вакыт юк,— Әхмәтов янә көчәнеп елмайды.

— Чир вакыт белән бик исәпләшеп тормый икән ул, Хәмит. Хәер... Син авырсаң да, ялгызың каңгырап ятмассың, дус-ишләрең яныңа ябырылып килер.— Уразмәт нигә кинәт кенә бу сүзләрен әйтеп салды — үзе дә аңламый калды. Көн буе шушы хакта уйланып ятуның нәтиҗәсе булды, ахрысы.

Әхмәтов исә аның бу сүзләренә аптырабрак калган иде, башын читкә борып, җилкәсен кашыды.

— Нигә алай дисең әле, Уразмәт? Әллә минем шулкадәр ча килә алмаганга үпкәләдеңме?

— Үпкәләдең дип...— Уразмәтнең нурсыз йөзендә елмаю галәмәте күренде.— Исеңдәме, баш инженер булып эшләгән чакта ике-өч көн авырып яткан идем.

— Әллә тагын... булгандыр инде.

— Син бит ул чакта минем янга иртәле-кичле килә идең, онытмагансыңдыр, мөгаен.

— Ул чакта бит мин үземә-үзем хуҗа идем. Иртәнчәк эшкә вакытында барып җиттеңме — ярады, сәгате җиттеме — кайттың киттең. Ә хәзер...

— Хәзер син үзеңә генә түгел, бүтәннәргә дә хуҗа. Вакыт та үз кулыңда.

Уразмәт, учын йөрәк тәңгәленә куеп, азрак эндәшми ятты. Үз уен Хәмиткә азагынача әйтеп бетерәсе килә иде аның. Әйе, хәзер әйтмәсә, бүтән чакта теле дә әйләнмәс.

— Хәмит, дусларча киңәш сүзем бар сиңа.

— Әйт соң.— Әхмәтов сагайды. Уразмәтнең кинаяләп, читтән-читтән төрттереп сөйләшүе аның ачуын китерә башлаган иде.

— Беләсеңме, нинди җирдә, кем булып эшләсәң дә...— Уразмәтнең тыны кысылды, сүзе өзелде; ул, тирән итеп берничә тапкыр тын алгач, дәвам итте — ...кешене дәрәҗәсенә, кайда эшләвенә карап бәяләмә, кешегә булган ихтирамыңны дәрәҗәгә карап бүлмә...

Бу сүзләрнең мәгънәсе Әхмәтовка шунда гына барып

житмәде, күрәсең, ул Уразмәткә, бу хәбәреңне нигә сөйлисең әле, дигән сымак, аптырап карап утырды. Шуннан кинәт бөтенесен дә аңлады, чырае караңгыланды, утырган урындыгы ыңгырашып куйды.

— Менә... күчтәнәч китергән идем сиңа,— диде ахырда, челтәрле сумкасын аның янына салып.

Уразмәт исә үзенең күңелендә ниндидер сафлык тойды. Көн буе йөрәген өйкәп торган яман төер ычкынып киткән сыман иде.

— Рәхмәт, Хәмит дус, килүеңә,— диде ул хәлсез тавыш белән, күз алдында кызгылт түгәрәкләр уйный башлагач, ирексездән күзләрен йомды.

Яшәү өчен тартышып яткан Уразмәтнең сүзләре Әхмәтовны хафалы уйларга салган иде, аңа хәтта бүлмәдә һаваз тынчуланып киткән сыман тоелды. Шуңа күрә җәһәтрәк чыгу ягын карады.

— Ярый, борчылма, Уразмәт, мин тагы килермен әле...— дип, ишеккә табан атлады.

Уразмәт эндәшми ятып калды. Гомер буе дуска исәпләп йөргән кешесенә ул күңелендәгесен әйткән иде инде.

Әхмәтов капка төбендә калган машинасы янында азрак таптанып торды да ишекне авыр ачып кереп утырды. Шоферына баш калкытып та карамый коры гына итеп әйтте:

— Өйгә, беркая да бармыйбыз.

Аның әйбәт кәефе кул белән сыпырып алгандай булган иде. Күңелен каплый башлаган кара болытларны Рәхимәсе генә тарата алыр сыман тоелды аңа.

РӘСИХ ХАННАНОВ

Рәсих Нургали улы Ханнанов 1931 елда Башкортстанның Кырмыскалы районы Кырмыскалы авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, биш ел Хәрби-Диңгез флотында хезмәт итә.

Кайтып, Стәрлетамак культура-агарту училищесын һәм КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбенең журналистика бүлеген тәмамлагач, башта үз район газетасының редактор урынбасары булып эшли, аннан Уфага республика газетасына күчерелә. Хәзерге көндә ул — «Кызыл таң» газетасының редактор урынбасары.

Р. Ханнанов башлыча яшьләр һәм үсмерләр өчен яза. Әдипнең «Яшьлек канатлары», «Кыр казлары киткәндә», «Әйтем юкка әйтелми», «Күңел нуры», «Күтәгез мине, тирәкләрем!» дигән хикәя җыентыклары, пьесалары укучылар тарафыннан җылы каршыланды. Аңа БАССРның атказанган культура работнигы дигән исем бирелде.

Р. Ханнанов — 1979 елдан СССР Язучылар союзы члены.

СӨЮ ГӨЛЛӘРЕ

Театр бакчасы янындагы тыкрыкта олы гына яшьтәге бер апа чәчәк сатып утыра. Күз камаштыргыч ак, ал розаларны бергә кушып, матур букетлар ясап бирә. Хакын да күп сорамый.

— Теләгәнегезне сайлагыз, оланнар,— ди ул ихлас күңелдән, ниндидер безгә ят акцент белән.

Ләкин миңа теләгәнемне сайларга туры килмәде. Чиратым җитүгә, кәрзин төбендә зәгыйфь кенә берничә чәчкә калды. Аларын да чәчкә сатучы апа чиратта миннән алдарак торган кызның кулына көчләп диярлек бушлай тоттырып җибәрде.

— Башка чәчәкләрегез юкмыни? — дидем мин, аптырап.

— Бетте шул. Элегрәк киләләр аны. Әнә, кибеттән генә ал инде.

— Миңа сезнекеләр ошаган иде шул.

Апаның таушалырга өлгермәгән, сылу, тулы битләре яктырып китте. Ул җылылык бөркелеп торган чем-кара күзләре белән мине баштанаяк карап чыкты да, яшерен бер сер белергә теләгәндәй:

— Бик кирәк идемени? — диде.

— Сеңелемнең туган көненә алып барырга иде.

— Ә сеңелеңә ничә яшь соң?

— Унсигезе тулды.

— Истәлекле бәйрәм икән. Унсигез яшь бит ул кызларның иң саф, иң күркәм чагы. Аларда унсигез язның гүзәллеге тупланган була.— Ул бераз уйланып торды.— Менә нәрсә, улым, бәйрәм чәчәксез булмый, киттек безгә, бакчадан иң матурларын өзеп алырбыз.

Наталья апа (аның исеме шулай икән) кәрзинен беләгенә элде дә Матросов бакчасы аша мине өйләренә алып китте. Үзе бертуктаусыз сораштыра.

— Үзеңне әйтәм, эшлисеңме, укыйсыңмы?

— Университетта укыйм. Башкорт теле һәм әдәбиятын өйрәнәм.

— Син башкортмыни? Алай икән! Маринамның атасы да башкорт иде. Өченче ел, көтмәгәндә авырып, дөнья куйды. Әлеге сугыш җәрәхәтләре инде, каһәр суккыры. Мин үзем Карпаттан, сугыш вакытында күчеп килгән идек, шушында оя корырга туры килде. Җирен дә үз иттем, кешеләрен дә яраттым. Гомерлеккәдер инде, кунакка барганда да сагынып йөдим.

Наталья апалар Агыйделгә каршы тау итәгенәрәк төшеп торган бик ямьле урында яшиләр. Зур гына йорт. Тәрәзә капкачлары ачык зәңгәргә буялган. Такта белән коймалап алынган ихата эчендә алмагачлар күренә. Без, җилкапканы ачып, эчкә үттек. Наталья апа, өй күтәрмәсенә якынлашкач та, боерулы тавыш белән:

— Маринка, монда чык әле! — дип кычкырды. Һәм шунда ук безнең каршыга кайдандыр бер кыз ялт итеп килеп тә чыкты. Ул урта буйлы, озынча аксыл йөзле. Сөйләшкәндә озын керфекләре, күбәләк канатлары кебек, җилпенеп-җилпенеп куя.

— Кунак алып килдем әнә, бакчага керегез дә икәүләп бер букетлык чәчкә өзегез,— диде Наталья апа.

— Тагы чәчкә сатарга бардыңмы? — дип сорады кыз

үпкәле тавыш белән һәм тиз генә мине баштанаяк кызыксынып карап чыкты. Мин, һәр студент кебек, ачык изүле ак күлмәктән, шактый таушалган чалбардан идем. Кызның үткер карашыннан колак очларына кадәр кызардым. Наталья апа уңайсызланып калуымны әллә сизмәде, әллә сизеп тә белдермәде. Маринага ашыкмый гына җавап кайтарды:

— Әйе, кызым, монавы бакча янына гына чыктым шул,— диде.— Озакламый кырау да төшәр, әрәм булганчы, кешеләргә куаныч китерсеннәр.

Мин дә, уңайсызлануымны җиңәргә тырышып:

— Чәчәк сату гаеп эш түгел,— дидем.

Кыз мине чем-кара күзләренең ялкыны белән бер көйдереп алды да коры гына:

— Әйдәгез,— диде һәм бәләкәй капка аша бакча эченә кереп китте. Мин аңа иярдем. Һәм үз күзләремә үзем ышанмый тордым: түтәл-түтәл чәчкә, әкияттәге сихри утраучыклар диярсең. Нинди җаның тели! Мин түзмәдем:

— Боларны кем үстерде? — дип сорадым. Марина бер дә уйлап тормыйча гына:

— Мин,— диде дә кинәт кенә уңайсызланып китте.— Ә нигә?..

— Мондый чәчкәләрне үстерү өчен саф һәм шигъри күңелле булырга кирәк.

Марина, таптың сөйләргә сүз дигәндәй, юка, ләкин үзенә бик килешеп торган иреннәрен бүлтәйтеп куйды, аннан күкрәге аша биленә үк төшеп торган калын толымнарын аркасына ташлап, чәчкә өзәргә тотынды. Бу кыз миңа күптәнге танышым кебек бик якын тоелды. Кайда күрдем икән мин аны? Ни өчен моңарчы очрашканыбыз да, сөйләшкәнебез дә юк? Әллә, хыялым белән тудырып, инде күпме еллар буена күңелемдә йөргән сөекле образ шулай чынбарлык булып күз алдына килеп бастымы?

— Сез студент бит, әйеме? — диде шулчак Марина, уйларымны бүлдереп.

— Кайдан беләсез?

— Күргәнем бар.

— Кайда?

— Университетта. Бер кичәдә шигырь укыганыгызны күргән идем.

— Сез дә шунда укыйсызмыни?

— Быел керергә йөргән идем дә, конкурстан үтеп булмады.

— Нинди факультетка?

— Тарих факультетына иде.

— Нигә, киләсе елга керерсең...

— Ю-ук,— Марина, чәчкә өзүдән туктап, миңа карады,— читтән торып кына укырга булдым инде. Эшкә дә кереп алсам, әнкәйгә ярдәм булыр.

Мин нәрсә әйтергә белмичә:

— Әйе шул,— дидем дә кыяр-кыймас кына аның саф нурлар белән балкыган күзләренә карадым. Аның күбәләк канатыдай озын кара керфекләре оялчан гына талпынып куйдылар, һәм ул тиз генә чәчкәләр өстенә иелде.

Аның:

— Менә, чәчкәләрегезне алыгыз,— дигән тавышы да шулкадәр ләззәтле булып, әллә кайдан ерактан ишетелә сымак иде. Ул биргән букетны кулыма алгач, күзләрем камашты. Шундый букет иде ул, моңарчы дөньяда андый булмагандыр да, һәм булмас та. Мин, чәчәкләр исенә исереп, бакчадан ничек чыгып киткәнемне дә хәтерләмим.

Бераз вакыт үткәч, Наталья апа янына мин тагын килдем. Ул мине шунда ук танып алды.

— Ә-ә, студент килгән икән! Чәчкә кирәкме? Бүген кемнең туган көне соң, тагы сеңлеңнекеме? — Үзе матур, нәкъ Мариныныкы кебек ягымлы карашларын сирпелдереп, рәхәтләнеп көлә.

— Минем башка сеңлем юк,— дидем мин, оялып.

— Димәк, яраткан кызыңа инде. Алайса, менә бу матурларын ал. Марина өзгән иде. Менә бит ул яшь чак нинди! Уйларда чәчкә дә гөл генә...

Наталья апа янына икенче көнне дә, өченче көнне дә килдем. Гадәтемә үк әйләнеп китте. Кич булдымы, шул тыкрыкка йөгерәм. Хәзер инде без аның белән танышлар гына түгел, ә якын дуслар булып киттек.

Ул мине күрүгә, бөтен ягымлылыгы белән ихлас күңелдән елмаеп, шаяртырга тотына.

— Бүген чәчкә бирмәскәме икән әллә үзеңә? Кызың янына чәчкәсез барырга куркмыйсыңмы? Әллә чәчкәле мәхәббәт көчлерәк буламы икән!..

Чәчкә алучылар көлемсерәп миңа карыйлар. Колак очларым ут кебек яна, нидер әйтергә телим, телем әйләнми. Ә Наталья апа, чәчкәләр сайлый-сайлый, сөйләнә бирә:

— Бәхетле хәзерге кызлар, без үскәндә чәчкә бүләк итүнең нәрсә икәнен дә белми идек.

Мин ал, зәңгәр, сары, ак төсләр белән нурланып, тәмле исләр бөркеп торган чәчкәләрне алам да, гадәтемчә,

акча сузам. Бу юлы Наталья апа җитдиләнә һәм акчаны кире кайтарып бирә.

— Ярар инде, студент кешегә болай гына булсын. Кызларга чәчәк бүләк итәм, дип стипендияңнән тәмәкелек тә калмас болай,— ди.

— Тәмәке тартмыйм бит мин.

— Эчмисең дәме?

— Эчмим дә.

— Алайса, чәчкә исен генә иснәргә кала шул. Мондый егеткә тап булган кыз бәхетле.

— Наталья апа, мин киттем,— дидем, уңайсызланып.

— Бар, йөгер, кызлар көттергәнне яратмый ул...

Чәчкәләремне имгәтмәс өчен сак кына тотып, мин шунда ук тротуар буйлап бертуктаусыз агылган кешеләр диңгезенә кереп чумам. Артыма әйләнеп карамасам да, сизеп, тоеп торам: бернидән шикләнмәгән Наталья апа: «Менә бит яшьләр, менә бит ул яшь чак нинди»,— дип күздән югалганчы мине җылы карашы белән озатып кала. Ә мин сөйгәнем янына ашкынам, канатланып очам. Агыйдел ярының иң биек, иң ямьле җирендә, Салават батыр һәйкәле янында, мине бәхет кояшым — Маринам көтә.

ЗИҺАТ СОЛТАНОВ

Зиһат Әдһәм улы Солтанов 1932 елда Оренбург өлкәсенең Саракташ районы Сәнкем авылында туа.

Армия сафына чакырылганга кадәр үз колхозында эшли. Хәрби хезмәтен 1951—1956 елларда Балтика флотында үтә. Читтән торып укып, урта мәктәпне һәм 1969 елда Башкорт дәүләт университетын тәмамлый.

З. Солтановның тәүге шигырьләре һәм хикәяләре республиканың әдәби журналларында илленче елларның азагында басыла башлый, ә «Урман бабай» дигән беренче җыентыгы 1967 елда дөнья күрә. Хәзерге көндә ул «Йолдыз яңгыры», «Таң нурлары», «Кояшлы кыя», «Кырыкбуын» һәм башка китаплар авторы.

З. Солтанов 1959 елда Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә, 1971 елдан — СССР Язучылар союзы члены.

СЫЕР ТУРЫНДА ҖЫР

Кордашларыма багышлыйм.

Табыннарда утырганда, кордашларым миңа тынгы бирмиләр: «Арабыздан бер син генә шагыйрь булдың, шуның белән үз өстеңә олы бурыч — йөк алдың; бөтенебезне, бер буынны, кеше иткән сыер турында җыр яз әле!» — диләр. Көтеп-көтеп тә, ул җыр һаман дөньяга күренмәгәч: «Кордаш, кордаш, оныттыңмыни үткәннәрне? Әгәр ул чакларда сыер булмаса, бүген син булыр идеңме дә без булыр идекме?!» — дип битәрлиләр. Мин эндәшми генә башымны иям. Их, белсә иде алар эчтә ни кайнаганын!..

Менә ничә ел инде шул җырны иҗат итә алмый интегәм. Өстәл тартмамда саргаеп беткән кәгазь ята, тынгы бирмичә мине үзенә тарта. Мин көн дә, кырык эшемне куеп торып, шул тартмага сузылам, анда уңып беткән зәңгәр каралы язу күрәм: «Сыер турында җыр». Шул язуга күз салам да, башым түбән иелә, кулымнан каләмем төшеп китә: мин тавышсыз сулкылдап бөгеләм, бөгеләм...

1943 елның әче язы иде. Бөек Ватан сугышының тарасаты өйдән-өйгә ишек шакып йөргән чак. Миңа унбер яшь, апаема унөч яшь. Сугышның башыннан алып Башкорт атлы дивизиясендә йөргән әтием, Донбасс җирен фашистлардан азат итү өчен дошман тылына тирән рейдка кергән чакта, дивизиянең бик күп кешеләре белән бергә камауда калып, хәбәрсез югалган. Әнием, шул кайгысыннан һәм ачлыктан интегеп, түшәккә егылган. Шулай итеп, дөнья йөге апаем белән минем җилкәгә төшкән.

Кичтән буран котырды, йөрәкне өзеп, әче җил сызгырды. Бер катлы гына тәрәзәбезгә шак та шок бозлы кар бәрде. Күз төбәп көткән бердәнбер малыбыз — йолдыз кашка сыерыбызның төнгелеккә тамагын тәрбияләп, торыр урынын томалап, абзарга җил сукмастай итеп капкасын ныгытып кергәнбез. Ләкин үзебезгә тәрәзә төпләреннән, сылаганы купкан бүрәнә ярыкларыннан җил бәрә. Сукыр шәм яктысында өй эчендә көмеш тузандай вак-вак кына кар бөртекләре бөтерелә. Сәке башында, почмакта, әтиемнең кара кайгылы хәбәр кәгазен учында йомарлап ятып, әнием ыңгыраша. Мич арасында ачлыктан песи балалары чиный. «Бу гына сезгә аз әле!» дигәндәй, өйнең соңгы җылыларын суырып алып, мич калагын тыкырдатып, морҗа елый...

Апаем да, мин дә, авыру әнием дә йокламый, һәркем үз уен уйлый. Бер өй эчендә ятсак та, һәрберебез аерым-аерым кар бураны ерып бара, буран кочагында интегә кебек.

Апрель житсә дә, һаман яз булмый, һаман көннәр суына; лапас башында — печән, утынлыкта — утын бетә дип пошынам. Иртәгә бер умачлык та он юклыгын, иртүк торып, билбау асты буш килеш, тагы да колхоз идарәсенә ашарга сорап барырга туры киләчәген күрсенеп күз алдыма бастырам. Юк, быелга мәктәпне калдырып торырга, кара яз башыннан ук, билне кысып буып, сабанга чыгарга кирәк дигән ныклы карарга киләм.

Ә тәрәзәгә шак-шок бәреп буран улый да улый, морҗа елый да елый. Нигә һаман яз килми, нигә болай озын-озак булды соң әле бу кыш?! Тукта, тукта, бу нинди моң,

бу нинди жыр?! Тәрәзәләрнең чыңлавын, моржаларның елавын, йөрәкләрнең сызлавын басып, кайдан килеп керде әле бу жыр? Нинди назлы жыр, нинди сазлы жыр!

Күзләремне ача алмый, хисләремне баса алмый, өй эченә тулган моңны тыңлап ятам, жырны тыңлап ятам.

Күңелем белән мин ташкын Сакмарымның ап-ак яллы дулкыннарын, колач ташлап, күкрәгемә кыса-кыса ярып барам, ак балыктай уйнап, карпып барам — ата-бабам, үзем эчкән жанчишмәнең, Сакмарымның тирән күкрәк моңы булып сызылып чыга бу жыр.

Күңелем белән мин, тилереп, май аеның аллы-гөлле чәчкәләре аткан яшел болынлыкта тәкмәч атып уйнап барам, ата-бабам печән чапкан, чәй пешереп, учак яккан, нигез төбе — казык каккан туган якның әрем исен сулый-сулый буйлап барам — газиз жирнең моңы булып сызылып чыга бу жыр.

Күңелем белән мин, жилкенеп, бөркет булып күккә ашам, ал кояшны карпып алып, Уралыма ак нур чәчәм, көнгә шыткан бөреләрнең чыклы күзен сыпырып ачам — яшел яшьлек гимны булып сызылып чыга бу жыр. Тәбәнәк кенә өебезне тормыш дәрте белән көйләп, гадиләрдән гади аваз булып сузыла бу жыр. Без белгән жыр, безнең балалык белгән жыр.

Мин, йөрәгем чыгып китәр сыман ашкынган хәлдә, жырның төштә түгел, өндә икәнлегенә ышанып житмәгән хәлдә, акрын гына сулыш алып, күзләремне ачам. Әйе, әйе, безнең өйдә бу минутта чынлап та жыр: миңа карап, моңлы итеп, бәгырь төбеннән мөңрәп тора сыер. Үзебезнең сынык мөгезле, ак билле, йолдыз маңгайлы Кашкасыер. Алдында, бер уч печән өстендә, тояклары балавыз сымак сап-сары, сырт-аркасыннан катык аккандай, ап-ак билле, әрчеп салынган шалкан кебек юп-юеш бозау ята. Кашкасыер, мөңри-мөңри, аның кызыл йоннарын ялап корыта, үзе мич арасыннан төшеп килгән арык песигә ачулы күз ата. Песи, әдәп саклаган сымак, ашыгып урындык астына кереп китте, сыерның да ачуы бетте. Мияубикә, качкан жиреннән чыгып, түргә сикереп менде, әсәрләнеп торып утырган әнием янына килеп, битен юа башлады: мондый изге минутларда кем генә кусын инде.

— Нигә бозау алып керешергә әйтмәдең? — дип шелтәләдем апаемны.

— Бик тәмле итеп йоклап ята идең шул, уятырга кызгандым.

Их, бу кызларны!..

Яланаяк кына пима эләктереп, тышка атылып чык-

тым, лапас башына очып мендем. Җил-тавыш дигәннең әсәре дә юк, күк йөзе, әнием юган тәрәзә өлгеседәй, чалт аяз. Баш өстендә, кул сузым гына җирдә, йодрыктай эре йолдызлар, чекерәешеп, уч төбенә үрелә.

Күздән үк аерым өеп, иске чана табаны белән бастырып куйган печәннең бер күтәрәмен җилдереп алып кердем. Әнием җиң сызганган, сөт бидрәсен ялтлатып юып куйган, инде хәзер әрсез бидрәгә казаннан су соса иде. Ул тәпәндәге барлы-юклы тозны ачып карады, анда безнең иң соңгы чеметем тоз иде. Бераз уйланып торгач, тәпәнне бидрәгә какты. Кулы белән болгатып, бидрәне апаема бирде. Күзләре төпкә батып, йончып торган Кашкасыер апаем кулыннан тозлы суны бетергәнче чөмереп, тыкырдатып бидрә төбен ялады. Тоякланып имәргә ябышкан ала бозавын, аледән-але мөңри-мөңри, беләк буе ягымлы-ялмавыр теле белән ялап, мин китергән яшел печәнне төреп тыга башлады. Өйгә бөркү чәчкәле җәй айларының хуш исләре таралды. Башын ак яулык белән коршаган әнием, әйтерсең, тәмам савыгып, сыерның икенче ягыннан ниндидер мәрхәмәтле, изге, нурлы йөз белән саварга утырды.

— Биргәнеңә шөкер, инде ачка үлмәбез. Балакайларым-колынчыккайларым бәхетенә берүк исән-сау була күр инде, йолдызым, әтиебез урынына калган сыерым! — дия сөйләнде ул.

Инәсенең угызын имеп арыган бозау, эскәмиядәй дүрт тоягын дүрт якка тарбайтып, как идәндә тая-тая, печән янына килде, борынына чыбык төртелеп бугай, төчкереп куйды. Аның зур булып куркып ачылган күзләрен, бөрчек-бөрчек тир каплаган тәңкә танавын, бәләкәй генә дагадай йолдыз кашка маңгаен әллә кайдан үрдән кинәт сәленеп төшкән бик зур, ягымлы нәрсә авырттырып иркәләде. Бозау бу нәрсәнең үзен хәстәрләүче әнисенең теле икәнлеген, аннан куркырга кирәкмәгәнлеген аңлады, иркәләнеп, сабый муенын сузды. Бу минутта сыерның да, бозауның да ачык зәңгәр күзләре саф аяз, җирне котлап тәрәзәгә нур койган таңдагы болытсыз күк төсле керсез аяз иде.

Әнием безгә карап елмаеп куйды:

— Инде без дә кара җиргә исән-сау аяк басарбыз, балакайларым.

Бидрә төбенә гөбер-гөбер агылган сөт җыры өйгә яңа тормыш килүе, язның ыжгыр кышны җиңү музыкасы булып яңгырады.

Чынлап та, ул елда безгә укуны калдырып торырга туры килде. Кара яздан ук апаем — җир тырматырга, мин сабанда үгез башы тотарга эшкә чыктык. Сугыш гараса-

ты озакка сузылу аркасында, колхозда мал бетеп, үгез дә, ат та җитмәгәнлектән, сабанга сыер җигәргә туры килде. Саулыкка туена алмаган әнием быел җиңелрәк эшкә — хат таратучы итеп тәгаенләнгән иде. Ул, иртүк почтага барырга җыенган җиреннән тукталып, ай да тулмаган ала бозауны кочаклап, мине, Кашкасыерыбызны җитәкләтеп, тәүге язгы сабаныма җибәрде, сабан артыннан кашка ала бозау — бакырып, әнием күз яшен сөртеп озатып калды.

Һәй, кыен булды ул елның сабаннары!.. Ашарга юк, өскә юк, аякта тишек чабата. Бер караңгыдан икенче караңгыгача бил язмыйча эшлисең. Маллар арый, йөрми, кычкыра-кычкыра тамак бетә. Ләкин ничек тә сөрергә, күбрәк сөрергә кирәк, фронтка икмәк үстереп бирергә кирәк. Сабан тотучым — солдат хатыны Мөнирә җиңги, мин малкайларны куам. Үгез рәтеннән сабан тарткан Кашкасыер чыбыркы шартлаган саен калтырап куя, ташу җилен-имчәкләре, атлаганда, тәртәгә бәрелеп канап бара. Туктаган кыска араларда ул, авыл ягына борылып карап, йөрәк өзгеч итеп бакыра, миңа ала бозауның да елау тавышы ишетелгәндәй була. Мин сыерның моңлы зәңгәр күзләреннән качып читкә борылам.

— Әй җаным, нинди гөнаһ шомлыклары икән бу? Гөбердәтеп сава торган бозаулы сыерны сабанга җигеп йөрибез... Гитлерның башына төшсен моның каһәре!..— дип ачынып сөйләнә җиңгәм. Бер ызанны тәмамлап икенчесенә төшкән арада ул, сабанны туктатып, сыерны тугара.

— Әй малкаем, нинди бәхетсез син! — ди ул, Кашканың канап торган камыш имчәкләрен сыпырып. Ләкин сыер аны якын җибәрми, мөгезе белән селти.

— Саварга иде. Җилене сызлый бит,— ди җиңгәм, миңа төбәлеп.— Кил, кайнеш, үзең тотынып кара, булмаса.

Малай башыма бу әллә ничек күренә.

— Нигә тугардың,— дим, үпкәләбрәк аңа,— җигүле килеш савасы иде.

Җиңгәм, чирканып, бөтен тәне белән калтырап, миңа кинаяле күз ата.

— Тәүбә, диген. Җигүле сыерны саварга, вөҗданымнан язмаган әле мин.

Мин, эндәшмичә генә, сыер янына чүгәләп утырам, тарткан саен имчәкләрдән безелдәп чыккан ап-ак сөтне буразна төбенә агызам...

Кичен әнием, эче эчкә кергән кашка ала бозауны җитәкләп, арманмыз булып кайткан Кашкасыер белән мине каршы ала. Әнием дә, мин дә, Кашкасыер да эндәшми-

без, фәкать бозау гына, сабыйдай үксеп, имчәкне тарта, аларның буш икәнлеген тоеп, зарлана. Тиздән ул да тына. Кашкасыерга колхоздан тигән бутауны салып, бозавы белән калдырабыз, үзебез, өйгә кереп, кара суга болгаткан умач эчәргә утырабыз. Апаемның да, минем дә күзләрне йокы баса, көне буе йөреп талган табаннар ачытып сызлый. Әнием, безгә карап, әкрен генә көрсенә. Бу минутта өчебез дә, мөгаен, моннан бер ай гына элек, кышны куып, кашка ала бозау булып өйгә кергән яз җырын, тәпән төбе такыраеп, өмет сүнеп, соңгыбызга таянганда, көтмәгәндә, экияттәгедәй кабарып пешкән угыз коймагын, иртән чүмереп эчкән тәмле куе сөтләрне, туглап каплкан бавырдай каты катыкларны, ак һәм кызыл эремчекләрне искә төшереп шым калгандыр.

— Бидрә биреп җибәрмәгәнсең,— дим мин, бераз өнсез утыргач, әниемә калкынып. Ул дертләп куя.

— Ә, нәрсә дисең?

— Сыерны саварга, димен.

Әнием, кырдагы Мөнирә җиңги кебек үк куркынып, күзләремә карап сөйләнә:

— Тәүбә-тәүбә... Әл дә савып эчмәгәнсең әле, балам. Гөнаһ ул. Әниеңне тышаулап куеп имү белән бер...

— Әрәм бит.

— Әй балам, әрәм иттек инде ул. Җиккән сәгатьтә үк...

Әнием сүзенең хаклыгына озак та үтми төшендем. Кашкасыерның агы безгә генә түгел, ялгыз бозавына да тими башлады. Ызан буеннан ул көн саен буш җилен белән кайтты. Беркөн килеп сутлы камыш имчәкләре корыды — мал гынабызның сөте бетте. Ала кашка бозау күпме ярсып-ярсып имсә, борыны белән төрткәләсә дә, авызы коры калды. Шуннан соң ул инәсеннән читләшеп, дүрт тоягын куша басып, башын түбән иде.

Беркөн, ызан буена килеп тәүге буразна яру белән үк, сыер җанга тия башлады. Ул, әледән-әле туктап, авызын үргә күтәреп, бәгырь өзгеч өн белән күкне ертып бакырды, күзгә карап, әйтерсең лә, сулыгып-сулыгып елады. Шул сәбәпле, бердән, юньләп эш бармый, икенчедән, йөрәк шомланып сызлый иде. Күпме куып карасак та, сыерны тыеп булмады.

— Әй җаным, тикмәгә генә болай өзелеп акырмыйсыңдыр инде син, берәр бәла-каза гына булмаса ярар иде...— дип сөйләнде җиңги. Моны ишеткәч, миңа тагы да кыенрак булып китте.

Төш авышкач, Кашкасыер бакырып барды-барды да ларс итеп җиргә ауды, күпме куаласак та, ул тормады.

Безнең озак тукталганны күтәрә алмый, бригадир килеп җитте, икебезне дә кыздырып тирги башлады: көндәлек эш нормасы әле тулмаган, тагы аны арттырасы,— безгә сөрәсе дә сөрәсе иде. Сыер белән ныклы алышканны күреп, ул үзенең дүрт буынлы чыбыркысын эшкә җикте. Суккан саен, малкай калтырап ята, күзләреннән җиргә тамчылар тама, үзе, миңа башын борып, елаган сымак сузып мөңри иде. Мин тыела алмадым, йөрәксеп, бригадирның чыбыркы сабына асылындым. Агай, аптырап, күтәргән кулын төшерде, күзләрен кысып, куе кашлары астыннан миңа төбәлде. «Их син, җебек, маңка малай!» — дип әйтә кебек иде ул миңа. Ләкин аның тел очыннан чыбыркы яруыннан ла ачырак сүзләр ычкынды:

— Үз малым, дип яклыйсыңмы? Анда, фронтта, кан түгәләр, ә син... дезорганизатор!..

Кырт борылып китеп барды, «дезертир» белән бәрабәр авыр сүз, «дезорганизатор», әйтерсең, миңа дегеттәй ягылып калды. Тешне кысып елый-елый, кулыма таяк алдым, сыерымның аркасына суктым. Бу юлы сыер торды, озын телен сузып, күземә борылып карады. Кулымдагы таяк җиргә бөгелде дә төшеп китте, йөрәк-бәгыремне шомлы ут кисте: сыеркаемның сәлберәгән дүрт имчәгеннән, энә нәзеклек кенә булып, кан катыш сөт чаптыра иде...

...Авыл сыртындагы әремле тугайлыкны кеше гомере кебек моңсу ай нуры коендыра, әйтерсең, минем кулбашларымнан шабырдап агып тора. Мин, тимер көрәгемне, җиргә кадап куеп, алдымдагы караеп яткан бозау зурлык түмгәккә — яңа туфрак өеменә текәлеп утырам. Анда кашка бозавыбызның өе, соңгы өе. Йокыга чумган авыл эченнән ялгыз сыер бакыруы — Кашкасыер тавышы ишетелә. Минем дә шул сыер кебек үк үзәк өзеп акыра-кычкырасым, мәңгелеккә этием киткән якка — Көнбатышка җир ярсытып ишетелерлек итеп елыйсым килә. Көрәкне кулбашка салып, кул арбасын сөйрәп, кайтырга чыгам. Артыма әйләнеп карыйм да өнсез генә елыйм. Төнге дала, ачы әрем исен сыгып, миңа кушылып сулыгып елый. Бара-бара тынычлангандай булам. Авылдагы ялгыз сыер тавышы да басыла. Иртән иртүк торып, миңа да, Кашкасыерга да кырга чыгасы бар, кайгыларны кара буразна буена каерып саласы бар...

Без, авыл тирәсе басуларын сөрә-сөрә, һаман ераклаштык, бик еракта куна ятып эшли башладык. Әниемне озак вакыт күрми йөрү бик кыен, көн дә иртән җилепйөгертеп өйгә кайтасы килә, ләкин кул тими, бригадир да авыл ягына карарга мөмкинлек бирми иде. Бозауларыннан

аерылган сыерлар да бакырыштылар-бакырыштылар да туктадылар, кайтып булмаслыгын, ахры, тойдылар. Кашкасыер гына, бозавы үлгәннән соң, өн-аваз ишеттермәде, әйтерсең, ул бөтенләй тавышсыз калды. Малкай, машинадай җигелеп, фәкать эшли дә эшли иде...

Эш араларында ял иткәндә мин, сыерымның алдына чыгып, ызан буена утырам, ике тубыгымны кочаклап, уйга чумам. Сабаны янында чүгәләгән Мөнирә җиңги авыз эченнән генә моңлы көй суза. Күз алдымда шул чак ике балчык өеме — кабер сурәтләнә: әтиемнеке һәм йолдыз кашка бозавыбызныкы. Миңа бик тә, бик тә ачы булып китә, мин, мөгаен, сулкылдап куям. Шундый минутларда мине бер җан нәкъ өйдәгедәй, әниемдәй итеп иркәләп сөя, кыштырдатып, көн дә шулай сыйпап-сөюеннән шомарып, ялтырап беткән кулбашымнан, чәчләремнән, маңгаемнан ялмап ала, үткер кытыршылыгы белән сискәндереп, ачы күз яшьләремне сыпырып сөртә. Мин, күз йомган килеш, оеп, иркәләнеп утырам, аз-азлап тынычланам. Иркәләүчемнең саф мәхәббәт тулы зур зәңгәр күзләренә калкынып карыйм. Нинди керсез һәм төпсез ул күзләр, мине улы итеп сөюче күзләр!.. Кашкасыер, нәкъ теге буранлы төндә өйдә кашка бозавын ялагандай, тирәннән, йөрәк эченнән мызылдап-мөңрәп куя, кытыршы сыер теле тагы да минем иңбашка сузыла, маңгаема тузгып төшкән чәчләрне калкытып, үргә сыйпап ала. Сыер күзләреннән миңа үлеп сагынган әниемнең миһербанлы күз нурлары коела...

Бер китүдән без көзгә кадәр өйгә әйләнеп кайтмадык: сабанны куып, печән, печәнне — урак, уракта соң туңга сөрү, арыш чәчү эшләре гел бер-бер артлы килә генә торды. Кышларын кырда молотилка белән иген сугу, салам ташу тынгы бирмәде. Бу йөкне дә кешеләр белән бергә сыерлар үз иңнәрендә тарттылар. Шуңа күрә ике ел буена безнең өйдә яшь бозау кычкырганы, гөбер-гөбер бидрәгә сөт агылганы ишетелмәде...

Шулай итеп 1943, 1944 еллар үтте. Апаем да, мин дә кабат мәктәп ишеген ача алмадык: авыр еллар кушуынча, чынлап ук билне буып, авылның данлыклы эшчәннәре, «колхоз тоткалары» булып киттек. Әйтергә кирәк, гарасатта укый алмый калган бу буынга соңыннан белем тавын яулар өчен күп көч, дәрт салып тырышырга, яныш тир түгәргә туры килде...

Кырык бишенче елның язында безнең колхозда сабанга сыер җиктермәделәр. Хәер, аларның күбесе былтыр иртә көздән үк камытын салган иде. Чөнки фронтта безнең гаскәр һаман алга бара, фашистларны илебездән сөреп

чыгарып, үз жирендә кыйрата иде. Шуның аркасында колхозда да хәлләр шөйлә җиңеләеп, элек житешмәгән кирәк тимер-томыр күбәеп, туктап утырган тракторлар гөрләп эшли башлаган иде. Мин тәү тапкыр язгы сабанга Кашкасыердан башка чыктым.

Бу юлы кырда озак йөрергә туры килмәде: аягым шешеп, кире кайттым. Урыныма әниемне җибәрделәр.

Менә хәзер, көбәктәй булып, өйдә ялгыз утырам. Әнием эштә, апаем эштә, Кашкасыер көтүдә. Кара песигә кадәр кайдадыр чыгып киткән. Ишегалдында, сөйләшим дисәң, хәтта бер генә тавык та юк.

Кичә бригадир калдырып киткән иде — үзебезнең район газетасын укыйм. Сугыш хәзер Берлинда, Гитлер явызның үз өендә бара. Их, шунда булсаң иде, җиңү сәгате суккаңын үз күзләрең белән күрсәң иде!

Мин чатанлап ишегалдына чыгам, баз кырыенда күпереп үскән песи үләненә чалкан ятам да зәңгәр күккә күзләремне төбим. Анда бармак битедәй дә болыт юк, бөтен галәм океан сымак күм-күк. Йомарлык май кебек ягымлы май кояшы дулкын-дулкын сары нурларын коя. Җирдә даланың куксел эрсмс май җиленә дулкынланып утыра. Сакмар аръягында моңлы кәккүк кычкыра.

Урам буеннан тырылдап килеп тарантас туктады, бригадирның карлыккан тавышы ишетелде:

— Улым, эү, улым!

Башымны калкытам.

— Улым, сөенче! — Бригадирның авызы колакларына житкән, ул чын күңелдән куана. Мин торам, чатанлап, янына киләм. Дулкынланудан тыным кысыла, йөрәгем чыгып килә.

— Кашкасыерыгыз бозаулаган бит!

— Агай, чынмы?! — Мин аны муеныннан кочаклап алырдай булам.

— Әйдә, киттек, барып алыйк!

Җиңел тарантас безне дала буйлап җилдерә. Авыл әллә кайда артта, кызыл убалар ышыгында кала. Сакмар буена борылабыз. Тирә-як — былтырдан чабылмый калган ап-ак кылган. Суган кебек яшел бүтәгәлектән безгә ак маңгайлы, сынык мөгезле, зур башлы сыер карап тора. Аның күзләрендә, әйтерсең, бая сөенче кычкырган бригадир агайныкы кебек куаныч чагыла. Янында үзе кебек үк зур зәңгәр күзле, ак йолдыз маңгайлы, ак тасма бугандай ала бозау, имеп туйган бөерләрен бүртәйтеп, койрыгын шештәй калкытып, чабарга әзерләнеп тора.

— Бисмилла, котлы аягың белән, алтын тояккай,—

ди бригадир агай, кайнар тәнле бозауны тарантаска күтәрешеп. Кашкасыерның житәк бавын арба артына тагабыз; сыер, казандай жиленен ян-якка салпылдатып, мин кочаклап утырган бозавын саклап, мөңрәп килә...

Шуннан соңгы вакыйганы мин бервакытта да тыныч кына сөйли алмыйм, күз яшьләремне күрсәтмәсәм дә, йөрәгем белән сызлыйм... Кашкасыер белән бозауны алып кайтып житкереп, угызын күрше әбидән саудырып, учакка ут яктык, тышта, куе үләнле баз кырыена утырып, угызның эреп төшүен көтә башладык. Бригадир агай артыннан ук әнием белән апаема күп көтелгән тапсык күчтәнәч — угыз эремчеге жибәрәсем килде. Кичкә әнием сыерны үзе кайтып саварга тиеш иде.

Көтмәгәндә, күз алдыбызда, Кашкасыер бозавын ялап торган жиреннән акрын гына арткa чүгә башлады, өзек кенә итеп бер мөңрәде дә лап итеп кабыргасына ауды; дүрт тоягын сузып, башын читкә ташлап, авыр гыжылдады. Йөгереп якын килүгә, сыерның бөтен тәне дер-дер калтырый, ашаган яшел үләннәре сулыш белән кушылып борын тишекләреннән бөркелә иде.

— Әй асыл малкай гынам, сөтле сыерларның чиренә тарыгансың бит...— дип кызганып сөйләнде күрше әби. Бригадир атын борып, туры ветфельдшерга чаптырды, мин, үксеп жибәрүдән чак тыелып, сыерымның баш очына утырдым. «Ни булды сиңа, газизем, ни булды сиңа, туганым?» — дип, үз тавышымны үзем ишетми сөйләнеп, аның айдай балкып янган ак маңгаеннан, сынык яртылаш мөгезләреннән, камыт басып катырган жилкә буйларыннан сыйпыйм. Кашкасыер, мине жәлләгәндәй, тонык күзләре белән бер генә калкынып карады да башын артка ташлады, минем белән мәңгегә саубуллашты...

Алачыкта олы казанда сикереп-сикереп угыз кайный, ишегалдында ала кашка бозау жансыз яткан анасының имчәкләрен борыны белән төртеп-төртеп елый, ә мин жирдә, баз кырыенда тубыкларымны кочып утырам.

Тагы тыкырдап тарантас тавышы ишетелде, бу юлы ул бик ашыгыч, бу таңгалдо туктамыйча үтте. Бригадирның көр тавышы мине сискәндереп жибәрде:

— Иптәшлә-ә-әр, безнекеләр жиңгән! Иптәшлә-ә-әр, клуб янына Жиңү митингысына барыгыз!

Бу хәбәр һич тә башыма сеңә алмый, алжып утырганда, урам буена бер көтү бала-чага килеп чыкты:

— Жиңү! Жиңү! Жиңү!

Ашык-пошык жиләнен ябынып йөгергән әби, капкага житкәч, миңа борылып карады:

— Ишетәсеңме, улым, сугыш туктаган, ди бит? Бөтен киткәннәр дә кайтыр инде хәзер!

Әй бу яз, гомердә онытылмас яз, 1945 елның чалт аяз күкле язы!..

Без сине ничек зарыгып көттек, сагынып көттек — кырык беренче елдан бирле Ватан өстен иңләп алган ике меңгә якын утлы көн һәм төннәр буе һаман бер синең хакта, бөекләрдән бөек Җиңү көне хакында, көндезләрен — хыялланып, төннәрен — төшләрдә күреп көттек. Ләкин хыял белән төшләрке, балавызланып, без тышка чыгармадык, еламсырап, йә моңаеп, үләндәй бөгелеп утырмадык — без эшләдек, кырыс җиңнәрне сызганып, тар изүләрне ычкындырып җибәреп, бөтен ил белән шушы газиз бер көн өчен, Җиңү көне өчен көне-төне янып эшләдек. Фронттагы каһарман эти һәм абыйларыбызга озын буразна буйларында, утлы мич һәм станоклар янында чын алмашчылар булдык — тылда торып, без дә көн-төн фронт тоттык. Һәм менә көтелгән бәхет — татлылардан татлы Җиңү хәбәре!..

Алачыкта олы казанда сикереп-сикереп угыз кайный, ишегалдында кашка ала бозау тынсыз яткан анасының имчәкләрен борыны белән төртеп-төртеп елый, урамда, гү килеп, бер көтү бала-чага сикереп уйный, ә мин баз кырыенда, тезләремне кочкан килеш, өнсез-тынсыз утырам. Үзәккә үткеч тынлык озакка бара алмады: мин дә бәгърем төпкеленнән ташып килгән ачы һәм татлы авазга ирек куйдым...

Күпме еллар үтте инде хәзер!..

Табыннарда утырганда, кордашларым һаман тынгы бирмиләр: «Арабыздан бер син генә шагыйрь булдың... Үзебезне кеше иткән сыер турында яз син җыр!» — диләр. Көтеп-көтеп тә, ул җыр һаман тумагач: «Их син, оныттыңмыни үткәннәрне? Әгәр ул чакларда сыер булмаса, бүген син булыр идеңме дә без булыр идекме?!» — дип битәрлиләр. Мин эндәшми генә башымны иям. Әйе, фашизмга каршы сугышта хәтта үләннәр дә катнашты, хәтта үләнәр дә җырланырга хаклы. Ләкин нигә тумый һаман мин йөрткән җыр?!

Каләм алып утырам да уйга чумам: ничек итеп язарга соң бу җырны, данларга гади Кашкасыерны?.. Ә нинди күп иде бит ул безнең язасы җырлар, Кашкасыерлар! Бәлки, бу җыр һәркемнең үз күңелендә генә шытып, җырланып йөридер?.. Шулай да аны ак кәгазьгә күчерәсе, бөген кешеләрдән җырлатасы килә. Безнең буын белән бергә утны-суны үтте сыер.

Сыерлар турында да йөрәк өзгеч бер җыр калсын иде.

МАНСАФ ГЫЙЛӘҖЕВ

Мансаф Таҗетдин улы Гыйләҗев 1933 елда Башкортстанның Чакмагыш районының Яңа Йомран авылында туган. Борай районының Чалкак урта мәктәбен тәмамлагач, ике ел китапханәдә эшли, балалар укыта. 1952—1955 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1960 елда Башкорт дәүләт университетын тәмамлап чыккач, телевидениеда редактор, өлкән редактор, баш редактор булып эшли. 1967—1969 елларда Ленинградта партиянең Югары мәктәбендә укый. 1984 елда ул Башкортстан китап нәшриятына баш редактор итеп эшкә күчерелә.

Мансаф Гыйләҗев студент елларында актив языша башлый. Ул — «Очрашу кичәсе», «Бәхетле кеше», «Язмышка үзең хуҗа», «Борма-борма юлларда» исемле китапларның авторы.

Мансаф Гыйләҗев КПСС әгъзасы, СССР Язучылар союзы, СССР Журналистлар союзы әгъзасы. Тырыш хезмәтләре өчен медальләр белән бүләкләнде.

ЧИБӘР ӘБИ

Гадәттәге эш көне иде.

Без — телевидение редакторлары — һәркайсыбыз үз эшебез белән мәшгуль. Кемдер әле генә командировкадан кайтып төшкән — блокнотына язганнарын тәртипкә китерә, икенче иптәш янына режиссер кергән — күрсәтеләчәк тапшыру хакында бәхәс алып баралар. Минем өстәл янында инде баядан бирле кинооператор утыра — текст көтә, аны кулына эләктерү белән монтажга тотыначак...

Әйтәм бит, гадәттәге эш көне. Бүлмәбез тулы кеше. Бәхәс, уйланулар, язулар, телефон шылтыраулары... Бер

генә журнал, газета редакциясендә дә бездәге кебек шаушу юк. Бер иптәш сүзләре белән әйтсәк, хезмәтебезнең үзенчәлеге шундый. Ләкин безнең эш бик тә, бик мавыктыргыч, кызык. Әлбәттә, төрле чаклар булгалый. Әйтик, эфирга чыккач, кем гаебе беләндер кайбер нәрсәләрне бутап күрсәтү. Бу очракта инде, безнең чәчләребез үрә тора, биш минутка дип җыелсак, икешәр сәгать утырабыз. Хезмәтебезнең үзенчәлеге шундый.

Берчак шулай безнең бүлмәгә ике карчык килеп керде. Алар ишекне әкрен генә яптылар да арытаба аякларын кузгатырга базнат итмичә тукталып калдылар. Баш кагып кына исәнләштеләр. Карчыкларның берсе корыган гөл шикелле бөрешеп калган. Коңгырт йөзен исәпсез-хисапсыз җыерчыклар кискәләгән, көннең җылы булуына карамастан, ул өстенә калын бишмәт кигән, ак чәчләрен мамыгы коелган шәл каплаган. Эчкә суырылган иреннәрен зәңгәр тамырлары бүртеп торган ябык кулы белән ышыклаган. Яшь пәрдәсе тартылган күзләре ниндидер өмет, ялыну белән беребездән-беребезгә күчә. Гәүдәсен селкетергә куркып, юка читек өстеннән кигән очлы башлы галошларын әкрен генә сала. Икенчесе — яшьрәк. Анысының гәүдәсе тулы гына, өсте-башында да җиңелчә һәм өр-яңа әйберләр. Янындагы карчыкны, күп еллардан соң очраткандай, беләгеннән тотып, аның йөзенә баккан, туктаусыз елмая.

Без бер-беребезгә карашабыз, ымлашабыз, ләкин әлеге ике карчыкны танучы юк, шулай ук чакырып китерүче дә булмаган.

— Әбиләр, сезгә кем кирәк иде? Нинди йомышыгыз бар? — дип сорый бер иптәш.

— Тәүдә утырыгыз, тын алыгыз, өченче катка күтәрелгәндә сезнең түгел, минә безнең хәл бетә әле,— дип, урыныннан торып, карчыкларга диванны күрсәтә икенче беребез.

Юк, әбиләр урыннарыннан кузгалырга теләмиләр, сөйләшмиләр дә.

Бүлмәдә сирәк була торган авыр тынлык урнашты. Килүчеләр дә эндәшми, без дә нәрсә дип әйтергә белмибез.

Ниһаять, әбиләрнең картрагы тутырып сулыш алды да:

— Сөйлә,— дип, күршесенә пышылдады һәм үзе, нәрсә әйтер икән дигәндәй, яртылаш борылып аның авызына карады.

Яшьрәге баш иеп кенә «ярар»ны аңлатты да учы белән авызын каплап тамагын кырды.

— Начар ишетә ул Чибәр әби. Без бик ерак авылдан килдек сезгә. Чибәр әби юлга бабае белән чыкмакчы иде дә, тегесе аяктан егылды. Сәфәргә җыенырга тәмам өмете өзелгәч, безне генә җибәрергә уйлады. Хәзер инде Чибәр әби ялгызы калды. Өч малай, бер кыз үстергән иделәр. Шул малайларның өчесе дә сугышта һәлак булды. Балалары бик тыйнак була торган иде. Авызларыннан начар сүз чыкканны ишетмәдек, кешелекле булдылар. Ике малайлары сугыш чыкканчы ук солдатта иде, төпчекләре ике елдан соң гына китте, яше җитми торды.

Өлкән карчык, елмая биреп, дөрес сөйлисең дигәндәй, башын кагып торды. Аның күзләре моңсу булса да, йөзендә, кечкенә гәүдәсендә шатлану, талпыну сизелде, ябык бит очларына алсулык йөгерде. Ул, болар тынлый микән дип, безгә дә күз салгалап ала. Без исә, бу сөйләшү нәрсә белән бетәр икән дип, тын да алмый хәбәр тыңлыйбыз.

— Өч малай үстереп илгә бирделәр Чибәр әби белән Минһаж бабай. Өчесенең берсе дә кайтмады. Икесе сугыш чыкканның тәүге көннәрендә үк һәлак булганнар, имеш, дип сөйләделәр, ә иң кечесен күптән түгел генә сез телевизор аша күрсәткәнсез.

Сөйләүченең иреннәре кыбырдаудан тукталу белән малайларын югалткан әби ялт итеп безгә борылды. Аның йөзенә елмаю йөгерде, күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты, танау яфраклары кабарды. Хәтта ул, безнең җавапны көтеп, сулыш алудан да туктагандай тоелды.

— Минем улымны күрсәткәнсез,— дип пышылдады ул,— кешеләр әйтте.

Безнең эндәшмәүне күреп, тарихны сөйләгәне кабат сүз башлады.

— Авылдашлар шәһәрдән кайтып әйтте. Ул чакта әле безнең авылда телевизорлар юк иде, шунлыктан үзебез күрмәдек.

— Ничек соң, апалар, ул кеше теремени?— дип сорыйм.

— Нәрсә сорый? —дип өлкәне күршесенә борылды.

— Малаең теремени, ди.

— Үлде шул, балакайларым, җир куенкайларында.

— Телевизор аша ничек күргәннәр соң?— дип сорыйбыз.

— Нәрсә ди?

— Телевизорда ничек күргәннәр дип сорыйлар,— диде кечесе кычкырыбрак.

— Әйт инде үзләренә, белгәннәреңне сөйлә,— ди Чибәр әби, әле күршесенә, әле безгә карап.

— Нәрсә дип кенә сөйлим соң? Китеп барган, мылтыгын күтәреп солдатлар белән китеп барган. Шулай диделәр.

— Кайчан күрсәткәнбез?

— Кая киттегез диме?

— Юк, кайчан күрсәткәнбез, дип сорыйлар.

Чибәр әби салынып төшкән кулбашын сикертте, белмәвен аңлатып башын селкеде.

— Башкача бер нәрсә дә әйтә алмыйбыз шул. Поездда килгәндә дә, ай-һай, таба алырсыз микән, дип шикләнгән иделәр. Чибәр әби, үлсәм-үләм, улымны күрми кайтмаячакмын, диде. Бик нык кына иде әле, колаклары да зирәк иде, бабае үлгәч бөтенләй бетеренде.

Без нинди генә киңәш бирергә дә аптырадык. Ичмасам, күрсәткән көнне дә белмиләр. Ә бит тәүлегенә күпме тапшырулар, фильмнар, спектакльләр, концертлар, хәбәрләр тәкъдим итәбез үзебезнең тамашачыларга. Күн булса, аның малае төшерелгән пленка ике-өч метрдыр инде. Аны табу өчен хәзер күпме километрлар пленка карарга туры киләчәк! Тик барыбер әбиләргә ничек кенә булса да ярдәм итәргә кирәк, аларны болай «буш кул» белән кире борып җибәрү безнең тарафтан кешелексезлеккә исәпләнер иде. Ә ничек ярдәм итәргә?

Уйламаган җирдән килеп туган әлеге хәлне җитәкчегә житкердек, ә ул зур дикъкать белән тыңлап бетерде дә:

— Хәзер үк прокаттан, фильмотекадан сугыш елларына кагылган документаль ленталарны алыгыз. Әгәр әбиләр арымаса, эштән калып күрсәтегез. Сиңа, Галиев, сугыш темасы якынрак. Бу эшне үзеңә тапшырам,— диде.

Без, машинага төяп, пленкалар салынган тартмалар китердек. Көндәлек эшләрне читкә куеп, кинозалга кереп утырдык. Караңгы залда өчәүбез: ерак-ерак авылдан килгән ике әби һәм мин.

— Хәзер башлыйбыз, игътибар белән карагыз, әбиләр, әгәр берәр кешене улыгызга охшатсагыз, әйтегез,— димен янымда тын гына утыручыларга.

Алар эндәшмиләр. Чибәр әби артык нык дулкынлану шикелле. Сулышын еш ала, авызы кибә, күрәсең, туктаусыз тамагын кыра.

Киномеханикка башларга мөмкин икәнлекне белдереп кнопкага басам.

Менә залда көчле, йөрәкләрне тетрәткеч музыка яңгырый. Экранга титрлар языла. Фюзеляжларына, канатларына тәре төшерелгән фашист самолетлары. Алардан шәһәрләр, авыллар, юллар, күперләр өстенә сызгырып

бомбалар коела. Дөньяны ут каплаган. Кара төтен күк белән җирне тоташтырган. Урамда һәлак булган балалар, хатын-кызлар, әби-бабайлар ауный. Кабыргаларына тәре ябыштырган кара танклар. Алар дулкынланып утырган иген басуларын таптап киләләр. Артларында ялкын, кара сөрем кала. Йолдызлы солдатлар окоптан аларга граната ташлый. Бер танкка ут кабынды, икенчесе төтәде.

— Шул кирәк ул дөмегеп киткерләргә, шул кирәк...— дип пышылдады Чибәр әби.

Өченче танк окоп өстенә килеп менә һәм бер гусеницасына тормоз салып әйләнә.

— Уф аллакаем, ярабби, үтерәсең бит балакайларымны...

Кадр артыннан кадр үтә. Аларның һәрберсе документаль, һәрберсендә илбасарларга каршы көрәшеп йөргән совет солдаты, күп кенә кадрларда — кешелек тарихында күрелмәгән вәхшилекләрне эшләүче фашистлар.

Менә совет гаскәрләре һөҗүмгә күчте. Немец илбасарлары, бөтен коралларын, техникасын ташлап, җир өстен мәет белән каплап, көнбатышка чигенә.

— Йөремәскә ару булыр. Арт сабакларын ныграк укытырга кирәк... Әнә минем улым! Ишбулдым. Бәбкәем!..

Мин тиз генә фильмны туктатырга сигнал бирәм һәм утны кабызам.

Ике яңагын учлары белән каплап, залда кечкенә генә гәүдәле карчык басып тора. Ул далада тирбәлгән кылган шикелле селкенә. Шәле җилкәсенә шуып төшкән. Чәче ап-ак. Эндәшми, сулышы өзелеп-өзелеп китә.

— Юк, Чибәр әби, ялгышасың, Ишбулды юк иде анда,— дип ярым кычкырды күршесе.

— Ул! Ул гына. Үз баласын танымаган ана буламыни. Ул!..

Әле генә үткән кадрларны яңадан карырга булдык.

Зал кабаттан дөм караңгы. Экранда тик мич торбалары гына утырып калган авыл аша үтүче безнең солдатлар. Бөтенесе дә бер төсле киенгән. Баягы кадрлар үтеп бетте. Эндәшүче юк. Димәк, Чибәр әби ялгышкан, ул, күрәсең, кемнедер улына охшаткан гына...

Ике сәгать буе Бөек Ватан сугышына кагылган фильмнарны карадык. Юк, меңәрләгән солдатлар арасыннан Ишбулды табылмады.

— Әзрәк ял итик,— дидем.

Чибәр әби, ике яңагын кысып тотып, башын түбән игән, эндәшми.

— Теләсәгез, буфетка төшик, чәй эчәрсез,— дип тә карыйм.

Юк, Чибәр әби бөтен күңеле, йөрәге белән уйлар диңгезенә кереп чумган. Ул кайда икәнлеген дә оныткандыр, мөгаен, әлеге минутта.

— Аны хәзер моннан куптарып та алалмыйсың инде,— диде Чибәр әбине озатып килгәне.— Барыйк та барыйк, дип теше төште бит. Ишбулдымны күреп кайтсам, үлсәм дә үкенмим, ди...

Без өчәүләшеп көне буе залда утырдык. Һәр фильмны караган саен Чибәр әби үзгәрә барды. Аның йөзендәге баягы алсулык югалды, ул керфекләрен дә еш-еш йомгалады, кашлары, үтәдән-үтә күренерлек булып калган танавы турына тартылып, түбән асылындылар. Бөрешеп эчкә баткан иреннәре кыймылдап куя иде, күрәсең, үзалдына нидер сөйләнә, күзләре дә төссезләнде. Бәлки, ул шушы минутларда үтелгән озын гомерен хәтерләгәндер, бәлки, Ишбулдының бишектә чәбәләнеп яткан чагын күз алдына китергәндер... Кешенең бөтен дөньясын онытып бу кадәр дә уйга батканын күргәнем юк иде әле.

Без икенче көннең иртәгәсендә шушы бинада очрашырга сүз куештык.

«Ничек соң Чибәр әбинең Ишбулдысын табарга? Әгәр тапсак, мин күп иттереп фотоларын эшләттереп бирер идем...» Шушы уй азга гына булса да күңелемнән чыкмады. Бәлки, Чибәр әбинең гомерендәге соңгы үтенечедер... Илебездә халкыбыз азатлыгын саклау, яклау, бүгенге матур тормышны дәвам итү өчен өч егет үстереп биргән. Өч улы да һәлак булган. Күпме кайгыны, хәсрәтне күтәрә алган кечкенә генә кеше! Нинди ихтыярый көчкә, йөрәккә ия! Ничек кенә ярдәм итим соң сиңа, Чибәр әби? Син иң зур хөрмәткә лаексың бит...

Иртәгесен уйларымның очына чыга алмыйча эшкә килдем. Бәй, ике әбием дә ишек төбендә утыра.

Мине күрү белән торып бастылар, баш кагып кына исәнләштеләр, бер сүз дә эндәшмәделәр.

— Нигә алай бик иртә? Без бит унынчы яртыда очрашырга сөйләшкән идек.

— Төне буе йокламады. «Син иплэп карадыңмы, үтеп китмәдеме?» — ди. Юк, дип аңлатып торам. Бераз ята да тагы шуны кабатлый. Төн уртасында алып чыгып китте. Вышкагыздагы кызыл утларга карап, җәяү килдек. Тәмам йончыды. Мин дә арыдым. Бүген тапсак ярар иде,— дип, сөйләнә-сөйләнә минде биек баскычтан Чибәр әбине озатучы.— Үлә-нитә калсам, берүк кайтарып картым янына

җырлагез, ди. Әллә кая китмәсен үзе дә белә дә бит, нәрсә эшлисең, бала. Бала...

Без өчәүләшеп кинофильмнар карый торган залга кереп утырдык. Киномеханик пленкаларны тикшерә, шуңа күрә азрак көтәргә туры киләчәк.

Чибәр әбинең авызын каплаган кулы дерелдн. Ул миңа нәрсәдер әйтергә тели шикелле. Борылып карый да ак экранга кабаттан текләнә.

— Хәзер, хәзер,— димен үзенә.

— Ярый, ярый, көтәрбез... Ишбулды таң алдыннан туган иде. Теремек булып үсте. Итәгемә тотынып урам буйлап елап ияреп тә йөрмәде. Үзең бирмәсәң, өстәлдә нәрсәләрең генә ятмасын, үрелеп алмас иде... Әй дөньялар, дөньялар... Кайсы кичне соңлап кайта торган иде. Күл буена кичке уенга чыгалар. Песи кебек кенә басып өйгә керә дә үзенә салып өстәлгә куйган сөтне эчә. Бик озак боргаланып ята. Әкрен генә үзалдына көлгән чакларын да ишеткәнем бар иде. Һәр уен беләсем килә дә соң, балачага биш-алты яшькә чаклы гына сер сакламый бит. Төрле уйлары булгандыр бәбкәмнең... Чылбырлы значугы әле дә сандык төбендә. Шуны күкрәгенә таккач, түбәсе күккә тигәндәй йөргән иде... Әй дөньялар, дөньялар... Очучы булсам, сине дә һавага алып менәрмен, ди торган иде...

Чибәр әби үзалдына шулай сөйләнеп утырды-утырды да миңа борылды.

— Улым, кинодагылар булган хәлме? — дип сорады ул гаҗәпләнеп, куркып.

— Әйе, Чибәр әби, әйе, булган хәлләр.

Аның күңеле төшенкелеккә бирелмәвен, иркенләп сөйләшүен телим, күзләре кабаттан яшьләнмәсен, куллары дерелдәмәсен, сулышы өзелеп-өзелеп китмәсен иде.

— Харап икән, харап икән. Шундый гарасатта кемнең газизләре генә исән калсын. Харап бит...

Аның томса тавышында аптырау да, курку да, нәфрәт тә яңгырый иде. Гәүдәсе тагы да бәләкәйләнә төшкәндәй тоелды, сулышы тагы ешайды, ярым кәкрәеп калган бармаклары белән күкрәген уып алды...

Экранда сугыш кадрлары...

Безнең гаскәрләр атакага ташланды.

Менә окоптан ниндидер яшь офицер сикереп чыкты да, пистолетын югары күтәреп, иптәшләренә борылды. «Ура!» тавышлары яңгырады.

— Ул! Ишбулдым, нигә артың белән борылдың?! Бу бит син! Нигә миңа табан карамадың?..

Мин утны кабыздым.

Маңгаен алдагы утыргычка терәп ап-ак чәчле ана яшь түгә иде. Аның тавышы чыкмый, тик аркасы гына дерелди.

Алар икәүләшеп елаштылар.

Яшь офицерның окоптан сикереп чыккан моментын яңадан кабатладык. Кадр кыска гына. Сикереп тә чыга, тиз үк иптәшләренә нидер кычкырып залга арты белән борыла. Бәлки, чынлап та, Ишбулдыдыр, бәлки, аңа охшаган гына кешедер? Кем белә инде, миллионнар катнашты бит узган сугышта. Ана әйтә икән, әйдә, әлеге сугышчы аның Ишбулдысы булсын.

Аннан соң килгән кадрларга алга йөгерүче безнең пехота төшерелгән. Туктаусыз атыш, шартлау... Дошманны куып барган солдатлар да сирәгәя...

— Җитәр, балам,— диде Чибәр әби.

Аның тавышы баздан килгәндәй генә ишетелде. Мин бик озак утны кабызырга базнат итми тордым. Ананың ничек өзгәләнүен, тавышын тыеп үксеп утыруын күрергә теләмәдем, коридорга чыктым.

Ике әби хәтсез вакыттан соң гына зал ишегендә күренделәр.

Яшьрәге Чибәр әбине култыклаган иде. Чибәр әби бер кулы белән маңгаен тоткан. Мин алар янына ашыктым һәм Чибәр әбине икенче яклап култыклап алдым. Янымда җип-җиңел, юка ана иде. Ул бөтен көчен, маңгай тирен җиргә, күкрәк сөтен, күз нурын балаларына биргән. Хәтта чәченең кара төсе дә үзендә түгел, авыр елларга бүләк ителгән. Үлгәндә алып китәсе нәрсәсе — балаларына, тормышка булган мәхәббәте генә. Алары инде тик үзенеке генә, беркемгә дә бирелә торган нәрсә түгел. Бүген яшәткән, бүген йөрткән көч тә шушы мәхәббәттер.

— Рәхмәт, улым, мең яшә, үзең дә тәүфыйклы бул, балаларың да тәүфыйклы булып үссеннәр. Берүк сугыш күрмәгез, балакайларым,— дип миңа карап алды Чибәр әби.— Шунысы үкенечле, әтиләре килеп күрә алмады улын...

Башын бер якка янтайтып сөйләнеп торган Чибәр әби кинәт кенә үзгәреп куйды: гәүдәсе турая төште, танау яфраклары кабарды, ябык йөзенә алсулык йөгерде, авызын каплаган бармаклары йодрыкка төйнәлде, күзләре кайдадыр текәлде.

— Рәхмәт, күгәрченем, куркып тормагансың,— диде ул, пышылдап.— Рәхмәт...

БУЛАТ РӘФЫЙКОВ

Булат Заһретдин улы Рәфыйков 1934 елда Башкортстанның Мәләвез районы Дәүләткол авылында туа. Җидееллык мәктәп һәм Стәрлетамак педагогия училищесын тәмамлаганнан соң Башкорт дәүләт университетында югары белем ала. Уку чорында ук редакцияләрдә әдәби сотрудник булып эшли.

Б. Рәфыйков әдәбият өлкәсендә үзен төрле жанрларда сынап карый. 1965 елда аның «Гаҗәпстан» дигән тәүге шигъри җыентыгы дөнья күрә.

1973 елның җәен ул республиканың зур төзелешендә — тимер юл салучылар арасында үткәрә һәм үзенең беренче проза әсәрен — «Тауларда кар иртә ята» повестен яза. Шулай ук балалар өчен «Лоуллә», «Җиһан азаматлары» дигән фантастик повестьлар да иҗат итә.

Соңгы елларда әдипнең «Чал кылган» һәм тарихи темага язылган «Карасакал» дигән романнары басылып чыкты.

Б. Рәфыйков 1966 елда Коммунистлар партиясе сафына кабул ителә, 1978 елдан — СССР Язучылар союзы члены. Хәзерге көндә ул Башкортстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре, республиканың атказанган культура работнигы.

КУРЧАК ТЕАТРЫ

Мостафа авылына курчак театры килгәнен без яланда кибән койган җирдә ишеттек. Бригадир чатан Бәдри дә шунда иде. Егетләр берәм-берәм аның янына җыелдылар, алар алдан кызлар белән чыш-пыш сөйләшергә өлгергән иделәр инде. Минем күбә тарттырып барган гына мәл иде, тамак бавын юнәткән булып юри тыңлап тордым. Ат сорыйлар: театр карап кайтабыз, авылда клуб юклыкка без гаепле түгел...

Тыңлар Бәдри егет-җилкенчәкне! Сүзгә беткән бер кеше ул. Әнә, фронттан да бичәсенә бәетләр язып япты.

Имеш, төш кургән, комбайнның куперендә янәшә басып торалар... Гаиләсе бездә өйдәш яшәде, шуңа да һәр хатын диярлек хәтерлим.

Менә ул әле егетләр камавында басып тора. Юк, яшьләрнең күңел ачарга баруына ул һич тә каршы түгел, бер ат кына җитмәсә — икене, өчне бирә ала. Тик менә — курчак театры! Адәм көлкесе бит. Шуңа алданып, йокы калдыр, ат йончыт, имеш! Нәрсә, безнең авыл яшьләре гомергә курчак күрмәгәнме әллә?..

Яртылаш күтәрелгән кибәндә сәнәк сапларына таянып басып торучы картлар Бәдринең соңгы фикере белән килешмәделәр:

— Менә инде, уйнап үскәндер шул алар!

— Әле һаман юньле аш, юньле кием күргәннәре юк...

Шундый тел ярдәмен ишетеп, кызлар да чәрелдәшергә тотынды, егетләр дә катырак сөйләшүгә күчте. Бәдри ризалашырга мәҗбүр булды. Тик бер ныклы шарт куйды: башланган кибәнне бүген үк очларга, иртүк, как штык, эштә булырга. Шул сүзләрдән соң печәнчеләрнең ничек комарланып киткәнен күрсәгез иде!

Без, күбә тарттыручы малайлар, үтә дә катлаулы тойгы кичердек. Беренчедән, курчак театрының нәрсә икәнен күз алдына китерә алмый җәфаланабыз: үзебезгә агай, апа тиешле кешеләрнең шулкадәр ашкынуына карагада, кинодан ким түгелдер ул. Икенчедән, без дә барып карар идек — атка кем утыртсын, ыбыр-чыбыр дип кенә җибәрәчәкләр. Җәяүләр идек — шөрләтә. Мостафа безгә унбиш чакрым чамасы. Җитмәсә, Бүре оясы дигән җирдән үтәргә кирәк. Бәләкәй малайларга да җан газиз шул.

Шундый көчсезлек, үз теләгеңне үти алмау тойгысы һәркайсыбызны ярсытты. Атларны юырттырып, күбәләрне кибән төбенә җилдереп китерәбез, ә кире борылгач, йөксез, чабышырга тотынабыз. Моңа игътибар итми калмадылар, әлбәттә. Төрле яктан кычкыра башладылар:

— Әй, шашмагыз!

— Болай да йончыган малкайларны!

— Алар да театрга ашыга дип торырсың.

Малайлар да ишеткәннәрдән үзләренчә нәтиҗә ясый белә. Туктале, без кемнән ким, һәрберебезнең кулында ат була торып?.. Шушы уй бөтенебезнең дә башына берьюлы килгәндер ихтимал, мин аны иң алдан кычкырып әйтергә генә өлгергәнмен. Эшне тәмамлап, кайтырга чыккан гына мәл иде. Берзаман берсен-берсе уздырып кычкырыш, бәхәс китте.

— Тегеләрдән алда барабыз да керәбез!

— Керерсең — арыган атларда!

— Ашатып-эчертеп алабыз, вакыт бар бит әле.

— Бәдридән ычкынып булмас ул!..

— Көтүгә кушмыйбыз, тал арасына кертәбез дә тышаулыйбыз. Беркем күрми калыр.

Шушы урында аңлатма биреп китәргә кирәктер. Бригадада ике конюх, аларның берсе — бригадирның хатыны, теге бәеттәге комбайн күперендә басып торучыларның берсе инде. Дөресрәге, конюх булып исәпләнә генә. Көндез атлар утарында йөри әле, ә төнге көтүгә йә Бәдри үзе чыга, йә Мөнир исемле бер малайны җибәрәләр. Бүген нәкъ аларның дежуры.

Бәдригә минем күптәнге ачуым бар. Исемен ишетү белән, агач аягын тукылдатып, бер якка янтаеп атлавы күз алдыма килә дә баса. Юри кыланамы, әллә гел генә уйланып йә сызланып йөрүеме — каршы очраган кешене дә күрми узуы ихтимал. Авыл моны үзенчә юрый, танау буена карап йөри, диләр аның хакында. Башында бәлшәеп беткән эшләпә, өстендә каеш белән буылган иске гимнастерка һәм сырылган җылы чалбар. Олы танаулы, бармак басымыдай гына мыегы бар. Кысык күзләр. Беләгендә һәрвакыт каеш чыбыркысы асылып торыр.

Шәп шул чыбыркы! Өске ике буыны чукланган, алтыдан үрелгән, аскы буыны өстән ишелеп, нәзек кенә булып тәмамлана. Бөтен тәме шул очында да инде — татып караган бар.

Сугыш бетәргә бер ел калган иде әле. Язгы көннәрнең берсендә авылның үрге очында борчак чәчкәннәрен ишеттек. Мин, озак уйлап тормый, энем белән сеңелкәшне ияртем дә юлга чыктым. Атлаган һәр җирдә ризык эзләргә дә, кирәк урында хәйләле белергә дә өйрәткән иде ачлык. Байтак урау ясап, басуның авылдан күренмәгән башына барып төштек һәм эшкә тотындык. Борчак сай күмдерелгән. Чәчкеч ярган буразнадан туфракны читкә сирпәбез дә бөртә генә башлаган ап-ак бөртекләрне, әйдә, чүплибез. Башта кесәгә җыярга, шуннан гына ашарга сүз куештык.

Безнең кәсепне әлеге Бәдри бүлде. Сугыштан кайтып, бригадир булып эшли башлаган гына чагы. Гаиләсен бездән үз өенә яңа күчереп алган иде, ә изгелекне онытырга да өлгергән. Атын җан-фәрман чаптырып, әллә кайдан килеп чыкты да чыбыркысы белән аркама берне тартты; сыным катып, тын алалмый тордым. Бәләкәчләр чеңләп еларга тотындылар. Бәдри, шул тавыштан курыккандай:

— Җүләрләр, бер борчактан утыз-кырык борчак үсә бит. Яшел кузак чүпләргә килерсез! — дип кычкыра-кычкыра ары чапты. Басуда бездән башка да кәсепчеләр барлыгын күреп калгандыр, мөгаен.

Без, кесәләргә бер өйрәлек борчак салып, яшьле күзләр белән өйгә кайтып кердек. Шуннан бирле, Бәдринең каеш чыбыркысын күрү белән, авызыма борчак тәме килә, күз алдында яшел кузаклар тирбәлә башлый.

Мин бригадирдан уч алырга сүз бирдем. Тик, нишләптер, һаман зураеп булмый. Тол калган хатыннарны, шул исәптән безнең әнкәйне дә шешенгәнче елатып, Җиңү көне дә житте. Ә мин һаман да унөчтә таптанам. Дөрес, бер җәһәттән дошманымны куып уздым инде: чабып барган атка да сикереп атлана алам, ә Бәдри тик торган каратурысының ияренә утыру өчен дә күпме сикергәли. Шулай да ул минем көч җитмәслек ир булып кала бирә әле.

Мин зураерга маташкан арада, Бәдри чыбыркысын тагы бер тәмләтергә өлгерде. Үткән җәй булды монысы. Печәнчеләргә төшке ашны яланда пешергән иделәр. Колхоз тәкә суйдырган. Ит исе әллә кайдан ук танауны кытыклый. Атны читкәрәк алып барып тышаулаганнан соң, бәләкәй йомыш белән куак арасына кереп чыктым да җәһәт кенә табынга килеп утырдым. Өлешемә сузылуым булды, арка буен нәрсәдер көйдереп алмасынмы! Ялт итеп артка борылсам — әлеге агач аяк. Мине генә күзәтеп торган, диярсең.

— Нигә кулыңны юмыйча аш янына киләсең? Әтиең укытучы иде бит, бар авылны тазалыкка өйрәткән кеше! — диде ул, чыбыркысын сабына урый-урый. Шау-шу купты, күпчелек мине яклады: ятимне кыерсытырга ярамый, фәлән-фәсмәтән. Сикереп тордым да читкә йөгердем. Әтиемә дә үпкәм зур иде шикелле: ул укытучы булмаса, янәсе, шуларны кичермәс идем.

Бераздан өлеш итемне тотып Бәдри үзе яныма килде. Нидер сөйләнеп, көрәктәй учы белән башымны сыйпарга маташты. Мин, әлбәттә, читкә янтайдым, ә кулындагы итне җиргә сугып төшердем. Шуннан бирле ашарга утырыр алдыннан еш кына Бәдринең каеш чыбыркысы күз алдымда уйнаклар булды да китте.

Әнә шул җәберләрнең үчен кайтарырга, күңелне азтына булса да тынычландырырга уңайлы мәл җитте шикелле бүген. Атларны алып китеп, агач аякны төн йокысыннан яздырырга, йөрсен, әйдә, яланда шәп чыбыркысын сөйрәп! Бер уңайдан курчак театры дигән нәмәстәкәйләрен дә карап кайту мишәйтләмәс...

Бөтен эшне Мөнир боза язды. Быел гына менгегә өйрәткән таена атланган да чапкан. Арттан куып килеп житте сөмсез. Кулына таяк тотып, каршыга чыгып басты. Кизәнә.

— Стоп, вы куда? (Русча гына жибәрә, мөртәт!)

— Синең ни эшең бар?

— Күздән югал исән чакта!

— Әйдәгез, аяк-кулын бәйләп, кырмыска оясына салабыз!

Тик безгә дә һәр минут кадерле. Туктап, сәяхәтнең максатын аңлатып бирергә туры килде.

— Бәдретдин агай сезнең атларны таба алмый кайткан, шуңа нык борчыла,— диде ул.

— Бигрәк әйбәт, мин дә тапмадым, диярсең.

— Минем дә театр карыйсым килә дә бит...

Мөнир бездән ике-өч яшькә өлкәнрәк. Төптән уйласаң, ул безнең белән түгел, ә рәхәтләнеп, егетләр һәм кызлар янында арбада барырга тиеш. Ләкин тиңдәшләре арасына керә алмый. Әллә нигә бик йомшак күңелле, еларга гына тора шул. Өстәвенә, буйга бәләкәй, шундый чебек, әгәр югычлап юсаң, тиресе аша сөякләре күренеп торыр иде. Шуның өчен дә малайлар исәбендә калуын дәвам итәдер инде. Тагы да бер сәер ягы бар. Аның атасы да, әнкәсе дә исән, шул ук вакытта ул үксез ятим булып йөри. Өлкәннәрдән әнкәсенең бик чибәр икәнен, сугыш башланыр алдыннан, ирен һәм балаларын ташлап, күчмә казакларга ияреп киткәнен беләбез. Әле дә шулар белән бергә Ашказар буенда яши, диләр. Атасы фронттан качып кайткан, һаман булса яшеренеп йөри. Аны әле күе тал арасында, әле Бүре оясында күрәләр. Вак мал югалгалавы — аның эше. Милиция эзенә дә төшеп карый, ди, тик теге ничектер качып котыла.

Мөнир ике агасы белән үги әнкәсендә тора. Авыл халкы аларны берчә жәлли, берчә яратмый. Кәжә-фәлән гаип булса, аларга көн бетте. Бала-чага, бичә-чәчә урамда артларыннан кычкырып кала: бур, качкын балалары!.. Быел яз өчәүләп авыл көтүен сорап караган иделәр — кайда ул, күзләрен дә ачтырмадылар жыенда.

Безнең тиңдәш малайлар өлкәннәр шикелле үк каты бәгырьле түгел, каты сүз әйткән суррәттә дә шунда ук кире кайталар: Мөнирне үчекләүчеләр табыла, әмма үз яныннан куучы юк. Менә әле ул, таеның ялына тотынып, минем янда курчак театрына китеп бара. Барсын әйдә!

Без офыктагы таулар ягына уңайлаган кояш артыннан киләбез. Алда башлы корт йомарламына охшаган бер-

ничә уба күренә. Кайчандыр шушы тирәдә каты сугыш булган. Дошманны куып җибәргәч, корбаннарны хөрмәтләп күмгәннәр, каберләр өстенә биек итеп туфрак өелгән. Убаларның хуҗалары турында әллә күпме кот очарлык хикәяләр тыңлаганыбыз бар. Имеш, ат тоягы тупылдавын ишетү белән, алар җир астыннан чыгалар. Кылычның кылычка бәрелеп чыңлавы, яралыларның хырылдап кычкырышуы ишетелә. Юлчы, куркып, алга ашыга, ә тегеләр аны, дошман белән бутап, куа башлыйлар. Аларның яу атлары да шунда күмелгән бит... Без, укучылар, бу әкиятләргә ышанмыйбыз, әлбәттә. Шулай да убаларны урап үтү хәерле. Атларны уңга бордык та чабышырга тотындык. озакламый тауның көнбатыш битләвендә үскән урманга барып кердек. Шушы урын Бүре оясы дип атала да инде.

Монда ярыйсы ук караңгыланган иде. Агач төпләренә сакка баскан тынлыкта ат тоякларының йомшак туфракта тонык кына дөпелдәве, аркылы яткан юан тамырларга сөрлегүе, ниндидер кошларның ачы кычкырып очып киткәне ишетелә. Тынычланып, урынына утырып җитмәгән малай-шалай күңеленә яңа шом өстәлә. Артта калган убаларның тимер киемле хуҗалары безне һаман да шырлык эченнән күзәтеп киләдер кебек. Бу шикне куып җибәрергә өлгермисең, алда сине бүреләр аңдып ята сымак тоела башлый. Читтән баручылар уртага омтыла. Нигә, дуамалланып, шундый хәтәр юлга чыктык әле, дигән уй колак төбендә көзге чебен шикелле безли. Ул кешедән кешегә күчә, ахрысы. Мөнир түзмәде, кычкырып ук әйтеп куйды:

— Краснояр юлына төшик тә кире борылыйк.

Ул юлда серле убалар да, урман да юклыгын барыбыз да яхшы беләбез. Тик Мөниргә ачу кабарды. Нигә инде куркуыңны шулай ачыктан-ачык белдерергә?!

— Нигә иярттек бу елакны?

— Әле дә куып кайтарырга соң түгел.

Кайчандыр, без дөньяга килгәнче үк, авыл уртасында агач мәчет утырган. Колхоз оештыргач, аның манарасын төртеп екканнар да ишегенә «Клуб» дигән язу кадаклаганнар. Курчак театрын шунда күрсәтәләр икән. Ишегалдында ук бик күп халык кайнаша. Безне әллә кайдан күрешеп, кычкырышып каршы алдылар.

— Тагы карагайлылар килә.

— Алар гына җитмәгән иде.

— Әйдүк, түрдән узыгыз, сезне генә көтә идек.

Абайладык та шаккаттык: клуб эче шыгрым тулы, хәтта ачык тәрәзә төпләренә менеп басканнар. Тыштагы-

лар урынсыз калучылар икән. Спектакль башланган иде инде, эчтә дәррәү көлешү ишетелеп кала да янә тынлык урнаша. Без, аттан төшми генә, тәрәзә аша ни дә булса күрергә тырыштык, әмма бушка гына. Ул арада безне Мостафа малайлары урата башлады. Мөнир белән тагы беребезгә кычыткан тәмләтергә дә өлгерделәр. Ят җирдә сугышырга тартындык. Отрядны яңадан бергә җыеп, куркаклар, дип әйтмәслек кенә шунда басып тордык та ашыкмый гына кайтырга чыктык. Әйдә, үзләре карасын! Курчак күрмәгән кешеләрме әллә без, чынлап та!.. Үз-үзебезне шулайрак юаттык, ләкин барыбер кәеф төшенке иде.

Менә киредән Ашказар тугаена да килеп төштек. Айлы төн су шикелле якты. Аяк астындагы юл гына түгел, тирәяктагы бөтен нәрсә диярлек ачык рәвешләнә. Кинәт алда тояклар тыпырдады, безгә каршы кемнеңдер җан-фәрман чабып килгәне күренде. Аңа юл бирергә төрле якка сибелештек. Безне күргәч, җайдак та тезгенен шакарып тартты, ахрысы, атының бер урында биегәне ишетелде.

— Малайлар, бу сезме?

Бәдринең тавышын танып, коелдым да төштем. Башкалар да эндәшмәделәр, хәтта Мөнир җавап бирергә базнат итмәде.

— Мин сезне юллап килдем, малайлар. Курыкмагыз, ачуланмам. Ярый әле, атларыгызны алып киткәнсез, югыйсә бит, дүрәк!.. Монда ничәүсез? Унике, Мөнирне дә сезнең беләндер дигән идем шул. Арбага җигелгәннәре белән унбиш баш.— Шулай сөйләнә-сөйләнә, бригадир яныбызга килеп җитте. Тавышында, чынлап та, гайрәтлелек сизелми, аркасында мылтык.— Бәла, малайлар! — Бригадирның тамагында нәрсәдер бүлкелдәде.— Көтүдә калган атларны куып алып киткәннәр.

Бу сүзләрнең мәгънәсе безгә тиз генә килеп җитмәде, шуңа да үзебезчә фараз кылырга тотындык.

— Иртәнчәрәк китереп тыщауларлар әле. Киногa киткәннәрдер берәр авылга.

— Селтәгәннәрдер берәр яры, Мөнир дә булмагач.

— Юк шул! — дип каршы төште Бәдри.— Конокрадларның эше. Хатыннар күргән. Кара битлек кигәннәр, ди. Сезнең Мостафага киткәнне дә хатыннардан ишеттем, шуны дөресләргә монда чаптым. Сезгә ачуым юк, шәп эшләгәнсез.

Күптәнге дошманымның бәлага эләгүен ишетеп, алдыбызда шулай еламсыравын күреп, миңа шатланырга кирәк булгандыр да ул. Атларны урлаткан өчен, билгеле, башыннан сыйпамаслар бит. Гомер буе түләп бетерә

алмаячак, төрмәгә ябулары да мөмкин... Ләкин мин шатлана алмадым.

— Ярар, кайтыйк, малайлар. Тирә-якны караштырып барырбыз,— дип Бәдри атын кузгатты.— Нигә бик иртәләдегез? Спектакль булмадымы әллә? — дип кызыксынды ул, байтак баргач. Эшнең нидәлеген аңлаткач: — Ул иске мәчеткә Мостафаның ярты халкы да сыймыйдыр шул. Тышта куйсалар, ни булган инде! — дип артистларга сукранып та алды, шунда ук рәхмәт тә укыды: — Алар килмәсә, сез Мостафага качмасагыз, шушы атлардан да колак кагар идек. Иртәгә ничек эшләр идек? Хәл яман, малайлар!

Кызык бит, әй, дөнья дигәнең! Әле генә рөхсәтсез ат менеп киткән өчен бик нык эләгәчәгеннән шүрли идек, менә хәзер көтмәгәндә колхозны бәладән коткаручыларга әйләндек. Шушы хакта әллә кемнән түгел, бәлки иртәгә безне пыр туздырырга тиешле кеше авызыннан ишетү күңелне үстереп җибәрде. Батыр иде һәркайсыбыз шушы мәлдә, утка-суга керергә әзер иде. Күшсыннар гына! Бу кыюлыкны гамәлдә Бәдринең аркасында серәеп торган мылтыктан да алуыбыз ихтимал. Һәрхәлдә, Бүре оясына бернинди икеләнү-шикләнүсез барып кердек.

Мөнир иң артта минем белән янәшә килә иде. Кинәт аның тае, борчылып, колакларын кайчылады, сузып кешнәп куйды. Бераздан еректан икенче атның кешнәве ишетелде. Тай юлдан читкә ташланды, куаклар аша кайдадыр чабарга тотынды. Мөнир, кулындагы тышаулар бәйләме белән башына суккалап, аны туктатырга маташты, ләкин тыңлата алмады.

Отряд туктады. Мине сорауларга күмделәр.

— Кая чапты?

— Әллә кире Мостафага җилдердеме?

— Театрның азагын булса да карап кайтырга!..

Бәдри дә килеп җитте. Тайның сәер кыланышы хакында ишеткәч, мылтыгын тиз генә кулына алды.

— Тай инәсен танып кешнәгән. Һаман ияреп йөри бит колын шикелле. Атларны шушы тирәгә яшергәннәр, мөгаен.

Шушы фикерен раслагандай, һавага атты. Безнең ярсыган күңелләргә янә ялкын өстәлде. Уникe җайдак, сызгырып-кычкырышып, Мөнирнең тае алып качкан якка ташландык. Шәп тамаша булгандыр бу, чынлап та! Сызылып килгән таң нурларында коенып, ялангач үкчәләре белән ат кабыргаларына тибә-тибә, бер көтү малай колхоз бригадиры артыннан чаба. Тубыкларны сыдырып, кабырга-

ларга сугып калган куаклар дошман гаскәре булып та күренгәндер әле хәтта.

— Качалар! Әнә, качалар! — дип алдагылар сөрәнләшә башлады. Мин, муенымны авырттырганчы сузып, янякка карыйм, әмма берни күрә алмыйм. Шуңа слар чиккә житеп, атымны тезген очы белән каезларга тотындым һәм тиздән атлыларның иң уртасына барып кердем. Кайда тегеләр, дип өзлексез кабатлыйм. Җавап бирүче юк, соравымны аңламыйлар, күрәсең. Менә тирән төпкелгә житеп баручы атлылар төркеме күзгә чалынып калды. Хәзер алар уңга борылачак һәм куе агач үскән ерыннарга кереп югалачак. Шуннан эзлә аларны!.. Бәдри дә шул турыда уйлап алды бугай, ул тагы да һавага атты.

Каршы яктан да ату тавышлары ишетелде. Качаклар бер урынга барып өелештеләр, шуннан төрлесе төрле якка сибелде. Төпкелдән тагын атлылар атылып килеп чыкты.

— Болары тагы кем? Милиция килеп җиткән, ахры! — дип кычкырды Бәдри, шатланып.

Без барып җиткәндә, каракларның өчәүсен тотып бәйләгән иделәр инде. Аларны саклаучы милиционер, мылтыгын күтәреп, якын килмәскә кушты, ләкин Бәдри ишетмәмешкә салышты. Мылтыгын миңа тоттырып, атыннан төште дә тегеләргә табан берничә адым атлады.

— Нихәл, Йомабай. Тәки килеп каптың инде, ә? Качып, урлашып яшәп була димени!.. Бәй, Оркыя, син дә монда икән, танымый торам, — дип бригадирыбыз каракларның икенчесенә эндәште. Шунда гына без теге өчәүнең берсе ирләрчә киенгән хатын булуына игътибар иттек.

— Кабаттан бергә икәнсез, белмәгән идем.

— Бер йоклап ятканында өстенә дә барып чыккан идем. Юкка жәлләгәнмен, болай күрешергә туры килмәс иде! — дип Йомабай ачу белән аяк астына төкереп куйды.

Без, күргәннәргә исебез китеп, аңшаеп карап торуыбызны белдек. Менә нинди икән ул ата дезертир Йомабай! Ыспай киенгән, мыек кына калдырып кырынган, күзләре дә алан-йолан йөгерми, караган кешесенә тишәрдәй булып кадала. Оркыяны күр, Йомабайдан да серлерәк Оркыяны! Чибәрлекнең нәрсә икәнен аңлый башлаган чагыбыз бит инде, авыл халкының аны юкка мактап та, жәлләп тә сөйләмәвенә тәүге караудан ук ышандык, бугай. Өстендә күн бишмәт белән чалбар, башында галәмәт кенә казак эшләпәсе, аркасында ике юан толымы ята. Тагы да нык кымтылган бәләкәй авызы, зур күзләрен

каймалаган кара кашлары хәтердә калган. Шундый кешеләр, ә нәрсә кыланалар!

— Мөнирне тап китердегезме соң? — дип бригадир һаман сөйләнүен белде.— Ул да безнең белән бит, алдан чапкан иде.

Улының исемен ишетү белән, Оркыя алга омтыла биреп куйды. Без килгәннән бирле тәүге хәрәкәтләнүе иде шикелле. Йомабай аңа киокен генә нидер әйтте. Безгә арты белән торучы өченче карак, башын борып, көлеп куйды. Менә аны качкын дисәң дә ярый, ичмасам: тешләре коелып беткән, кыеш танаулы, чигәләрен куе шырт баскан, башында — йонтач малахай... Чибәрлек белән ямьсезлекнең шундый янәшәлеге кемнәр алдында торуыбызны янә дә искә төшерде.

Алар янына пар ат җигүле бричка килеп туктады. Кулга алынучыларны төрткәләп-типкәләп шунда утырттылар. Кинәт Оркыя чәбәләнә башлады: «Улым! Улым!» — дип кычкырып, арбадан сикереп төшәргә маташты. Янәнарында наган тотып утыручы сакчыларның берсе аны шыбашыннан тартып кире утыртты һәм олаучыга:

— Кузгал! — дип боерды.

Чаптырып чыгып та киттеләр. Мөнир шушы чакта безнең тирәгә якынлашып килгән икән. Караусыз калган атларны җыеп йөргәндерме, әллә таен тыңлата алмый соңлаганмы, әмма Оркыяның үзенә эндәшкәнен ишетергә өлгергән шикелле. Башка билгеләр буенча да тоемлап алуы мөмкин. Бричканы куып җитәргә ниятләп, чабарга тырышып карады. Тай шул якка уңайлый бирде дә, башкалардан, аерылырга җыенмавын аңлаткандай, кырт туктады. Мөнир аның башы аша җиргә мәтәлеп барып төште һәм чирәм тырный-тырный еларга керешге: «Әнкәй, әнкәем!..»

Малайларга әллә нәрсә булды. Әле генә үзләре карап торган аянычлы күренештән соң Мөнирнең килбәтсезлеге кызык тоелдымы, әллә каракның ана дип аталырга хакы юклыгын исбатларга теләделәрме? Бәлки, үксез ятимнең өйрәнмәгән иреннәре әлеге сүзне ипсезрәк тә әйткәндер... Кыскасы, көлешә башладылар. Мин дә ияреп көлдем. Шулчак Бәдринең җилле чыбыркысы аркама өченче тапкыр килеп кунды. Мылтыгы һаман минем кулда иде — аның төшеп киткәнен сизми дә калдым.

— Шундый вакытта көләләр димени! — дип кычкырды Бәдри. Миңа түгел, башкаларга карап, гүя миндәге сызлану шул сүзләр белән иптәшләремә дә күчәргә тиеш иде...

Хәзер уйлавымча, күчәдер дә ул...

РӘШИТ СОЛТАНГӘРӘЕВ

Рәшит Гыймран улы Солтангәрәев 1935 елда Башкортстанның Күмертау районы Таймас авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң китапханә мөдире һәм колхозның комсомол оешмасы секретаре булып эшли.

1958 елда Башкорт дәүләт университетын тәмамлый һәм журналист булып эшли башлый. 1966 елда партиягә кабул ителә. Мәскәүдәге Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Аның тәүге хикәяләр җыентыгы 1967 елда чыга.

Р. Солтангәрәев Башкортстан Язучылар союзы идарәсенең тәкъдиме буенча нефтьчеләр арасында эшли. Шул чорда язган «Җылы яңгыр», «Нефтьчеләр юлыннан» дигән китаплары республиканың Салават Юлаев исемендәге премиясенә лаек булды.

Әдип 1971 елда СССР Язучылар союзына кабул ителде. Хәзерге көндә ул «Туган йорт», «Ак тирәкләр», «Чәчкәләр бүләк итегез», «Ак умырзая», «Таш болан», «Тау», «Безнең дус», «Туган якка кайту» һәм башка китаплар авторы.

Р. Солтангәрәев — Башкортстанның атказанган культура работнигы.

ТУГАН ЯККА КАЙТУ

I

Эрнестның күршесе бу юлы да төенчекләр белән кайтты. Көн дә шулай әйбер ташый ул. Кичә бер генә төенчек иде, бүген икене тоткан. Челтәрләп үрелгән букчасының берсендә чүпрәк-чапрак әйберләр, бала-чага киемнәре, куян бүрек күренә, икенчесендә әфлисун, лимон, алма, калач, тагы әллә нинди ашамлыклар дыңкычлап тутырыл-

ган. Ул, кунакханә бүлмәсенә кергәч, дөрес кайттыммы дигәндәй, түрдә газета укып утырган Эрнестка карады да, сак кына басып, эчкәрәк үтте, кулындагы әйберләрен җыештырылган урынга ыргытты һәм, авыр эштән котылгандай, «уф-ф...» дип куйды. Чәче коелудан шактый ачылган маңгаен сыпырып алды, янә бүлмәдәш күршесенә карады, һаман да эндәшүче булмагач, кире ишек ягына китте.

Эрнест, газета укыган кеше булып, өстенә борынгы шинель шикелле озын пальто, аягына калушлы пима, башына, җил үткәрмәс күн бүрек кигән күршесен тын гына күзәтә иде. Алар дүртенче көн бергә яшиләр, шулай да күршесе һаман нидәндер тартына, уңайсызлана сымак. Таеп егылып куймыйм дигәндәй, сак кына йөри, Эрнест эндәшмичә, үзе башлап сүз катмый.

Ул, пальтосын салгач коридорга чыгып, өстендәге карын кагып алды, пималарын бер-берсенә суккалап, караваты янына утыртты, шуннан урынына барып ятты. Агач караватның сыгылма тимерләре, авыр йөктән ыңгырашкандай, шагыр-шыгыр килде.

Эрнестның ялгызына күңелсез, шуңа да күршесенең кайтуын көтебрәк ята иде. Бу кеше белән сөйләшүдән ул үзенә ниндидер рәхәтлек таба. Әле дә күршесен сөйләндерергә итә дә, тик сүзне нидән башларга белмирәк тора. Менә күршесе, шул яткан килеш, бер-ике хырылдап та алды, күрәсең йоклап китәргә чамалый.

— Ну, Әхмәтзәки дус, син бик хәстәрле кеше булып чыктың әле...— Эрнест тегеңә йокы бирмәскә булды.

Әхмәтзәки күршесенең нәрсәгә төрттергәнен аңлады, зур җәлпәк куллары белән әйберләрен каплап куйды да акрын, салмак кына итеп:

— Әй, бичәнең күңелен күрим дип тырышкан булам ла,— дип сукранды.

— Сезне бүген нык йончытканнар, ахрысы?

— Әй, бу киңәшмә дигәннәре корысын ла,— диде теге шул ук пошмас кыяфәт белән.— Аптыраттылар инде: сөйлиләр дә сөйлиләр. Ул кадәр хәбәр кайдан чыга, диең. Утыра торгач, очалар әчетеп бетә.

Эрнест, ниһаять, эзләгәнне таптым дигәндәй, калкына биреп ятты. Менә шундый сүзләрен ишетү өчен көтә дә ул күршесен. Киңәшмәгә дип килгән авыл кешесенең дөньяга карашларын шулай үзенчә гади, ихлас һәм тапкыр итеп әйтүе бу инженерга кызык тоела иде.

— Ә нәрсә сөйлиләр соң? — Эрнест торып ук утырды.

— Әй, аны кем тыңлаган да...

Эрнест рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Бәрәкәт,— дигән булды ул,— тыңламагач та нишләп утырасың анда? Юллык, көнлек акча биреп Уфага җибәргәннәр, акыллы сүз ишетеп кайтсын да тагы да шәбрәк эшләсен дигәннәрдер...

— Хәбәр тыңлап кына шәп эшләп булса...— Әхмәтзәки дә үзенчә төртмә телләнде.

— Ә кайткач, киңәшмә турында сөйләргә кушсалар, ни дисең инде?

— Соң, андагы сүзне отып бетәрлекмени, чыга да сөйлиләр, чыга да сөйлиләр, шомарып беткәннәр. Ул хәбәрләрне азак газетка язалар бит, шуннан укырлар.

— Газета бәләкәй, бөтен хәбәрне дә сыйдырып бетерә алмый.

— Язылганы җитә ул.— Әхмәтзәки үзенчә катгый һәм кире какмаслык итеп әйтеп куйды.

Тамаша бетте дигән сымак, Эрнест кире ятты, аны күреп, Әхмәтзәки дә башын яңадан мендәргә терәде.

— Бүген концертка алып бармадылармыни? — Эрнест сораша бирде.

— Юк, бер заводны күрсәткән булдылар. Кич әллә кая алып барабыз, диләр иде, барып тормадым. Опера күрсәтәләр диме шунда...

— Операны карамыйлар, тыңлыйлар,— диде Эрнест. Шуннан күршесенең бу сүзләренең мәгънәсен аңлап җитмәсен сизепме, икенчегә борды.— Операны яратып җитмисеңмени?

— Әй, бер караган булган идем дә, мәгънәсен тапмадым. Ата — улны, инә — кызны белми дигәндәй, болганып алалар да китәләр. Берсе — бер якка, икенчесе икенче якта кычкыра, хәс хуҗасыз мәҗлестәге сымак.

— Юк, Әхмәтзәки, операның хуҗасы була ул. Әнә бер кеше, халыкка арты белән басып, бәләкәй генә таягын селтәнләп торамы? Шул була инде операның хуҗасы! Дирижер, диләр аны.

— Анысын гына беләм лә мин.— Күршесенең үзен утә наданга санап ятуы Әхмәтзәкинең чәменә тисп куйды шикелле.— Тәүге көн театр куйган иделәр, анысы да әллә ни булмады. Клубы шәп, уеннары кызык түгел.

— Бәй, син ни... бөтен сәнгатьне кире кагып тик ятасың түгелме? — диде Эрнест бер киная белән.

— Гел әчке күрсәтәләр. Андые авылда да җитәрлек. Үзебезнең авылныкылар лутчы уйный. Шундый килештерәләр, рәхәтләнеп карап утырасың. Әнә, кичә концертка алып барган иделәр, вәт, ичмасам, шәп! Баянда да уйна-

дылар, курай да тарттылар. Бер кыз җырлады, үзе яшь кенә, ну, тавышы, малай! Кул чаба-чаба аптыратып бетердек. Биргән кешегә бирә бит тавышны. Шундыйларны тыңлыйсы килә, ичмасам, ә булыр-булмас көеңә кеше алдына чыгуы эш түгел.

Эрнест күршесенә сәнгатьтән ни ошаганын, ни ошамаганын башта ук аңлап алган иде инде, бу турыда башкача сөйләшмәскә булды, ә теге, шушы тәнәфестән файдаланып калыйм дигәндәй, хырылдап йоклап та китте.

Уфада авыл хуҗалыгы алдынгыларының киңәшмәсе бара. Эрнестның күршесе шул киңәшмәгә килгән. Колхозның малын карый икән, яхшы эшлисең дип җибәргәннәр, үзе әйтүенчә.

Дүртенче көн бер бүлмәдә яшиләр, әмма шуңача дусларча гына сөйләшеп утыра алганнары юк. Теге көн дә диярлек соңлап кайта, кайтса да — йә үзе кебек киңәшмәгә килүчеләр янына кереп утыра, йә инде керә дә караватына ауган уңаена йоклап та китә. Киеме дә, кыяфәте дә, сөйләшүе дә икенчерәк булган Эрнест янында үзен ятрак тоя шикелле.

Бер ягыннан мәшәкатьсез кеше инде, тик үтә иртә торып кына аптырата күршесен. Төн карасы агару түгел, урамда машиналар да кузгалыша башламый, ә ул торып йөрергә тотына. Бер керә, бер чыга, кирәге булмаса да юынып ала, кайдандыр кайнаган су табып, чәй пешереп эчеп ала. Шуннан, аптыраштан, ахрысы, янә ята.

— Йокы бирмисең,— дип Эрнест икенче көнендә үк сукранып алды.

— Уяндыра да куя бит,— дигән булды Әхмәтзәки, уңайсызланып кына.

— Уянсаң да ят! Монда бит сиңа ферма түгел. Киңәшмәгез сәгать унда башлана, тугызда торсаң да өлгерерсең. Әйдә, әлеккәндә йоклап кал!

— Тугызга кадәр йоклап була димени? — Шулай диде Әхмәтзәки, әмма бу сөйләшүдән соң тәртипкә күнде, әлбәттә, ул өйрәнгән вакытында уяна-уянуын, мәгәр кузгалмый ята, тик караңгыда бых-бых итеп тын алуы, авыр гына көрсенеп куюы ишетелә. Иртә торуны да гаеп эш санаган кала тормышына эчтән генә сукрана, бугай. Шушы көннән соң ул Эрнестка «сез», «агай» дип эндәшә башлады.

Эрнестка күршесе бераз җол дә булып куйды. Үзеннән байтакка өлкән күренгән колхозчыга ихтирамлырак, ке-

челеклерәк булырга тырышып карый да, әмма мәзәкләп эндәшүен ташлый алмый.

Әхмәтзәки үзе дә күршесенең, аны наданрак кешегә санап, кимсетебрәк сөйләшүен аңлый, әмма моңа үпкәләми. Шәһәрнең укымышлы адәме үзен шулай югарырак куярга тиештер, дип уйлый, бугай. Хәтта зур җирдә укыган инженер белән бергә торуына, бергә иптәшләрчә сөйләшеп алуына эчтән генә әллә кем булып та куя.

Күршесенә Эрнест та өйрәнеп алды. Ул кайтмаса ашарга да, телевизор карарга да бармый, тегене күтенкерәп тора. Әлбәттә, аның Әхмәтзәкине якын күрүе дә үзенчә, сәеррәк. Кайсыдыр ерак авылдан килгән бу көтүче ана адәм кулы тимәгән урманда исән калган бердәнбер затлы агач, йә шул урманда өненнән яңа торып чыккан аю кебек тә күренеп куя. Эрнестның, әлбәттә, авыл халкы белән аралашканы, эш иткәне бар, хәзер анда да күпләрне каланыкыннан аера алмассың, ә бу икенчерәк, ничектер, дөньяның җил-яңгыры нык тимәгән сымак. «Мал арасында йөреп, холкы да малныкына охшап беткәндер. Тәртәгә җигелгән ат шикелле, кушканны гына эшләп тик йөридер, ә җитәкчеләр андыйны ярата»,— дип уйлый Эрнест.

Күршесенең шушы фикерләрен расларга теләгәндәй, Әхмәтзәки, тач чалкан яткан килеш, бүлмәне күтәреп чыккыдай итеп хырылдый. Әйдә йоклап алсын, чынлап та йончыган, бугай. Хәбәр тыңлап утырып өйрәнмәгән кешегә бу киңәшмә дигәннәре эштән дә авыррактыр. Эрнест, аны уятырга жәлләп, коридорга чыгып әйләнде.

Шулай йөри торгач, ул Әхмәтзәкинең пинжәге кесәсеннән яртылаш күренеп яткан тартманы шәйләп алды. Тартма матур, кызыл бәрхет белән тышланган, кыскасы, ниндидер затлы, серле әйбер икәне әллә кайдан кычкырып тора.

Күршесенең үпкәләмәсен белгән Эрнест тартынусызнисез тартманы алып карарга булды, әмма ничек кенә сак кыланмасын, шәһәргә килгән авыл кешесе шунда ук каты тупас бармаклары белән Эрнестның кулын эләктереп алды, битараф карашын Эрнестка төбәде. Моның гөнаһсыз яшькелт күзләренә, кыска ямьшек борынына карап, Эрнест эчтән генә: «Торганы Швейк»,— дип куйды.

Әхмәтзәки эндәшми генә тартманы кире кесәсенә тыкты:

— Сәгать ничә ул?

— Кәтү китте инде,— дип шаяртты Эрнест.— Кесәңә төшәргә иткән идем дә, сизгер икәнсең. Әллә бик җилле нәрсә бүләк иткәннәр инде үзеңә?

— Әй, медаль биргән булган иделәр лә...— Әхмәтзәки авызын зур ачып иснәп алды да, сез исәнме әле дигән шикелле, баягы әйберләрен капшап куйды.

— Медаль?! — Эрнест кычкырып ук җибәрде. Әлбәттә, алдынгы мал караучының киңәшмәгә килеп, медаль алып йөрүе гаҗәп эш түгел түгелен, тик аның шушы хакта, магазиннан сатып алган әйбер турында сөйләгән шикелле исе китми генә әйтеп утыруы мәзәк күренде.

— Кая, нинди медаль?

— Әй, шул яхшы эшләгән өчен, дигән булганнар инде...

Эрнест күршесенә карады. Тегенең, «булганнар», «шулай да, болай да» дип, һәр нәрсәне үзенчә бераз кимсеткән кебек сөйләп утыруы аеруча мәзәк иде. Эрнест, сорапнитеп тормый, тартманы ачып, медальне алды:

— «За трудовую доблесть»,— дип укыды ул.— Җилле медаль эләктергәнсең бит! Аны сиңа кесәгә салыр өчен бирделәрмени! Тагып кайтырга кирәк иде!

— Кеше көлдереп...— диде Әхмәтзәки.

— Бәрәкәт! Медальдән көләләрдер шул!

— Медальдән көлмәсәләр ни, таккан кешесеннән көләләр,— Әхмәтзәкинең һәр нәрсәгә катгый карашы бар һәм моны тиз генә үзгәртерлек түгел иде.

Эрнест тегеңә бераз тын гына карап утырды да яңадан башлады:

— Вәт, әй, күрше, эндәшмисең дә! Юдырудан курыккансыңдыр инде. Юк, болай гына котыла алмассың, әйдә, киттек! Кара, мин сине шундый кешедер дип уйламаган идем! — Эрнест юрамал үпкә белдергән булды. Ул шаярып әйтсә дә, беркатлы кеше чынга алды, урыныннан торып ук утырды.

— Аннан курыккан юк та,— диде.— Нәрсә, ысталуайга барабызмы?

— «Ысталауай»да хәзер эчермиләр, тотып алып китәләр. Барсак, ресторанга инде. Вак нәрсә түгел бит, исеменне ташка басып, Указ чыгарганнар!

Бу сүзләр Әхмәтзәкигә бөтенләй нык тиде шикелле, пимасын тартып китерде.

— Тик менә син пима кигәнсең бит әле. Нишлибез?

— Нигә, әллә ресторанга чүчинкә белән кертмәгән булалармы? — Әхмәтзәки дә үзенчә эре генә эндәште.

— «Чүчинкә»...— Эрнест янә рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Күптән онытылган сүзләрне ишетүдән аңа рәхәт иде.—

Кеше шәһәргә чүчинкә киеп киләмени? Киңәшмәдә дә шул чүчинкәң белән йөрдеңме?

— Нигә, бик ипле нәрсә ул чүчинкә дигәнең,— диде Әхмәтзәки.— Монда белеп буламыни, әле генә катырып җибәрә, әле генә җепшетә, ә бу кайсылай да ятеш. Киңәшмәдә ни минем кебек пималы кешеләр дә бар иде. Ай алла, ресторанына кертмәсәләр, искиткән юк, бер ярты алабыз да... Анда кереп, тамак туямы! Акчасын алалар каерып, ач чыгып китәсең. Аз гына утырдыңмы, теге нәрсәләрен доңгырдатырга тотыналар.

— Кара әле, әйдә, медалеңне так та, мин алдынгы малчы, киңәшмәгә килдем, дип әйт, мөгаен, кертерләр.

Әмма көтүченең, ресторанга керәм дип, медален күрсәтеп вакланып йөрисе килмәде, кул гына селтәп куйды. Бераз уйлашкач, Эрнест аңа үзенең җәйге ботинкасын биреп торырга булды. Әмма фырт егет шикелле ялтыр туфли мал караучының аягына якын да килмәде.

— Аяк та бар икән үзеңдә! — Эрнест, эзләнә торгач, зуррак ботинка тартып чыгарды.

— Әллә сез бу гостиницада дөнья көтеп торасыз инде?

— Тормыш булгач, бардыр инде. Мин эшкә яңарак килдем, квартира алып өлгермәдем. Кара әле, Әхмәтзәки дус, син нигә алай миңа «сез» дип эндәшәсең. Җитмәсә, «агай» дип тә җибәрәсең. Үзебез ничә көн бергә яшәп ятабыз.

— Сез бит зур кеше,— диде Әхмәтзәки, ышанычлы итеп.

— Зур... Сиңа ничә яшь соң әле?

— Кырыкка җитеп киләм.

— Ә мин җитәргә уйламыйм да.

— Мин бит яшькә карап әйтмим. Сез бит укыган кеше.

— Укыган икәнен кайдан беләсең? — Эрнест канәгать төс белән ирәеп, елмаеп җибәрде. Әлегәчә күршесенә үзенең кем икәнен дә, кайда эшләвен дә әйткәне, ә тегенең сораганы да юк иде.

— Анысын гына белеп була,— диде мал караучы.

Шуның белән сүзне бетерделәр. Әхмәтзәки кыенсынып кына йон оекбашын салды да аягын тегенең ботинкасына тыкты. Әлеге озын пальтосын, күн бүреген киеп алгач, ямьшек торба шикелле бөтәрләнеп беткән чалбар балакларына, ят туфлигә карап торды да монда мине кем белә дигән кыяфәт белән ишеккә атлады.

...Юллары уңмады аларның. Урамга чыгып, бер-ике адым да бара алмадылар. Әхмәтзәки кинәт киселгән агач

шикелле, гөрселдәп тротуарга барып төште. Үзе — бер якка, кәпәче икенче якка очты.

— Һай, атаң башы...— Әхмәтзәки, куллары белән ипсез генә таянып, аягына торып басты.

— Нәрсә, Уфа белән исәнләштеңме? — диде Эрнест. Әхмәтзәки, аның ни әйтергә теләгәнен аңламыйча, күзен тоздай итеп тора бирде.

— Наполеон, үз гаскәрләре белән Мисырга килеп төшкәч, менә синең шикелле абынып егылып киткән, ди. Әмма ул синнән арттырган, «һай, атаң башы» дип сукранмаган, сүгенеп тормаган, абынуын белдермәс өчен: «Саумы, Мисыр!» — дип кычкырган, ди. Янәсе дә, ил белән исәнләшә.

— Мин абынмадым да ул... Ботинканың табаны шома икән. Чүчинкә белән ничә көн йөредем, бер дә егылмадым.

Эрнест, моның белән ресторанга барсаң да инде дигәндәй, шым гына карап тора:

— Әллә кермибезме?

— Әйдә соң!

— Әй яхшы кешесең дә инде. Ни әйтсәң дә — ризасың.

— Эрнест агай, әйдә, мин әйткәнчә, магазинга барып, берәр шешә алыйк та... Ашарга бар, бүген тегендә каклаган колбаса саткан иделәр. Чәй кайнатып эчәрбез, лампасый да бар.

— Нәрсә-нәрсә бар дисең? — Эрнест моның мәзәк сүзләренең чиге юк, ахрысы, дигән төсле, елмаеп, тегеңә карады.

— Лампасый...— Ну, кәнфит инде. Бәләкәй чактан өйрәнелгән дә, шулай тик йөреләә. Элек кәнфитне шулай дип әйтәләр иде бит.

— Лампасый икән — лампасый. Әйдә, ләкин өстеңне как!

Алар урам буйлап киттеләр. Эрнест алдан, Әхмәтзәки, пальто чабуларын ялпылдатып, ике-өч адым арттан килә, Эрнест аны көтеп алды да:

— Шәбрәк атла! — диде.

— Ярар, монда танышларыгыз күп очрый, кем белән китеп бара икән бу, дип аптырарлар.

Әхмәтзәки нәрсәгәдер төрттердеме, әллә ихлас күңелдән әйттеме, һәрхәлдә, Эрнестка кыен булып куйды. Юлдашы белән китте. Күңелен күрер өчен:

— Өеңә кайткач, монда йөрегәннәреңне бер мәзәк итеп сөйләп утырырсың әле,— диде.

— Әй, надаел инде. Бер ел яшәгәннән артык күренә башлады.

— Авылың әллә кайда качмас. Хәзер шулай тоелса да, кайткач исеңә төшерерсең әле. Кайчан китәргә?

— Бүген лә ул. Тик поезды бик соң кузгала, төнге бердә генә. Шуңача вакытны ничек үткәрергә, дип аптыраган баш.

— Бәрәкәт, мин дә төнге бердә китәм бит! Кайсы поездга утырасың?

Сөйләшә торгач, алар икесе дә бер поездда, бер үк станциядә, хәтта бер колхозга диярлек бара булып чыктылар. Җәй җиткәч Әхмәтзәкиләрдән ерак түгел Кужанак елгасында зур буа буарга тиешләр икән. «Гипромелиоводстрой» оешмасының инженеры Эрнест шул төзелеш эшләре буенча бара. Бу хәбәрне ишеткәч, Әхмәтзәки дә үзгәреп китте:

— Шулай сөйлиләр иде шул! Әйдә, алай булгач, алып барам үзеңне! — диде ул эре генә кыяфәт белән. Хәзер ул Эрнестны үз арбасына утырган кеше сымаграк тоя иде, бугай.

II

Поезд станциягә иртән соңламыйча, үз вакытында килеп җитте. Әллә ни ашыгыр эше булмаса да, Әхмәтзәки, төенчекләрен алып, тамбурга чыгып торган иде. Поезд тукталу белән, беренче булып җиргә сикерде дә, әйберләрен читкәрәк куеп, составның койрык ягына карап басты.

Алар бер вагонга эләгә алмадылар. Әхмәтзәкигә билетны кисәшмәдә үк бирделәр, ә Эрнест вокзалга төшкәч кенә алды. Вагонга утыргач та, бер-берсенең хәлен белешергә туры килмәде. Әхмәтзәки ятып торган иде, йоклаган да киткән, ә иртән кешене бимазалап тормады, шәһәр кешесе озак йокларга ярата, дип уйлады. Менә хәзер инде юлдашын алып кайту, йә озатып куюны үзенең бурычы дип исәпли.

Ул Эрнестны әллә кайдан танып алды. Өстенә кыска көрән тун, башына колаксыз бүрек, кулына тактадан юнып эшләгәндәй дүрткел портфель тоткан бу тәбәнәк адәм авыл кешеләре арасында, бодай өстенә төшкән борчактай, әллә кайдан аерылып тора. Әхмәтзәки дөнья яңгыратып сөрәнләп җибәрде:

— Һай, Эрни-ис! Шаккатканга юл бу якта! Әйдә! — Станциягә килеп төшү белән үк, ул кичәге «сез», «агай» дигән сүзләрне оныткан иде инде.

— Нихәл, йокы туйдымы? — Әхмәтзәки эре генә елмаеп кулын сузды.— Адаштыңмы әллә? Монда сиңа Уфа түгел! — дип шаяртты. Ни дисәң дә, монда ул хуҗа, ә Эрнест шушы мәлдән алып — килгән кеше.

— Каршы алырга тиешләр иде, шуларны карыйм.— Эрнест та, үз хәлен аңлагандай, басынкы гына әйтте.

— Әйдә, мин аларның шоферын таныйм.— Әхмәтзәкинең кәеф шәп. Кычкырып сөйләнеп килә, шуннан: «Әй, нихәл, нишләп йөреп ятасың монда?» — дип, иренмичә төенчекләрен куеп, әллә кемнәр белән күрешеп, исәнләшеп китә. Тегеләр сорамаса да, үзенең Уфадан, киңәшмәдән кайтып килүен әйтеп куя. «Менә бу инженерны ияртеп җибәрделәр»,— дип тә җибәрә.

Шулай тавышланып бара торгач, кемдер аңа:

— Әнә, улың килгән каршы алырга, ашханә янында тора! — дип сөрәнләде. Моны ишеткәч, Әхмәтзәкиең тагы да ныграк үзгәреп китте. «Ат бар, әйдә, киттек безгә!» — дип юлдашын янә үгетләде. Эрнест ризалашмады, бүген үк эшлисе эшләр бар колхозда, каршы алырга тиешләр мине, диде. Күндерердәй күренмәгәч, Әхмәтзәки, җәй эш башлангач, үзе барып алырга вәгъдә биреп, тегеңә үзенең каты кулын сузды, аркасыннан кагып алды. Ул инде хәзер чит якта йөргән Әхмәтзәки түгел, ә туган ягына кайтып төшкән кеше.

Әхмәтзәки, малаен табып, чанасына әйберләрен ыргытты, арлы-бирле хәл-әхвәл сорашты да шуннан, тагы кемне тап китерермен икән дигәндәй, бераз каранып торгач, чәй эчеп, җылынып чыгам дип, ашханәгә кереп китте. Дөресен әйткәндә, аңа чәй эчеп җылынып алудан бигрәк, ашханә тирәсендә якташларын очрату, үзенең олы юлдан кайтып килүен күрсәтү, шәһәр хәлләрен сөйләп алу кирәк.

Ул, йомышларын бетереп, ашханәдән чыкканда, вокзал алдындагы халык таралышып беткән, тик Эрнест кына берүзе колга шикелле сераеп тора иде.

— Бәй, син һаман мондамыни әле? — Әхмәтзәки тегенең китә алмый торуына куанды гына.

— Нишләптер машина күренми. Әллә бер-беребезне танымый аймылыш булып куйдык,— диде теге пошынып кына.

— Син, туганкай, һәрбер әйткән сүзгә ышанып барма алай! Әйткән дә онытканнардыр, йә шоферы киреләнгәндер, йә башка берәр эш килеп чыккандыр. Телефон сүзе — телефон сүзе бит инде! — диде Әхмәтзәки, бер ма-

лайга нотык укыган сымак.— Әйдә, утыр минем чанага! Ходай үзе шулай кушкандыр.

— Миңа ничек тә колхозга барып җитәргә иде бит әле. Районда да эш бар.

— Соң, җитәргә кирәк, дип җәяү чыгып китмәссең бит инде? Башта безгә сугылыйк, шуннан күз күрер. Ул колхоз бездән ерак түгел, берәр әмәлен табарбыз! Үз эшең белән йөрмисең бит! — Әхмәтзәки шундый итеп әйтте, теге, малай шикелле, шым гына моның артыннан ияреп китте.

Хуҗа кеше Эрнестка чанасында яткан толыпны алып сузды. Әйдә, син өшүчән адәмгә охшагансың, ә мин түзәрмен дип әйтергә уйлады шикелле. Әмма тегенең дә сер бирәсе килмәде:

— Ярар, ярар, бирешмәм,— дигән булды.

Әхмәтзәки, урын җәйгән хатын шикелле, чанадагы печәнне суккалап кабартып, чыптасын җайлабрак түшәде, бияләен салып ук ыргытты да, кулын төкреклэп, дилбегәне алды. Ул нindидер ләззәтле эш эшләргә җыенган кешегә охшый иде.

— Әйдә, иплэп утырыгыз, очып калырлык булмасын. Бу сиңа трамвай түгел! — дип фәрман бирде ул.— Һоппа, чаптар бия! Әйдә, Әхмәтзәки агаеңны очырт әле!

Хуҗасы шикелле үк, кайту ягына атлыгып торган чаптар, фәрманны ишетү белән, алга ыргылды. Биткә ат җиле, кар тузаны бәрелде.

Чанада бару Эрнестка кызык та, сәер дә бугай, ә Әхмәтзәкигә олы кинәнеч. Ул, ниһаять, үзен читлектән чыгып, күккә чөелгән кош шикелле тоя. Машина, тракторфәлән бозгалаган юлдан чыгып, чын чана юлына төшүләре булды, ул, үзеннән башка кешеләр барлыгын да оныткандай, сузып җырлап та җибәрде:

Һай, яшел генә чанай, зәңгәр дугау-у...

Мал караучының тавыш та, моң да юк, мәгәр кәеф шәп, шуңа җырлый һәм әле үзе Уфада концертта тыңлаган җырчылардан арттырыбрак җибәрә сымак иде. Җырлап бетергәч, ул үз моңына үзе бераз рухланып барды да малаеның аркасыннан кагып алды:

— Шуннан, улым, дөньялар иминме? Минем кайтырны кайдан белдегез әле?

— Колхоздан әйттеләр...— дип быгырдады малай.

— Колхоздан??! Ну-у! Шулайдыр дип уйлаган идем дә! Карале, Эрнис, мин дә хәтәр кеше, ә! Кайчан кайтырны

белеп каршы алып торалар — Гагарин киләмени! — Шулай, ат җибәреп, үзен поездлан каршы алып торулары Әхмәтзәкигә бик зур мәртәбә күренде шикелле. Һәм әле ул печән чанасында чаптар биягә утырып кайтып баруын унарлаган затлы машиналар, мотоциклар озатуында китеп барган космонавттан бер дә ким күрми иде.

Эрнест кенә бөкрәеп артка карап утырып алган да тавыш-тынсыз килә. Бер авыз сүз дә әйткәне юк, каршы алмауларына эче пошамы икән? Ярый, барып җитәр. «Дөнья күрмәгән кешегә охшаган, рәзе шул кием белән юлга чыгалар, кыш көнендә,— дип уйлый Әхмәтзәки.— Аяккынасына бичәләрнеке шикелле итек кигән булган. Сыйраклары да нәзек кенә икән».

Әхмәтзәкинең сөйләшеп барасы килә. Түзмәде, янә артына борылды:

— Карале, Эрнис, нигә алай «Эрнис» дип әллә нинди ят исем кушканнар ул? — Ул күршесен үзенчә мәзәкләп алды.

— Шундый исемле бер революционер булган, антифашист...— Эрнест житди җавап бирде.

— Ә теге немецмы? Беләм...— Әхмәтзәки күрше авылдагы танышын исенә төшергән сымак кына әйтеп куйды.— Значит, әтиеңнәр укымышлы кешеләр булган инде...

— Нигә? — Эрнест сәерсенеп сорап куйды.

— Әллә кайдагы немец исемен кушканнар бит. Шулай да немецлар малайларын «Әхмәтзәки» дип атамыйлардыр әле?

— Атамыйлардыр...

— Барыбер үз исемеңә җитми,— дип фәлсәфә итте малчы. Ул юлдашының авызы бөрешеп, сөйләшер-сөйләшмәс кенә килүен тоеп, атын туктатты:

— Әйдә әле, толыпны киеп ал, туганкай! Кәләш алырга китеп бармыйсың ла! Салкын эләктерсәң, булыр аннан соң...

Эрнест чынлап та өшегән иде, күрәсең, эндәшми генә толыпны алып киде. Ә Әхмәтзәки дөнья шулай ул дигән шикелле генә карап алды да чыбыркысын селтәде:

— Һоп-ла!

Кәеф шәп аның! Әнә, Уфасы да, биек йортлары да, театрлары да, андагы тәкәббер кешеләр дә әллә кайда ятты да калды, ә ул кайтып бара. Чаптар бия, тоягы белән кар тузаны чәчрәтеп, гырш-гырш юырта, тимер чана үз көен көйли. Аның уңаена Әхмәтзәки дә эчтән генә җырлап бара:

Кайтаем илләремә,
Әллә ниләр булыр кебек
Минем күңелләремә...

Әхмәтзәки уе белән күптән авылына җитеп килә инде. Ул чанасында җилдерми, ә оча гына. Бишектәге шикелле тирбәлә-тирбәлә оча. Тирә-як ап-ак дала. Дала гынамы, бар булганы шулай акка манчылган.

Ул бара да бара, ә дөньясы шундый иркен, киң.

Һы, гаҗәп, тора-бара бөтенесе дә: чаптар биясе дә, маяк кадалган юлы да, карга күмелеп утырган эскертләр дә, биек-биек убалар да шушы ак томанга кушылып эреде, әллә кайда юк булды да куйды. Ап-ак дөньяда Әхмәтзәки үзе генә торып калды.

Юк, үзе генә түгел, алда бер туп та бар икән. Туп шундый зур, чикләре дә күренми, ә үзе зәп-зәңгәр. Зәп-зәнгәр һәм шоп-шома. Тик бер урынында гына базлап ут балкый. Ут торган саен якынайганнан-якыная, зурайганнан-зурая бара. Уфада гына түгел, Әхмәтзәкинең бөтен гомере буе кичергәннәре дә, поезд тәрәзәсеннән ялтлап калган күренешләр шикелле, әллә кайда ятты да калды, хәзер җиһанда Әхмәтзәки үзе һәм шушы базлаган ут кына торып калды.

...Бу якын урын — аның авылы, йорты, гаиләсе. Әлеге зәңгәр шарда шул урын гына базлап яна, аңа якынайган саен, Әхмәтзәки үзе дә зурая, үсә, һәм, әкияттәге җир өстендә пәйда булган гыйфрит шикелле, күккә аша бара сымак иде.

Бераздан алар Сарыбия тавына җиттеләр. Чаптар атлап кына бара башлады. Әхмәтзәки эчтән генә: «Менә сиңа чүчинкә...» — дип юлдашын үчекләп алды да чанасыннан төште.

— Әйдә, туганкай, бераз җәяүләп алыйк. Аягың өшегәндер.

— Бераз бар...

— Бая ук әйтми ни! Җәяүләсәң, җылындырып китә ул.— Әхмәтзәки, кардан ясалган кешедәй, үзенең кырт та итми баруын моның алдында яман зур өстенлек итеп саный.

Эрнест чанадан төшүе булды, толыбының чабуына басып, йөзтүбән тәгәрәп китте. Әхмәтзәки торырга ярдәмләште дә:

— «Саумы, Мисыр!» — дип әйткән дисеңме әле теге Наполеон? — диде. Ул моны тәрттерүдән түгел, кичә үзенең дә шулай егылып китүен исенә төшергәнгә генә әйтте. Эрнест эндәшмәде.

— Озакламый бер авылга житәбез, туктап жылыныи чыгарбыз,— диде Әхмәтзәки.

— Кирәкмәс, түзәрмен.

Тауны да кичтеләр. Хужа дилбегәсен малаена тоттырды да юлдашы янынарак килеп утырды:

— Шәп бит безнең яклар, ә?

— Иркен яклар...— Бер офыктан икенчесенәчә тип-тигез кар чүллегеннән башка берни күрмәгән ят кеше шуннан артыкны әйтә алмады, ә атлыгып кайтып килгән малчыга бу житә калды:

— Һи-и, син аны жәй күрсәң икән! — дип кычкырып жибәрде.— Сәхрә! Кайбер якларда мал котәргә урын юк, ә бездә ялан тутырып йөриләр. Менә жәй күрерсең әле.— Әлбәттә, көтүче кешегә шундый даладан да шәбрәк як юк инде. Ул янә дилбсгәсен үзе алды:— Кая, бир әле, әллә кем бахыр шикелле, атыңны да тота алмый барасың!

Озакламый Әхмәтзәки әйткән авыл да күренде. Очка житәр-житмәстән, хужа кеше атын туктатты. Кесәсеннән теге бәрхет тышлы кызыл тартманы чыгарды:

— Энем, син шуны матурлап кына түшкә када әле! Үзең әйтмешли, тагып кайтыйм.— Әхмәтзәки моны да басынкысызлыкка санамады. Медаль белән Уфаны аптырата алмассың, ә авылда ялтлап торачак. Әлбәттә, көн дә тагып йөрмәс, ә кайтып кергән уңаена купаеп алу язык эш түгел.

— Килеп життекме инде?

— Юк әле, тагы биш чакрым кала. Бажаларга сугылып китәбез. Бераз жылынып алырга кирәк.— Әхмәтзәки дилбегәсен кабат малаена тоттырды. Кучер белән кайтып килә, янәсе дә.— Миңнегужа бабаеңнарга борыл!

Эрнест эндәшеп тормады. Әхмәтзәкине ниятеннән кире чиктереп булмасын аңлый иде. Чаптар бия бер йортның капка алдына килеп туктады.

— Тр-р!..— Әхмәтзәки бар тавышына сөрәнләп жибәрде. Янәсе дә, әнә кем килеп төшкән! Ишегалдында кешефәләң күренмәгәч, чанасыннан төште дә, шалтыратып, араталы капканы ачып жибәрде.— Тр-р!

Ишеттеләр бугай, өйдән күлмәкчән генә көенчә бер ир белән хатын килеп чыкты.

— Нәрсә, әллә һаман йоклап ятасызмы?! — дип кычкырган булды юлаучы.— Бажаң килгәндә капкаңны шар ачып торырга кирәк, ә сез утырасыз! Минем кайтырны ишетмәдегезмени? — Әхмәтзәки уенлы-чынлы шаярган булды. Дүрт көн буена чит жирдә басылып яшәү мал карау-

чыны шулкадәр изгән, ахрысы, хәзер инде ул үзен бөтен дөньяга баш кешедәй тоеп йөри иде.

Хуҗалар йөгерә килеп күрештеләр дә хәл-әхвәл сорашып алдылар.

— Бүген кайта дип ишеткән идек тә ишетүен,— диде баҗасы,— әллә сугыла, әллә юк, дип тора идек.

— Сугыламы-юкмы, аш-суың әзер булырга тиеш!

— Аш кайнап утыра... Мактап киләсез,— диде каенбикә кеше.

— Без шулай йөрербез ул! Бәлки, сугылып та тормас идек, менә кеше алып кайтып киләм. Уфадан. Юка чыккан юлга, җылынып китик, дидем. Монда синә шәһәр урамы түгел шул.— Әхмәтзәки эре генә кыяфәт белән Эрнест ягына карап алды.— Гидроэлектростанциядән, Кужанак елгасын буарга чамалыйлар икән.— Әхмәтзәки үзе кичә генә ишеткән «Гипромелиоводстрой» сүзен отып өлгерә алмаган иде. Ә туганнары, үз колакларына үзләре ышанмагандай, тын калып, бер Әхмәтзәкигә, бер толыбын салбыратып торган теге ят адәмгә каранды.

Киңәшмәдән кайтып килүче баҗа тиешле кешегә, атын туарып тормыйча, аркалыгын гына бушатып, алдына печән салырга кушты:

— Озаклап утырырга форсат юк, менә энекәш ашыга. Әйдә, Эрнест! — Ул ишекне шар ачып башта үзе кереп китте, юлдашына артыннан ияреpгә кушты.

Хуҗалар, кызмача кешегә ошаңкырап киткән туганнарына кайсылай ярарга белмәгәндәй, тирәсендә уралана, ни дисәң дә, әллә кайларда йөреп, әллә кемнәрне күреп кайтып килгән кеше ләбаса. Ә теге аның саен тәкәбберрәк җибәрә. Бераз тын алгандай булгач, каенбикәсе белән баҗасы, әйбәт кенә йөреп кайттыңмы, дип иркенләбрәк сорашып алды.

— Бәй, әйбәт йөрми әллә, безне кем дип беләсез ул кадәр! Селкеттек инде Уфасын дүрт көн буена! Аларны бер утырып иркенләп сөйләмәсәң, кинәт кенә очына-башына чыгарлык түгел. Йөртмәгән җир, күрсәтмәгән урын калдырмадылар. Заводы да, театры да...

— Анда ни сезне бушка гына ашатып йөртәләр, ди, түгелме соң? — диде каенбикәсе.

— Бушка булмый ни, бәй, шулкадәр җирдән үзләре чакырып китерсеннәр дә! Күзең акайганчы сыйлыйлар инде,— дип алдашты теге.

Сүзгә мавыгып, хуҗаларның Әхмәтзәкинең күкрәгендә ялтлаган медаленә күз салырга һаман акыллары җитми, ә моның җаны көя. Ахырда түзмәде:

— Әнә, медаль тагып кайтарган булдылар,— диде.

— Шулаймыни әле! Кая, котлыйк үзеңне!

— Как же, без ни ул, үзегез беләсез, төшеп калганнардан түгел! Туктагыз әле, монауларга күчтәнәч бирим. Ул төенчекләрен чишеп җибәрде.

Баядан бирле кунакның төенчекләреннән күзен алмый утырган малайлар, авыз-борыннарын буяп, әфлисун ашарга тотынды, ә хуҗалар, моның күңеле булсын дипме инде, медальне мактый.

— Кайсылай матур, яңа гына сукканнар, ахрысы. Ялтлап тора.

— Төп хуҗа үз кулы белән тапшырды! — диде Әхмәтзәки.

— Министрмы әллә?!

— Юк, нишләп министр гына булсын, тегендә аннан зурраклары да бар. Төп хуҗа үзе инде. Башкортстанның башлыгы! — Әхмәтзәки беренче секретарьның исемен әйтте.

— Шулай укмыни? Үзе тапшырдымы?

— Кулны кысты да, яхшырак эшләсәң, орден да бирербез,— диде.— Әхмәтзәки монысын да алдады. Эрнест, кем тапшырды бүләкләрне, дип сорагач, әй, аларны кайдан белеп бетерәсең дә, дип исемен дә әйтә алмый иде, әле шыттыра бирә. Тегеләр ышана, бугай, ә Эрнест, күршесенең шулай үзгәреп китүен кызык күреп, шым гына утыра.

Аш-су китереп куйдылар. Әхмәтзәки Эрнестка өстәлгә якынрак утырырга кушты:

— Әйдә, энем, бер туйганчы ит ашыйк әле! Уфагызның ашы корысын. Ашыйсың, ашыйсың, эч таша, тамак туймый. Чәе юынтык су кебек,— дип ул, үзе дә сизмәстән, әле генә мактаган җирләрен яманлап ташлады.

Әхмәтзәкинең күңеле булды шикелле инде: баҗасына сугылды, Уфа хәлләрен сөйләде, кеше алып кайтып килүен дә күрсәтте, хәзер инде артабангы турында уйларга кирәк. Ул, тамакны ныгытып, кинәнгәнче авыл чәе эчкәч, кыштырдык тышлы матур кап чыгарып, сигарет алды да кабызып җибәрде. Мондый ят сигаретны киңәшмәдә саттылар. Әхмәтзәки үзе юньләп тартмый, тик, кайткач, фермада, егетләр алдында, әллә кем булып тотатеп тору өчен генә алган иде.

— Ярар, баҗа, рәхмәт якты йөзегез өчен! — дигән булды ул.— Өйрәледә — бер көн, боткалыда — ике көн дигәндәй, без ары киттек.

— Адәмгә санап кергәнегез өчен үзегезгә рәхмәт,— диделәр баҗасы белән каенбикәсе. Монысын алар әдәп өчен

генә әйтте, ә ярсып алган малчы чынга кабул итте:

— Бәй, адәмгә санамый ни, киңәшмәдән кайттым дигәч тә... Бергә яшәгән кешеләребез дә инде,— диде ул.— Ярар, үзебезгә кайтыйк әле, туганкай. Син алай ашыкма инде, бүген барыбер артык әллә ни кыра алмассың, кунак булып китәрсең.

— Агай, бер дә вакыт юк бит әле. Бүген председательне күрергә дә иртәгә районга китәргә иде.— Эрнест үзе кичә генә кимсетебрәк утырган бу кешегә «агай» дигәнен сизми дә калды.

— Вакыт, әнә тегендә киткәч, күп була ул...— диде Әхмәтзәки белдекле төс белән.— Эшне аны берәү дә бетереп үлмәгән. Әхмәтзәки дигән агайларга төшкән идем, дип, инженер иптәшләреңә сөйләрсең бер... Мунча ягып җибәрербез, кеше җыярбыз. Абыең әллә ни юка тормый ул, мал караучы дигәч тә! — Аның, чынлап та, гостиницада гына көн итеп яткан бу мосафир инженер алдында купаеп аласы килгән иде: кайтып төшә, хатынына мунча ягарга куша, үзе Эрнестка сарай-кураларын, мал-туарларын, түшкә-түшкә ит эленеп торган келәтләрен күрсәтә, кичкә инде үзе кайту, Уфадан килгән олы кунак хөрмәтенә күршетирәләрен җыеп ала.

Әмма тегенең вакыт тар иде, бугай. Эш чыгардай күренмәгәч, Әхмәтзәки күңелсезләнеп кенә бераз тын утырды.

— Әхмәтзәки агай, мин хәзер бу якка еш йөриячәкмен, икенче килгәндә төшәрмен. Әле миннән бизеп бетәрсез,— диде Эрнест.

— Безнең никогда кешедән бизгән юк! — диде Әхмәтзәки катгый төс белән. Шулай итеп, хәзер боларның берсе законлы «агай», икенчесе «энекәш» булып китте.

Әхмәтзәки уйланып торды да хуҗаның малаена ниндидер сөт машинасының шоферын чакырып китерергә кушты. «Тиз йөрсен, Әхмәтзәки агай кушты, диң»,— дип өстәп тә җибәрде. Шуннан тагы җитдирәк төс алды да юлдашына борылды:

— Алай вакыт ягы тар булгач, кыстамыйм инде. Дөрес әйтәсең, башта эшне эшләргә кирәк, шуннан уйнарга да ярый, Габдулла Тукай әйтмешли. Без бит дәүләт кешеләре,— диде ул җитди кыяфәт белән.— Әллә үзеңне шул колхозга кадәр озаттырып куйыйммы?

— Шәп булыр иде, агай! — Эрнестның күзләре янып китте. Теләсә теләмәсә дә, ул хәзер кененең шушы кешегә калганын таный башлаган иде, ахрысы.

— Тик сөт машинасы була инде. Кабинада барырсың. Үзем һаман машина ала алмыйм бит, гүләтеп кенә илтеп ыргытыр идем дә. «Запорожец»ны аласы килмәде. Хәзер машинага да чират зур.

— Ярар, миңа барып җитүе кыйммәт,— диде Эрнест.

Күп тә үтмәде, капка алдына машина килеп тә туктады. Әхмәтзәки, тәрәзә шакып, шоферга керергә кушты. Яшь егет ишектән күренү белән:

— Туганкай, сиңа хәзер Казмашка барып кайтырга туры килә,— диде ул хуҗа кеше төслерәк. Шофер бу кадәр катгый фәрманга аптырабрак калды:

— Мин иртәнге сөтне илтеп килдем инде,— диде.— Кичкә генә барам.

— Кичкә дә барырсың, ә хәзер шушы агаеңны илтеп ташлыйсың. Уфадан ул, гидроэлектростанциядән, минем белән килде. Зур эш белән йөри.

Шофер егет бер Әхмәтзәкигә, бер «гидроэлектростанциядән» килгән ят кешегә карап торды да шым гына чыгып китте. Үзләренең колхоз көтүчесенә ияреп кайтып килгән кешенең шулкадәр зур урыннан булуына шикләнеп тә куйды шикелле. Шулай да, ярар, бармый чара юк дигәндәй, баш тартырга кыймады.

Эрнест Әхмәтзәкигә карады:

— Рәхмәт, агай! — Ул үзенең Уфа кунакханәсендәге күршесенә беренче тапкыр шулай җитди һәм ихтирам белән эндәште.

Сөт машинасы, артыннан аксыл төтенен болгап, урыныннан кузгалды.

Әхмәтзәки кычкырып җибәрде:

— Һай, тукта әле! Мин ни, үзебезнең авылның исемен әйтмәгәнмен бит!

Шофер егет әллә ишетмәде, әллә ишетсә дә туктап тормады: Әхмәтзәки дә, кулын гына селтәп, үзен тынычландырып куйды:

— Ярый, Әхмәтзәки дигән кеше белән Уфадан бергә килдек дисә — белерләр.— Бөтен тирә-якта һаман да әле бары тик аның киңәшмәдән кайтып килүе турында гына баш ваталардыр сымак тоела иде.

РОБЕРТ БАИМОВ

Роберт Нурмөхәммәт улы Баимов 1937 елда Башкортстанның Кырмыскалы районы Үтәгән авылында туа. Урта белем алганнан соң мәктәптә балалар укыта.

1959 елда Башкорт дәүләт университетына укырга керә. Шунда 1963 елда партиягә кабул ителә. Мәскәүдә аспирантурада укый, фәннәр кандидаты дәрәҗәсен ала. Хәзерге көндә ул филология фәннәре докторы, университетның башкорт әдәбияты кафедрасы мөдире.

Р. Баимов «Өлгергәнлеккә адым», «Иҗади бизәкләр», «Эзләнүләргә чик юк», «Жанр язмышы», «Башкорт тарихи-революцион романы» дигән монографияләр авторы, Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе. Ул шулай ук проза өлкәсендә дә актив иҗат итә. Аның «Соңлап килгән моң», «Солдат булып кайтырбыз», «Бикле хәзинә» һ. б. хикәя җыентыклары, «Ышаныч» дигән романы чыкты.

Р. Баимов — 1973 елдан СССР Язучылар союзы члены.

ӘПТРӘХИМ

Авылына кайтып төшү белән, Әхтәм көтелмәгән күңелсез хәлгә очрады. Станция яклап олы урамга килеп керүе булды, аргы очтан кинәт җиз торбалардан иңрәп сарыккан матәм авазлары ишетелде. «Кемне җирлиләр оркестр белән? — дип гаҗәпләнде Әхтәм.— Андый гадәт элек авылда булмый торган иде ләбаса! Анавы бер елны озак еллар председатель булып эшләгән гражданнар сугышы герое Халик агай үлгәч, район культура сараеннан китерткән иделәр, башкача оркестр белән җирләү хәтердә калмаган... Әллә авылга да үтеп керәме бу заман модасы хәзер?»

Кешенең кайгылы вакытында шулай оркестр чакыруга исе китеп бармый хәзер Әхтәмнең. Элек ул да, шәһәрдә тора башлаган елларда, урамда шундый тамашага тап булса, әллә нишләп эсселе-суыклы булып калтыранып китә, җиз торбаларның газаплы иңрәвеннән аның күңеле тулыша, йөрәген шом кысып ала торган иде; шундый тетрәткеч авазлар тудыра алучылар үзләре дә ниндидер изге кешеләр, мәрхүмнең иң якын дуслары булып күренә, торбаларына кушылып алар да тыела алмыйча сулкылдап-сулкылдап елыйлардыр сыман тоела иде... Тик былтыргы бер очрашудан соң гына Әхтәм бу тамашага карата кинәт кенә сүрелде дә куйды.

Шәһәрдәге бер якын иптәшенең атасы үлеп киткән иде ул чакта. Әхтәм дә мәрхүмне соңгы юлга озатуга ярдәмләшеп, андый чакта килеп чыга торган төрле йомышларны башкарып йөрде. Оркестр да чакырган иделәр. Хәер, «оркестр» дигәне дә олы барабан, юан-юан кәкре җиз торба күтәргән үтә таушалган кыяфәтле өч-дүрт кенә ирдән гыйбарәт булып чыкты. Аларның да күз төпләре, күрәсең, шешәгә күп караудан, кызарып, шешенеп беткән. Шуларның өлкәнрәге килеп җитәр-җитмәстән, кайгылы, тынып калган кешеләрдән дә тартынмый, карлыккан тавыш белән сорап куйды:

— Кем чакыртты оркестр, кайсыгыз хуҗа?

Әхтәмнең иптәше аның янына килгәч, тегесе тавышын аз гына баса төште дә гадәти эш башкарган сымак:

— Бер литрны хәзер үк куясың,— диде.— Ә акчасын соңыннан бирсәң дә була...

Ул шундый хак әйтте — үз колагына үзе ышанмыйча, Әхтәм иптәшенә күтәрелеп карады. Әхтәмнең иптәше дә, күрәсең, мондый бәяне көтмәгән иде, кызара төште. Ләкин чакырып китергәч, кире бору уңайсыз дипме, ризалыгын белдергәндәй җиңелчә баш какты...

Менә шуннан соң Әхтәм җиз торба хуҗаларына да, аларны чакырган кешеләргә дә башкачарак карый башлады. Бу тамаша бер дә ихлас түгел кебек күренә аңа, кешеләр бер-берсеннән күрмәкче генә шулай кылана. Мәрхүм янында кирәкмәгән кәмит уйный, чын йөзләрен җиз торба тавышлары артына яшерә сыман тоела.

Ул арада баягы матәм авазлары якынайганнан-якыная барды. Әнә, алдан дистәләгән буйчан ир-ат чигүле озын тастымаллар ярдәмендә мәрхүмнең табутын күтәргәннәр. Алар артыннан әллә күпме халык ияргән. «Ни булган боларга, алай йөрми торган иделәр,— дип гаҗәпләнә янә Әхтәм.— Югыйсә авылда да хәзер һәркемнең үз кайгысы

кайгы: берәүнең эшкә барасы бар, икенчесенең йөрәге начар, җирләү гореф-гадәтен күтәрә алмый, туган-тумача, күрше-күлән кадере инде ул мәрхүмне җирләү, аның истәлеген саклау. Ә монда, гаҗәп, бөтен авыл чыккан... Әнә, иң алдан тастымалларын иңбашына салган Рәхмәтулла агай атлый. Чатлама декабрь челләсенә карамастан, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан... Ул берәүне дә күрми, ниндидер олы кайгыга баткандай атлый бирә. Арттан кемдер килеп аны табут янында алыштырырга теләгән иде, Рәхмәтулла агай: «Юк, юк, туган, үзем... арымадым әле»,— дип ярдәмне кире какты. Әллә аның берәр кардәше үлеп киткәнме? Кемне җирлиләр авылдашлар ул кадәр хөрмәтләп?

Әхтәм кайгылы агымның үзе белән тиңләшүен көтеп алды да, үтеп китүне килештермичә, кушылып атлый башлады. Аны, әлбәттә, күпләр шунда ук танып алды, тик кадимгечә кочаклашулар, шатлыклы авазлар гына ишетелмәде. Берәүләр тыйнак кына баш какты, икенчеләр сүзсез генә кул кысты. Хәтта Әхтәмнең бергә аунап үскән Гали исемле шар-бар гаугалы дусты да әллә ни ачылып китмәде. Кешеләрне аралап, аның янына үтте дә, бөтен шатлыгын шуның белән белдергәндәй, беләгеннән кысып тотып Әхтәм белән янәшә атлап китте...

— Кемне күмәләр? — диде Әхтәм шыпырт кына...

— Әптрәхимне... Кәлимуллин Әптрәхимне...

Әхтәм аны кинәт кенә исенә дә төшерә алмады.

— Кайсы Әптрәхим ул? — дип сорарга мәҗбүр булды.

— Һе, беләсең дә инде,— Әхтәмнең иптәше урынсызга нигәдер көлемсерәп куйды,— теге Әптрәй... Кызык Әптрәхим...

— Ә-ә! — диде кинәт Әхтәм, үзе дә ирексездән елмая биреп.— Нишләп үлгән, чирләгән идемени?

— Чирләштерә иде болай.— Гали янә җитдиләнде,— тик үлеме башкача... Суга батып әрәм булган...

— Менә ничек! — Әхтәм тагы гаҗәпләнә калды.— Тәки шул алама гадәтен ташлый алмаган, үлеме судан булган икән бахырның...

— Бахыр түгел ул,— дип бүлдерде Әхтәмне иптәше нигәдер кырыс кына. Аннан бераз йомшара төшеп өстәп куйды.— Үлә белгән ул Әптрәхим, йөрәге житкән, Бызык димәссең...

Иптәше башкача эндәшмәгәч, Әхтәм дә сүзне яңартуны хуп күрмәде. Алар шулай тын гына янәшәдән атлый бирделәр. Әхтәм һаман шуңа гаҗәпләнә: «Шушы хәтлем халык Бызык Әптрәхим өчен куптымы икән? Яшәве дә

кәмит иде үзенең, әле дә шуны дәвам итәләрме югыйсә? «Мине оркестр белән күмегез»,— дип әйтеп калдыруы да ихтимал әле аның».

Чынлап та, тере чакта Әптрәхимгә авылда беркем дә житди карамый иде шикелле: «Бызык», та «Бызык». Исеме белән аңа сирәк кенә, анда да янә бер кушамат тагып, «Кобиля Әптрәхим» дип кенә «олылый» торган иделәр. Авыл халкы сүз сайлап әллә ни кәнфитләнеп тормый бит ул, бәһасын да, кушаматын да турыдан ярып чәпи дә куя. Мәрхүмнең дөньяви кушаматлары да шундый иде, бала чактан ук үзенә иярә килде. «Бызык» дигәнен Әхтәм үзе дә хәтерли, теге авыррак еллардан калган. Ул чакта авылның олысы-кечесе, яз житсә, черек бәрәңгегә йөри торган иде. Кайберләре язгы боз өстенә калыккан салкын суны тубыктан кичеп, хәтта Идел аръягындагы рус авылы жирләренә дә баралар: аларда бәрәңге ишелеп уңа, күздән жирдә дә байтак ятып кала. Кечкенә генә булсалар да, Әптрәхим дә, Әхтәм дә, башка малайлар да йөри торган иделәр андый кәсепкә. Шулай бер көн төшкә кадәр сукыр тычкандай жир актарып йөреп арыгач, бичә-чәчә, бала-чага урман акланында ут ягып, тамак ялгау әмәлен кайгырта башлый. Ә Әптрәхим нигәдер башкаларны көтми, берүзе урман төпкелендәрәк яткан кечкенә генә күлгә бәрәңгеләрен юарга кереп китә. Ләкин күп тә үтми, төсе качып, акыра-акыра, шыр ялангач, уктай атылып килеп тә чыга...

— Ни булды? Нәрсә бар анда? — дип куркышалар акландагы бичәләр.— Киемнәрең кайда?!

— Әнә!... Анда... Әллә ни... Те-ге-ен-дә калды,— дип дер калтырап коелып тик тора. Бичә-чәчә кумәкләп жыелышып, курка-курка әлеге күл буена барып, малайның куакка эленгән юеш чалбарын, бәрәңге тулы бидрәсен кире алып чыгалар. Ләкин бернәрсә дә ачыклый алмыйлар. Тик бераздан гына, тынычлана төшкәч, нигәдер кинәт сакаулый-сакаулый Әптрәхим әлеге хәлне болай аңлата:

— Салбарны шундагы суда сайкап, агаска киптерергә элдем дә бәрәңге юарга күл эсенә атлый гына башлаган идем, камыш арасыннан кинәт ниндидер тупас тавыш:

— Бузк-бызк, бузк-бызк! — дип акырды да жибәрде. Минем шәрә торганны күргән, ахрысы, явыз. Бүзегемне алып кала күрмәсен дип курыктым да, усым белән капладым да йөгердем...

Әптрәхимнең үрдәк быкылдавыннан шулай коты алынуын авылда гомер буе оныта алмадылар, ирмәк бер әй-

темгә әйләндереп җибәрделәр. Кешеләргә, әлбәттә, көлке, ә менә Әптрәхим мескенең шушы хәлдән соң бик озакка сакау булып калды. Дулкынланган, кызып-ярсып киткән чакларында ул әле олыгая төшкәч тә күп кенә өннәрне тик «с» аша гына салдыра да җибәрә торган иде. Ә баягы үрдәк вакыйгасыннан соң истәлек булып «бузк-бызк» аңа үзеннән-үзе килеп ябышты.

Хәер, Әптрәхим бәләкәйдән үк бөтен авыл өчен бер ирмәк күренеш, күңел тилберлеге иде шикелле. Сугышта йөргән аталарының үлем кәгазе килгәч, бу гаиләгә авырлык күбрәк төште. Бер анага тупырдап торган берсеннән-берсе бәләкәй биш-алты баланы туйдыру җиңел булмады. Шуңадырмы, Әптрәхим бәләкәйдән үк үз юнен үзе күреп, авыл халкы мәрхәмәтендә үсте. «Өйрәледә — бер кич, боткалыда — ике» дигәндәй, кем сыендыра, кем туендыра — шунда йөрде. Күндәмлеккә дә, тыйнаклыкка да шунда өйрәнгәндер инде ул. Ләкин тамак тәмугка кертә, чарасын да күрдерә, диләр бит. Бу яктан Әптрәхимнең бөтен һөнәре — җырлау була торган иде. Аңа, әйтик, икмәкме, башка берәр ризыкмы бирәләр. Ләкин ул «бушка» алырга уңайсызлана, хакына җыр бүләк итә, ягъни «эшләп ашый». Бу җырны Әптрәхим үзе чыгаргандырмы, башка берәрсе өйрәткәндерме, тик хуҗасына охшап мәзәк кенә, гел бер төрле була торган иде ул:

Агыйделдән аша чыктым,
Ак тавыкка атланып.
Ирсез бичәләр күп диеп,
Йөремәгез мактанып.

Кемгә төбәп җырлагандыр аны Әптрәхим, мәгәр сугыштан соң, һәр өйдәге диярлек тол хатын күңеле өчен аның җыры ифрат якын булгандыр инде. «Бәләкәй булса да, акыллы безнең Әптрәхим,— диләр ирләрен көтеп зарыккан хатыннар яшь аралаш.— Замана баласы шул...»

Әйткәндәй, бу җыр, берникадәр генә үзгәртелеп, Әптрәхимгә гомере буе җитте дә куйды. Бызык әле дөньялар рәтләнә төшеп, үзе өйләнеп алгач та, чөгендердән коелган «ахун хәзрәтне» мул гына салып, изүләрне шар ычкындырып җибәреп, урамга чыга калса, бичәсенәме, башкагамы төрттереп, һаман шушы ук җырны өздерә торган иде. Тик ирмен дигән иргә «ак тавыкка атланып» йөрүне азак килештермәде, шул урынын гына:

Агыйделне аша чыктым,
Аргамакка атланып,—

дип бераз купыртып, күкрәк каккандай, мактанып ала да соңгы ике юлда, нигәдер, көтмәгәндә әрсез зарлана башлый:

Дөнья калды бичәләргә,
Беркем дә юк якларлык...

Менә шундый мәлләрнең берсендә ныклап ябыша да инде аңа икенче кушамат.

Ул чакта ир-ат кирәкме-юкмы сүз арасына, нигәдер, еш кына «ата-анасын», кыстырып сөйләшергә ярата иде. Ансыз сөйләү — тозсыз аш ашау белән бер тоелгандыр инде, күрәсең. Әшәке уй, хөсетлек белән әйтелмәгәч, бу әллә ни гаеп тә саналмый. Тын бетеп, сүз җитми торганда бәйләгеч, уңайсызлыктан коткаручы бер «бизәк» кенә була да куя. Әптрәхим дә башкалардан калышмыйм, кеше рәтендә булыйм дигәндер инде. Бер мәл ул да сүз арасына бисмилла урынына ниндидер ят, мәзәк сүз кыстыра башлады.

— Кисә кислэтеп кенә Янүзәк урманыннан кайтып килә идем, кобиля,— дияр иде ул,— арттан кинәт кемдер кыштыр-кыштыр үтте дә китте... Котым очып, артка әйләнеп карасам, берни юк, күренми, кобиля...

— Теге чактагы сымак тагы «бызк-бузк!» булгандыр ул,— дип көлешәләр кешеләр.

— Юк, төлке булган.— Бызык үзе дә кушылып көлә.— Ялгыз кешегә иярә икән ул... Авылга җитәрәк кенә төсендем суңа, кобиля...

Бызык сөйләгәндә бу сүзләр үтә ешая башлагач, шунда кемдер кызыксынып куя:

— «Кобиля» дә «кобиля» дисең, нәрсә дигән сүз була соң ул?

— Нәрсә булсын? — Бызык эре генә теш арасыннан чертләтеп төкереп куя.— Сүгенү сүзе...

— Булды, ди! — Белдеклерәк берәү аның сүзләрен кире кага.— «Кобиля» дә түгел, Әптрәй дөрес әйтми, ә «кабилә». Кешеләр борын әнә шулай кабиләләргә оешып яшәгәннәр...

Бызык аңа мыскыллы карый:

— Синең борын кабиләгә оесып яшәвеңне урыс Ыстипан кайдан белсен?

Кайберәүләр елмаешып куялар: үзе дә сизмәстән Бызык сернең очын, сүзнең чыгышын ачып ташлый. Әйе, Әхтәмнәр авылында озак еллар тимерче булып торган иде Степан агай. Сугыш заманында ирләр юклыктанмы, янында ул гел хатынын эшләтте. Ә тегесе бер өйрәнгәч, азак

та китмәде. Хәер, Анна апа үзе дә юк-бар иргә биргесез, эре сөякле, туры сүзле, үткер хатын иде.

Элек, малай чакта ук, Әхтәмнәр тимерлеккә килә дә, кызык табып, еш кына аларның эшен күзәтә торган иде. Менә Степан агай күрек белән өрдерелеп торган ут эченнән озын кыскыч белән ап-ак булып кызган берәр тимер кисәген эләктереп ала да җир идән уртасындагы түмәргә беркетелгән сандалга китереп тә сала... Аннан үзенең бәләкәй генә чүкече белән әлеге тимер кисәгенең берәр җиренә «тек»! иттереп сугып алган була. Шуны гына көткәндәй, Анна апа бала башыдай зур, озын саплы чүкечен (аны «кувалда» диләр) күтәрә сала да нәкъ шушы урынга, очкыннар чәчрәтеп, зыңкылдата китереп суга. Степан агай сандалдагы тимер кисәгенең янә икенче бер җиренә текелдәтеп ала. Анна апа ул җиргә дә җәһәт кенә зыңкылдатып тондыра. Әнә шулай алар гади бер тимер кисәгеннән менә дигән дагамы, уракмы яки башка берәр кирәк-яракмы килеп чыкканчы үзара ярышкандай «тек» дә «доң», «тек» дә «доң» килә бирәләр...

Малайларга тик шунысы аңлашылып җитми: нишләп Степан агайның ир кеше булса да чүкече уенчыктай гына бәп-бәләкәй, ә Анна апаныкы — суксаң, җиргә сеңдерерлек? Шуңа да аларга бөтен эшне Анна апа башкара сыман тоела. Тик авыл халкы гына, нигәдер, аңа түгел, ә гел Степан агайга гына мөрәҗәгать итә. Хәер, Степан агай текелдәтеп кенә торгандай булса да, эшнең иң катлаулы һәм мөһим өлешен башкаруын, шулай зур күтәрми, артык көчәнми, шаяргандай гына җиңел эшләү еш кына осталык һәм, гомумән, талантның төп сыйфаты икәнен ул чактагы малайлар кайдан белсен?!

Бызык авызыннан әле дә шушы Степан агай турында ишеткәч, башкалар кызыксынып куя:

— Степаннан ишеттеңмени бу сүзне,— диләр алар,— нәрсә була соң ул?

— Әйттем бит инде,— Бызык та һаман үзенекен сөйли.— Сүгенү сүзе... Иң катысы...

— Нигә алай «иң катысы» дисең әле?

— Бәй-й, шулай булмаса,— дип кыза башлый Бызык.— Ыстипан агай бер бүген генә сүгенми бит инде. Әллә нәрсәләр әйтеп бетерә. Ә Анна апа ыжламый да... Ә менә теге көн Ыстипан агай аңа «кобиля» дигән иде, Аннасы тузды да китте, өстенә менеп килә...

Шунда гына кайсы берәүләр сүзнең нәрсә турында баруын аңлап дәррәү көлеп җибәрәләр. Баксаң, Бызыкның «иң каты сүгенү» дигәне «кобыла» дигән гади сүз, имеш.

Башкортча «бия» була инде. Бызык аны белмәгәнме, әллә белеп тә сүгенүнең «йомшагракларын» сайлау өчен юрамал шулай кыланганмы, әмма Степан агайның элек тә бер сәер гадәте бар иде шул. Айгыр дагалыймы ул, атмы, бияме, аның өчен барыбер, «кобыла» ди дә куя. «Ну, ну, кобыла, тик кенә тор, паразит!» — дип кенә җибәрә иде ул, ачуланып. Хәзер инде күптән тимерлектә дә эшләмидер алар. Әмма гадәт, күрәсең, калган. Атларга әйтә торганын Степан агай уйламыйчарак Бызык алдында карчыгына да ычкындырган. Айгыр ни, мескен, тар гына дагалау станына кысрыклангач, нишләсен, «кобыла» дигәндә дә түзәргә мәҗбүр. Ләкин ирләр киеме киеп, ирләр эшен эшләп йөреп, ирләр холкына да ияләшә башлаган пәһлевандай Анна апа хурлауга ничек түзсен!

Әлбәттә, Әптрәхимнең бу «табышына», бәлки, артык игътибар да итмәгән булырлар иде, баягыча авылдагы кайсы ир-ат үткер сүздән качып, «тозсыз аш» ашый? Ә бәлки, бу сүзнең мәгънәсендә «тоз»ның азрак булып чыгуы сәбәпле, ул әкренләп сүнәр, онытылып та куяр иде. Тик, әмәлгә калгандай, Әптрәхимнең йомшартылган әлеге сүгенү сүзе озакламый авылның озын колаклы, сирәк тешле берәүсе — шушы Рәхмәтулла агай аша мәзәк хәлгә үрелеп, янә бер онытылмас көлкеле әйтемгә әверелеп киткән иде...

Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, хатынынннан әллә уңды, әллә туңды инде Әптрәхим. Болай үзе сүз тидермәде. Еш кына хәтта:

— Кисә ыграк салып кайтканмын, кобиля, бүген хәтта бас авыртып тора... Бисәне дә кыйратып таслаганмын, әй...— дип кабык сугарга да ярата торган иде. Хәер, күпләр аның ничегрәк «кыйратканын» беләләр инде, шуңа да эндәшми көлемсерәп тик торалар. Әйткәндәй, Әптрәхимнәрнең ыгы-зыгысы үзе бер мәзәк. Әзрәк төшергән чагы булып, нәрсәгәдер ачуланса, Бызык дулап урамга чыга да китә икән: «Китәм, башымны югалтам!» Аның артыннан елый-елый хатыны иярә башлый: «Кыйланма инде, Әптрәхим,— ди ул, инәлә-инәлә.— Башкача алай әйтмәм, эчүеңә дә ачуланмам, әнә, үзеңне малаең да көтә... Әйдә инде, җаныкаем, алтын бит син, алай итмә, безне кемгә калдырырга итәсең?..» Әллә яратты, әллә курыкты, әмма хатыны Әптрәхимне үтә иркәли, үтә төчели торгач, тәмам бозып кына бетте шикелле...

Шул көннәрнең берсендә, каршы гына торган Рәхмәтулла агай үз ихатасында вак-төяк эш бетереп йөргәндә, кинәт Әптрәхимнең бәләкәй генә киртә капкасы шар ачылып

китэ дэ аннан янэ чыр-чу килеп Бызык белэн хатыны күренэ...

— Житте, бисэкэй,— ди Эптрэхим, тузынып,— кадерне белмэдең, кобиля... Эйдэ, тыныч яшэ моннан соң, мазаңа тиюче дэ булмас... Э мине... Мине соңыннан су төбеннэн эзлэрсез...

Эптрэхимнең хатыны эллэ шуңа ышана, эллэ күңеле берэр нэрсэ сизенэ, эллэ юри кылана, елый-елый иренең муенына асылына, үгетли, юата, ялвара, жиңеннэн тотып, өйлэренэ табан сөйри, э тегесе аның саен ярсый:

— Жибэр димен, бисэкэй, күлмэкне... ыскындыр,— кызып китүдэн Бызык бала чактагы кебек еш-еш тотлыга башлый,— ситсаның метры бер сум түгел, ертасың бит, нислисең син, кобиля?!

Рэхмэтулла агай бу күренешне азак жиренэ житкереп, кызык итеп, тэмлэп-тэмлэп башкаларга да сөйлэгэн. Менэ шуннан соң Бызык янэ «Кобиля Эптрэхим» булды да китте. Егет-жилэн, малай-шалай үзара көрмэклэшэ башладымы, татулашу өчен Эптрэхимнең элеге бер генэ сүзе житэ дэ куя: «Ситсаның метры бер сум түгел, жибэр күлмэкне, ертасың бит, кобиля...» «Йэ, житэр, бызыкланмыйк инде»,— дилэр елмаешып андый чакта.

Лэкин Эптрэхим, аннан ничек кенэ көлмэсеннэр, теге гадэтен барыбер бик озак ташлый алмый жэфаланды. Хатыны белэн чыр-чу килгэннэн соң атна-ун көн тагы чөкердэшэ-чөкердэшэ тыныч кына яши башладылармы дисэң, элеге хэл кабатлана да куя, Эптрэхим янэ Иделгэ табан йөгерэ. Бэлэкэй генэ хатыны елый-елый аны куып житеп тагы тотып ала. Үгетли торгач, Эптрэхим дэ бүгенгэ «суга батмаска» риза булып хатынына ияреп, телэмэгэндэй генэ кайтып китэ. Э иртэгэсенэ (гажэп инде алар!), берэү дэ кыланмаганны, авыл урамында икэү култыклашып йөри башлыйлар, бер-берсенэ нэрсэдер сөйлэп, ихлас көңгер-көңгер килэлэр, эйтерсең, алардан тату, алардан гашыйк кеше дөньяда юк...

Тора-бара күрше-тирэ дэ аларның бу гадэтенэ күнегеп бетте шикелле, читэн артыннан мэзэк ыгы-зыгыны ихлас тамаша кылып, мыек астыннан гына елмаешып тик торыр булдылар. Лэкин Эптрэхимнең хатыны гына иренең бу кылыгына күнегэ алмады. Бызык тузына башладымы, аның сүзлэрен ихласка алып, язмышы өчен борчылып, ничэ карама ире артыннан елый-ялвара йөгерер дэ чыгар иде.

Эптрэхимнең суга бату «хыялы» ул чакта шушы Рэхмэтулла агай ярдэме белэн кызык кына өзелеп куйган иде.

Күрше хатынның өзгәләнүләрен күреп торган Рәхмәтулла берчак аңа болай ди:

— Син, килен, Әптрахим тагы шулай кылана башлый икән, аның артыннан чыгып торма, җәһәт кенә безгә кил дә әйт. Нишләргә үзебез белербез...

Хатын кеше нишләсен инде? Ни кылырга да белми йөдәп беткәч, ире өчен бераз шөрләп куйса да, Рәхмәтулла агай:

— Курыкма, тырнак белән дә чиртмәбез,— дигәч аптырап, сынамак булып, язмышын яңа тапшыра. Шулай берчак төшереп кайткан Бызыкның тавыш күтәреп, гадәтенчә дулап ишектән чыгып китүе була, хатыны җәһәт урам аша күршеләренә йөгерә. Ә Рәхмәтулла агай аңа борчылмаска, өйдән чыкмый гына ире кайтканын көтеп утырырга куша да, күрше-тирәдән тагы да берничә ир-атны ияртеп, үзе җәһәтләп кенә Иделгә табан чыгып китә...

Ә Әптрәхим бу вакытта гадәтенчә артына да карамый: «Батам! Иделгә барам да батам! Яшәмим, кобиля»,— дип сөрәнли-сөрәнли йөгерә бирә икән. Ләкин эчкән булса да, бер мәл ул нәрсәдер сизенеп артына борылып караса, гаҗәп итә: бу юлы аны беркем дә кумый, беләгеннән тотмый, үгетләми... Ул аптырап адымнарын әкренәйтә... Шулай да сирәк-сирәк сөрәнләп, артына карый-карый су буена бара бирә.

Тик яр буена җиткәч кенә ул бөтенләй туктап кала да нишләргә белмәгәндәй, өйләре ягына моңсу гына карап тора башлый...

Әнә шул чакта гына Рәхмәтулла агай белән теге ирләр килеп җитәләр дә Әптрәхимне җилкәсеннән эләктереп алып су эченә тарта башлыйлар... Бызык, нәрсәдер сизенгәндәй, кинәт читкә тартыла. Аннан ап-аек күзләре белән Рәхмәтулла агайга гаҗәпләнеп карый:

— Син, күрсе, нисләмәксе буласың әле? — ди ул шүрләүдән тагы бөтен хәрефләрдә дә тотлыга-тотлыга,— нигә күлмәккә ябесәсең?

Тегесе дә астыртын тынычлык саклый:

— Нишләмәкче дип ни, сиңа ярдәм итәргә булдык. «Батам, батам!» — дисең дә, инде күпме бата алмый интегәсең бит...

Әптрәхим чынлап та шүрли кала:

— Ә син кесе батырганга ни булырын беләсеңме, кобиля? — дип җибәрә ул аптырагач, калтырый-калтырый.

Ләкин шунда үзара алдан сөйләшеп барганнармы, әлеге өч-дүрт ир, Әптрәхимнең чәбәләнүләренә дә карамый,

аны суга сөйрәп алып кереп китәләр. Аларга көймәгә утырып алган Рәхмәтулла агай да ярдәм итә... Әнә шулай котын алалар Әптрәхимнең, Идел уртасына кадәр җиткереп, чумырып-чумырып җибәрәләр дә ант иттерәләр. Шуннан соң ул, бахыр, башкача: «Батам! Иделгә барам да батам!» — дип сөрәнләп йөрмәгән иде, хатыны белән урамда чыр-чу килүләре дә ишетелми башлаган иде.

— Тәкъдире барыбер судан булган икән, мескеннең,— диде Әхтәм, уйларын бүлеп,— теге чакта да: «Батам!» да «Батам!» — ди торган иде...

Иптәшенең нигәдер кинәт төсе җимерелүен шәйләп, Әхтәм әйтер сүзеннән өзелеп куйды. Ә тегесе, чынлап та «син дә сөйләдең сүз!» дигәндәй, аңа ризасыз карашын сирпеп алды да, үзалдына гына сөйләнгәндәй, уйларын саран гына кысып чыгарды:

— Кешедән көләргә дисәң, без барыбыз да шәп инде... Харап... Ә ул.. бер зыянсыз изге җан, һич тә көлке булмаган икән... Авылыбызның ямен, күңелен йөреткән...

Әйтсәң дә, хаклы инде Әхтәмнең иптәше. Үтә дә эчкерсез, үтә дә талымсыз иде Бызык — әзгә дә канәгать, булмаса да ярый. Кулыннан әллә ни килмәсә дә, тик тормас, йөреп ятыр, йә булмаса теленнән кинәндерер иде, пошыну белмәде. Шуңадырмы, ул төрле мәзәк хәлләргә эләкте, авырлыкларны җиңелләштереп, кайгыларны көлке белән бутап, ирмәкләнеп йөри бирде. Әхтәм дә хәтерли аларның кайсыларын...

...Бер мәл Әптрәхим шәһәргә киткән иде, һич көтмәгәндә ике кулының да бармакларын төптән үк өздереп кайтты. Юлда чакта ул ниндидер станциядә вагоныннан төшеп буфетка кергән дә озаклаган. Чыкса, поезд кузгалып кына тора икән. Бу йөгереп барып ишек тоткасына ябыштым дисә, ашыгудан ирексездән рельсларга таяна да куя...

Больницада ятып кайткач, үзен күрергә кергән күршекүләнгә Әптрәхим азак болай мактанган:

— Үәт, кобиля, бармакларны онтаганы җитмәгән, иссү газиз басны сорый... сыкылдап торган зур тәгәрмәсләр астына суырып кертергә самалый... Ну, үзем дә, кобиля, сос икән: бирмәдем басны, бармаклар белән генә котылдым...

Үзенчә яшәде инде фани дөньяда Әптрәхим, бер карасаң, көнләшерлек, икенче карасаң...

...Ә кешеләр агымы табут артыннан һаман атлый бирә. Көн аяз булса да, декабрь чиләсе үзен нык сиздерә, битколакларны өтеп алып бара. Усал кеше үлгәндә генә шулай яман суыта дигән булалар тагы, кайдан килсен инде

Бызыкка усаллык... Башкаларны зиратка элек ат белән генә илтәләр дә куя торган иделәр, ә моны чатлама суыкта да күтәреп баралар.

Әхтәм, нигәдер, шунда тагы Степан агай белән Анна апаның тимерлектә эшләүләрен искә төшерде... Менә Бызык та Степан агай сымак ук бервакытта да «чүкечнең» зурын күтәрмәде: тыңдәшләре калага, зур эшләргә, югары уку йортларына киттеләр. Ә ул авылда калды, зур эшләр башкаруга караганда авыл халкын күбрәк мәзәкләре белән кинәндерде, кайгы белми яши бирде. Ә үзен хөрмәтләргә әнә күпме кеше чыккан. «Минем өчен шулай кузгалырлар иде микән?» дигән көнчел уй чагыла биреп куйды Әхтәмдә. «Ай-һай... Абруйлыракларга да әле болай булмый торган иде... Гаҗәбрәк хәл бу барыбер... Кәмитлек белән каһарманлык бер чама бәяләнәме әллә кешеләрдә?! Хәер,— дип юата урынсызга кузгалган күңелен Әхтәм,— тормышта шатлыклары күп булмады, соңгы юлда булса да хөрмәт күреп китә Әптрәхим, әнә нинди дәрәҗәле кешеләр күтәреп бара үзен. Хәтта гомер буе Әптрәхимне ирештереп көлеп йөргән Рәхмәтулла агай да табут янындагы үз урынын һаман бирәүгә дә бирмәгән. Атлаганда аның ара-тирә авыр көрсенгәне, уфтануы гына ишетелеп кала. Тын авыл өстеннән күңелләрне сулкылдатып җиз торбалар салмак кына матәм авазлары сибүен дәвам итә... Кешеләр иң кадерле нәрсәләрен югалткандай моңсу да, җитди дә...»

— Ә оркестр кайдан китердегез? — дип сорады Әхтәм нигәдер.— Каладанмы, әллә районнанмы?

— Юк, күрмисеңмени? — Тегесе гаҗәпләнгәндәй итте.— Үзебезнең мәктәп укучылары... Музыка кораллары үзебездә бит хәзер... Клубта концерт та куялар... Болар Илшатның иптәшләре инде...

— Нинди Илшат ул?

Гали аптырагандай кинәт аңа күтәрелеп карады да, нәрсәдер исенә төшеп, кулын селтәп куйды:

— Әй, син белмисеңдер шул әле,— диде ул гафу үтенгәндәй.— Әптрәхим бит әнә шул баланы коткарам дип, һәлак булган. Рәхмәтулла агай малае...

Сөйләү авыр идеме аңа, башкаларның игътибарын җәлеп итмәскә тырыштымы, иптәшенең тавышы әллә ничек үтә тонык, өзек-өзек кенә ишетелде Әхтәмгә:

— Әнә шул Илшат иртәле-кичле гел Идел бозында конькида шуып уйный торган иде... Ә ул көндә... Декабрь бозы шома... Уйнау рәхәт... Бала кеше ни, мавыгып ташлагандыр инде... Искәрмәстән теге кыш та туңмый яткан

шарлавык тирәсенә барып та чыккан, бозы уелып төшеп тә киткән.

Әхтәмнең иптәше, нигәдер, тынып калды. Күзләрен ящереп, аска карап тын гына бара башлады.

— Әптрәхимнең өе яр башында гына бит,— шулай ялгады ул сүзне бераздан,— ул үзе дә арткы киртәдән бала-чага уенын кызыксынып күзәтеп торган икән. Ярдәмгә ташланган. Ләкин бала авырлыгыннан да уелып торган боз өстеннән ничек атлыйсың инде, сикергән ул да...— Галинең тавыш тагы калтыранып китте, тынычланырга тырышкандай, тамагын кыргалады.— Ә аннан... суда килеш ни әмәл беләндер баланы шома боз өстенә көч белән этәреп җибәреп өлгергән, ә үзе боз астына китеп югалган... Хәер, тупый бармаклары белән ничек уелып торган шома бозга ябышып чыга алсын инде ул?..

Гали янә читкә карап беразга тынып калды да өстәп куйды:

— Аны табарга өмет тә өзгәннәр иде инде, тик берничә көннән соң гына агым белән теге комлы култыкка килеп чыккан...

Әхтәм дә иптәшенең хәбәреннән телсез калды. «Менә сиңа Бызык,— дип куйды ул эчтән генә.— Аңламассың дөньяны!» — иптәшен җитәкләгән көе ул алгарак үтте, табутта яткан авылдашына җентекләбрәк карады. Әптрәхимнең йөзе караебрак китсә дә, бозлы суда яткангамы, әллә ни үзгәрмәгән иде. Тыныч, хәтта бераз хәйләкәр көлемсерәгән дә кебек. «Матур гына булган икән ләбаса ул Бызык,— дип янә гаҗәпләнеп куя Әхтәм,— килешле төз танау, ак йөз, киң маңгайдан артка таралган калын чәч... Элек бер дә игътибар ителмәгән, күрәсең...»

Әхтәм аңа янә күтәрелеп карады, авылдашының йөзендә кадимге оялчан тыйнаклыкны күргәндәй булды. Менә ул сикереп торыр да үз үлеме белән ихтыярсыздан шулкадәр кешенең игътибарын алуга уңайсызланып, тотлыга-тотлыга базнатсыз гына акланыр сымак:

— Ну, кобиля, бу Идел гүзәл булса да, явыз икән: Рәхмәтулла агаемның алма кебек малаен алып китәргә самалый, оялмый да... Бала басы бер сумдыр шул... Ярый, кобиля, миндә дә соплык зур: малай урынына үземнең исәр башны бирдем дә җибәрдем...

...Ә кешеләр агымы һаман тукталмый. Әптрәхимнең якты истәлеген хөрмәтле тыгыз тынлык белән уратып, олы кайгыны күмәк җилкәләргә йөкләп, табигать кырыслыгын күңел җылысы белән эретеп һаман алга бара бирә...

ТИМЕРГАЛИ КИЛМӨХӘМӘТОВ

Тимергали Габделгалим улы Килмөхәмәтов 1941 елда Үзбәкстанның Ферганә өлкәсендә Багдад районы Серов станциясендә туа.

Башкортстанга кайтып, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң берничә ел колхоз комсомол оешмасы секретаре булып эшли. 1962 елдан Башкорт дәүләт университетында укый башлый, шуннан Мәскәүгә аспирантурага җибәрелә. 1970 елда Т. Килмөхәмәтов филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклый.

1967 елда аның «Айчуак» исемле тәүге повесте басыла. Шуннан соң «Йолдыз төсе», «Зәңгәр тояк» дигән повесть һәм хикәя җыентыклары дөнья күрә.

Т. Килмөхәмәтов СССР Язучылар союзына 1973 елда кабул ителгән.

АКБИРДЕ АЛМАЛАРЫ

Акбирде койма буендагы имән бүкәнгә акрын гына килеп утырды да агач аягын каршысындагы кискәгә салды. Ике кулы белән тотып, аз гына кузгаткалап, аны бушаткандай итте; менә ничә еллар үзенә аяк хезмәтен үтәгән, каракучкылланып шомарган агач кисәге кискәнең нәкъ уртасына уңайлы булып ятты.

— Ул китәчәк... Тагы бер сәгатьтән...

Атна буе күңелен әрнетеп йөргән шушы уй үткер ук булып бер тын алымында Акбирденең йөрәге аша чәнечтереп үтте.

— Тагы бер сәгатьтән...— Шушы хәерсез минутның бөтен мәгънәсен ачыграк күз алдына китерергә тырышып, Акбирде учы белән йөзен каплады.

— Тагы бер сәгатьтән...

Әлисә, аяк-кул буыннарының йомшара баруын каршысында утырган ахирәтенә сиздермәскә итеп, керләрен чайкарга дип ялгашка салкын су койды.

— Әлисә, кайчан барып җитәсең инде анда?

— Кичкә таба. Самолет белән очсам — иртәгә үк.

— Олыгаеп барган көнендә шуның ише озын-кара юлга чыгарга ни җитмәгәндер сиңа, белмим.

— Әй, Гөлниса, син шулай дисең дә ул.— Әлисә, кулларын терсәк очларына кадәр суга тыккан көенчә ахирәтенә карады.— Син шунда тугансың, шунда үсеп, шунда картаеп киләсең. Туган җирдән аерылу дигәнне белмәгәнсең дә. Ә мин хәзер унтугыз ел туган якларымны күргән юк.

Кул эшен алдына куеп, Гөлниса беразга сүзсез утырды. Әлисәнең хәбәре аны уйга салды булса кирәк.

— Син алай дигәч тә, мин дә инәйнең өйдән чыкмас иркә баласы түгел. Ирләр сугышта чакта Катай якларында яртышар ел урман кисеп ята идек. Сагындыра торган иде. Сагынуны яхшы беләм. Тик, Әлисә, мине бер нәрсә аптырата: унтугыз ел буе тор, тор да бүген килеп туган як дип чап. Торган, торган да йөгергән дигән шикелле була инде.

Әлисә чайкалган керне сыгып табакка өйде. Ялгашка җылы су коеп, озын плитә өстендәге бидрәдә кайнап утырганнарын китереп салды.

— Картлар бигрәк тә әллә нәрсәләр язып җибәргәннәр шул, Гөлниса.— Әлисә, пары чыгып торган суны җиңелчә болгатып, нәрсәләрне чайкады.— Әҗәлләре җиткән кешеләр шикелле кыланып, «бәбкәм, бер генә күреп калыйкчы», дип беткәннәр.

Әлисә ахирәтенә башкача күтәрелеп карамады: әллә ничек, күңелендәге серләрен Гөлниса аңлап алыр кебек иде.

Чынын әйткәндә, картлардан мондый хатларны аз алмады Әлисә. Әнкәсе белән әткәсе немецлар тарафыннан үтерелгәч, ата-ана урынына калган картәти, картинәй янына барыбер кайталмады. Ерак Украинадагы туган авылына бүген килеп юлга чыгарына икенче бер нәрсә сәбәп булды.

Картлар үзләренең соңгы хатында, авылдагы төрле яңалыкларны язганнан соң, болай дип өстәгән иде: «Яңарак Петро Гончар да кайтып төште». Шунда Әлисәнең йөрәге дертләп киткән иде. Картаеп килгән көнендә шулай кылануына кеше-карага күренергә оялып йөрде. Тик аның хыял дөньясында Петроның исеме, сыны ачыкланганнан-ачыклана барды.

...Иртәнге чыкны елкылдатып коеп, яшь кенә кыз суга китеп бара. Аның көянтә өстеннән салып җибәргән чәч

толымнары очасына чаклы салынып төшкән дә ал чәчкә төшерелгән зәңгәр бидрәләр уңаена талгын гына тирбәләләр. Ап-ак итеп буялган ха́талар, су юлына тезеп куелган маяклар сымак, авыл очына кадәр озатып баралар да иртәнге җилдә селкенгәләгән ачык тәрәзәләре белән кул болгап калалар. Әнә озын төз тирәкләр арасындагы тегермәнче йорты, аның артында буа. Аннан тутырып су алуга, атын җитәкләп, яланаяк малай килеп җитәчәк. Менә кыз бидрәләрен богырдатканчы тутырды да, су сирпә-сирпә аякларын чайкап, ярга атлады. Шулчак су юлында йолдыз кашка белән яланаяк малай күренде. Менә аларның арасы бер адымдай гына калды. Кыз, уңгарак каерылып, урап үтмәкче булды. Малай көянтәсен тотты.

— Олеся.

— Петро.

Алар, бер-берсенең күзенә туры карарга кыймыйча, озак кына сүзсез торды. Шуннан Петро: «Олеся, Йолдыз кашка сусаган, әйдә суыңны эчерик»,— дип, аның бидрәсен эләктерде. Бидрәләр бушап калгач, Йолдыз кашканы кызга тоттырып, малай буага омтылды. Йолдыз кашка, танау тишекләрен киңәйтеп, башын кызның ялангач беләген тери; тәнне чемердәтеп, ниндидер бер салкынлык йөгерә. Ул арада тулы бидрәләрне җитез уйнатып малай килеп җитә. Алар кайтырга чыга. Арадаш ат пошкыруы белән тирәк яфраклары кыштырдавыннан башка бер тавыш юк. Менә тегермәнче йортына илтә торган сукмак. Йолдыз кашка белән яланаяклы малай шунда кала. Сынын туп-туры тотып, вак-вак кына басып килүче кыз авыл очына кергәнче аларның карашын тоеп бара. Көн саен кабатлана шушы күренеш. Озакламый Олеся шәһәргә медицина училищесына укырга китте. Шунда ул беренче тапкыр тегермәнче малае Петроның үз күңеленнән беркайчан да чыкмас кешегә әйләнгәнен аңлады. Җәйге каникулга кайткач, буа буендагы очрашулар элеккедән дә ләззәтлерәк тоелды. Беркөн иртән буа буеннан кайтуга алар коточкыч хәбәр ишетте: сугыш... Озакламый авылны немецлар алды; Петро белән Олеся беренче тапкыр тегермән буасында очрашмады. Петро шунда ук юк булды. Тиздән аның Совет Армиясе сафында дошманга каршы сугышларда катнашуы, соңыннан хәбәрсез югалуы билгеле булды.

Ә кызның үз язмышы башкачарак килеп чыкты. Чигенүче бер төркем совет сугышчыларына ияреп, партизаннарга китте. Анда медицина сестрасы булып эшләде. Соңыннан Совет Армиясе белән бергәләп үзенең туган авылын азат итүдә катнашты. Дошманны эзәрлекләүче хәрби

частьлар белән үтеп баручы госпитальдән авыр яралы бер сугышчыны тапшырып, аны авылда калдырдылар; аягы киселгән бу солдатка тынычлык һәм хатын-кыз тәрбиясе кирәк иде. Олеся сугышчы егетне ихлас күңелдән карады. Көннәр үткән саен ниндидер бер тойгы аларны якынайтты. Бөтенләй савыгып, кайтып китәр көне җиткәч, бу югалтуларны күтәрә алмаячагын аңлаган кыз аннан калмаска карар итте. Шулай итеп, ул Акбирденең хатыны булды. Акбирденең туган авылына кайтып төшкән көнне үк аңа башкортчалап Әлисә дип эндәшә башладылар; бу авылда сугыш чорында Украинадан күчеп килгән кешеләр арасында берничә Олеся булган икән, аларның һәммәсен дә Әлисә дип йөрткәннәр.

Агыйделгә терәлеп үк торган биек тау итәгендәге бу башкорт авылын ул тиз үк үз итте. Өйләр, үзләрендәге шикелле ап-ак булып ялтлап утырмасалар да, өскә авып килгән урман-тау, аяк очында уралган ак тасма — Агыйдел авылга ямь бирә. Кешеләренә дә ияләште. Авылдагы медпунктка эшкә урнашты. Атна-ун көн үтүгә халыкны күреп-йөреп чыкты. Шулай да Әлисәнең ят авылда күрсәткән иң «зур» эше көтмәгәндә булды. Килеп яши башлагач, йорт алларының ялангачлыгы, бакчалар юклыгы күзенә чалынды. Акбирдене пароходына утыртып (ул бакенщик булып эшли башлаган иде), шәһәргә алма агачлары алырга җибәрде. Җимеш-җиләк, алма-мазар тәрбияләүгә Әлисәне өйрәтеп торырга түгел иде. Берничә елдан аларның бакчасы алма чәчәгенә күмелде, алар утырган ташлы тау итәге алма үстерү өчен генә яратылган кебек иде. Бераздан аларның бакчасыннан тирә-якка алма исе бөркелде. Күбрәген Әлисә үзе тәрбияләсә дә, бу алмалар халык телендә «Акбирде алмалары» булып китте. Әлисә моңа сукранмады. Эш андамыни: алмалары күпереп чәчәк аткан, алланып пешкән чакларда ул үзен Украинадагы өендә кебек хис итте. Алардан күрмәкче, күрше-күлән дә алма утыртырга тотынды. Әлисә алма үстерүнең үзенә билгеле барча серләрен өйрәтте. Акрынлап алма бакчасы булмаган йортлар да калмады. Сугыштан соңгы авыр елларда үзләре үстергән алмалар ару гына күтәрде халыкны: шәһәргә алма алып барсалар, аннан азык-төлек, кирәк-ярак алып кайттылар. Көндез медпунктта, кичләрен Акбирде белән икәүләп бакчада мәш килеп гомер үткәргәннәре сизелми дә иде. Аллы-артлы ике малайлары булды. Алары да шәһәрдә укый. Инде ул үзен шушы дөньядан башка күз алдына да китерми иде. Тик менә картларның монавы соңгы хаты йөрәген кузгатты. «Ниләр генә булыр,

Аның, Петроның, мөгаен, гаиләсе бардыр. Ул турыда картлар берни әйтмәгән. Шулай да хәзер аңа да илледән артык. Әгәр чынлап өйләнмәгән булса, йә өйләнеп тә гаиләсе шул йөргән якларында калган булса? Нишләрмен ул чакларда? Ул миңа ничек карар? Ә Акбирдем? Басынкы, эшчән, намуслы Акбирдене бит мәңгелеккә яраттым. Юк, Петроны минем болай гына күрәсем киләдер. Акбирде алдында оят та инде. Тик бер генә кабат, бер генә...»

Әлисә, юеш кулларын алъяпкычына сөртеп, битенә төшкән чәчен рәтләп, сәгатькә карады.

— Ярты сәгать калды,— диде Акбирде, тәрәзәдән ишетелгән сәгать сугуын тыңлап.— Ярты сәгать...

«Чынлап та китәр микәнни минем Әлисә? — дип уйлады Акбирде, күзләрен ачмыйча гына.— Ел саен, туган якларыңа барып кайтыйк, дип әйтә килдем. Уйламады да. Әле торып очынды да китте. Петроны чынлап күрәсе килде микәнни? Иң тәүге яраткан кешеңне онытуы кыен дигәннәрен ишеткәне бар иде. Дөрестер. Ә минем Әлисәгә чаклы яраткан беркемем дә булмады шул...»

Акбирде акрын гына күзен ачты. Аның алдында гына күпереп чәчкә аткан алмагачлары уйга баткан сымак торалар. Аңа моннан янә ямансурак иде. Әйтерсең, алар: «Әгәр дә Әлисә киткән җиреннән әйләнеп кайтмаса»,— диләр.

«Чынлап та, Әлисәм кайтмый калса. Петросы белән калса...— Акбирде көпә-көндез үзенең шундый хилаф уйларга батуына хафаланып куйды.— Ә нигә ул туган якларына кайтып әйләнмәскә тиеш әле? Бәлки башка туры да килмәс аңа бу бәхет».

— Ничек кенә булмасын, хатынны озатып куярга тиешлемен,— диде Акбирде акрын гына, агач аягын кискәдән алып. Торып басты. Ап-ак куе чәчен куш куллап артка сыпырды. Киң иңбашлы озын калын гәүдәсен төп-төз тотып өйгә таба борылды да, бер адым алга басып, бакча капкасын ачты. Өйдән алачыкка тартылган бауга Әлисә аның әле генә юылган күлмәк-чалбарларын эләә иде. Акбирдегә тагы да кыенрак булып китте. «Гел минекеләрне юган,— дип уйлады ул,— әллә чынлап та соңгы тапкырмы?»

Чәй озак эчелмәде. Гөлниса берничә кабат авыз ачып караса да, сүз ялганмады; аерылышу алдындагы киеренке минутларны һәркем эчтән генә кичерде.

Акбирде, өй алдындагы утыргычка чыгып утырып, тә-

мәке кабызды. Озак та тормыйча, күтәрмәдә Әлисә күренде. Акбирде авызыннан бөркеткән тәтен аша аңа карады. Әлисә бик гади киенгән иде: башында парчалы косынка, өстендә бала итәкле күк күлмәк, аягында тәбәнәк үкчәле, йомры башлы ак туфли. Кулында шәһәргә барганда йөртә торган кадимдәге сумкасы. Акбирде җиңел генә торып капкага таба атлады. Аның агач аягы урамдагы йомшак үләнне җиргә сеңдерә бара иде. Авыр, бик авыр булачак Акбирдегә үз йорты белән ике-өч йөз адым чамасындагы Агыйделгә чаклы Әлисәнең янынннан атлавы. Әлисәгә дә бу яхшы аңлашылды. Ул шәп-шәп житеп, иренең беләгеннән тотты.

— Акбирде,— диде ул, аны сизелер-сизелмәс кенә үзенә тартып,— син барып торма. Гөлниса ахирәтем озатыр.

Әлисә белән Гөлниса икәүләп түбәнгә төшеп китте. Акбирде ашыкмыйча гына бакчага кереп, алмагачлар төбендәге теге бүкәнгә утырып, агач аягын ипләп кенә каршысындагы кискәгә салды. Фуражкасын маңгай өстенәрәк төшереп Идел ягына карады. Моннан пассажир пароходы туктый торган урын ап-ачык күренә иде. Түбән төшеп барган Гөлниса белән Әлисә яр башында пароход көтеп торган халыкка барып кушылды. Матур итеп кычкыртып ак пароход килеп туктады. Башкача ул якка карап торырга көченнән килмичә, Акбирде күзен йомды.

Шулай күпме утыргандыр, аның колагына бер тавыш чалынды.

— Акбирде димен, син кайда?

Бу — Гөлниса иде.

— Мин монда, Гөлниса апай, ни бар?

— Акбирде, мин кереп тормыйм. Әлисәнең йомышын гына әйтим дип килдем. Ул сиңа иртәгә үк урманга барып күп итеп каен суы саркытып алып кайтырга кушты.

— Каен суы?

— Әйе.

Акбирде сикереп торды да шау чәчкә алма агачын кочаклады.

— Болай булгач, туган көн бергә булачак,— дип сөйләнде ул, бите белән хуш исле чәчәкләргә кагылып.

Акбирде белән Әлисәнең бергә тора башлаган елдан бирле килгән бер гадәте бар иде: май азакларында була торган туган көннәрендә кунакларны каен суы белән сыйлау.

— Каен суы!.. Әлисәм каен суы эчәргә кайтып житәчәк! Житәчәк!

Акбирде хәлсезләнеп кискәгә утырды. Ак пароход борылышка кереп югалган иде инде. Ерактан куәтле гөрелдәве генә ишетелде.

НАИЛ КОТДУСОВ

Котдусов Наил Якуп улы 1941 елда туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, бер ел колхозда эшли. Аннан Башкортстан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Колхозда зоотехник, ВЛКСМ шәһәр комитетының беренче секретаре вазифасын үти, район авыл хуҗалыгы идарәсендә баш зоотехник булып эшли.

Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач, аспирантурада укый. Аны уңышлы тәмамлап, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. Хәзерге вакытта Башкортстан авыл хуҗалыгы институтының фәнни-тикшерену секторы җитәкчесе булып эшли.

Н. Котдусов — 1964 елдан КПСС әгъзасы. 1978 елда аны СССР Язучылар союзына алалар.

Ул — алты китап авторы. «Гафу ит, әнием», «Җәй иртәсе», «Олимп тавы текәме?», «Яшен яктысы» исемле повестьлары укучылар тарафыннан җылы кабул ителде.

МАТРОС ФӘЙЗИ

Моряк булу — Фәйзи өчен бәхетнең иң югары түбәсе иде. Ул яшьтән үк тельняшка, бескозырка белән саташты. Китапларда язылган, киноларда күрсәтелгән «диңгез бүреләре» аның гомерлек мәхәббәтен яулап алды. Кыскасы, Фәйзи өчен матростан да кыю, көчле, бөек кеше юк иде.

Һәм менә аның хыялы тормышка ашты. Аны флотка хезмәткә алдылар. Аның башы күккә тиде. Элекке механизатор, ул монда тиз арада моторчы һөнәрен үзләштерде һәм өч ел буе «ыһ» та итми авыр хезмәтне җиңел итеп, алай гына да түгел, шатланып, бәхет итеп башкарды.

Үзе, мөмкинлек булган саен тулы формасы белән фотога төшеп, авылга — әнкәләренә, дус-ишләренә, туган-тумачаларына җибәреп торды. Күрсеннәр әйдә Фәйзинең кемлеген!.. Кыскасы, түшен тутырып значоклар тагып, көзге бер көнне хезмәтен тәмамлап кайтып төшкәндә, авылда бөтенесе дә аның матрос Фәйзи икәнлеген беләләр иде инде.

Авылда да ул бик озак формасын салмый йөрде. Кичләрен бескозыркасын кырын салып кияр дә, бушлатының төймәләрен ычкындыра биреп, сигезенчедә укыган энесе Салихны ияртеп килеш, киң чалбар балакларын җилфердәтеп, эре-эре атлап кичке уенга юнәлер булды. Клубка барып керә дә баянистка ике бармагы белән генә чирттереп:

— Давай, безнекен! — дип әмер бирә.

Теге аңлаганын белдереп башын селкә һәм ашыкмый гына, ләкин өздереп уйнап җибәрә.

Фәйзи бескозыркасын чос хәрәкәт белән мангаена төшерә, ике кулын җәеп җибәрә һәм, уртага чыгып, музыка тактына биеп тә китә. Гармунчы баянын җәһәтрәк тарта башлый, матросның да аяк йөрешләре шәбәя төшә, ул кулларын күкрәгенә, ботларына, идәннәргә сугып ала. Баян торган саен кыза бара һәм, ниһаять, иң житез ритмнарга барып житә. Егет тулысынча музыка тәэсиренә бирелә, гәүдәсенең һәрбер хәрәкәте, йөзендәге һәр үзгәреш ритмга буйсындырылган. Әйтерсең лә, залда биюче дә гармунчы гына, әйтерсең лә, музыканың күренмәс йөзәрләгән, меңәрләгән кыллары белән матросның аяк-куллары гына түгел, ә бөтен тән-мускулларына кадәр тыгыз бәйләнгән һәм алар бер каршылыксыз күрек тавышына буйсына...

Бөтен зал бердәй булып Фәйзинең осталыгына таң калган. Егетләрнең йөзендә ихтирамлылык, ә кызлар карашында соклану, хәтта менә-менә кабынып китәргә торган мәхәббәт, өмет чаткылары балкый.

— «Яблочко»,— дип, янында торганнарга әкрен генә аңлата Салих.— Шуны биеп, флотта икенче урынны алган.

Ничек кенә булмасын, урта буйлы, киң күкрәкле бу егет күп кызларның күңелен җилкендерде. Әйе, аны төшләрендә күреп уянып, татлы хыялларга чумып төн үткәрүче берәү генә булмагандыр. Ләкин аңа иң саф, иң газаплы беренче мәхәббәт белән гашыйк булучы клуб мөдире Гөлгенә иде.

Чем-кара озын чәчле, ут чәчеп торган күмер кара күзле, озынча битле, тигез ап-ак тешләрен һәрчак күрсәтеп

елмаеп торган чая кыз ул. Былтыр унынчыны тәмамлап клубта эшли башлау белән авылның бөтен егетләре җимешнең нинди затлы икәнлеген сизеп алдылар. Сизделәр, ләкин өзеп каба алмадылар. Чөнки кыз беркемне дә ошатмады. Берсеннән-бер мәхәббәт турында авыз ачтырмады, берсеннән дә озаттырмады. Ә менә Фәйзине күрү белән тәүге көннән үк ничектер йөрәге урыныннан купты да куйды. Егетнең клубка килүен түземсезлек белән көтеп ала да, аннан кич буе күзен алмый, башка егетләрнең биюгә чакыруын читкә кагып, стена янында утыра бирә.

Матросның чакыруын көтте ул. Ләкин тегесе кызны искә дә алмый, почмакта егетләр белән юк-бар хәбәр сөйләп көлешеп, күңелен ачып утырды. Аптырагач, клуб мөдире, төрле эш табып, шул почмакта уралды. Фәйзинең игътибарын җәлеп итәргә тырышты.

.Моны тәү башлап Салих сизде.

— Чәчкә! — диде ул клубтан кайтканда агасына.

Фәйзи аңламады:

— Нинди чәчкә?

— Гөлгенәне әйтәм, синнән күзен дә алмый...

Бескозырка бераз эндәшми барды.

— Матроска тиң булырлык кыз юк монда, энекәш...

Салих канәгатьсезлеген белдереп, чертләтеп төкерде. Ул да агасы кебек аз сүзле иде.

— Анысы шулай да, чәчкә бит, матур чәчкә! — дип кенә куйды.

Көннәр үтә торды. Гөлгенә газаплана бирде, ә Фәйзи аңа әйләнеп тә карамый, килеп «Яблочко»сын бии дә кайта да китә. Ниһаять, кыз түзмәде, бер кичне егетне биергә үзе чакырырга булды. Уенның иң кызу вакытында гармунчының «дамский» вальсны уйнап җибәрүе булды:

— Мөмкинме? — дип аның алдына да килеп басты.

Фәйзи тәүдә бераз каушап киткәндәй булды, аннан иңбашларын сикертеп алды (янәсе, мине чакыруыгызның мәгънәсен аңламыйм) һәм кызга каршы чыкты.

Матрослар юкка гына оста биючеләрдән саналмыйлар шул, Фәйзи шулкадәр салмак, кызның һәр хәрәкәтен алдан сизеп, шулкадәр аңа җайлашып биеде! Берәр конкурста булса, алар һичшиксез беренче урынны алган булырлар иде. Чөнки кыз да сөйгәненең көчле кулларына таянып, аның якынлыгыннан, тын алуларын тоюдан башы әйләнеп киткәндәй, нindидер сихри шатлык дөньясында үз авырлыгын да тоймый күбәләктәй очып әйләнде. Аларның буйлары бертигез икән дә! Ул сирәк-саяк кына егетнең түгәрәк кырыс йөзенә, бескозырка астыннан тырпаен

чыгып торган кыска гына итеп алдырган чәченә күз сирпә дә куркып китә: егетнең үзсүзлеген белдереп кысылган иреннәре бөтенләй якын бит! Әгәр ялгыш үбеп куйса?..

Менә музыка өзелде. Бию тәмамланганчы, Фәйзи авыз ачып Гөлгенәгә бер сүз әйтмәде. Ул кызны урынына кадәр озатып «рәхмәт»ен әйтте дә, энесен ияртеп, клубтан чыгып китте. Гөлгенә, елардай булып, күзләре белән озатып калды.

— Чәчкә! — диде тагы Салих. Агасы эндәшмәде.

Эшкә нык иде Фәйзи. Кайту белән тракторга утырды. Нинди җаваплы, нинди авыр эш килеп чыкса — егет анда булды. Кайсы чак бригадир аңа, икенче сменага эшкә калырга сораудан уңайсызланып:

— Син, туган, рәнҗемә инде, аптыраганнан, кеше булмаганнан сиңа килеп төртеләм,— дисә:

— Хафаланма, агай, без өйрәнгән, матрос түзә ул,— дип кенә җавап бирә.

Яз җитте. Берчак Фәйзи тракторы белән фермага салам тарттырырга китеп бара иде. Авыл янындагы елгага җитсә — ни күзе белән күрсен: яр буена халык җыелган, кычкырышалар, кулларын болгап, елгага төртеп күрсәтәләр. Ни булган? Кызыксынып, егет тракторын туктатты да шунда атлады. Бәй, елгага бер сыер баткан түгелме соң? Күрәсең, елга аша чыкканда боз күтәрә алмыйча җимерелеп төшкәндер. Бахырның башы гына күренә. Ул чыгарга омтылып бозга башын да сала, аякларын да ыргыта, ләкин булдыра алмый, үзе ясаган бәке зурая гына. Бахырның хәле дә бетеп бара. Менә-менә бөтенләй югалачак.

— И-и, илаһым үлә бит,— дип, бер апа елап җибәрде.

— Янына барыр әмәл дә юк...

— Әйе, сыер белән бергә су астына китүең бар.— Ирләр үзләренең көчсезлеген белдереп кулларын җәя.

Эшнең нидәлеген тиз төшенде Фәйзи. Күп сөйләшеп торырга вакыт юк. Шунда бер җигүле ат тора иде, йөгереп барып тиз генә дилбегәсен алды да елгага сикерде. Боз шартлап ярылды, егет бил тиңентен суга чумды. Шунда гына бөтен халыкның күзе аңа төште.

— Ай, харап була бит бу бала!..

— Фәйзи, чык, үзең һәлак буласың!..

— Ничего, матрос Фәйзи әле ул, бирешмәс!..— диеште җыелган халык.

Егет бозны вата-вата алга барды. Салкын су аның бөтен тәнен көйдерде. Кан йөрешен әкренәйткәндәй итте.

«Бары тик тукталмаска, ничек тә алга»,— дип әмер бирде ул үз-үзенә.

Менә сыер. Күзләре канланган хайван ничектер мөлдерәп, ялварып, өметләнеп карагандай булды кешегә. Фәйзи тиз генә дилбегәне аның корсак астыннан уратып алды.

Инде эшне халык та аңлап алган иде. Кайдандыр тагын бау табып алдылар да бер башын Фәйзигә ыргыттылар. Ул аны дилбегәгә ялгады. Ярдагылар бауны әкрен генә тарта башлады. Фәйзи үзе ярган боз аралыгына турылап сыерны арттан этте.

Егет судан чыгу белән суык аны куырып алды, киеме салкын тимер булып катты. Бөтенесе аңа ашыкты: кемдер иңбашына толып салды, кемдер башындагы кәпәчен алмаштырды.

— Үпкәсенә генә салкын тидермәсә ярар иде...

— Рәхмәт, егет икәнсең!..

— Урының оҗмахта булсын,— диде карты-яше.

Аның тешләре тешкә тими иде. Ул тракторына сикереп менеп утырды да өйләренә юл тотты. Тиз генә өс киемнәрен корыга алмаштырды, бер стакан аракы эчте дә юрганга төренеп ятты. Ә кичен, берни булмагандай, тракторын паркка үзе үк илтеп куйды.

Шуннан аның абруе тагы да үсеп китте. Картлар да, ихтирам итеп, әллә кайдан ук сәлам бирә торган булды.

Сыер кемнеке иде соң? Ул Гөлгенәләрнеке булып чыкты. Аның әнкәсе көн-төн Фәйзине мактады. «Бәхетле кешенең кияве булыр»,— дип кызның йөрәгенә тагы да ут өстәде. Гомумән, Гөлгенәнең Фәйзигә карата булган мәхәббәте мәңге сүнмәс тә, сүрелмәс тә булып ялкынга әйләнде. Тик егет кенә һаман сер бирмәде.

Кыз аны тагы биюгә чакырды. Инде сөйләшергә сәбәп тә бар иде.

— Кереп чыгар иден безгә, әнкәй сиңа бик зур рәхмәтләр укый, кунак булырсың,— диде.

— Ә син?

Кызның күңелендә өмет уянды.

— Сыерыбызны мин дә яратам,— дип шаярткан булды ул.

— Сыерны гынамыни? — Егет тә шаяруга кушылды. Кыз башын иде.

Музыка тәмамланды, бию бетте. Фәйзи кызны урынына озатып куйды да тагын клубтан чыгып китте.

Җәй җитте.

— Сиңа, матрос кешегә, кораб бирәбез, кыр корабы,— дип, егетне, урак өсте җитә башлагач, комбайнга күчерде-

ләр. Матрос дәртләнеп техникасын урып-җыюга әзерли башлады. Үзе дә иксез-чиксез иген басуларында йөргән «Нива», «Колос»ларны өскә калкып чыккан су көймәсенә охшата иде ул. Шуңа күрә аның штурвал тотып шушы диңгезне айкыйсы, айкыйсы гына түгел, э көн-төн эшләп, алдынгы «капитан» буласы килде.

Авылда механизаторлар җитешми иде. Арышка төшәргә атна-ун көн калгач, колхозга авыл хуҗалыгы институтыннан берничә егетне җибәрделәр. Аларны берәмләп дигәндәй бригадаларга бүлделәр. Үзәктә какча гәүдәле озынча бер егет калды. Аны да комбайнга тәгаенләделәр.

Спорт костюмы кигән, чәчләрен бөтенләй төптән үк ялтлатып кырдырган бу егеткә Фәйзи тәүдә ныклап игътибар да итмәгән иде. «Килгән икән, әйдә, эшли бирсен. Ялан җитәрлек».

Ләкин кичен клубка Гөлгенә белән килеп кергәч, ничектер ачуы кабарды да китте. Әллә күңеленең бер төпкеленнән көнләшү сымак бер нәрсә дә тавыш бирде инде. «Кара син аны, Фантомас! — дип уйлап куйды ул.— Авылга ныклап аягын басарга өлгермәгән — кызлар җиненә ябышкан».

Ләкин энекәше:

— Аларда фатирда тора,— дигәч, тынычлана төште. Әйдә, ияреп йөрсен, барыбер кызлар вальсына Гөлгенә аны чакырачак, Фәйзи почмакта егетләр белән «ләчтит» сатуны дәвам итте.

Гармунчы: «Дамский!» — дип кычкырды. Егетнең бөтен тәне киеренке хәлдә катып калды. Менә Гөлгенә тагы елмаеп, аның каршысына атлаячак.

Кыз, чынлап та, урыныннан кузгалды, уртага чыгып, Фәйзи ягына атлады (егет җиңел сулап куйды), тик ярты юлга җиткәч, туктап калды, күзләре белән кемнедер эзләп тапты һәм кинәт йөзен балкытып студентны чакырды.

Фәйзинең яңагына чаптылармыни! Аның битенә кан йөгерде, күз аллары караңгылангандай булды. Ул кешеләргә бәрелә-сугыла ишектән чыгып китте.

— Студент! — диде мәгънәле итеп Салих.

Ни булганын үзе дә аңламады Фәйзи: шул минуттан аның уе һәрчак Гөлгенә турында гына булды. Аның зифа буе, яшьлек, сафлык бөркеп, тулышып торган гәүдәсе күз алдыннан китмәде. Моңа кадәр тәкәббер, игътибарсыз булуына Фәйзи үзен-үзе эттән алып эткә салып сүкте. Хәзер ничек тә кызны үзенә каратырга кирәк. Ә инде аның башка кеше яры булып китә алу ихтималлыгын башына да сыйдыра алмады ул.

Икенче көн кичке уенга чыгар алдыннан Фәйзи яхшылап кырынды, иң әйбәт костюмын киде, туфлиләрен көзгедәй ялтыратып тазартты. «Яки бүген — яисә беркайчан да!» — дип карар итте ул.

Менә биюләр башланды. Ләкин Фәйзи ак-кара күрмичә Гөлгенә янына йөгермәде. Монда түземлек, сабырлык кирәк. Югыйсә шунда ук абруең төшәчәк һәм син — жиңелүче. Олтырак булырга әзер торган егетне бер кыз да яратмый...

Ул шулай фикер йөрткән арада, колгадай буен селкетеп, студент Гөлгенә каршысында тора иде инде. Алар музыка тактына әйләнеп биеп киттеләр.

Баян икенчегә уйный башлагач та кымшанмады Фәйзи. Өметләнде, бүген Гөлгенә аны кызлар вальсына һичшиксез чакырыр кебек тоелды. Менә «дамский» да яңгырады. Гөлгенә бернинди икеләнүсез үзләренең фатирчысын чакырды.

Бу юлы Фәйзи ишекне шап итеп ябып чыгып китмәде, тешләрен генә ныграк кысты. Инде хәрәкәт итәргә вакыт житкән иде. Югыйсә соң булуы мөмкин. Тәнәфестән соң гармунчының танго уйнап жибәрүе булды, ул Гөлгенәгә табан атлады. Студент та шунда китте. Алар кыз янына икесе берьюлы барып туктадылар.

— Рөхсәттер бит? — диде Фәйзи, Гөлгенәнең кулыннан тотып.

Ләкин кыз кулын кырт кына тартып алды һәм:

— Юк, мин бүген Фоат белән биергә вәгъдә бирдем,— дип студент белән китте. Димәк, бу колганың исеме — Фоат.

Фәйзи бик аптырашта калмады. Мондый очракка да аның планы алдан әзерләнеп куелган иде. Ул бармакларын чиртеп жибәрде:

— Әй, дускай, туйдырды бу бию. Әйдәле, безнекен сызДырт...

Гармунчы — авыл егете, үз тиңдәше бит. Эшне ярты сүздән аңлады. Танго музыкасын кинәт туктатты да «Яблочко»ны уйнап жибәрде. Шуны гына көткән Фәйзи пинжәген салып энесенә бирде һәм уртага чыгып та китте. Әй биеде, әй биеде, аяк астыннан очкын, юк, очкын түгел, ялкын чыккандай булды. Моңа кадәр шулкадәр тырышып, шулкадәр чәмләнеп биегәнен ул үзе дә хәтерләми иде.

Менә ул шыбыр тиргә батып туктады. Бөтен зал кул чабарга тотынды. Фәйзи сабантуйдагы батыр рәвешендә эре генә үз урынына барып утырды.

— Йә, тагы кем? — диде гармунчы. Ул музыка, бию шаукымына бирелгән, уенны сүрелдерәсе килми.

Беразга клуб тынып калды. Шуннан кинәт бер көр, шаян тавыш яңгырады:

— Әйдә, уйна! — Бу — студент иде.— Шуны ук!..

Клуб гөж итеп куйды. Халык Фоатка аптырап, ышанмыйрак, хәтта бераз кызганып карады. Шулкадәр биюдән соң уртага чыгарга нинди батырчылык, нинди осталык кирәк! Хурлыкка кала бит кунак егете!

Ләкин студент бернинди икеләнүсез, ышанычлы адымнар белән уртага чыкты да аякларын чын матросларча тыпырдатып биеп тә китте.

Һәм халык гаҗәпләнеп, тынып калды. Әйтерсең лә Фәйзи!.. Юк, Фәйзидән дә әйбәтрәк бии иде шикелле ул. Залдагылар авызларын ачып студентка баккан, ә ул кулларын күкрәгенә куйган да елмаеп армый-талмый бии дә бии...

Матроска ничектер эссе булып китте, изүләрен ычкындырып җибәрде. Ул да ярдәм итмәгәч, тышка атлады, Салих, шәүлә сымак, аңа иярде...

Алар Фоат белән Гөлгенәне өйләренә табан борылган тыкрыкта каршы алдылар. Фәйзи аякларын киң аерып баскан, ике кулы кесәсендә, кашлары җимерелгән. Тегеләр култыклашып, нидер сөйләшеп, көлешеп килә иде. Багана башындагы электр лампасы яктысында егетләрне күргәч Гөлгенә кинәт «шым» булды, ә теге һаман әкиятен сөйли бирә. Ул Фәйзи белән Салихка игътибар итмичә кыздан күзен дә алмый үтеп китмәкче булды. Ләкин Фәйзи юлга аркылы төште.

— Әй, студент! — диде ул, теш арасыннан гына.

Тегеләр туктады.

— Әйе, тыңлыйм...— Егетнең йөзендә бер үзгәреш булса! Әйтерсең, шәһәрдә аннан кемдер юл сорый...

Моңа матросның ачуы аеруча кабарды, хәтта тотлыгып, бераз ни әйтергә белми торды. Ул күкрәгенә сугып алды.

— Беләсеңме, мин кем? — диде, ниһаять.

Студент җиңелчә генә елмаеп куйды.

— Әлбәттә... кеше...

Фәйзинең муенында кан тамырларына кадәр бүртеп чыкты.

— Мин — матрос, подводник. Матросларча кисәтеп куям: безнең кызларга кулыңны сузасы булма, шпаргалка...

Кинәт студент кычкырып көлеп җибәрде:

— Синме матрос? Син бит этәч!..

Бу мәсхәрәгә Фәйзи генә түгел, дөньядагы бер дингезче дә түзеп тора алмас иде.

— Ах, шулаймыни әле?..

Ул Фоатның пинжәк якасыннан алды.

Гөлгенә куркып, кычкырып җибәрде:

— Фәйзи, ни эшлисең?..

Ләкин шул ук секундта диярлек матросның беләгеннән ниндидер тимер кыскыч кысып алгандай булды, бу — студентның кулы иде. Фәйзинең бармаклары үзеннән-үзе язылды, ул пинжәкне ычкындырды.

Ә Фоат берни булмагандай өс-башын каккалады да:

— Нәрсәдә тукталган идем әле мин? — дип Гөлгенәне култыклап алып та китте.

— Полундра-а! — диде аптыраган Салих. Аның агасыннан көчле кешене беренче күрүе иде.

Фәйзи эчендәге бөтен ачуын энесеннән ала язды.

— Цыц, чебеш!

Менә уракка төштеләр. Фоат белән Фәйзи икесе бер урып-җыю транспорт отрядына туры килде.

— Әйдә, карап карыйк әле кемнең кем икәнен...— диде эченнән генә матрос. Энесен, өйрәнә торсын дип, үзенә ярдәмче итеп алды һәм алар чын күңелдән эшкә керещте. Икесе дә бер басуда булуга, бергә көндезге ашка җыелуга карамастан, студент белән матрос бер-берсенә «исәнме», «саумы»дан тыш сүз кушканнары юк.

Тәүге биш көн үтеп тә китте. Идарәдә йомгак ясауларын Фәйзи түземсезлек белән көтте. Ниһаять, агитатор итеп тәгаенләнгән Гөлгенә ашлык ташучы машинага утырып килеп җитте. Ул иң башта Фәйзиләр комбайнына табан атлады. Егетнең йөрәге «жу» итеп китте. «Мин!» дигән уй йөгереп үтте аның башыннан. Менә Гөлгенә килеп җитәр дә елмаеп: «Котлыйм, Фәйзи, чын егет икәнсең»,— дип әйтер сымак тоелды аңа. Үбеп тә алмас микән? Бу ләззәтле уйлардан аның күңеле бөтенләй эреп китте. Ул, комбайнын туктатып, җиргә төште.

Ләкин кыз килеп исәнләште дә:

— Мәгез, «Молния», элеп куегыз,— дип, кулына тереп тоткан кәгазьләрнең берсен Салихка сузды да китеп барды.

Малай кәгазьне җәеп җибәрде. Анда зур хәрефләр белән «Беренче бишкөнлектә ярышта алга чыккан комбайнчы, авыл хуҗалыгы институты студенты Фоат Искәндәровтан үрнәк алыгыз» дип язылган иде.

— Бункерга ябыштырабызмы? — Салих абыйсының йөзе бозылуын абайламый калды.

— Нәрсә, ул сиңа игъланнар тактасымыни? — диде Фәйзи ачу белән һәм комбайнына сикереп менде дә кузгалып китте.

Ул алдагы бишкөнлектә ничек кенә булса да беренчелекне яулап алырга булды. Шуңа күрә комбайнын көндез дә туктатмады — энесе белән чиратлап ашадылар.

Аннан Салихка өстәмә бер эш йөкләтелде. Арытаба үзләреннән һәм студент комбайныннан төяп киткән һәр машинаны язып барырга тиеш булды ул. Бункер саен дәфтәргә бер таяк! Һәм көн саен кичен шул таякларны саный бардылар.

Ләкин эш һаман күңел хушланырлык түгел иде. Берүзе булуына карамастан, теге Фәйзиләрдән һич калышмады. Икесенең дә суккан ашлыгы бәрабәр.

Ичмасам, комбайны да ватылмый бит, майлаган сәгать кебек йөри,— дип сукранды матрос, дүртенче көнне таякларны исәпләгәч.

Ләкин иртәгәсен студент комбайнын кабыза алмады. Башкалар басуны бер әйләнделәр... өч... Ә ул һаман эш башлый алмый. Шулай итеп ике сәгать тә үтте... Өченче сәгатьтә механиклар, инженерлар җыелып, комбайнны энәсеннән җебенә кадәр тикшереп, майларын алмаштырып, ниһаять, кабыздылар. Ләкин бу вакытта инде Фәйзи байтак алга китеп өлгерде.

Иртәгесен «Молния» аңа багышлап чыкты. Башка мактау сүзләре белән бергә «Матроска басу корабы да буйсына» дип язылган иде анда.

— Котлыйм! — диде Гөлгенә, аңа вымпел тапшырып.— Әйдә, арытаба да сынатма!

Бу сүзләр ничектер ягымлы булып ишетелде Фәйзигә. Аңа уракка төшкәннән бирле тәү тапкыр рәхәт булып китте.

— Ничего, без, матрослар, бирешә торганнардан түгел,— дигән булды ул эре генә.

Аның эче тулы шатлык иде.

Ләкин бу куаныч озакка бармады. Комбайн көтмәгәндә ташка барып менде һәм ургычның чалгысы кырылып та чыкты.

Егет, сүгенеп, арттан килгәннәргә юл биреп, комбайнын читкә алды. Ул җиргә төште, уфтанып җилкәсен тырнап алды — монда өч-дүрт сәгатьлек эш бар иде.

Янга тагы бер комбайн килеп туктады. Аннан студент сикереп төште.

— Ни булды?

Матрос аяк очы белән генә чалгыга күрсәтте.

— Тә-әк,— Фоат бераз уйлап торды һәм: — Ярдәмчеңә комбайнны ышанып тапшырырга буламы? — дип сорады.

Фәйзи аптырап калды.

— Ә нигә?

— Соң ул минекендә ура торса, без икәү моны тиз генә төзәтеп алыр идек.

— Кирәкмәс,— диде матрос, сер бирмәскә тырышып.— Без аны энекәш белән хәзер бергәләп алабыз.

Ләкин шул вакыт Салих сүзгә килеп кушылды:

— Ә нигә, агай, мин булдырам аны...— Үзе инәлеп бер абыйсына, бер студентка карады. Аның бик тә комбайнда үзаллы йөрисе килә иде.

Фәйзи икеләнә төште:

— Белмим шул... Моның эше күп түгел инде, югыйсә...

— Бар, алайса,— студент, малайны хуплап, аркасыннан кагып алды. Үзе комбайнының запас частьлар йөртә торган ящигына үрелде.

— Эш вакытында төрле чак була инде,— дип сөйләнде ул, ургыч бармаклары, чүкеч-сандал алып килеп.— Әнә бит, элгәре көн минем бензин багына да кемдер тоз салып киткән...

Матрос дертләп китте, әйтерсең, аның башына китереп суктылар...

Ашыгыч техник ярдәм машинасында слесарьлар килеп житкәндә, егетләр эшне бетереп баралар иде инде.

— Ярый, иптәш, башкача ватылма...

Фәйзи аңа кул болгап калды. Шуннан, бер сәгать чамасы комбайнны ватмыйча иген уруына шатланып елмаеп торган энесен комбайн артына алып чыкты да яңагына сугып җибәрде:

— Бу сиңа тоз өчен...

— Соң мин бит синең өч-е-н ты-рыш-тым,— диде Салих, күз яшьләрен сөртеп.

— Ә мин сиңа куштыммы?

Теге башын аска иде...

Урак өсте тәмамланды. Колхоз җитәкчеләре, бөтен халыкны клубка җыеп, тантаналы зур җыелыш ясадылар. Анда ярышта беренчелекне алган студент Искәндәровка баян, икенче урынны алган матрос Фәйрузовка радиоалгыч тапшырдылар.

Халыкның күңеле шат, бәйрәмчә. Айдан артык рәтле йокы, ял күрмәсә дә, берсе дә кайтырга ашыкмый. Җыелыштан соң бөтенесе дә диярлек кинога калды.

Киномеханик аппаратын көйләгән арада, Фәйзи күзләре белән Гөлгенәне эзләде. Ләкин ул клубта күренмәде.

Шулвакыт кемдер аның җиңеннән тартты. Бу — Салих иде.

— Сине чакыралар,— диде ул.

— Кем?

— Чыккач күрерсең...

Энесенең тупаслыгына кәефе кырылып, егет тышка чыкты.

Ишек төбендә аны Фоат, Гөлгенә һәм тагы бер ят кыз көтеп тора иде. Студент, ихлас күңелдән елмаеп, егеткә кулын сузды.

— Иртәгә иртүк китәм, Фәйзи, хушлашырга дип чакырттым. Менә арттан бичә дә килгән.

Матросның күзе дүрт булды:

— Бичә?!.

— Әйе, ул икенче районда практикада иде...— һәм, Фәйзинең тәмам аптыраганын күргәч өстәде: — Без бит сине Гөлгенә белән шаярттык кына... Гафу ит инде, мин дә бит матрос...

— Ә?..

— Әйе, матрослар, белүеңчә, шаяртырга ярата...

Сүзгә Гөлгенә кушылды.

— Ярый, әйдәгез, әнием кичке чәйгә көтәдер...— диде ул, хәйләкәр елмаеп.

— Киттек, алайса. Хуш, матрос, алдагы елга, бәлки, тагы сезнең колхозга җибәрерләр...

Исен-акылын җыя алмаган Фәйзинең берүзен калдырып, алар кайтыр якка атлады...

Икенче көн кичке уенны егет чабышка әзерләнгән ярсу ат кебек ашкынып көтте. Баянчы тәүге вальсны уйнап җибәрүе булды — ул беренче булып уртага чыкты һәм иң чибәр, иң мут, иң акыллы, иң уңган кыз янына килде.

— Биергә чакырырга мөмкинме, Гөлгенә?..

ДИНИС БҮЛӘКОВ

Динис Мөдәррис улы Бүләков 1944 елда Башкортстанның Мәләвез районы Арслан авылында туа.

Урта мәктәпне тәмамлагач, бераз колхозда эшли. Шуннан авыл хуҗалыгын механикалаштыру һәм электрлаштыру техникумында укып, техник-механик була.

Хәрби хезмәттән кайткач, Уфага газета эшенә чакырыла. Бер үк вакытта ул читтән торып М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый.

Д. Бүләков күп еллар республика «Пионер» журналының баш редакторы булып эшләде. Хәзерге көндә Башкортстан радио һәм телевидение комитеты председателе.

Әдип «Кояш ярчыгы», «Авылымның ак өйләре», «Акбүз алышка чыга», «Сары сандугач баласы», «Кыңгырау чәчкә», «Кыерчык ай», «Чаган яфрак яңарта» дигән җыентыклар авторы, республика комсомолының Г. Сәләм исемендәге премия лауреаты.

Д. Бүләков 1973 елдан СССР Язучылар союзы члены. Партия сафына 1966 елда кабул ителгән.

ЧИРАТ КӨТКӘНДӘ

Алар бер өйдән чыкса да, икесе ике яктан килде. Маһинур туры юлдан, ә Шәһит, хатыны белән очрашмас өчен, тыкрыктан атлады. Ләкин авыл советы йортының ихатасына кергәч, аптырашып калдылар. Әйтерсең, сөйләшеп куйганнар инде: Маһинур үрелгән ишек тоткасына Шәһит та кул сузып тора. Шунда алар, ялгыш кына бер-берсенең кулына кагылып китеп, утка пешкәндәй, кинәт кенә читкә тартылдылар. Икесе дә бер-берсенә юл бирде.

— Әйдә, нигә маңгаең бәрелгәндәй туктап калдың, син кер беренче булып! — Мәһинур әзгә генә карашын иренә ташлады да горур башын читкә борды. Синең белән башкача сөйләшәсем дә килми, янәсе. Бу минутта аның нечкә кашлары югары чөелде, күзләрендә очкыннар сикереште. Чокырланып торган бит очлары тагы да алсулана төште. Хатынының бүлтәеп кысылган иреннәренә карап сокланып куйды Шаһит. «Ачулану нинди килешә үзенә»,— дип уйлап алды. Үзе, сер бирмәскә теләп, салкын гына эндәште:

— Үзең кер, син башладың бит!..— Шаһит та, ике кулын кесәсенә тыгып, ишек төбендә баганадай катып калды. Хатыны кымшанмый да, ичмасам, шуңа җаны көеп китте. Нишләргә белмәде, ашыгып сигарет кабы тартып чыгарды кесәсеннән. Шуннан берне алып кабызды да исе китмәгән төс белән:

— Бездә хатын-кызга почет,— дип арткарак чигенде һәм ишеккә ымлады. Үзе, тәмәке тартып керергә тиешлеген сиздереп, стенага ук сөялде һәм, һичкемгә игътибар итми, комсызланып тарта башлады. Үзен тыныч тотарга тырышса да, йөрәге, җилпелдәп, күкрәгеннән чыгып килә иде. Сигарет тоткан кулының җиңелчә генә калтыранганын сиздермәс өчен, тәмәкесен теш арасына кыстырып, кулын кесәсенә тыкты. Әллә төтеннән, әллә болай гына уң күзен кыса төшеп, хатынына карап тора башлады. Озынча какча йөзендә кимсетүле елмаю галәмәтләре калыкты. «Әйдә бая бик шәп идең бит», дигән кебек үзе.

Мәһинур иренә җелт итеп карап алды да, тегенең хәйләсе барып чыгуга гарьләнеп, иреннәрен тешләде. Чакчак кына елап җибәрмәде ул шушы минутта. «Нахал, житмәсә иренен чалшайтып тора», дип уйлады эчтән генә. Керергә кирәк, башка чара юк.

— Эгоист, гомерең буе шулай булдың инде,— диде Мәһинур, кулъяулыгы белән күз төпләрен шыпырт кына сөртеп. Шуннан чыртлатып сумкасын япты, яше утыздан үтсә дә, әле кырыкка җитмәгән хатын-кызларда гына була торган килешле хәрәкәтләр ясап, кабарынкы сары чәч бөдрәләрен озынча бармаклары белән артка сыпырды. Аның бу кыланышын ярата Шаһит! Әле шуңа сокланып карап торды. Ләкин иртәнге сөйләшүне исенә төшереп:

— Эгоист дип син генә әйтәсең бит, әйдә инде,— дип сүз кыстырырга ашыкты. Ихата капкасының шыгырдап ачылуын ишеткәч: — Гаризаны да башлап үзең яздың,— дип өстәп куйды. Ничек тә хатыныннан ныграк үч алып каласы килде шушы минутта. Мәһинур, аңа кинәт башын

борып, нәфрәтле карашы белән бер көйдереп алды да:

— Ярар...— дип куйды тамак төбе белән, әмма сүзен ары дәвам итәргә туры килмәде, якында гына ишетелгән аяк тавышларын абайлап, җәһәтрәк ишекне ачты. Аның каты-каты басып үткәненә караганда, күңелендә әйтеп бетелмәгән үкенечле хәбәре калган иде. Моны Шаһит шунда ук сизенде. Димәк, алар арасындагы әрепләшү эчтә дә дәвам итәчәк әле. Шуңа сагая төште. Һич тә кеше күп җирдә бу турыда сөйләшәсе килми иде. Берәүләр тантана итәчәк, икенчеләр, бәлки, чын күңелдән аларны жәлләр. Кем белә инде... Ә хатыны чатнатып бөтенесе турында да сөйләячәк. Имеш, ул, Шаһит, аның озак еллар колхозда шофер булып эшләвенә дә төкерим, азгын, өйгә сирәк кайта, кайтканда да төн уртасында да таң алдыннан... Шул Гамбәриясе белән гүләйт салдыра, белеп торам... Шаһит беразга гына хатынын күз алдына бастырды. Әйе, нәкъ әле ул уйлаганча, ярсып, елый-елый сөйләячәк Маһинур бу турыда. «Шул Гамбәриясен алсын да торсын, бик тансык булгач,— диячәк.— Мин аның белән яшәмим, җитте, ун ел этләнүем башымнан ашкан...»

Кемдер Шаһитның уйларын бүлдерде.

— Нигә алай, Шаһит туган, авыл советы ишеген саклап торасың әле?

Әйләнеп караса, янына Бәгыйдә апасы килеп туктаган икән. Оятыннан җир тишегенә керердәй булды Шаһит Тиз генә тәмәкесен читкә олактырды, өс-башын какты, елмаерга итте. Ләкин килеп чыкмады, ахрысы, каушап кына:

— Саумысыз, апа,— дип эндәшкән булды. Көтелмәгән очрашу шул, каушарсың да. Бәгыйдә апа — аның беренче укытучысы. Тәүге хәреф танырга өйрәткән кеше. Авылда да үзен бик ихтирам итәләр. Ире белән кушарлап гомер буе балалар укыттылар. Хәзер Бәгыйдә апа пенсиядә, чәчләре дә нык чалланган икән шул. Йөзен җыерчык каплаган. Әмма күзләре үтә теремек. Шаһит аларны күргәч, дәресен әзерләми килгән укучы бала кебек, кызарынып китте, күзләре җиргә төбәлде.

— Олыгаеп та барасың инде әллә? — диде Бәгыйдә апа, һаман аннан карашын алмый. Шаһит елмаеп җибәрде.

— Бәгыйдә апа, ни бит, киләсе ел кырык яшь бит инде.— Шушы сүзләрдән үзенә җиңелрәк булып китте. Әле генә күңелен борчыган уйларын да оныткандай итте. Әнкәсе кебек якын ул Бәгыйдә апа. Үзенең укучыларын күрсә, сөйләшеп сүзе бетми. Хәер, аларның Маһинур бе-

лән өйләнешүендә дә Бәгыйдә апаның турыдан-туры кысылышы бар. Ул чакта Шаһит, армиядән кайтып, яңа гына шофер булып эшли башлаган иде. Колхоз китапханәсенә утын китереп аударып йөри иде ул. Тап шул мәлдә ишектән, култык астына китаплар кыстырып, шушы Бәгыйдә апа килеп чыкмасмы. Әле ул заманда укыта иде. Шаһитның шулкадәр житез эшләвенә сокланып карап торды да, килеп, әлегедәй аркасыннан сөйде.

— Менә, туганкай, син дә кеше булдың, рәхмәт,— дип куанган иде ул.— Инде солдаттан кайттың, һөнәрең бар. Матур итеп тормыш көтәргә генә кала.— Шуннан ул артына әйләнә биребрәк карап торды да: — Ә син китаплар укуыңны ташламадыңмы әле? — дип, култык астындагы китапларына ишарәләде.

— Вакыт барда укыштырам,— дип җаваплаган иде шикелле Шаһит. Ләкин Бәгыйдә апа моның белән генә тынычланмады.

— Әйдә әле, алайса, әйдә,— дип, кулыннан житәкләп дип әйтерлек, китапханәгә әйдәде. Үзе һаман әлегә кадәр Шаһитка таныш булмаган китапханәче кызны мактады.— Шундый да уңган, шундый да инсафлы, техникум бетереп кенә килгән. Үзе белемле, культуралы, кеше белән дә сөйләшә белә. Укымаган җирдән укырсың ул биргән китапны...

Әйе, Бәгыйдә апа, чынлап та, аларны таныштырып китте. Бу мәлдә үзе ни уйлагандыр инде, билгесез, әмма тыйнак кына елмаеп басып торган китапханәче кызның бәләкәй генә йомшак кулын кысканда да, аның сөрмәле озын керфекләре астыннан караган оялчан зур зәңгәр күзләре белән ялгыш кына очрашып куйганда да чиксез дулкынлану кичерде Шаһит. Аның атлап йөрүләре дә, китап алырга дип иелгәндә килешле генә чүкәеп, гаеп итмәгез инде, дигәндәй, «елт» әйләнеп бер елмаеп куюы да охшаган иде ул чак егеткә. Әнә шул көннән алып ул иң актив китап укучыга әйләнде... Күңеле гел китапханәгә генә тартты да торды...

Әле, шуларны хәтерләгәч, Шаһитка кыен булып китте. Бәгыйдә апаның юкка гына Маһинур белән таныштырмавын азак кына аңлаган иде ул. Менә, шул Бәгыйдә апа әле аның алдында басып тора. Сорауларына ни дип җавап бирергә дә белми Шаһит.

— Улыгыз Хәмитне әйтәм, үсәме соң? — дип сорый Бәгыйдә апа.

— Үсә, хәзер зур инде.

— Ничә яшь булып китте инде, һай, хәтер дигәнең?..

— Тугызы белән бара.

— Вәт үткән гомер. Әйләнеп карарга да өлгермисең...

— Сез ни, Бәгыйдә апа, үзгәрмәгәнсез. Минем өчен һаман элекке укытучы чагыгыздагы Бәгыйдә апа кебек сез,— дип хәбәрне тизрәк читкә борырга итте Шаһит.

— Һи-и, туганкай, шул сиңа гына элеккечә күренмәсәм ни...— Бәгыйдә апа кеткелдәп көлеп алды.— Картаябыз, картаймаган кая. Үзең дә тик тормыйсың бит. Әйткәндәй, Хәмитегез нигә күренми әле. Югыйсә минем онык лар кунакка килгәндә, бездән кайтмый торган иде?

«Каптым!» — дип уйлап өлгерде Шаһит, тәне эсселесуыклы булып китте.

— Каникул бит, кайнанамнарга кунакка җибәрдек,— дип җаваплады ул, һәм, бераз шүрли төшеп, кабат бу турыда сорашмавын теләде.

— Әйбәт, бик әйбәт, әйдә кунак булсын. Ә... Маһинур нихәлдә? Саулыгы ничек?

Шаһит янә «дерт» итеп калды. Күз алларында йолдызчыклар сикерешеп үтте. Нәрсә дисең соң? «Аерылышабыз»,— дип әйтә алмый бит инде ул Бәгыйдә апага. Олы йөрәкле шушы апаның күңелен һич тә генә китәсе килми иде. Ә Бәгыйдә апа чынлап та кайгырачак алар өчен. Бу — көн кебек ачык. Туйда бит ул беренче булып алар бәхетенә тост күтәргән иде. Моннан ун ел элек булган хәл, әмма ул көн бүгенгедәй күз алдында тора. Нәрсә дигән иде әле шунда Бәгыйдә апа? Ә, әйе, Маһинур белән Шаһит кебек пар килешкән кешеләр бик аз, бер-берсенә төсләре, холыклары белән дә охшашып торалар, алар бәхетле булачак, мин моңа бик ышанам, дигән иде. Бу сүзләрнең мәгънәсен яхшы аңлый Шаһит. «Минем укучым бит ул!» — дигән горурлык тойгылары да чагылды аларда. Бәгыйдә апа тормышта да шулай гел генә кыек атып туры тидерергә яратты инде. Күзләре дә үзенең: «Теге вакыт мин сезне юкка гына таныштырдыммыни?» — дип, елмаеп караган иде шунда.

Әйе, танышу юкка булмады. Маһинур, китапханәче кызыкай, шул көннән башлап Шаһитның уеннан чыкмады. Гел генә шул зәңгәр күзле сөйкемле кызыкайны күрәсе килде дә торды егетнең. Көн саен китапханәгә йөреде. Кичләрен клубларда да очратты. Яшьләр яңа кызга (ул шәһәр кызы иде) җиңел генә ияләште дә китте. Егетләрнең кайсыберләре аның кулларыннан тотып биергә дә батырчылык итте. Бигрәк тә Басыйрга хәйран кала иде Шаһит. Шундый да кыю кеше булыр икән. Хәер, ФЗОда укып йөргән иде шул. Авылга кайтып, клубка тәүге

килүендә үк Маһинурны күреп алып, аның белән танышырга да өлгерде. Кич буе бергә биеделәр. Күп егетләр Басыйрга көнләшеп карады. Ә ничәмә көннәр ут йотып йөргән Шаһит һаман да кызыкай белән исәнләшеп калудан ары үтмәде. Күңеленнән шулкадәр нык көнләште ул бу кызны Басыйрдан. Гәүдәгә аннан чебегрәк булса да, бердәнбер көнне Маһинурны фатирына озатып куйганнан соң, аның белән якалашыр хәлгә җитте. Ләкин табигате белән оялчан, һәр тавышлы нәрсәдән тартынып баруы аның бу ниятләрен дә тормышка ашырырга бирмәде. Басыйр китапханәче кызның артыннан бер тотам да калмый йөри башлады. Бу турыда хәзер бөтен авыл белә иде.

Шаһит Басыйрның нинди егет икәнлеген дә сизенде. Күңеле кутырлы иде аның. Җыелышып бергә утырган чакларында бу турыда ачыктан-ачык әйтә торган иде. Отпускасы беткәнче йөриячәк тә, янәсе, азак шәһәргә олагачак. Ә инде кыз алданып калса, үзенә үпкәләсен...

Беркөнне Шаһит, йомышларын төгәлләгәч, соңлатып кына район үзәгеннән авылларына кайтырга чыкты. Машинасына яңа культиватор төяп алган иде. Шуны яздырып, чират көтеп төяткәнче, соңлабрак китте. Район үзәген чыгарак, автобус тукталышында, Маһинурны күреп калды. Бер-ике кәгазь төргәк тә тоткан иде теге. Тукталмаска да иткән иде тәүдә Шаһит. Басыйрдан үзен көнләшеп йөргәнен беләдер дә бик уңайсыз тоелыр кебек иде. Ләкин автобусның башка булмаячагын хәтерләп, тормозга басты. Кызыкай аптырап та китте хәтта:

— Шаһит!..

Аның исемен тәүге тапкыр телгә алуы иде кызның. Әллә ничек рәхәт булып китте егеткә. Шулай да, Басыйрны күз алдына китереп, эндәшми калды. Кинәт ташып чыккан хисләре суынды.

— Ә мин, книготоргтан яңа китаплар алып йөреп, соңлап киткәнмен,— дип сөйләнде Маһинур, төргәкләрен кабинага куеп.— Чыксам, автобус киткән. Аптырап тора идем әле. Әле дә син очрадың, Шаһит...

Маһинур шундый матур итеп, зәңгәр күзләрен тутырып карады, Шаһит хәтта ни дип җавап бирергә дә белмәде.

— Ут-утырыгыз...— дип кенә мөңгерәп куйды.

Менә Маһинур аңа ап-ак нәфис кулын суза.

— Шаһит, зинһар, тарт әле,— үзе, бит очлары алсуланып китеп, ояла.— Күтәрелеп булмый, тар юбка кигәнмен дә...

Кызның кулын тоту шофер егеткә бозлы судан кайнар суга ыргыткандай тәэсир итте.

Кузгалдылар. Шаһит башына кинәт сәер бер уй килеп куйды. «Шушы куллары белән Басыйрны кочаклыйдыр әле...» Моннан соң ул тик алга гына карап барды. Юл начар иде. Җитмәсә, культиватор машинаны як-якка чайкый.

Маһинурның баядан бирле сөйләшәсе килгәнлеген дә сизә ул. Башлап сүз кушарга тартына! Аннан килеп... кеше яры бит.

Байтак юл үттеләр. Кызыкай да нигәдер боегып калды. Кулларын күкрәгенә кушырды да иксез-чиксез булып сузылып киткән көрәнсу офыкка төбәлеп тик килде. Көн нык кичләгән иде. Шаһит машинасының фараларын кабызып җибәрде. Ләкин фараларның берсе «былт-былт» итеп килде дә сүнде. Алар туктарга мәҗбүр булды.

Ерактагы таулар сыртыннан, җиз подностай, тулган ай күтәрелеп килә иде. Аның нурлары юл тасмасын сихри моңга төрде. Әкрен генә җил исте. Юл читендә башаклар кыштырдашты.

— Их, киче дә соң, киче! — дип хисләнде җиргә төшеп өлгергән Маһинур, сокланып. Шаһит отверткасы белән фараны сүткән бер арада аңа сирпелеп карады. Һәм аның шулкадәр ыспай буй-сынына хәйран калды. Кабат күтәрелеп карамас өчен, кепкасын батырыбрак киде дә эше белән булды. Ә теге, үч иткәндәй, аның янына ук килеп басты. Тын гына Шаһитның нишләгәнен күзәтте. Шуннан, егет эшен бетереп кулларын сөрткәч, сорап куйды:

— Шаһит, ә син нигә минем белән сөйләшергә теләмисең? Гел генә...

Шаһит калкынып басты. Беренче тапкыр якыннан Маһинурның күзләренә карады. Төпсез дингез кебек серле иде алар.

— Ничек, гел генә?

— Шулай шул. Урамда очраганда да...

— Әллә инде. Әйтер сүзем булмагач.

— Ялганлыйсың. Синең күзләрең икенчене сөйли.

— Һе...— Шаһит беразга гына югалып калды, шулай да үзен тиз үк кулга алды.— Миннән башка да теңкәңә тиючеләр бардыр әле.

— Их, син...— Маһинур аңа чәнечтереп бер карады да кабинага юнәлде. Үзенең бөтен кыяфәт-торышы: «Ә минем синең белән сөйләшәсем килә»,— ди иде шикелле.

Ары кузгалгач, Шаһит батыраеп китеп, эндәшеп куйды:

— Басыйр телгә оста бит...

Әнә шулай аңлаштылар алар. Мәһинур Басыйрны күралмавы турында әйтте. Нинди адәм икәнлеген бик тиз төшенгән икән.

Көн артыннан көн үтте. Ныклап яратыштылар да киттеләр. Дөрес, азаграк Басыйрның: «Мин ул Шаһитның кикриген тиз шиңдерермен әле, Мәһинур барыбер минеке булачак»,— дигән хәбәре ишетелеп калды. Тик моңа игътибар итүче генә табылмады. Әнә шулай, туй ясап, яшәделәр дә киттеләр. Күпме бергә торылган. Мәхәббәтләре дә саф булды. Тик әле килеп кенә... Ни дип әйтерсең инде Бәгыйдә апага? Мәһинур ни хәлдә, ди бит.

Шаһит шуларны кичереп торды-торды да:

— Ару әле, ару Мәһинур,— дигән булды. Үзенең керфекләре түбән карады. Бәгыйдә апа да сизми калмагандыр, әлбәттә. Тик сер генә бирмәгәндер.

— Ярар, бәхетле торыгыз,— дигән булды. Хәбәрне икенчегә борды.— Менә, картны әйтәм, оныкларны алып китте дә оланнарга, ялгызым калдым. Тик ятуы кыен, берәр ярдәмем тимәсме дип, килүем. Председатель үзендәме икән?

— Әллә, мин яңа килеп торам. Мәһинур чират алырга керде...

Бәгыйдә апа Шаһитка яңа күргән кешесенә карагандай итеп тагы бер карады да күтәрмәгә күтәрелде.

— Йомышыгыз бармы әллә? Югыйсә эш вакыты...

— Әйе...— дип көчкә җаваплады Шаһит һәм, Бәгыйдә апа кереп китү белән, тизрәк тәмәке кабызды. Күзләре алдына янә Мәһинур килеп басты. Председатель бүлмәсендә нинди тавыш куптарачагын күрәзәлек кылырга тотынды. Җитмәсә, анда Бәгыйдә апа да булгач, ул хәзер тиз генә моннан чыкмаячак, Мәһинур тагы да ярсый гына төшәчәк. «Гамбәрия белән чуала, минем белән канәгать түгел,— дип әйтәчәк ул.— Төндә машинасына утыртып районга алып барган, аннан кайтышлый, урманга борылып кергәннәр... Аннан төн авышкач кына кайтып керде. Тегесе дә бит, битсез, урам уртасында гына машинасыннан төшеп калды, чуалышулары буш хәбәрдер дигән идем, кеше сөйләгәч, чыктым. Үз күзләрем белән күрдем. Әле монысы аның чүп кенә... Тормыйм, бер минут яшәмим Шаһит белән... Аерыгыз безне, менә минем гаризам!»

Шаһит тәмәкесен нык итеп эчкә алды да куен кесәсенә тыгылды. Дүрткә бөкләнгән дәфтәр битен капшау белән тынычлана төште. Ул да хатынының авызына карап тик кенә тормаячак, шушы гаризаны өстәлгә салачак. «На-

хак сүзләр»,— дип әйтәчәк ул иң элек. Шаһит хәтта ничек итеп гаризаны куен кесәсеннән чыгарачагын, ничек атлап барып авыл Советы председателе каршысына басачагын ачык кына күз алдына китерде. Әйе, ялган сөйли Маһинур, дип дәвам итәчәк сүзен. Әнә шунда бөтенесен дә, быел колхоз үзен сөт машинасына утыртуын да, үткәнендә сөт заводында чират зур булу сәбәпле, бер машина сөт әчүе, шуның өчен ферма мөдире Гамбәриягне кайтып алып, яңадан район үзәгенә юллавы, ә инде кайтышлый, ачыган сөтне әрәм итмәс өчен, дуңгызлар фермасына борылуы, ватылып утырулары турында бәйнәбәйнә сөйләячәк. Хәтта Бәгыйдә апаның күзләренә туры караудан тартынмаячак ул. Чөнки күңеле саф, намусы таза. Ә халык юкны бар итеп сөйли икән, әйдә, сөйли бирсен, шуның өчен халык бит ул. Әмма Маһинурның үзе турында бер нәрсәне дә яшереп калмаячак. Басыйрның, сөяркәсенең, әле авылда ятуы, көннәр буе шул китапханәдән чыга белмәве хакында да тезеп салачак. Кешеләр күргән инде...

Шулчак Шаһит Маһинурның әле кереп киткәнендә әйткән «эгоист» дигән сүзен хәтеренә төшерде. Хәтта башын чайкап куйды. «Һе, таба бит сүзен дә,— дип уйлады ул,— тегендә дә шушы сүзләрне кабатлаячак әле. Әйе, һичшиксез кабатлаячак»... Үзе дә каршы әйтергә җавап әзерләп куярга булды. Тик ни дияргә соң? Шунда Шаһитның хәтеренә кылт итеп газетадан укыган бер сүз килеп төште: «Аморальный...»

— Без дә төшеп калганнардан түгел,— дип шыбырдап куйды ул үзалдына. Шуннан янә сөйләячәк сүзләрен хәтерләргә тотынды. «Без,— дип әйтәчәк ул,— бала үстерәбез. Малаебыз буй җиткереп килә. Ә шушыңа карамастан Маһинурның чит ирләр белән чыш-пыш килеп утыруы, бигрәк тә эш вакытында, ошамый, ул — амораль эш дип атала. Вәт!..» Һәм тагы да соңгы сүзе итеп шуны өстәячәк: «Әйе, гаризамнан баш тартмыйм. Гаилә таркалуда тик Маһинур гына гаепле...»

Шулардан соң Шаһит тәмәкесен итеге белән изде дә, үзендә билгесез көч тоеп, ишек тоткасын үзенә тартты.

Коридорда хатынынннан башка тагы да берничә кеше бар иде. Бөтенесе дә председательгә керү өчен чират көтеп утыра, күрәсең. Маһинур иң соңгысы. Шаһит кая утырырга белми карап торды да, авылдашларының кызыксынулы карашларын очраткач, шыпырт кына хатынынннан артып калган эскәмия башына кунаклады. Маһинур, башын калкыта биреп аңа карап, кысталыбрак утырып,

аңа урын киңәйтте. Икесе дә өнсез калды. Ахырда, башка кешеләр юк-бар уй уйлап куймасын дип, сүз кушарга булды.

— Кеше күбрәк икән бүген.— Тавышы «без, бик тә булмаса, иртәгә дә килә алабыз», дигән кебегрәк яңгырады. Маһинур да әвәс кенә җавап бирде.

— Күп шул. Эш кала инде.

Шаһитның хатынына булган үпкәсе нишләптер кимегәндәй тоелды. Аның кофтасына ябышкан чүпне күрә, хәтта алып ташларга да итә, ләкин тыелып кала. Терсәкләрен тубыкларына бастырып, башын учлары белән каплый да тынып кала. Инде башкаларның хәбәренә колак салганда да ярый. Ни сөйлиләр икән? Аларның эшен сизеп калмаганнармы?

Шундагы бер әби, чиратта ул беренче утыра, сельпога сөт тапшырып та акчасын ала алмый йөргәненә зарлана.

— Куй инде, авызыбыздан өзеп илтеп бирәсең, рәхмәт әйтү юк, артыннан юллап йөр...

Аңа ир кеше тавышы кушыла.

— Булган акчаны, әбекәй, бирерләр, жалуга килмәсәң дә... Ә менә минем тана ужым җирендә ятып үлгән. Эче күбеп, председатель белән сөйләшеп карыйм әле, страховкасы чыкмасмы икән?..

Икенче бер яшьрәк хатын улына паспорт алу өчен справка юллый икән. Шуларны тыңлап утырды-утырды да Шаһитның җаны көеп китте. Һәркемнең үз мәшәкате, үз дөньясы. Ә алар?

Шунда танасы үлгән абзый Шаһитның уйларын бүлдерде.

— Сез нәрсә, туганкай, ирле-хатынлы килгәнсез?

Шаһит аптырап калды. Маһинурга карап алды, син боларга бернәрсә дә әйтеп ычкындырмадыңмы, янәсе. Хатынының аңа ышанычлы итеп каравын сизгәч:

— Йомыш бар иде,— дигән булды. Агай кеше моның белән генә тынычланмады, кызыксынуы аеруча арта гына төште, ахры. Әйтерсең, учактагы кузны кузгатып җибәрделәр.

— Хәзерге яшьләр шулай инде,— диде агай, үпкәле тавыш белән,— астыртын дөнья көтәргә яраталар. Син дә, Шаһит туганкай, шуларның сыңарыдыр әле...

«Юк» дип әйтеп булмый бит инде. Калган чират көтүчеләрнең дә игътибары аларга юнәлгәч, мәгънәле итеп елмаеп куюдан башка чара калмады.

— Һе, беләм, беләм, туганкай, әйтмәсәң дә сизеп то-

рам. Кирпечтән йорт салырга җыена диләр иде, мөгаен, председательдән яна урын даулыйсыңдыр әле. Шофер халкына нигә салмаска. Машинасы белән тегесе-монысы кайтып тора. Килен урында. Акчасы кирә. Шулай булгач ни...

— Сөт машинасында эшлим бит,— дип сүз кыстыруны кирәкле тапты Шаһит, чөнки хатын-кызга азык кына бир, Маһинур, ачуы килсә, ни сөйләгәнен үзе белмәс.

— Аңысы да машина,— дип элеп алды агай кеше,— төнлә теге түбән оч Гатифәнең малае, бензовозда эшләгәне, өрлек буе бүрәнә сөйрәтеп алып кайтты.

— Әйе, машина-машина инде...— дип аңа кушылды башкалар. Тегеләрнең янә үзара гәп китте. Шаһит моңа куанып куйды. Янә уйга чумды. Әйе, быел чынлап та кирпечтән яңа йорт салдырырга дәртләре бар иде шул. Хәтта мебель фабрикасыннан сөйләшеп, әзер тәрәзә рамнары да кайтарткан иде. Типовой проект буенча салачаклар. Кирпече дә әзер. Менә, бөтенесе дә бушка кала инде. Маһинуры бит әле, хатын кешемен дип тормады, Шаһит бушамагач, кирпеч заводына үзе йөрде...

Председатель кабинеты ачылып ябылды. Кемнәрдер чыгып, кемнәрдер керде. Шаһит күзенә янә хатынының кофтасындагы чүп чалынды. Үзе дә сизмәстән шуны үреләп алып читкә ташлады. Моны күргән Маһинур елмайгандай итте, ләкин нигә килгәнлеген хәтеренә төшереп, кинәт җитди төс алды һәм читкә борылды. «Койрык болгама,— дип нәтиҗә ясап өлгерде Шаһит эчтән генә.— Амораль эш бу...» Ә үзе Басыйрны күз алдына бастырды. Һы, кайсылай фыртланып кайткан булган, үз машинасы белән... Имеш, акыл утырткан, укып институт бетергән, хәзер инде аспирантура тәмамларга җыена... Булачак фән кандидатына китап күп кирәк инде. Шуңа көннәр буена Маһинур яныннан чыкмый. Анавы кичне хатыны нәрсә диде әле җитмәсә?! «Һи, хәчтерүш, кулыңнан килсә, читтән торып техникумга укырга керер идең»,— ди. Әнә шул Басыйрның фән кандидаты булырына ишарә ясый инде. Ачуың килмәс җирдән килер.

«Бик тузынсаң, машинасына утыр да кит. Яшь чактагы сүзләрен онытмагансыңдыр бит»,—дип салды. Маһинур да тик тормый: «Үкенер дип уйлыйсыңмы әллә,— ди, күз дә йоммый.— Син шул Гамбәриян белән...»

Әнә шунда кызды да китте Шаһит. Юкка гына хатыныннан сүз ишетеп, кешедән көлдереп яшәргә, аның башыннан бүреге төшеп калмаган әле. «Авызыңны тыймасаң, әнә бара юлың»,— дип үк ычкындырды. Монысы артык

икәнлекне үзе дә аңлап өлгерде, ләкин соң иде инде. Утка керосин сибелгән иде. Маһинур да каты гына җавап бирде. Атна буена сузылган шушы тәмсезләшүдән соң бүгенге хәлгә җиттеләр...

Шаһит чыгып тәмәке тартып керде. Ишек белән аралар кыскарган саен икесе дә басыла төште, күңелләрен курку алгандай итте. Ничек дисәң дә, бергә булуларының соңгы сәгатьләре бит. Маһинур, сумкасыннан көзге алып, өс-башын төзәткәләде, озак кына үз-үзенә карап утырды. «Әллә ни картаймаганмын да болай»,— дип уйлап куйды. Ә Шаһит: «Хәмитне үзе белән алып китсә, малайсыз мин ничек түзәрмен икән?» — дип баш ватты. Улларын, араны өзгән мәлдә өйдә тормасын өчен, кайнаналарына җибәрделәр дә инде. Димәк, шуннан кайтып та килмәячәк.

Маһинур да, Шаһит та ишек ачылган саен дертләп китә башлады.

— Бәгыйдә апа председательдәме? — дип сорап куйды Шаһит, борчылып.

— Шунда шул, чыкмады,— дип әвәс кенә җавап бирде Маһинур.— Җитмәсә, кечкә чәйгә чакырды икебезне.

— Син барырсың.

— Юк, синең укытучың бит, үзең барырсың.

Тынлык урнашты. Шуннан Маһинур шыпырт кына эндәште. Аларга бер генә кешене күтәргә калган иде. Соңгы сүзләрен әйтешергә булганнардыр инде.

— Шаһит, яманмы-яхшымы, сыерны теләсә кемнән саудырма инде, тәрбияләп кенә алган идем үзен.

Шаһит эндәшми, башын аска ия.

— Электр сепараты белән сөт аертканда тирә-ягына сөт түгеп куймагыз, бик тиз бозылучан.— Маһинурның тавышы калтыранып чыкты. Нигәдер Шаһит та аңа сыенып утырды. Янә эндәшмәде. Үзе күзләре белән хатынының теге ягында утырган карчыкка карый. Хәзер аны чакыралар да...

— Маһинур, ми-миңа малай янына килеп йөрергә рөхсәт итәрсең инде...— Шаһит пинжәгенең чабуын бөтәрләргә кереште, тавышы бик акрын чыкты. Алар хәзер бер-берсенә борылып утырганнар. Маһинур, «әйе» дигәнне белдереп, башын какты.

Инде танасы үлеп калган агай да, йомышын йомышлап, болдырда тәмәке тартып тора. Чак кына кысык калган ишектән аның канәгать йөзе күренә. Кем беләндер гәпләшеп, елмаеп ала. Әше пешкәндер, мөгаен, үлгән танасына страховка чыккандыр. Шаһит аңа көнләшеп ка-

рап куйды. Шунда баягы эскәмиянең теге очында утырган соңгы әби дә күтәрелде — хәзер аларның чираты...

Маһинур белән Шаһит, йөрәкләре жулап, шуны уйларга да өлгермәде, эскәмиянең буш башы күтәрелеп китте. Чак егылмады болар. Шаһит тотып калды. Эскәмиянең сырлы тактасын сыйпап тын утырды да күзләрендә хәвеф уйнаган хатынының колагына пышылдады:

— Хәтереңдәме, теге без язылышырга килгәндәге эскәмия бит...

Маһинур ялт иттереп әйләнеп, зәңгәр күзләрен зур ачып иренә төбәлде. «Әйе, чынлап та, без язылышырга килгәндә дә шушы эскәмиядә утырган идек, әйе, хәтеремдә, хәтеремдә!..» — ди иде анын карашы. Ул нык дулкынланды. Менә хәзер кемдер берәү председатель кабинетының ишеген ачар да аларның исемен кычкырыр төсле тоелды. Керфекләре дымланды. Ә Шаһит хатынына караганда да ныграк кичерә иде бу минутны. Нигәдер Маһинурның кулыннан тотып алды. Үзенә таба тарткандай итте. Тегесе кинәт ашыгып аякларына басты, куркып кына председатель ишегенә карады. Беләген әкрен генә иренең кулларыннан бушатты да, керфекләрен жиргә төбәп, тышкы ишеккә атлады. Әйтерсең, Шаһит та шуны гына көткән, хатынының артыннан ашыкты. Ихатадан чыктылар да, ярыша-ярыша атлап киттеләр. Аларны күзәтеп торган әлеге танасы үлгән агай:

— Әллә болар председательгә керми кайтып китте инде,— дип, сәерсенеп эндәште.— Яңа йорт салырга урын сорарга килгәннәр иде дә.

Анын белән гәпләшеп торган кеше:

— Нигә, аларның әлеге торган урыннары да менә дигән,— дип куйды.

НАИЛ ГАЕТБАЕВ

Наил Әсгать улы Гаетбаев 1948 елда Баймак шәһәрендә туа.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Магнитогорск тау-металлургия институтында укып чыга. Берничә ел Себердә машиналар төзү заводында мастер, өлкән мастер, инженер-конструктор, баш механик булып эшли. 1976 елдан Сибай шәһәрендә махсус ремонт идарәсендә өлкән инженер вазифасын үти.

Н. Гаетбаевның «Әлфия» дигән беренче повесте 1976 елда дөнья күрде. Хәзер аның дүрт китабы чыкты.

1983 елда ул Мәскәүдә Югары әдәби курслар тәмамлады.

1976 елдан — КПСС әгъзасы, 1980 елдан — СССР Язучылар союзы члены.

ГОМЕР

Иделбайда хәзер егермеләп кенә өй калса да, вакытында шаулап торган авыл иде ул. Шул заманнарда Илчебикә тавының итәгендәге чаукалардан башланып китәр дә Зариф коесына кадәр сузылыр иде. Авылның очыннан-очына җәяү үтүләре өчен генә дә бер тына вакыт җитми торган иде. Халык сход-фәләнгә җыелса, анавы мәйданчыкка сыймый иде. Ә яшьләре күпме иде Иделбайның! Кичләрен Акчишмә буена төшеп уен оештырып җибәрсәләр, бөтен тирә-юнь гөрләп торыр иде. Әй заманалар! Ул вакыттагы яшьләрнең тере калганы ак сакаллы бабай булып бетте инде хәзер, Иделбай да шаулап торган авылдан тавышсыз-нисез ару гына көн күреп яткан утарга әйләнде. Инде монда яшьләр дә юк, аягына басып өлгермиләр, район үзәгенә качалар. Авыл үзе дә

сирәк-мирәк өйләре белән төрле урыннан тешләре суырылган картның авызына охшап калды...

Шөгаеп карт ишегалдындагы бәбкә үләннәр өстеннән яланаяклап йөреп ята. Үлән яшел бәрхет палас сыман йомшак, ул табанны рәхәтләндереп иркәли. Шуна да Шөгаеп карт шәһәрдән кунакка килгән дүрт яшьлек оныгы Нурга тәүге көн үк:

— Сандалиеңны анавы почмакка салып ташла да давай рәхәтләнеп яланаяк йөр,— дип боерык бирде.

Нур үзенең атасына, ягъни Шөгаеп картның киявенә охшап үзсүзләнеп маташты тәү мәл:

— Әнием «сандалиеңны киеп йөре гелән», ди бит соң...

Шулай да картәтисе каты гына итеп:

— Каланда киеп йөрерсең чабатаңны гелән,— дигәч, кыенсынып кына риза булды Нур. Бер өч көн дигәндә яланаяклап йөрергә тәмам күнекте бу малай, ә хәзер, әнә, яңгыр явып көн суытып җибәргәндә дә аягына кимәскә маташа, күлләвекләрне кичеп йөрүне әллә ни күрә.

Ә бүген көн җылы. Менә алар өйдән килеп чыкты да күтәреп килгән паласларын үлән өстенә түшәргә тотынды. Кечке ашка әзерләнеп йөрүләре. Паласны түшәп бетүгә Нур тагы өйгә табан йөгерде. Әнә, әллә никадәр түшәкләр күтәреп килә. Шунда ук паласның урта тирәсендә ашъяулык өчен урын калдырдылар да түшәкләрне әйбәтләп җәйделәр. Менә картәти өчен ястыклар да килеп ятты, ә Нур җан-фәрман учаклыкка табан йөгерде.

— Уй, күзең чыккыр бала,— дип каршы алды аны картинәсе Зәйнәп әби.— Соң егыласың бит хәзер! Иплән! Бабай, нәрсә карап утырасың анда шушы баланы тотмый?

— Бәләкәй бала егылмыйча үсми инде ул,— дип тыныч кына фәлсәфә сатты Шөгаеп карт, мендәр өстенә урнашып.— Бер-ике тапкыр маңгае күгәрмичә, күпме талкысаң да, аңламый бит ул.

— Иплән! Кайда менеп барасың анда? — дигән тавышы ишетелде ул арада учаклык эченнән Зәйнәп әбинең.— Казан эченә егыласың ләбаса хәзер! Чакырсаң ни була шушы баланы!

— Кил, кил монда,— дигән булды Шөгаеп карт.

— Ашъяулык,— дип аңлатты теге бала үзенең ни өчен өскә менеп баруын.

— Бар, бар әнә картәтиең янына. Хәзер үзем алып чыгам ашъяулыкны.

— Мин җәям ашъяулыкны,— дип үзсүзләнде Нур.

— Шушы баланы пешереп кенә бер бәлагә калырбыз инде. Әнкәсе ышанамыни аның үзе казан эченә егылганы-

на, без юрамал утырткан, диячәк бит ул. Менмә, менмә, димен бит мин сиңа анда. Мә, үзем алып бирәм. Бар, төшәгез дә шунда көтеп кенә утырыгыз. Сөйләсәң ни була, ичмасам, шушы баланы алдаштырып берәр экият, сиңа әйтәм!

— Ә кашыгаяк? — дип сорады Нур, башын кырын салып. Үзе түп-түгәрәк, зур, җитди күзләрен картинәсенә төбәде. Моның белән, кашыгаякны гел генә мин алып чыга торган идем ләбаса, дип әйтергә тели иде ул.

— Ярар, тагы кашыгаякны алып чык та, әнә, картәтиеңнең экиятен тыңлап утырып тор,— дип ризалашты Зәйнәп әби, казандагы ашны табакка бушата-бушата.

Нур, стенадагы биек киштәдән кулына күчкән ашъяулыкны түшенә кысып, картәтисе янына атылды. Әмма учаклык белән тышның арасында ятучы такта — тупса — ничәнче тапкыр инде үзенең кара эшен эшләде: Нур аңа эләкте дә сөрлегеп барып төште. Шунда ук аның елаган тавышы талгын гына булып кечке һаваны тирбәлдереп, кечкенә авылның өстенә күтәрелде. Иделбай, көндезге ыгы-зыгыдан талып, тыныч тормыш белән яши иде бу минутта. Шуңа да Нурның гадәти елавына беркем игътибар итмәде диярлек. Тик учаклык эчендә булышкан Зәйнәп әби генә кулындагы табагы белән чүмечен куеп килеп чыкты, ә түшәктә яткан Шөгаеп карт, Нур ягына борылып:

— Әй, эттәгенәсе! Тор! Тор! — дигән булды.

— Иплэп йөрсәң ни була? — Зәйнәп әби, ашъяулыгын түшенә кысып җирдә елап яткан Нурны күтәреп алды.— Йә, йә, дим инде. Кайсы җирең авырта? Шушы җиреңме? Өф, өф! Әйттем мин сиңа, баланы карап утыр, дип. Кайтарып кына җибәрмәсәк булмас инде. Өф, өф! Тынычландыңмы инде?

— Тынычландым,— диде Нур, тынычланырга тырышып. Ул картинәсенең алдыннан төште дә, яңа гына кычкырып елавын онытып, ашъяулыкны кочаклаган килеш, картәтисе янына йөгерде. Битендәге яшьләре әле кибеп өлгермәсә дә, аның йөзе бер дә еламаган кешенеке кебек тыныч, җитди иде инде.

Алар ашарга утыруга, кояш Илчебикә тавының артына яшеренә башлады. Шушы минутта тауның түбәсе кылычка охшап китте. Әйе, әйе, бала чагыннан бирле кояш баеган мәлдә шушы тауның түбәсен кызыл кылычка охшата Шөгаеп карт. Кайчак, шунда менеп, баягы кылычны тотып аласы килгәннәре дә исендә аның. Ә ул заман-

нарга алтмышка якын ел үтеп тә киткән. Һә-әй, гомер, аккан сулар белән берсең шул син!..

Шөгаеп карт үзе дә сизмәстән уфтанып куйды. Зәйнәп әби тәлинкәләргә аш коеп утыра иде, бабаена күз кырые белән генә карап алды.

— Аһ-аһ, нишләп уфтанасың алай итеп? Әллә тагы биленнән тоттымы?

— Бил авыртмый да ул. Шушы дөнья бездән дә калыр микәнни, дип аптырап утырам.

— Бездән генә түгел, әллә кемнәрдән калгандыр әле бу дөнья дигәнең. Әллә гомер яшәмәкче идеңме? Аһ-аһ, яшәрен яшәдек тә инде, гомеребезне дә заяга үткәрмәдек шикелле. Хәзер, әнә, Нурлар яшәсен.

Зәйнәп әби оныгын дөпелдәтеп сөеп алды.

— Анысы шулай да ул,— дип ризалашты әбие белән Шөгаеп карт, мыегын сыйпый-сыйпый.— Яңа гына Илчебикә тавына караган идем, кайчандыр аның итәгендә булган чабынлыгыбыз искә төшеп китте. Шуны хәтерләгән идем, сугыштан кайткан чаклар күз алдына килде. Һә-әй, заманалар! Сөйләргә генә калды инде хәзер.

— Куй инде,— дип көрсенде Зәйнәп әби дә.— Мин дә ураган саен хәтергә алам әле шул чакларны. Уйлап карасаң, үзебезнең иң дәртле чаклар булган икән! Үзең санап карачы: сиңа барлыгы утыз биш кенә яшь булган бит. Аннан соң әле өч балабыз булды. Ә синең сугыштан кайткан көнең кичә генә кебек хәтеремдә. Балам, аша, аша ашыңны. Әйе, ашап бетер шул. Менә зур булып үсеп китәрсең. Ул көн Илчебикә битләвендә төшкә кадәр печән чаптым мин. Көн килеп торып эссе. Хәл бетеп китте. Чалгыны шундагы бер ботакка элдем дә кайтып киттем. Инде ашъяулык җәеп, чәй эчәргә генә утырган идем, ишекне җимерердәй булып Мәсәгут килеп кермәсенме! «Сөенче!» дә «сөенче!» — дип үтереп алып бара бит, мәлгунь. Сугыш бетеп, сине, әнә кайта, менә кайта, дип торган чор бит әле. Буыннарым өзелеп төште дә куйды шунда. Белеп торам, син кайтып килә дип кергән Мәсәгут, ә менә берни дә эндәшә алмыйм да куям.— Зәйнәп әби яулыгының очы белән генә авызын каплап көлеп алды.— Җитмәсә, урындыкка утырып, Мәсәгуткә карадым да каттым. Ул, бахыр, үзе дә куркып китте шикелле. Сөенчесе турында да онытты. «Зәйнәп апа, Шөгаеп агай кайтып килә, димен дә инде»,— дип янымда нишләргә белми йөгергәли. Ә мин шул җирдә исемә килдем дә, кулымдагы чынаягымны урындык өстенә ыргытып, урамга йөгереп чыктым. Ә районнан килүче юл безне ишек алдыннан уч

төбендәгедәй күренеп тора бит. Карасам — юл буп-буш... Мин бер юлга, бер Мәсәгуткә карыйм. Ул да аптырап китте. «Зәйнәп апа, мин алдамыйм,— дигән була,— ул яңа гына килә иде. Кайда булды икән?» Берәүгә кереп киткәндер дисәң, безнең өй бит авылның иң очында утыра...

Шөгаеп карт, ашындагы кортны изә-изә, Зәйнәп әбине тыңлый, ә карашы тагы да Илчебикә тавының түбәсенә оча. Уйлар да, әнә шул караш сымак, ансат кына үткән заманнарга җилә. Яшь-җилкенчәк, гадәттә, киләчәк белән яшәсә, карт-корылар күбесенчә үткән гомер белән көн күрә бит ул. Үткәннәрне хәтерләп, бер-берсенә сөйләп алу алар өчен үзе бер юаныч, үзе бер бәйрәм. Менә яңа гына Зәйнәп әби сөйләгән вакыйганы алар икесе дә яхшы хәтерли, ул гына да түгел, аны инде ничәнче кабат бер-берсенә сөйләгәннәре бар. Әмма шул вакыйгаларны күз алдына китергән саен, янә бер тапкыр хәтерләп аласылары килә. Тик Нур гына, аларга игътибар итмичә, яткан җиреннән песи белән булаша, тегенең ашъяулыкка омтылганын күреп, аны аяк-кулы белән этеп маташа.

— Шушы җирдә Мәсәгут тамагы ярыла язып кычкырып җибәрмәсенме,— дип исенә төшерә Зәйнәп әби заман юлында торып калган көннәрне.— «Зәйнәп апа, карале. Илчебикә итәгенә!» — дип яр сала бит, бахыр, куанычыннан нишләргә белмичә. Ул курсәткән якка күз салсам, анда кемдер берәү колач ташлап печән чабып йөри... Әй, заманалар... Төш кебек итеп кенә сөйләргә калды инде хәзер.

— Әй-йе.— Шөгаеп карт үзенә сөйләргә чират җиткәнен аңлап, Зәйнәп әбинең хатирәләренә йомгак ясагандай, дөрес кенә сөйләдең, хата җибәрмәдең, хуп, дигәндәй, сакалын сыпырып куйды.— Сине тыңлап утыра торгач, шул искә төшеп китте әле. Сугышта кичкәрәк, бушрак вакытта, күңел йомшарып китә дә, үзем дә сизми калам, берәр озын көйне сузып җибәрә торган идем. Безнең вызвутта мин берүзем башкорт идем, шулай да күпләр күз яшен сөртә иде мине тыңлаганда.

— Хатыннарын, бала-чагаларын сагынып елаганнардыр инде, бахырлар.

— Аларны сөйлим!.. Шунда бит үзем җырлыйм, ә үземнең күздән чорлап яшь ага. Син искә төшкән булгансыңдырмы икән?

— Шулай дисең дә ул, ә үзең өйгә дә кереп тормыйча, печән чабарга төшеп киткәнсең.— Зәйнәп әби үпкәләгән кебек әйтеп куйды.

— Һы.— Шөгаеп карт, моннан кырык ел элек, чынлап та, бик сагынып кайтып килгән җиреннән, нигә өйгә кермичә, чабынлыкка менеп китүен аңларга теләгәндәй, бераз уйланып утырды.— Авыл очына җитеп килә идем, кинәт танауга яңа гына чабылган печән исе килеп керде бит. Дүрт ел чалгы тотылмады кулга. Ә печән чабасы килгән минутлар була торган иде! Ис килгән якка карасам, янда гына, Илчебикә итәгендә, яңа гына чабылган покослар күренә. Шунда, агач ботагында, чалгысы да эленеп тора. Тукта, мин әйтәм, барыбер кайтып җителде инде, җае туры килгәч, юл уңаенда чабып карыйм әле, онытылмаганмы икән? Яңа чабылган печәнне дә яхшылап иснәп карыйсы килә бит әпәт же. Печән исе дә сагындыра икән ул.— Шөгаеп карт, ни өчен өйгә туры кайтмый, чабынлыкка менеп китүен күңел белән тоеп булганына, сүз белән һич тә аңлатырлык түгеллегенә үкенгәндәй, ашъяулыкка бераз текәлеп утырды да, кинәт кулындагы агач кашыгын куеп, яшьләр сымак, җиңел генә ыргып торды.

— Иплэп, ашны түгәсең ләбаса,— дип ачуланып алды Зәйнәп әби.— Йөз кат күрсәттең бит инде ничек чабуыңны. Билең биртелгәч, бүген күрсәтми торсаң да ярар иде.

Картәтисенең кинәт урыныннан калкуына аптыраган Нур, песи турында онытып, кулларына таянды да, башын өскә күтәргән хәлдә, тагы да нишләргә уйлый икән бу дигәндәй, катып калды. Песи шул арада иплэп кенә ашъяулык янына килде дә Нурның икмәген иснәргә тотынды. Моны күреп калган Зәйнәп әби кулындагы чүпрәге белән аңа сугып җибәрде.

— Песи, каһәр суккан! Бу кадәр дә убыр булыр икән, күпме генә ашаса да туймас...

Песи шунда ук бөршәеп читкә сикерергә иткән иде дә, Нур ике кулы белән аны эләктереп алды.

— Җибәр, китсен!

— Ул ачыккан,— диде Нур, песине борыны белән баягы икмәккә төртеп.

— Тотма шул песине, ашап утырганда.— Зәйнәп әби оныгыннан песине тартып алырга иткән иде дә, тегесе аны кочаклап, тиз генә читкә шылды.

— Баягы чабынлыкка барып җиткәч,— дип сүзен дәвам итте Шөгаеп карт, әбие белән оныгының үзара ызгышуына бөтенләй игътибар итмичә,— чемодан белән букчаны үләнгә ыргыттым да кулга чалгыны алдым. Ә ул заманнарда покослар арасы киңнән дүрт адым була торган иде бит.

— Мактану дисәң, сине куш инде.

— Мактанмыйм, чын шулай иде ләбаса. Чалгыны шулай итеп тотып алдым да шулай итеп... Алла, алла, билем! Әй, әттәгенәсе!

Моннан биш ел элек, бүрәнә күтәрәм, дип билен кузгатканнан соң печән чабу түгел чалгы да тота алмаган Шөгаеп карт шушы җирдә ихласрак кыланып ташлады — аның ниндидер сөяге кырт итеп калды. Бабай, аһ та уһ килеп, мендәр өстенә чүгәләде.

— Күпме әйтәм мин сиңа, иплэп, димен. Юк, тыңламый! Менә урыныңнан торалмый ятсаң, шунда булыр эле.

— Курыкма, курыкма, әби. Уже, әнә бетеп тә бара авыртуы. Быел печән чаба алмам микәнни, дип сынап кына карамакчы идем билемне.

— Әнә, балалар килеп чабып бирер эле. Гайрәтләнмә, гайрәтләнмә, билсез калырсың, димәдеммени мин сиңа? Бутта егерме яшьлек егет.

— Әллә нишләп син сөйләгәнчә була да куя шул.

— Ярар инде, кеше түгел, картайган агач та бөгелә, — дип куйды Зәйнәп әби, бабаен юатырга теләгәндәй. Шуннан Нурга борылды да аның яңа гына песигә ашатып маташкан икмәкне үзе согынырга йөргәнен күреп, тартып алды. — Әй, шушы бала бер генә дә әйткәнне аңламады. Песи иснәгән нәрсәне авызыңа алма, дип күпме талкыдым бит сиңа.

Песиен үлеп яраткан Нур картинәсен аңламады, еламсырап икмәкне кире сорый башлады:

— Би-ир! Ачыктым, ашыйсым килә-ә!

Зәйнәп әби ул икмәкне песигә ыргытты да оныгына яңадан телеп бирде, ә үз уйларына чумган Шөгаеп карт Илчебикә тавына текәлеп тынып калды. Әнә, тауның ялангач бите буйлап кемдер әкрен генә өскә үрмәли. Ул яктан тау сөзәгрәк тә, ташлары да баскыч сымак булып тезелешеп ята, менүе ансат.

Ә менә теге кеше кайчандыр, сугыштан кайтышлый, Шөгаеп печән чабарга туктаган тәңгәлне дә үтеп китте.

— Кайда үрмәли икән, анау кешене әйтәм, төнгә таба? — Шөгаеп карт үзалдында гына сөйләшкәндәй, карашын таудан алмыйча, әкрен генә шулай дип куйды.

— Сиңа монда төн булса да, тау башында көн әле, — диде Зәйнәп әби, шулай да бер кулын каш тәңгәленә куеп, Илчебикәгә карап алды. — Йөргән бер мосафирдыр инде. Кеше башында нинди уй барын кайдан беләсең? Теге Шәйшәрип дивана түгелме икән?

— Мендерерсең ул Шәйшәрипне тауга. Дивана булса

да, бик хитрый ул,— дип сөйләнде Шөгаеп карт.— Бер безнең чабынлык Богалынырда булган иде, исеңдәме икән? Шунда менеп барсам, әмәлгә калгандай, баягы Шәйшәрип дивана очрады. Капчык тотырып таш күтәреп алган да әллә кая китеп бара. Мине күрде дә: «Кайда менәсең? — дип сорый бу.— Тауны аша төшкәнче, урап үтсәң җиңелрәк ул»,— ди. Мин әйтәм: «Урап үтәр идем дә — чабынлыгым шунда»,— дим. Шул җирдә Шәйшәрип дивана бот чабып көләргә тотынмасынмы миннән: «Җүләр икәнсең син, Шөгаеп,— ди бу, кеше тау башыннан печән чабамы? Аны ничек алып төшмәкчесең?» Чынлап та шул ел печәнне чак алып төштек бит. И башка анда чапмастый булдым. Менә сиңа дивана! Хитрый дивана ул Шәйшәрип, мендерерсең син аны тауга.

Ул арада теге кеше тауның түбәсенә менеп җитте дә туктап калды. Аның тирә-юньгә сокланып карап торуын моннан да аңлап була иде. Ә түбәдән ачылган күренеш, чынлап та, матур шул. Бигрәк тә эңгер төшәр алдыннан. Иделбай авылы, таза чишмә төбендәге кырчын таш сымак, кара сыек күләгә эчендә ята, ә аннан арырак, көнчыгыштарак, ялан-таулар кояш нурында сап-сары төскә манчылып иркәләнә, назлана әле. Бер-берсеннән аерылып торган шушы ике төс, ерактагы упкыннарга җәелгән күксел томанга кушылып, күңелләрне биләүче сихри бер көчкә әверелә. Шөгаеп картның күпме тапкыр шул түбәгә менеп, тирә-юнь белән сокланып торганы бар!

Тау башындагы баягы кеше нишләр икән, дип көтеп яткан Шөгаеп карт, корт чаккандай, кинәт урыныннан торып утырды. Ни өчен дисәң, шушы минутта кечкенә сыек һаваны ерып, авыл өстенә талгын гына коела башлаган таныш моң Шөгаеп картның да ката төшкән колагына килеп җитте.

— Кара, кара, җырлый түгелме? — дип аптырау катыш куанычлы йөзен әбиенә борды ул. Әллә колагыма гына ишетеләме икән, дигән курку бар иде аның күңелендә. Шуңа, һаман да Нур белән булашкан әбие берни дә эндәшмәгәч, тау ягына яхшылабрак колак салды. Куанып китте.— Чынлап та җырлый бит бу, чәчрәгер.

— Синең сыман җиңелрәк адәмдер,— дип телгә килде Зәйнәп әби дә, һич исе китмәгән кеше булып. Шулай да үзе, кулын каш өстенә куеп, карашын тау башына юнәлтте.

Ә анда торган кеше чынлап та җырлый иде. Үзе өчен генә, артык көчәнми генә моңайса да, аның җыры монда да ачык кына ишетелә. Көч әзрәк тә, әмма моң бар иде

бу тавышта. Җырчы әллә тормышының ялгыш үтеп киткәненә кайгырып, әллә үкенеп, сагышлы гына сыздыра. Бу сагыш авыл өстенә, ак ящгыр кебек, әкрен генә ява. Һәр өйгә барып керә. Иделбайдагы бар кеше, кулындагы эшен ташлап, Илчебикә тавында җырлап торучыга төбәлде, тик аның кем икәнен беркем дә төсмерли алмады. Әмма аның үзе билгесез булса да, җыры таныш иде.

Еракларда, ай, күренә
Ирәндеккәй тауның ак ташы.
Кайда бармый, нилэр күрми
Ир-егеткәй белән ат башы.

Шөгаеп карт бу җырчы хакында кем беләндер сөйләшеп алырга кирәклеген аңлады. Әбиенең ни әйтерен белә ул. Берәр эшсез адәмдер, диячәк, шунда интегеп менеп җырлап торганчы, өенә кайтып берәр эш белән шөгыльләнсәче, диячәк. Ул кешенең күңелендә онытылгысыз тойгы ятадыр, бәлки. Шул алып менгәндер дә инде аны шушы тауга. Бу турыда уйлыймыни ул Зәйнәп? Йә, ярый.

Шөгаеп карт, урыныннан торып, алга бераз иелгән хәлдә, кулларын биленә салып, күршесе Зариф картка уңайлады. Ул ни уйлый икән бу мосафир турында?

Палас өстендә песие белән гамьсез генә уйнап яткан Нур, картәтисенең кайдадыр китә башлавын күреп, сикереп торды да песиен кочаклап аңа иярде.

Зариф карт, тауга якынрак булыйм диптер инде, урамга килеп чыккан да, кулын каш өстенә куеп, тауга текәлгән. Үзе, җырлаучыга комачауламыйм, дигәндәй, селкенми дә.

— Шөгаеп, ишетәсеңме? Җырлый бит бу, җырлый, ә? — диде ул, үзенә якынаеп килүче күршесен күреп калып.

— Ишетүен ишетәм дә ул,— диде Шөгаеп карт, ике кулын артка куеп. Ул да җырчыга төбәлде.— Кем булды соң әле бу? Тавышыннан һич тә төсмерләмим.

— Безнең авыл кешесе булмый, кем дисең? Хәзер җырлап бетерер дә монда төшәр. Шуннан, алла боерса, танырбыз.

Песи белән уйнаган Нур ике бабайның сөйләшүенә дә, тау башында моңланучы кешегә дә игътибар итмәде. Өлкәннәр әнә шулай гел күңелсез сөйләшәләр инде. Нур башта, берәр кызык нәрсә ишетмәмме икән, дип аларның сүзенә колак салып карады да азак тынды. Бушка гына өметләнә икән. Анавы җырчыга аптыраган булалар. Бу җырны Нур көн дә диярлек ишетә. Шәһәрдә чакта йә ку-

наклар жырлый торган иде аны, йә атасы берәр эш беләк шөгыльләнгәндә мәңрәп йөри, монда да картәтисенең авызыннан еш кына ишеткәне бар. Хәзер килеп, шуны тау башында торган агай жырлый икән, нигә аптырарга моңа? Теләсә, аны Нур үзе дә жырлый ала. Менә шулай ул:

Ераааклааааааардааааан, аааай, күүүүреееенәәәә...

Ике бабай авызларын ачып Нурга текәлде.

— Кара әле. Жырлый түгелме ул, монавы гурыт малае? — дип беренче булып хәйран калды Зариф карт.

— Шөгаеп токымы булсын да, жырламасын, имеш! — Шөгаеп карт әле һаман жырлап маташкан оныгын үзенә кысты да агач кебек каты бармаклары белән сөеп алды.— Вәт, маладис! Әнә шулай бирешмә, улым. Атасына охшаса, бик моңлы бала булмакчы.

— Әсгать жырлауны булдыра инде ул,— дип куйды Зариф карт, Шөгаеп картның өлкән киявен, Нурның атасын исенә төшереп.

Ул арада Нур, картәтисеннән ычкынып, качып барган песие артыннан йөгерде. Ә ике бабай, тагы да тау түбәсендәге жырчыга төбәлде.

Шушы жирдә теге кеше жырлаудан туктады да, тирәягына бераз карап торганнан соң, шундагы бер ташның өстенә утырды. Жырчының кара шәүләсе, аръяктан суккан кояш нурларында сары ука белән каймаланып, яңа гына өзелгән жыр моңына кушылгандай, бик-бик сихерле күренә иде. Тик тоныклана төшкән күзләре белән генә ике бабай моны күрмәде.

— Утырдымы? — дип сорады күзгә начаррак Зариф карт.

— Утырды шикелле, һич тә күренми бит. Нур улым, кара әле, таудагы анау абыең утырдымы шул?

— Утырды,— дип кычкырды йөгереп йөргән жиреннән Нур.

— Эшсез йөргән бер кеше түгелме икән бу? Кабаланмавын әйтәм дә. Уттай эш вакытында шулай итеп йөрергә форсат кирәк бит.

— Гурыт кешесе булса гына инде...

— Торды,— диде шушы жирдә Нур.

— Тордымы? — дип сорады Зариф карт, тауга табан ныграк төбәлеп. Ләкин бу вакытта эңгер куера төшкән иде, шуңа ул кешенең торып басканмы, әллә утырганмы икәнен кинәт кенә аңлап булмый иде.

— Торды, ди бит,— диде Шөгаеп карт, ышанычсыз гына.— Әйе, әйе, торганга охшый шул.

Җырчы, чынлап та, урыныннан күтәрелде дә килгән юлыннан ашыкмый гына төшә башлады.

— Кара, кара, китә түгелме соң бу?

— Китә шул.

— Кая китә ул? — дип аптырау катыш сорады Шөгаеп карт. Хәзер бу юлчының авылга төшәчәгенә, аның белән сөйләшеп алырына шикләнми иде бабай. Ә җырчы туры район үзәге ягына уңайлады.

— Туры юлны белми, ахры,— дип нәтиҗә ясады Зариф карт.— Тау башыннан үзәндәге агачлык кеше үткесез булып күренә ләбаса. Шуны урап үтмәкчедер.

— Үзебезнең авылныкы булса, туры юлны белергә тиеш.

— Әйе шул,— дип ризалашты Зариф карт.— Әллә авылга да сугылмыйча районга киттеме икән?

— Безнең авыл кешесе түгелдер бу,— дип нәтиҗә ясады Шөгаеп карт.— Әллә, мин әйтәм... безнең авылдан булса да, монда кайтырга тартынамы икән?

— Һе-һе! — дип көлеп алды Зариф крат.— Хәзерге заманда андый кеше бармы икән? Үз авылына кереп чыгарга тартынырга кем ул?

— Сугыш чорында дезертир булып йөргән теге, кем әле, шул булмаса?

— Гайзулланы әйтәсеңме?

— Әйе, әйе. Шул, имеш, күрше районда гына син дә мин яшәп ята, диләр ләбаса. Нишләп авылыңа килеп тә күренмисең, дигәч, кеше алдында оят, дип әйтә, имеш, диләр.

— Төрмәдә дә утырып чыкты шикелле ул.

— Утырса да, кеше күзенә күренүләре җиңелдән түгелдер инде. Югыйсә кайтып әйләнер иде шуңа кадәр.

Ул арада теге билгесез җырчы таудан район үзәге ягына төшеп, күздән югалды. Ә ике бабай аны күрә алмауларына үкенүдән әкрен генә көрсенеп алдылар да, үз уйларына чумып, тынып калдылар.

Ә бу вакытта авыл кичләргә әзерләнә иде. Әнә, урам очында көтүгә каршы чыккан бичә-чәчә сөйләшеп тора. Берерәк, ата каз алпан-тилпән басып, ялкау гына какылдап, гаиләсен буа буеннан алып кайтып килә. Кайдадыр бала-чаганың көлгәне ишетелә. Кемдер чаңк-чаңк тимергә сугып алды. Менә «Беларусь» белән чаң туздырып Мотыйк үтеп китте. Шунда ук тирә-юньгә яңа чапкан печән исе таралды. Авыл яши, яшеллеккә күмелеп тыныч кына гомер кичерә. Бурәнә өстендә ике бабай утыра. Алар ялангач аяклары белән яшел, йомшак үләнгә басканнар

да уйга баткаңнар. Ни уйлый алар? Кем генә беләинде моны? Бәлки, хатирәләр дулкынында йөзәдер ике картның уе. Аларның озын гомерендә сагынып искә алырлык вакыйгалар аз булган, дисеңме? Бабайларның янында гына Нур, чыбыкка атланып, уйнап йөри. Әйдә йөрсен әле, ичмасам, шушы үлән өстендә яланаяк. Көз җитеп, кире шәһәргә кайткач, әләгәме аңа мондый бәхет?

Менә ике бабай янында район үзәге ягыннан килүче урта яшьләр тирәсендәге кеше туктый. Бу кайчандыр: «Шөгаеп агай кайтып килә»,— дип Зәйнәп апасыннан сөенче алырга йөгереп килгән Мәсәгут. Ул инде күптән һәр яңалыкны беренче булып авылга җиткереп йөргән җитез егет түгел. Аның да иңенә тормыш үзенең авыр йөген салган. Мәсәгут калыная, бераз алга бөгелә төшкән. Нишлисең, тормыш шулай бит ул: балаларыңны ир җиткереп, башлы-күзле иткәнче, гомер үтә дә китә. Карт көнендә кеше бер генә уй белән яши: көчемне, гомеремне биргән балаларым өчен кеше күзенә карарга оят булмасын. Ул яктан Мәсәгут тыныч. Бар балалары да башлы-күзле булып, район үзәгендә матур гына яшәп ята. Менә бүген дә шуларда кунак булып кайтып килүе аның.

Мәсәгут авыл аксакаллары белән ике куллап күреште.

— Әссәламәгаләйкүм, агайлар! Йә, хәл-әхвәл ничек?

— Вәгаләйкүмәссәлам, Мәсәгут туган. Без болай, аллага шөкер, ару гына. Үзең ни хәлдә? Бала-чагалар исәнме?

— Бик әйбәт кенә яшәп яталар. Сезне сагынып сөйлиләр. Шөгаеп картәти белән Зариф бабай ничек яшиләр, саулыклары ничек, дип белешеп кенә торган булалар. Менә яңа кайтырга чыкканда да, икесенә дә бездән әбизәтелне сәлам әйт, дип торып калдылар.

— Вәгаләйкүмәссәлам,— бабайларның икесе дә берьюлы дога кылып куйды.— Ярый инде, шулай онытмыйча сорашып торгач. Игелекләрен күр, Мәсәгут энекәш. Яхшы, матур, итагатьле балалар үстердең. Битеңә кызыллык китерерлек түгел.

— Анысы шулай да ул,— дип ризалашты Мәсәгут.— Тик менә авылга сирәк кайталар. Үзләре сагынабыз, диләр, авылны.

— Шулай булмыйни. Туган туфрак тарта инде ул,— ди Шөгаеп карт.

— Анавы Гайзулланы да, Иделбайга кайтып күренә алмас, диләр иде. Тәким килеп киткән икән авылга, сагынгандыр инде, бахыр.

Мәсәгутнең бу сүзе ике бабайны аптырата төште.

— Кайчан? — дип сорады алар икесе берьюлы.

— Сез күрмәдегезмени? — дип гаҗәпләнде Мәсәгут тә.— Соң, яңа гына авыл ягыннан районга китеп бара иде ләбаса.

— Әллә очраттыңмы?

— Очраттым шул.

— Алайса, Илчебикә башына менеп җырлаган анавы адәм шул Гайзулла булды микәнни? — Шөгаеп карт, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, шулай дип әйтеп куйды.

— Аһ-аһ,— дип аптырады Зариф карт та.

Барысын да сөйләп биргәч, Мәсәгут тә уйга калды.

— Чынлап та, таудан төшкәндер ул,— дип куйды Мәсәгут соңыннан. Мин как рас Илчебикәдән төшкән сукмак тирәсендә очраткан идем шул аны. Авылдан килә икән бу, дидем бит әле.

— Мин, башка берәү җырлагандыр, дигән идем.— Зариф карт көрсенеп алды.— Бигрәк моңлы, сагышлы итеп җырлады. Гайзулла икәнен белгәч, күңел бераз кырылып куйды. Ни дисәң дә, дезертир бит әле ул.

— Син аны дезертир дип карама, кордаш,— диде шушы җирдә Шөгаеп карт.— Дезертирлыгы өчен ул җәзасын да алган, шул аркада, әнә, һаман авылына килергә оялып йөри. Ә барыбер Иделбайны сагына. Һә-ә-ә-әй, гомер...

— Әй-йе,— дип ризалашты Зариф карт белән Мәсәгут.

Алар барысы да тынып калды...

Кич. Бүрәнә өстендә эндәшми генә өч карт утыра, аларның янында кечкенә генә бер малай йөгереп уйнап йөри.

Ә аларны уратып алган таулар, авыл өстенә үзләренең күләгәсен ябып, иксез-чиксез вакытның бүгенге шушы күренешен мәңгелек сандык-хәтеренә сендерә...

САБИР ШӘРИПОВ

Сабир Нәгыйм улы Шәрипов 1948 елда Башкортстанның Белорет районы Бакый авылында туа.

Сигезьеллык мәктәп һәм педагогия училищесын тәмамлагач, ике ел укытучы булып эшли. Шуннан Башкорт дәүләт университетының филология факультетында белем ала һәм республика газетасы редакциясенә эшкә чакырыла. Әлеге вакытта «Агыйдел» журналында проза бүлеге редакторы. Яшь әдипнең «Таулардагы эз» һәм «Каенлы үткел» дигән китаплары дөнья күрде.

С. Шәрипов — 1970 елдан КПСС әгъзасы. 1986 елда ул СССР Язучылар союзына кабул ителде.

ОНЫТЫЛГАН ҖЫР

Җәйнең беренче көннәре. Ни эссе, ни салкын түгел әле. Шулай да җанга рәхәт мәлләр килә.

Сөнәгат карт, миңгерәүләнгән кешедәй, һаман да өй ишеге алдында утыра бирде. Карт дип, нәрсәсе карт булсын инде аның. Быел алтмышка чыга чыгуын, ләкин, үзе әйтмешли, хәзерге заманда кеше картая беләмени?!

Тиздән кызы Әлмирә мәктәптән кайтыр. Укытучы булып эшли ул. Үз классын уку елы бетү хөрмәтенә бер көнлек походка — моннан ун чакрым тирәсендәге рудникны күрсәтергә алып чыгып киткән иде. Дүртенче класста гына укыган ыбыр-чыбыр балалары житез атлый алмыйлар инде, озакладылар.

Картыбызга, әлеге дә баягы, үзе әйтмешли, ике кулына бер эш — пенсия ала, анысын да өйгә китереп, кулына гына тоттыралар. Гаҗәпләнергә урын юк. Сөнәгат бик

яшьли генә хезмәт армиясенә эләкте. Делянкаларда, билдән кар ярып, шпал кисте, буыннары ката төшкәч, рудникта өлкәннәр белән беррәттән тимер рудасы чыгарды. Һай, ул заманнарда!.. Руданың яртысын диярлек кәйлә белән чокый-актара торган иделәр. Хәзер нәрсә! Әнә, җир куенына аммонал тыгып, шартлатып аталар да катлам ачалар, тау токымнарын машинага төяп, фабрикага озаталар, анда чаң-комын арлы-бирле су белән юдырганнан соң, тимер юлдан металлургия заводына җибәрәләр.

Рудник элекке ише түгел шул хәзер. Үзе бер комбинат! Азаккы тапкыр анда Сөнәгат моннан биш ел элек пенсия юллаганда справка-фәлән артыннан барган иде. Тау эшендәге стажы күп булгач, ул ялга илле биш яшьтән чыкты.

Әле дә теләсә нинди кара эшне түздермәс иде Сөнәгат. Тик былтырдан бирле, ягъни Сәлимәсе — начармыяхшымы, утыз тугыз ел бергә дөнья көткән карчыгы — вафат булганнан соң, эшкә дәрте сүрелде дә куйды. Югыйсә ел да колхозга печән чабыша, җыеша, утын әзерләшә, тегесен-монысын юнәтешә торган иде. Үзенең йорткурасы какшамаган, һаман да нык әле. Шөкер, атыкамытыннан язарга тырышмый, арба-чанасы бар, утыны икеөч кышка җитәрлек. Ашыйм дисә — ризыгы, киим дисә — киеме җитә. Тик менә Сәлимәсе вакытсызрак китеп барды. Эчтә, йөрәк тапкырында, яман шеше бар иде. Шул галәмәт гүргә тыкты үзен.

Менә хәзер Әлмирә кайтып керер. Әнкәсенә охшатып, җиңелчә сукранып алыр. Әй, эттәгенәсе, дияр, аркылыны буйга да салмый башладың бит. Ичмасам, чалгы, сәнәкләрне рәтли торыр идең, дип әйтер. Алай әйтмәсә, шуңа охшашрак башка сүз табар. Шул рәвешле атасын эчпошыргыч кичерешләреннән арындырырга, уй-зиһенендә яшәү дәртен сүрелтмәскә телидер инде. Моны Сөнәгат агай үзе сизми дә иде шикелле. Мәгәр ул Әлмирәсе, кече кызы, башкаларга караганда яратып-назлап үстергән кызы әйткәннәрне күңеленә сеңдереп барырга, хәленнән килгәнчә үтәргә тырыша. Әллә ничегрәккә әйләнде шул Сөнәгат агайның кәеф-сафасы соңгы чорда. Ямь тапмый карт үзенә, тынгы тапмый. Сөйли башлады исә — уйламаганда йомылып кала, көләргә ниятләсә — ихласлыгы җитми, тегене-моны әтмәләргә тотынса, тәгәлли алмый азаплана. Әнә бит, арбасының арткы тәгәрмәчләрен ныгытып, шиннәрен тарттырып куярга һаман да кулы җитми. Җигеп чыгарга язмасын. Адәмнән оят: исерек тәгәрмәчләр кыйшан-койшан тирбәтә башлар.

Нинди дә булса эш-көшкә тотынып, күңелен басарга ниятләптерме, карт урыныннан торды. Юк, бөтенесеннән элек ишегалдын ялт иткәнче себереп алу зыян итмәс. Ансат эш бу, аның ишегалды тоташлыйга яссы-яссы каен такталары белән түшәлгән. Шуңа да вак-төяк чүп-чар әллә кайдан күзгә ташлана.

Чынлап та, әллә ничегрәккә әйләнде шул Сөнәгат картның күңеле бу елларда. Сәлимәсен юксынадыр, вакытсызрак канаты каерылды, дияр идең, хатыны белән әллә ни мөкиббән яратышып дөнья көтмәделәр дә кебек. Болай какмады, сукмады, адәм алдында йөзен ертып, ким-хур итеп җәберләмәде. Биш бала үстерделәр, теләгән һөнәрләренә укытып чыгардылар, кеше арасында кеше итеп тәрбияләргә тырыштылар. Шулай да гөнаһлары аз түгел аның мәрхүмә алдында. Ай-һай, җитәрлек. Торганы бер азгын булмаса да...

Үзе дә сизмәстән, ул өенә табан уңайлады. Чоланда да, бүлмәләрнең алгысында да, төпкесендә дә салкынча иде. Әйе, күп әйбер-җиһаз Сәлимәне хәтерләтеп тора ләбаса! Түрбаштагы тәрәзәдә килен булып төшәрдән алда ук чиккән бер генә пәрдәсе элүле тора, азак, магазинга фабрикада чигелгәннәре кайта башлагач, кеше рәтенә ул да шушы бәхет кошы чигелгән пәрдәдән башка бөтен чигелгән-сырылган әйберләрен алыштырып бетте. Анда, юка гына итеп эшләнгән ак стенада, парлашып төшкән фотолары куелган. Ул заманда Сөнәгаткә — кырык биш, Сәлимәгә кырык өч яшьләр тирәсе булгандыр. Кыска гына итеп алдырылган чәчле Сөнәгат, дүрткел мыегы астыннан сизелер-сизелмәс кенә елмайган булып, кысык соры күзләрен билгесез бушлыкка төбәгән. Хәзер дә Сөнәгат чәчен җиткереп йөртергә яратмый. Ә Сәлимәсе... Сәлимәсе менә әле моңсу гына карашларын нәкъ аңа төбәгәндәй. Иңбашына эре бизәкле юка шәл ябкан, түшенә кыр чиясе зурлыгындагы төймәләрен таккан. Гүя ул Сөнәгаткә шелтәле, ниндидер аңлашылмаган үпкәчел карашын төбәгән. Моны сизгәндәй, Сөнәгат фотосурәткә туры карамаска, уйларын читкә борырга тырыша. Ярар, башын стена ягына кабат күтәрмәде, әмма уйларыннан тиз генә арына алмады. Була бит шундый мәл: син ниндидер уйны миеңә якын да юлатмаска, аны онытырга телисең, ләкин ул әрсезләнеп зиһенне телгәли, башны катыра. Кеше үз-үзен битәрләгәндә булгалый мондый кичереш. Тансык түгел инде ул мондый хис-тойгы, ләкин нишләргә кирәк, уйланасың, нидер хәтерләп сискәнәсең, үзеңне акларга маташасың...

* * *

Сөнәгатнең үсмер чагы да, егет чоры да авыр елларга туры килде. Яшьлек — яшьлек инде, дәверенә карап тормый, барыбер үзенекен итә. Рудник поселогы Акташтан бик үк ерак булмаса да, эти-әнисенә сирәгрәк, икеөч атнага бер генә кайтып йөри торган иде Сөнәгат. Чөнки егет-җилән алмаш-тилмәш бер-берсенең якын-тирәдәге авылларына баргалап йөрделәр, ә менә сугыш беткән елның җәйге айларында Сөнәгат туган төягенә кайтып китүләрен ешайта төште. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар иде. Ул чакта да, еллар авыр булуга карамастан, яшьжилкенчәк Кызлар тавында күмәкләшеп уен кора, гармун, такмак йә курай көенә җыр-биюләр оештыра торган иде. Шунда уйнаса-уйнамаса да буталып йөргәндә егетнең үрге очтан Шәүрә дигән кызга күзе төште. Исеме дә, үзе дә матур гына кыз. Гәүдәгә ыкчым, елмаюы серле, атлап йөреше килешле, җиңел. Ул мәлләрдә Сөнәгат кызларга гыйшык тотуның тәртип-йолаларын аңлап та, белеп тә бетмәгәндер инде. Берәр аулак җирдә култыклап йөртәсең дә үбәсең-кочасың — вәссәлам. Шулайрак та уйлаштыра иде егет. Һәрхәлдә, Сөнәгат боларын булдырды һәм азмы-күпме вакыт үтүгә ике яшь йөрәк бер-берсенә ныграк тартыла барды. Тик аларның шытып килгән мәхәббәт тойгылары искелек шаукымыннан торып калган бер күтәрелмәгән киртәгә юлыкты. Сөнәгатнең атасы, усал, үзсүзле Сабирҗан карт, тәүдә төпчек улын зәһәр сүзләр белән Шәүрәдән биздерергә маташты, шуннан, күп карышсаң, аталыкны танытырмын әле мин сиңа, дип сөйләнде-сөйләнде дә көзгәрәк кода тиешле күршесенең кызына яучы җибәрде. Карап торырга мескен генә тоелса да, тоткан җирдән сындырырга ярата иде шул аның атасы. Язмыштан узмыш юк дипме, әллә яшьлек хатасына бирелепме, Сөнәгат, шулай итеп, Сәлимәгә өйләнде. Шәүрәгә өйләнә алмасын Сөнәгат аңлый башлаган иде инде. Ул имеш-мимешләрдән шуны белде: Шәүрәнең атасы Заһит, хәлле генә булганлыктан, гражданнар сугышы елларында ук әле Сабирҗанның сабый чагында колак тешләгән кызын тартып ала һәм шуңа өйләнә. Замана көчленеке булгандыр инде. Шәүрә әнә шул бозык Заһитның хатынынннан туган төпчек бала. Ни кылырсың? Ул елларда әле авыл халкы арасында йола куу, ата-ана сүзеннән чыкмау әдәбе нык кына хакимлек иткән шул.

Сөнәгат, эчтән генә ут йотса да, сер бирмәде, башка чыгып, Сәлимә белән ару гына тормыш корып җибәрде.

Еллар үтә торды, бала артыннан бала туды, аларны ачялангач итмәс өчен Сөнәгат төрлечә кәсеп итте, аяусыз эшләде. Сәлимә дә йорт эшләренә оста булды. Әмәле чыкса, күнлеккә, кулалмашка йөрде, сораганнарга алдан килешенгән хакка күлмәк-ыштан текте, юрган-мазар сырып бирде. Авылда бер дигән тегүче иде ул. Үзенә дә, балачагасына да бер дә әзер күлмәк сатып алмады диярлек. Туй-төшемдә бүләккә тигәннәрен генә кигәләде.

Тәү тапкыр кайчан хыянәт итте соң әле Сөнәгат Сәлимәсенә?.. Һи-и, онытырлыкмыни...

Сөнәгатләр ул еллары үләң өлгерү белән звеноларга бүленешеп колхоз өчен печәнгә төшә торган иделәр.

Әлеге ище көн нык кына кичкә авышкан вакыт. Сөнәгат, звено башлыгы, үзенекеләр өчен азык-төлек, сәнәктырма төяп китермәкче булып авылга кайтып бара. Кичүдән-кичүгә сузылган шар яланнарны озынбил арбага җигелгән Турыкай дыңгырдатып кына юырта. Өченче кичүне чыккач, еракта ук Шәүрәне шәйләп калды. Ялгызы гына. Чабынлыкның әле бу, әле теге төпкелләрендә калку гына күбәләр күренештерә. Бүген генә җыеп өйгән, башларын җил туздырмасын дип, агач кисәкләре белән бастырган. Хәзер кайтырга әзерләнеп йөргәнгә охшый.

— Кипми дә кипми дип елый идең, әнә күпме күбәләп ташлагансың.— Ияк кагып кына исәнләшкәч, Сөнәгат Шәүрәгә шулай дип эндәшкән булды.

— Әйләндереп-тулгандырып кына инде ул. Безнең кебек ялгыз хатыннарга тигез генә чабынлык тәтимени. Бер үзем булгач, эш тә үрчеми.— Чынлап та, Шәүрә яз башында гына күршедәге Өчкәҗә дигән авылдан кайткан иде. Иреннән аерылып. Әллә чын, әллә буш — кияве Шәүрәне бала тапмаганга хушсынмаган, имеш, дигәнрәк хәбәр таралып калды бер заман авылда.

— Утыр минем арбага. Җәяү кайтма, болай да аякларың талып беткәндер.

— Куйчы, Сөнәгат. Уйламыйча да утырыр идем дә, кешедән оялам. Хәләл җефетең ишетеп калса, чәчемне йолкып бетерер. Ялан аша турыга төшәм.

— Әйдә, димен. Исәр чакта түшкә-түш терәшеп үбешкәләдек бит әле без.— Яшь ирнең калын тавышыннан бераз үкенү, үткәннәрне сагыну, шул ук вакытта әрсезләнеп, тиктомалга шаярырга маташу чаткылары сизелде.— Зиратка җитәрәк төшеп калырсың. Печән өстенә уңайлап кына утырабыз да,— дрым-дрым. Ат җилле...

Дрым-дрым... Янәсе, очыртып алып кайтырга ниятли. Ләкин Сөнәгат атын нигәдер куарга теләмәде. Үләне

чабып җыелганнан соң иркенәеп калгандай күренгән ланның аргы очына житәрәк, көтмәгәндә атын сулга, иске юлга каерды. Аты тыңламыйча киреләнергә маташкан иде, очасына шомырт чыбыгын чак-чак кына тидереп алды.

— Кая барасың, Сөнәгат? Исәр чакта арбаңа утыртмаганны. Башыңа нинди уй төште?

— Борынгы юлдан алып кайтам үзеңне. Урау булса да, кичүе юк. Турыкайның дагалары болай да купшап беткән.

Кабат әллә ни сөйләшеп тормадылар. Турыкай җайлап кына үргә тартыла. Борынрак бу юлдан яндырылган агач күмере ташыганнар.

Шәүрә нишләргә белми, өнсез генә тик утыра, карашлары моңсу, азрак уйчан. Елмаерга тели, тик йөзе генә сытыла.

Күмер юлы буенда чабынлыклар юк. Бу арада берәү дә үтмәгәнгә охшый. Әлегә кеше печән-фәлән ташырга тотынмаган шул. Бу тарафларда агачлар куерак, ара-тирә ташлы болыннар да очраштыра.

Урманда тынлык. Яңа чыккан кош балалары пырылдашып оча, кичке шәфәкъ нурлары агач башларын гаҗәеп төсләргә манчыган.

Сөнәгат тәүдәрәк сүзен гел үткәннәр, бая үзе әйткәнчә «исәр чаклар» тирәсендәрәк уралтты. Менә ул өзексурык Шәүрә ягына каерыла, аңа күз салып ала, карашлары очраша, күңеле әллә нишләп китә аның. Бәләкәй генә калкулыкка җитәрдән, сөзәк сырт буенда арба кинәт сулга, Шәүрә утырган якка нык кырынайды: Сөнәгат, егылып төшмәсен дип, җайлап кына юлдашының беләгеннән кочып алды. Салулаган арба тиз үк тигезгә чыкты, ләкин яшь ир хатынның беләгеннән кулын алырга теләмәде.

Куучы кеше булмагач, Турыкай да адымнарын җайлатты, тора-бара бөтенләй үз җаена бара башлады. Акланга чыгу белән, авызлыклы көе, сайлап йөреп ат борчагын ашарга тотынды.

Яр салам, диде Шәүрә — кычкырмады, тешләшәм, диде — тешләмәде...

Авылга кергәндә күп кенә өйләрдән лампа яктысы сирпелә иде.

Азак... бер-ике атна үткәч, Сөнәгат куыштан кичкә таба гына атының камытын кидереп, атланып килде дә Шәүрәнең күбәләрен кибәнгә салды. Алдан сөйләшкән иделәр. Кыш уртасындарак өч-дүрт чана печәнен ташыды... Печәнне сарай башына тутыргач, аш-суын эчеп, соңлабрак кайткалады. Авылда ир-атның тол хатыннар-

га мондый гына түләүле ярдәме, аракыга-балга «сатылуы» гадәти күренеш булганлыктан, беркем дә Сөнәгаткә шелтәле карамады.

Хәер, кырын караучы кеше булмаса да, Сәлимә барысын да сизгән, барысын да белеп йөргән, әмма берәүгә дә ләм-мим белгертмәгән. Хәтта аның Сөнәгатне берәрсеннән көнләп авыз ачып сүз ычкындырганы булмады. Ә Сөнәгатнең Шәүрә белән буталып йөрүләрен иренә былтыр гына, үзен больницага озатыр алдыннан гына әйтте.

Болай булды. Кичтән Сөнәгат түшәктә яткан Сәлимәсе белән озак кына гәпләшеп утырды.

— Ярар инде, атасы, бер-бер хәлгә тарып, бу юлы балнистән кире кайталмасам, син... оялып-нитеп торма. Шәүрәне... теге, үрге очтан... ал да кайт.

Сөнәгат сискәнеп куйды, Сәлимә, кыенлык белән булса да, үз фикерләрен ачык итеп тезә бирде.

— Чакырып алып, үзенә дә әйтермен дип уйлаган идем дә, нишләптер кыймадым. Әйе, әйе, Шәүрәне генә ал да тор. Аш-суга тәрбияле, акылы камил. Мин берчак аннан болай дип сораган идем. Нигә, димен, Шәүрә, үзеңне сораткаинар бар, ошатканнар бар, шуларның берәрсенә тормышка чыкмыйсың? Буй-сының күркәм, көн итмешең җитеш, димен. Көлде дә куйды. Бала тапмагач, ди, нигә кешене бәхетсез итәргә. Ирләр дә адәм затыннан бит. Ул көлә, ә минем, үзем дә аптырыйм, нигәдер шул чак елыйсым килгән иде...

Сөнәгат янә үзенең фотодагы берникадәр масаюлы йөзенә, мәрхүмәнең басынкы чыраена төбәлә.

«Их, Сәлимә, синдәй сабыр, синдәй күндәм, синдәй илтифатлы башка хатын бар микән җир йөзендә?! Рәнҗемә инде миңа. Авыр туфрагың җиңел булсын. Синең алда гаеплемен...»

Боларны картлач эченнән генә, Сәлимәсеннән бигрәк, үзенә төбәп эндәште. Йөрәгенең кайсы катында басылып яткандыр мондый миһербанлы уйлар? Әллә олыгайган көнендә тәүбәгә килүеме? Үзен-үзе битәрләп кенә гөнаһларын җиңеләйтмәкчеме?

Тышта шыгырдап авыр капка ачылды. Әлмирә кайткандыр. Аптырый атасы: башка балаларын иркәләбрәк үстергән иде, алары хәзер җаннары теләгән җирдә яшәп яталар, Әлмирәсе — үзе белән. Үзләренә торырга атасын чакырмыйлар, дисәң, дөрес булмас иде, чакыралар. Ләкин тормыш бит, кайчакларда шулай шик-шөбһәләре күңелне кытыклап алгалый. Өлкән килене сыйдырмас — монысы көн кебек ачык. Уртанчы кызының ганләсе болай да

ишле. Кияве ачык, кеше җанлы да бит, барыбер алар белән бергә яшәү килешмәс, аларга артык тамак кына булыр. Бер улы армиядә хезмәт итә, офицер. Үзе күчмә тормышта яши. Бер-ике ел Ерак Көнчыгышта хезмәт иткән иде, хәзер бөтенләй икенче якта, тундрада йөри. Бер Әлмирә, кече кызы гына, күзле-башлы булмаган әле. Яше җиткән, хәтта узып бара. Нигә узмасын ди? Бер уйласаң, әниләре егерме өч яшендә өченче балага йөкле иде ләбаса. Әлбәттә, заманаларны чагыштырудан файда юк. Шулай да сизенә карт, сизенә: Әлмирәнең шуңа кадәр кияүгә чыкмавына өлешләтә аның да гаебе бар. Кызы, мөгаен, этиемне тәрбияләргә кирәк, ялгызын калдырырга ярамый, дип уйлыйдыр әле. Холык-фигыле белән әнкәсенә нык тарткан ул. Ләкин этисен генә уйлап йөрсә, хаталана ул. Хаталана. Әлегә бирешерлек түгел ләсә Сөнәгат. Саулыгына зарланмый, мал-туары имин йөри. Умарталары көчле, мур төшмәсә, быел да флягалап бал суыртачак. Йорт тирәсен карарга үзе дә шап-шактый. Сыерны саумагач саумас инде. Бәй, Әлмирә берәр яры китеп барса, сыер малын бөтенләй дә асрамас. Әгәр кияү балакай бергә торырга тели икән — рәхим итсен. Анавы ветфельдшер белән серләре берегә, дигән хәбәр чалынган иде колагына, шуңа күңеле тыныч әле бер яктан. Итагатьле егеткә охшый, үзе эшкә дәртле генә күренә. Бер-берсеннән уңарлар кебек.

Менә шулай, беркая да китмәячәк Сөнәгат. Шушы авыл туфрагында аның ата-бабалары, хәләл җефете җирләнгән, үзенә дә шунда дөнья куярга язсын. Бала-чагасына, кияүләренә, киленнәренә аның җавабы үзгәрмәс. Элеккечә: «Картайган агачны кузгатмагыз... Югыйсә тиз ава»,— дияр.

Әлмирә хакындагы уйлары картны тышка әйдәде.

— Арыдыңмы, кызым,— атасы ишегалдындагы иске диванда ял итеп утырган Әлмирәгә шулай мөрәҗәгать итте. Кызы атасының йомшак кына соравына пышылдап «әйе» диде һәм башын какты. Әлмирәнең бит-танау очлары дымланып, кызарынкырап тора.

— Ничауа, бирешмәгәнсең. Күп йөргәннең аягы сызлаусыз була. Көндез үк аш пешереп куйган идем. Хәзер самавыр яңартам,— дип сөйләнә-сөйләнә картлач алачыкка таба юнәлде. Электр чәйнеге бар аның, ләкин карт анда кайнаган чәйне хушсынмый. Анынча самавыр җырлатып чәй эчү — үзе бер дәвер!

— Мәшәкатьләнмә, эти, үзем генә кайнатырмын. Син көтүгә каршы чык, яме.

Сөнәгат тыңлаучан малайдай урамга уңайлады. Тик нидер исенә төште, күрәсең, кире борылып, чоланга кереп чыкты. Чите кырылып, уңып беткән яшькелт эшләпәсен башына кырын киеп алырга онытa язган икән.

Кояш баюга таба бара. Тиздән ул ерак-ерак офык сызыгын күкшелләткән таулар арасына кереп батачак. Җылы кич, хәтта бөркү. Җилнең әсәре дә юк. Сөнәгатләрнең урамында өйләр күп түгел. Алары да бер генә рәткә тезелеп утыра. Өч өйне узгач, Сөнәгат күршеләренең кеченә кызына тап булды. Ул үзләренең тукалын, Сөнәгатләрнең ала сыерын да бирегә табан куып килә иде.

— Һай, рәхмәт яугыры, мин әпәт соңладым бит бүген.

— Ярар, бабай, капкагызны үзем ачып кертермен әле.

— Һай, рәхмәт яугыры!

Нәкъ шул чак каршыдагы юан-юан бүрәнәләрдән салынган борынгы өй капкасы аша иңбашына кыска туным ябынып, аягына карчыгының калошын киеп алган Бәхтияр карт урамга чыкты. Сиксәнне куган бу юантык кына карт — Сөнәгаткә ике туган тиеш агасы. Үзенә һич тә житмеш җидене бирмәссең. Шартлатып утынын да яра, мал-туарын караша, кыскасы, карчыгы белән чөңгер-чөңгер яшәп яткан көннәре. Башкорт әйтемендәгечә «картайган агачка сөялеп, тагы кырык ел яшәрлек рәте бар» әле икәүсенең дә.

— Сөнәгатулла, здрасти, кил әле монда.— Бәхтияр агасының, мөгаен, койган балы нык кына ачыгандыр — кәефе күтәренке. Өстәвенә, карт кызмачарак чагында рус сүзләрен кыстырырга ярата.— Әллә эреләнүең, әллә адәмгә санамавың, бер дә абыеңа күренгәнең юк бу арада. Әйдә, попути кер. Урамга хәл алырга, һава иснәргә чыккан идем дә, зерә ятеш тап иттем әле үзеңне. Давай миңа табындаш бул. Әзрәк бар ул миндә, бар...

Агасының сүзен екмады Сөнәгат. Болай да илке-салкы йөргән мәлендә кем белән булса да гәпләшеп утырасы, эч серләрен чишәсе килә иде аның.

Карт алачыкка җитәр-җитмәстән карчыгына:

— Әби, берәр чирек саркыт әле... Кайнешең, Сөнәгатулланы әйтәм, чакыруга килгән! — диде. Бәхтияр карт шуннан энесенә хәйләле генә күз кысып алды да сөйләвен белде.— Попути инде, попути.

Төтенгә ысланып беткән алачыкка керделәр. Җинсез камзул кигән әби өстәл яңартып җибәрде. Бәхтияр карт Сөнәгаткә чәчкә балыннан коелган эчемлекне бизәкле агач кружкага салып кулына тоттырды.

Сөнәгат инәлтеп-кыстатып тормады, бер тында дияр-

лек беткәнче чөмерде. Шулай итмәсәң, агасы ошатып җиткермәс, йә мыскыллый башлар. Әйе, карт баягы көләчлеген сүрелтмәгән иде.

— Син, энекәш, кеше булсаң, кеше бул, аңшаеп, җанны үртәп йөрмә. Давай... кәләш... әй әттәгенәсе, никахыңны яңартыйк,— карт энесенә сынаулы карап торды, тегесе хәбәргә кушылмагач, һаман үзенекен талкыды.— Миннән пример ал, ичмасам. Үзеңә мәгълүм, Шакирә җиңгәңне җирләгәнгә унбиш былтыр. Миңа алтмыш өч кенә иде әле ул елны. Барыбер олыгаелган иде инде. Олы кешегә тәрбия кирәк бит ул, энекәш, тәрбия кирәк...

Ләкин картның җитдилеге күпкә бармады. Янә тотынды ул үзенчә шыттырырга.

— Бәй, җиңгәңнең кырыгын укыту белән әби күзләргә чамаладым бит бер заман. Тегене димлиләр, моны димлиләр. Анысы яман, монысы саран дигәндәй, берәүгә дә күңел ятмый бит, әй. Баш тубалдай булды инде.

Шуңа кадәр килде-китте хәбәргә әллә ни кысылмаган Хөснә әби, сабырлыгын җуеп, картын бүлдерде дә җиңелчә генә битәрләп алды.

— Башлады инде, башлады. Сөнәгатулла синең кем икәнлегеңне белмидер шул. Бу кадәр дә картая белмәс булыр икән кеше.

— Һәй, әттәгенәсе, чынны сөйлим мин, син дә тыңлап тор. Мин үлгәч, оланнарга сөйләп кинәнерсең,— Бәхтияр карт карчыгын тыя бирде дә бая башлаган мәзәген дәвам итте.— Бер заман анавы, әй, хәтер дигәнеңне әйтим, карабайлар затыннан кем әле, кем?..

— «Юан» Нәзифәме, әллә «саранымы»? — Сөнәгат көлемсерәп куйды.

— Әйе, нәкъ үзе — юаны инде, юаны. Сараны белән ачтан үлиммени? Тап иттем бит шуны бер аулак урамда. Сүз кузгаттык. Мин хәбәрне теге яккарак бормакчы бит инде. Кодача, димен, син дә ялгыз, мин дә ялгыз, яучы җибәрсәм, ничек булыр икән, дим. Риза бит әй, вәт шайтан. Икенче юлы тап булышкан идек, тотты да сүз башлады. Йә, кода, кайчан килә яучың, димәсенме. Мин ни, ачык-ярык бит, үзең беләсең. Үпкәләмә, кодача, яшьрәксең, балабыз-мазар туып куйса, олыгайган көндә асравы бида булыр бит әле, димен...

Карт ләззәтле кинәнеч белән озак итеп кеткелдәде. Сөнәгатнең дә бу юлы авызы ерылды.

— И-ий ялганчы! Үзенең буш хәбәренә үзе көлгән кешегә нәрсә әйтәсең инде. Җитәр инде, бөтенләй ялкыттың. Сөнәгатуллага да кайтырга кирәк.

— Әби, лыгырдама дим, лыгырдама. Акташ тирәсендә әби-сәбиләр минем өчен тарткалаша башлагач, түзмәдем, җиктем дә Колатны сыпырттым Мырдакайга попути. Бер күрүдә күзем төште бит әй үзенә. И алып та кайттым. Кәничнә, димчеләр дә котыртты инде. Үзең дә чат ябыштың.

Бу юлы картның уенлы-чынлы сүзләреннән өчәүләшеп көлештеләр.

Беразга тынып калдылар.

Әкренләп картның чыраена уйчанлык, тәвәккәллек йөгерде. Ул каты корт ярчыгына сары майны мул гына сылады да сирәк тешле авызына капты.

— Шуңа әйтәм: үлем бар, туым бар фани дөньяда, ну үлгән артыннан әбәзәтельно үләргә димәгән. Син дә, туганкай, алдагы тормышыңны кайгырт. Моның бер дә ояты юк. Яшәрең бар, ашарың бар әле.

— Анавы Шәүрәне димләсәк, шәт отылмас идең,— Сөнәгатнең җингәсе, картының акыллырак сүзгә күчүен хуплаптырмы, үзе дә берәр файдалырак тәкъдим әйтер өчен кыяр-кыймас киңәшкә кушылды. Ләкин нигәдер сүзе өзелеп калды. Ул, кыска чәч үреме очындагы куш тәңкәләрен чыңлатып, кабаланмый гына җиделе лампаны кабызды. Тышта да ярыйсы ук караңгы иде бу чакта.

Алачыкта бер чама тынлык урнашты. Көндез үк бал исенә кереп калган бер корт зыр килеп үрли дә егылып төшә, үрли дә егылып төшә. Бәхтияр карт аны иплэп кенә бармаклары арасына кыстырып алды да ярым кысык ишектән тышка чөйде:

— Бар оч, ояңны тапсаң ярар иде.

Шуннан карт сәке читенә килеп утырды да итләч куллары белән эз генә кагылуга да селкенеп барган өстәлгә таянды.

— Борынгылар әйткән: хатын алсаң, биш буынын тикшер дигәннәр. Шәүрәне үзең карарсың әле, энекәш. Хан заманындагы гишык-мишыгыңны куптарудан ни фәтва? Ә мин икенчегә киңәш итәр идем. Өчкәҗәдәге Фатыйма белән сөйләшергә чамала. Бик дөньяви хатын. Оланнары күзле-башлы, үзләре кешегә иплe, үзләре эшкә җигәрле. Күнсә, төя дә алып кайт шуны. Юк, сразы алып кайтма, тәүдә килеш үзе белән. Булгач, адәмчә булсын. Иҗапны ни, үзем укырмын. Аллага шөкер, рәтен-чиратын сукалыйм әле. Шулай, Шәүрә дип гелән уйлама. Ялгызлыкка өйрәнгән бит ул, аңа да кыен булыр, сиңа да рәхәт булмас.

Сөнәгаткә Фатыйма таныш, яхшы гына таныш. Фа-

тыйманың ире моннан өч ел элек уйламаганда машина астында калып һәлак булган иде. Сөнәгат белән Фатыйма икесе бер чордарак ялга чыктылар. Иң мөһиме, аның ире белән Сөнәгат үткән авыр елларда рудникта бергә эшләп йөрде.

...Хәтерендә, элек Өчкәҗәгә кичке уенга барганда, Фатыйма — каракучкыл йөзле, кыйгач кашлы яшь кенә кыз — Сөнәгатне «Комсомольский» дигән күмәк биюгә чакырган иде. Эреләнеп шунда Сөнәгат биюгә төшмәгән булды. Нәфикъ алдында уңайсызландымы икән, хәзер онытылып беткән инде. Тик шул чакта Фатыйма җырлаган бер дүртмәле такмакны онытмый Сөнәгат. Ничек әле...

Тау башында тимер бүкән,
Типкәләмә, Сөнәгат...

Әйе, ятеш кенә көйгә салып, аксыл ситса күлмәген җилфердәтеп бии-бии нәкъ шулай дип җырлаган иде түгелмени? Яңгыравыклы, моңлы тавыш белән. Ә азагы соң? Әлбәттә, азагы да җиңел-җилпе генә иде — дүртмәле такмак бит.

Синдә чыккан такмак түгел,
Үпкәләмә, Сөнәгат.

Үзләренең авылындагы уенда булса, Сөнәгат, мөгаен, җавап итеп каршы җыр да табар иде әле. Валлаһи, табар иде. Мәсәлән, болай дип җырлар иде.

Тау башына тары чәчтем,
Кош чүпләп изалатты.
Бәләкәй генә җиңгәмне
Тәкә сөзеп колатты[1].

Җырлар иде, валлаһи җырлар иде. Арлы-бирле такмак әйтергә Сөнәгат тә булдыра торган иде бит элек.

Һай, заманалар! Җырларны яңарта да, искертә дә, оныттыра да.

* * *

Сөнәгат ул көнне Бәхтияр карттан соң гына кайтырга чыкты. Урамда болыт, җиләс. Кайдадыр чыңкылдатып гармун тарталар, авыл көенә җырлыйлар. Караңгы. Үрге

[1] Колатты — екты.

урамда эт абалап өреп җибәрде, бирерәк аңа икенчесе кушылды, аргы очтан өченчесе күтәреп алды.

— Кит инде, эти, попути бабайга керергә куштыммыни сиңа? Белмим, арытаба болай ничек яшәмәк кирәк...

— Ярый инде, кызым, тиргәмә бер юлга.

— Сине тиргәгән кеше юк, эти. Тик аптырыйм, картайган саен бәбәйгә әйләнеп барасын.

— Ярар, кызым, ярар. Кәефем зерә шәп әле минем бүген. Әйрән генә эчеп алам да әвен базарына китәм. Иртәгә юл төшеп тора.— Карт бераз эндәшми торды да мәгънәле генә өстәп куйды.— Өчкәҗәгә барып әйләнергә кирәк.

— Өчкәҗәгә дисеңме? Анда нәрсә бар сиңа?

— Йомыш бар, кызым. Дөнья бит, йомыш төшми тормый...

Уйламаганда якында гына бер әтәч кычкырып җибәрде. Таңга ерак иде әле. Күрәсең, төшләнеп кычкыргандыр. Әтәчләр дә кайчак вакытны бутап тавышлана, диләр, дөрес икән.

ЭЧТӘЛЕК

Сәгыйть Агиш. Эш самавырда түгел 3
Әнвәр Бикчәнтәев. Сакалсыз кыен икән 12
Рәис Габдрахманов. Трудармеецлар 20
Мостай Кәрим. Томау 28
Динис Исламов. Соңлаган үкенү 33
Ярулла Вәлиев. Гомер дәвам итә 46
Гаян Локманов. Очрашу 58
Габдулла Байбурин. Көмеш арба, көмеш ат 71
Шакир Янбаев. Сайрар кош 89
Вәзих Исхаков. Солтан агай 97
Фәрит Исәнгулов. Кышкы җәйгор 105
Фәнил Әсәнов. Алгы тәгәрмәч 116
Марат Кәримов. Кортлы алма 122
Шаблонны шартлатканда 128
Ногман Мусин. Мазасыз көн 134
Расих Ханнанов. Сөю гөлләре 150
Зиһат Солтанов. Сыер турында җыр 155
Мансаф Гыйләҗев. Чибәр әби 166
Булат Рәфыйков. Курчак театры 174
Рәшит Солтангәрәев. Туган якка кайту 184
Роберт Баимов. Әптрәхим 202
Тимергали Килмөхәмәтов. Акбирде алмалары . . . 215
Наил Котдусов. Матрос Фәйзи 221
Динис Буләков. Чират көткәндә 233
Наил Гаетбаев. Гомер 246
Сабир Шәрипов. Онытылган җыр 259

Коллектив авторов

БАШКИРСКИЕ РАССКАЗЫ

(на татарском языке)

Редакторы *Н. Вәлитова*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Ф. Абдрахманова*
Корректорлары *Г. Галиева, И. Иксанова, Х. Фәйзрахманова*

ИБ № 5158

Җыярга тапшырылды 30.08.88. Басарга кул куелды 16.12.89. ПФ 09244. Форматы 84×108¹/₃₂. Типогр. кәгазе № 2. Литературная гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 14,28. Шартлы буяу-оттиск 14,7. Нәшер-хисап табагы 15,52. Тиражы 15 000 экз. Заказ Е-473. Бәясе 1 сум 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан. Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. 420084. Казань. ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.